ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

1.2012





Татарстанның беренче Президенты
Минтимер Шәймиевкә 75 яшь

# Казан утлары
# Qazan utlari

2012

**1**
**(1071)**

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Камил Кәримов, Ләбиб Лерон, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир—262-10-62.
Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—262-11-28.
Исәп-хисап бүлеге—222-09-80.
**Факс**—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Өмет ....5

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Разил ВӘЛИЕВ. Җанымны җылыткан уй табам. *Шигырьләр.* ....7

Марат КӘБИРОВ. Бердәнбер һәм кабатланмас. *Роман.* ....12

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Үлемсез дан җиңел бирелми. *Шигырьләр.* ....64

Айдар ХӘЛИМ. Үрнәк эшелон. Viktoria. *Хикәяләр.* ....68

Рөстәм СУЛТИ. Идел-йортым мөлдерәпләр тора күз төбәп. *Шигырьләр* ....87

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

Фәварис ГАЛИ. Чәнечкеле робагыйлар. ....91

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Туфан МИҢНУЛЛИН. Үзгәрү. ....94

**ХӘТЕР**

Альбина ӘПСӘЛӘМОВА. Ул утлар беркайчан да сүнмәс! ....116

Фәнис ЯРУЛЛИН. Хәтер төпләрендә утлы күмер. *Көндәлекләр.* ....143

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Айдар Хәлим: шәхес һәм иҗат *(Фирдәвес Хуҗин белән әңгәмә)*. ....125

Әдип турында каләмдәшләре *(Флера Низамова, Рифат Сверигин, Рөстәм Зарипов)*. ....129

Рифә РАХМАН. «Бөек мәгънә эзли юкса шагыйрь» *(Ркаил Зәйдуллага 50 яшь)*. ....137

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Тын дөньялар моңын тыңлаганда... *(Нәкыйп Каштановка 70 яшь)*. ....164

**КАЙТАВАЗ**

Рим ИДИЯТУЛЛИН. Кайдан ала алар бу көчне?! ....140

**ЗАКОН ҺӘМ КЕШЕ**

«Судларның гомере мәңгелек...» *(А.Гыймадиевның Фарук Сөнгатуллин белән әңгәмәсе)* ....151

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Габдулла ГАЛИЕВ. Дога кылып кит! ....156

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ....161

**АК ҖИЛКӘН**

Марат ӘМИРХАНОВ. Бәләкәй Марат. ....170

**ЯҢАЛЫК**

Илсөяр ИКСАНОВА. Җыелыйк бер түгәрәккә... ....184

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Слово главного редактора»: Р. ФАЙЗУЛЛИН. «Надежда».
«Проза и поэзия»: роман М. КАБИРОВА «Единственный и неповторимый»; рассказы А. ХАЛИМА «Образцовый эшелон», «Viktoria»; стихи Р. ВАЛЕЕВА, И. ГИЛЯЗОВА, Р. СУЛЬТИ.
«Сенной базар»: Конкурс сатирических произведений.
«Публицистика»: Т. МИННУЛЛИН. «Меняемся».
«Память»: А. АБСАЛЯМОВА. «Никогда не угаснет»; дневниковые записи Ф. ЯРУЛЛИНА.
«Наши юбиляры»: беседа Ф. ХУЗИНА с А. ХАЛИМОМ; статьи Р. РАХМАНА, посвященная к 50-летию Р. ЗАЙДУЛЛЫ и Г. БАЙРАМОВОЙ к 70-летию Н. КАШТАНОВА.
«Человек и закон»: беседа А. ГИМАДЕЕВА с Ф. СУНГАТУЛЛИНЫМ.
«Рассказы из жизни»: Г. ГАЛИЕВ. «Помолись!».
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Белый парус»: М. АМИРХАНОВ. «Маленький Марат»; стихи Г. ГАФУРОВОЙ; рассказ А. ГАБДРАХМАНОВОЙ.
И. ИКСАНОВА. «Сомкнемся в тесный круг».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Зимний лес»; писательница Гаухария ХАСАНОВА.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Editor's word»: R. FAYZULLIN «Hope».
«Prose and poetry»: novel by M. KABIROV «One and only»; stories by A. HALIM, «Model train», «Viktoria»; poetry by R. VALEEV, I. GILYAZOV, R.SULTI.
«Hay market»: Competition of satires.
«Journalism»: T. MINNULLIN. «Let's change».
«Memory»: A ABSALYAMOVA. «Never goes out», diaries by F. YARULLIN.
«Our jubileers»: conversation of F. KHUZIN with A. KHALIM, articles by R. RAHMAN, dedicated to 50th anniversary of R. ZAYDULLA and G. BAYRAMOVA, to 70th anniversary of N. KASHTAN.
«Man and Law»: conversation of A. GIMADEEV with F. SUNGATULLIN.
«Stories of life»: G. GALIEV. «Pray!».
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages».
Pages from «Tatar Encyclopedia».
«White Sail»: M. AMIRKHANOV. «Little Marat», poems by G. GAFUROVA, story by A. GABDRAHMANOVA.
I. IKSANOVA. «Close up at friendly range».
From photo archives of magazine.
Diary of a social-cultural life.
On our covers: «Winter Forest»; writer Gauharia KHASANOV.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 30.12.2011, график буенча 30.12.2011.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Р–2015. Тираж 4020.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ТУ 16-00337.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААЖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2012 ел.

# ӨМЕТ

Кешене Өмет яшәтә. Ә Өметнең нигезе—иманлы Максат. Күпләрнеке шикелле бездә дә бар андый максат. (Без дигәндә, шөгыль-гамәлләре белән Кеше рухын калыплауга мөнәсәбәтле затларны күз алдында тотам. Алар, минемчә, зирәк җитәкчеләр, дин эшлеклеләре-руханилар, әдәбият-сәнгать вәкилләре, мәгариф әһелләре, галимнәр, укытучылар... Гомумән, Кешелекнең әхлак кануннарын үстерә алырлык яңа буын тәрбияләү, һөнәре нинди булуга карамастан, зыялы һәркемнең вазифасы инде ул!)

Ә Максат нидән гыйбарәт? Аның асылы шул: күп гасырлар дәвамында кешене Кеше итеп тота алган рухи, мәдәни, әдәби хәзинәне (нәкъ менә хәзинәне!) яңа буыннарга мирас итеп калдыру. Табигый бу омтылыш, әлбәттә, борынгы дәверләрдән килә. Әмма максатка ирешү ысулы—һәр заманның үзенчә. Глобализация, ассимиляция кызулана барган саен хәл катлаулана, четерекләнә генә бара.

Мисалга ерак барасы юк: милли матбугатларның бүгенге хәле моны ачык раслый. Алыйк үзебезнең «Казан утлары»н. Сез кулыгызда тоткан яңа журналның тәртип саны 1071. Бик зур сан бу. Россиядә, гомумән, элеккеге СССРда мондый санга ирешкән әдәби журнал юк. Чыга башлавына быел 90 ел (башлангычын совет дәверенә кадәр нәшер ителгән «Ан», «Шура» кебек әдәби журналлардан санасак, яшебез йөздән дә ашар иде) тула. Насыйп булса, бу юбилейны зурлап уздырырбыз. Болары яхшы. Уйландыра торганнары бүтән. Заманында йөз меңнән артык данәдә басылып, күбесе дөньяның төрле почмакларында таралган абруйлы журналның бүгенге тиражы күпме? Кызганыч, азрак шул (Россиянең бүтән журналлары белән чагыштырганда безнеке яхшырак булса да). Киләчәк дәвердә аның 1500нче яки 2000нче саннары чыга алырмы? Укучылар табылырмы? Мондый сораулар бүтән журналлар хезмәткәрләренә дә тынгы бирмидер.

Хикмәт нидә соң? Сүз дә юк, тәкъдирнең, вакыт-заманның таләбе яки сынавы диикме, соңгы дәвердә кеше рухын формалаштыруда яңа көч, яңа факторлар пәйда булды. «Китап—белем чишмәсе!» кебек шигарьләрне хәзер бик күреп булмый. Кеше җаны өчен көрәштә бүтән көчләр хәзер.

Ул көчләр беркемгә сер түгел, һәркемгә ачык: алар, беренче чиратта—электрон мәгълүмат чаралары, интернет. Бөтен дөньядагы исәпсез-сансыз адәм балаларының вакытларын, әйткәнемчә, җанын яулап алды инде алар. «Интернет башлы» яңа буын үсеп җитте. Бу буын, асылда, классик китаптан бизде диярлек. Сүз дә юк, тәрәккыят котылгысыз, Кеше акылы үзе ирешкән биеклектән төшә, чигенә алмый. Әйтик, моннан күп еллар элек, электр, телефон, самолет, телевизор һ.б. төшенчәләр бөтенләй булмаган... Үткәнгә кайтып булмый. Ат җигеп Америкага бара алмассың. Әмма цивилизация үсешендә, бигрәк тә рухият өлкәсендә тарихи эзлеклелек, табигый дәвамлылык сакланылырга тиеш. Чиктән чиккә ташлану хәерлегә китерми. Интернет—мәгълүмат җыю өчен бөек мөмкинлек (шунысы да бар, ул мәгълүматның күбесе, бигрәк тә балаларга, үсмерләргә кирәк микән әле?). Интернет—кемнәрнеңдер дөнья каршында борын сеңгерү урыны булмаска тиештер... Уйлансаң, сорау арты сорау туа. Экран артында утырып зур күләмдәге әсәрләрне, әйтик романнарны, поэмаларны укучылар бик күп микән? Экран китап битләрен алыштыра алырмы? Китап укудан алган күңел ләззәтенә ни җитә икән? (Әлбәттә, сүз соңгы вакытта акча түләп чыгарган китапчыклар турында түгел, чын китап, чын әдәби китап турында бара.). Соңгы елларда милли басмаларның традицион кәгазь

вариантын кыскартып, аларны башлыча электрон вариантка күчерүне хуплаучылар да ишәйде. Шулай итеп, Галиҗәнап Китаптан ваз кичәбезмени? Заманында дәүләт тоткан халык тормышында китапның аерым бер зур урыны бар. Китап телне, илне саклады монарчы. Мәгълүм хакыйкать: Тел булмаса Ил дә, Дәүләт тә, Халык та була алмый.

Яңа ел алдыннан, укучыларыбыз, каләмдәшләребез белән фикер уртаклашу, бер очтан «Казан утлары»ның якынлашып килгән юбилее турында да белдерү нияте белән бу бәләкәй мәкаләмне язган көннәрдә укытучы Мәдинә Кәримуллинадан (Кама Тамагы районы) хат килеп төште. Күнелгә хуш килде ул хат. Ник дигәндә, хат авторы белән уйларыбыз бертөрлерәк булып чыкты. Мөхтәрәм укучының да, баш мөхәррирнең дә фикерләре туры килү яхшы бит инде! Бу кереш язма өчен бераз озынрак булса да, шул хаттан өзек китереп үтәргә телим.

«Күптән жыелган, йөрәкне, күңелне борчый торган, рәнжеткән тел, әдәбият, мәдәният мәсьәләсендә фикеремне сезгә җиткерми булмас, ахры. Чөнки журналны һаман яратып укыйм, шөкер, «Казан утлары» бик әйбәт эшли, бик шәп чыга, яшьләр иҗаты да бик ошый, афәрин, рәхмәт сезгә!

Әмма дә журналны алдыручылар аз, мәктәпләрдә бигрәк тә. Ә «Казан утлары»ннан башка әдәбият дәресләре кызыклы үтә алмый, укучыларны бүгеннән үк журналны укырга күнектерергә, түмен белергә өйрәтергә, тирән белем чыганагы икәненә инандырырга кирәк. «Казан утлары» бит ул—халкыбыз әдәбиятының, мәдәниятенең йөрәге. 90 еллык тарихы булган журналны мәктәпләрдә, һич югы авыл мәктәпләрендә 9-10 укучы, шәһәр мәктәпләрендә татар балалары санына карап 20-25 укучы укырга тиештер, минемчә. Югыйсә безнең киләчәк буын әдәбият, мәдәниятебез үсешеннән артта кала, алай гына да түгел, киләчәктә журналыбызны бөтенләй укучы булмаска мөмкин. Кешене бит аны көчләп укыту кыен, теләге булган кеше ул үзе теләп, яратып, эзләп табып укый. Яшь буында менә шушы омтылышны тәрбияләү өчен, мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбиятын яратып укучыларга, олимпиадаларда җиңгән укучыларга, гомумән, мәктәп тормышында актив катнашучы укучыларга журналны бүләк итеп яздырырга кирәк. Мәсәлән, безнең Олы Кариле урта мәктәбендә 90нчы еллар уртасында, колхоз рәисе Р.Хөсәенов татар телен һәм әдәбиятын яхшы белүче, олимпиадаларда җиңүче укучыларга ел саен 6-7 журнал яздыра иде. Ул укытучы белән киңәшләшә, ничә журнал кирәклеген сорый һәм шуның кадәр яздыра. Укытучы сөенә-сөенә укучыларга тарата, балалар да шатланып алалар, укыйлар, иншалар язганда шулардан файдаланалар иде...

Ә мондый тәҗрибәне бүген дә эшләп була бит. Район мәгариф башлыгы, район хакимияте белән киңәшләшеп, район мәктәпләрендәге укучылар саныннан чыгып 15-20 журнал яздыра ала. Хәтта моны республикабызның Мәгариф министрлыгы дәрәҗәсендә дә эшләргә мөмкин бит. Мәдәният һәм Мәгариф министрлары, язучылар, журнал хезмәткәрләре белән бергә киңәшләшеп, теләктәшлек табып эшләсәләр бик яхшы булыр иде, минемчә. Кыскасы, яшьләрне мәктәптән үк «Казан утлары»ның тәмен, белем чыганагы икәнен күрсәтеп, инандырып үстерәсе иде!»

Рәхмәт мөхтәрәм укучыбыз Мәдинә ханымга!

Сүземне Өмет сүзеннән башлаган идем, әйе, ул Өмет бар һәм сүнмәячәк. Өмет белән бергә Ышаныч та торса, монысы инде тагын да яхшы. Шөкер, икесе дә бар, шулай булыр, иншалла. Чөнки артыбызда, җилкә терәге булып, тарихи Хәтер, Халык тора.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*«Казан утлары» журналының*
*баш мөхәррире.*



Разил
Вәлиев

# ҖАНЫМНЫ ҖЫЛЫТКАН УЙ ТАБАМ

***

**Туктатып булмый ла вакытны:
Яз үтә, җәй үтә, көз үтә.
Мең кабат ялгыша табигать,
Мең кабат ялгышын төзәтә.**

**Язларын ялгыша сөюдә,
Шуңадыр, җәй буе көенә.
Күзләрен, тук җимеш өлгергәч,
Кызарып, алланып сөенә.**

**Кыш килеп чәченә чал саргач,
Моңаеп сагышлы җыр суза:
«Нигә мин бу кадәр ашыктым,
Гомерләр, ай-һай, дип, тиз уза».**

**Туктатып булмый ла вакытны:
Табигать яңадан уяна.
...Кичләрен офыкта алланып
Үткәнгә хатирә-моң яна.**

## Соңгы тукталыш

**Көтмәгәндә яңгыр түккән өчен,
Сүгә-сүгә болыт ертыгын,
Чыланудан качып, трамвайга
Болай гына кереп утырдым.**

**Трамвайга кыйбла кирәк түгел,
Аңа барыбер, кая барса да...
Рельслардан чыгып булмый ла шул,—
Китәр идек туры Арчага.**

Разил ВӘЛИЕВ (1947) – *Татарстанның халык шагыйре, прозаик, публицист, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, «Ядкарь», «Бер алманы бишкә бүләек», «Җанга уелган уйлар» һ.б. утызлап китап, дүрт томлык сайланма әсәрләр авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Чабар идек Тукай якларына,
Әй, тәгәрәр иде «Кисекбаш»...
Бер–беребезне аңлар идек әле,—
Тукай белән без бит гасырдаш.

Кая илтә мине язмыш юлы? –
Тирә–юньдә юк дус, юк таныш...
Авыр сулап, кемдер әйтеп куйды:
«Килеп җиттек. Соңгы тукталыш».

* * *

*(В. Портновтан).*

Очрашырга иде йолдызда бер...
Җирдә юктыр сөю, тугрылык.
Мең мәшәкать тулы бу хаятта
Мәхәббәткә, ахры, урын юк.

Качып китик дөнья рәхәтеннән,
Качыйк, әйдә, дус һәм дошманнан!
Синең күзләр чәчәкләргә түгел,
Йолдызларга күбрәк охшаган.

Очрашырга иде, кавышырга...
Юлга чыгыйк карап йолдызга.
Күпме кеше, ярын табалмыйча,
Янәшәдә генә юл уза.

Мин йолдызда учак ягар идем,
Син ашыгыр идең яныма.
Элеккечә... безнең мәхәббәткә
Шаһит булыр иде таң гына.

Сине каян эзләп табыйм икән? –
Җавабың юк, күпме дәшеп тә.
Безгә шундый рәхәт булыр иде...
Рәхәт булган кебек яшьлектә.

Очрашырга иде йолдызда бер...

## Төсләр

Бихисап дөньяда буяулар,
Җир үзен яшелгә буяган...
Тургайлы үзәнгә карыйм да,
Җанымны җылыткан уй табам.

Кызыл төс күрдисәм—кан уйный,
Зәңгәр төс күңелгә моң сала.
Нигәдер төсләргә табынам,
Тормышым бертөсле булса да.

Сап–сары көземә күз багып,
Җаныма сагышлы уй табам,
Салават күперенә сокланып,
Уйларда, хисләрдә буталам.

**Үгиме әллә мин дөньяда?!**
**Илдә җәй, ә миндә кыш һаман...**
**Буранда югала бар төсем —**
**Дөньяда ак, кара төс кала.**

## Бер кайтырмын әле...

*Шагыйрь Сибгат Хәким истәлегенә*

**Кытлык булмас җирдә шагыйрьләргә,**
**Туу белән үлем булган чакта.**
**Чәч агаргач шигырь язып кара...**
**Һәркем шагыйрь юләр балачакта.**

**Еллар йөге баскач иңнәреңә**
**Очып кара хыял канатында.**
**Гомер буе җыйган байлыгыңны**
**Син чәчәргә тиеш, таратырга.**

**Ай-кояшка тиңдәй Тукай барда,**
**Туфан барда шагыйрь булып кара...**
**Охшатам мин моңлы язмышымны**
**Кояш нуры иңгән болытларга.**

**Гашыйк идем язгы бураннарга,**
**Гашыйк идем җәйге рәшәләргә.**
**Исемемне онытмаслар әле,**
**Гашыйк җаннар җирдә яшәгәндә.**

**Мин киткәч тә дөнья матур булыр.**
**Моңсуланыр Аккош күле генә...**
**Аккош булып бер кайтырмын әле,**
**Ышанмагыз минем үлемемә.**

## Үзебезгә кайтабыз

*Язучы Нурихан Фәттахка*

**Утыртмадылар түрләргә,**
**Чөймәделәр күкләргә...**
**Аның телле-тешле сүзе**
**Ошамады күпләргә.**

**Без гөр килеп кул чапканда,**
**Карап торды аптырап...**
**Шуңа бүген аның йөзе**
**Безнекеннән яктырак.**

**Без Казанда балкыганда,**
**Ул шәм якты Чыңгызда.**
**Без табындык—күкрәктәге,**
**Ул—күктәге йолдызга.**

**Ул барасы юл читендә**
**Маяклар кабынмаган.**

**Анда әле Болгар исән,**
**Казан да алынмаган.**

**Анда әле безнең тарих**
**Көл белән күмелмәгән.**
**Анда әле минем телем**
**Кырыкка бүленмәгән.**

**Тигез анда бар милләтләр,**
**Уртак анда киң җиһан...**
**Шушы хөррият илендә**
**Патша икән Нурихан.**

**Кем килмәде, кем китмәде,**
**Кем булмады атабыз?!**
**Менә бүген без яңадан**
**Хөр мәмләкәт ханлыгына —**
**Нуриханга кайтабыз!**

## Түзсен генә йөрәк

*Юбилее көнендә мәшһүр артист*
*Шәүкәт Биктимеров авызыннан*
*әйтелгән сүзләр*

**Йола куша: туган көндә һәрчак**
**Зурлау, мактау кирәк.**
**Мактый дуслар, мактый хәтта хатын,—**
**Түзсен генә йөрәк!**

**Кул сузардай дуслар сирәк булды,**
**Ишелгәндә ярлар.**
**Яңгыр булып күктән таш яуганда,**
**Кайда иде алар?**

**Ярылмыйча ничек түзгән икән**
**Йодрык хәтле йөрәк?! —**
**Олау—олау ачы хәсрәтләрне**
**Барган чакта сөйрәп...**

**Ышанмассыз, ил болгавыр чакта:**
**«Мин бәхетле!» —дисәм.**
**Уйнап түгел, уйлап яшәгәнгә**
**Безнең башлар исән!**

**Кемнәргәдер артык зат булсак та,**
**Без гавамгә кирәк.**
**«Алтын» диеп түгел, «халкым» диеп**
**Типте безнең йөрәк.**

**Акты еллар: язны, җәйне уздык,**
**Инде көзләр җиткән.**
**Артка карап, олавымны барлыйм,—**
**Уңыш мулдан микән?**

**Мин Ленин да, Әлмәндәр дә булдым,**
**Булдым һәрчак үзем...**
**Әлмәндәрле халык мәңге яшәр,—**
**Бирсен Ходай түзем.**

**Егылмадык, югалмадык илдә—**
**Без һәрвакыт кирәк!**
**Халык безгә терәк булган кебек,**
**Без — халыкка терәк.**

**Чәчләргә дә көл төсләре кунган,—**
**Яндык бугай артык...**
**Янсак — яныйк, азаккача барыйк**
**Ил арбасын тартып!**

## Җыр булып яшәр күңелдә

**Соңгы тапкыр, башны иеп,**
**Килдек аның каршына.**
**Җиргә бүген көз иңдерде,**
**Фәридә Кудашева.**

**Ул бит безнең һәммәбезнең**
**Чордашы, жырдашы да.**
**Татар—башкорт бәгырендә**
**Уртак моң—Кудашева.**

**Язын кошлар кунып сайрар**
**Аның кабер ташына.**
**Сандугачның туганыдыр**
**Фәридә Кудашева.**

**Җәй җитүгә, ак пароход**
**Казаннарга ашыга.**
**Пароход юкка ашыга,**
**Юк анда Кудашева.**

**Юк шул анда Кудашева,**
**Күңелем моңсу шуңа.**
**Без һәммәбез әвереләдек**
**Фәридә моңдашына.**

**Мин хушлашмыйм.**
**Саубуллашам.**
**Басып аның каршына...**
**Җыр булып яшәр күңелдә**
**Фәридә Кудашева...**
**Фәридә Кудашева...**

## Безнең язмыш

*Мөхтәрәм Тәлгат Абдуллинга*

**Ир язмышы—ил язмышы, диләр...**
**Бәхет эзләп ерак барылган.**
**Елатты да, юатты да безне,**
**Кочагына алып Маргилан.**

**Татлы язмыш түгел мөһаҗирлек,**
**Еллар безне кат—кат сынады.**
**Кичләр җитсә, моңсуланды әти,**
**Телләрендә—Тимер[1], Туймазы.**

**Себерләрдә уелдымы икән**
**Әниемнең маңгай сырлары?..**
**Себердә дә, үзбәк җирендә дә**
**Ул «Чирмешән»[2], диеп җырлады.**

**Күпме татар, чит җирләргә китеп,**
**Тирләр түккән, даннар казанган!..**
**Канатлары канап, каерылса да,**
**Аерылмаган җаны Казаннан.**

**Безнең кыйбла гел Ватанда булды,**
**Яшәсәк тә әллә кайларда.**
**Татар булып пешеп җитәр өчен**
**Казаннарда кирәк кайнарга.**

**Милли мәҗлес—туй мәҗлесе түгел,**
**Булдык анда тәкъдир язганга...**
**Ауган дәүләт белән тузган торак**
**Каршы алды чөнки Казанда.**

**Адашмадык язмыш юлларында,**
**Давылларда сынып аумадык.**
**Без яңадан илле, җирле булдык,**
**Без Казанны кабат яуладык.**

**Ир бәхете—ил бәхете белән,**
**Бәхет түгел патша тәхете...**
**Мин дусларым, туганнарым белән,**
**Туган халкым белән бәхетле!**

[1] Тимер – әтисенең туган авылы.
[2] Чирмешән – әнисенең туган ягы.



Марат
Кәбиров

# БЕРДӘНБЕР ҺӘМ КАБАТЛАНМАС[1]

## 1. Чакыру билеты

*Казан. Татарстан.*

Фатыйма карчык учындагы тиеннәрне күнегелгән житез хәрәкәт белән кесәсенә салып куйды да, дога кылырга тотынды:

—Раббәнә этинә фиддунйә хасәнәтән...

Нәкъ шул вакытта аны күз кырые белән генә күреп калды. Бер мизгелгә догасын онытып шул якка борылып карады. Әйе, нәкъ үзе. Элеккечә кара күн куртка, джинсы чалбар кигән. Кыска итеп алдырылган чәчен алга тараган, кара күзлектән. Хәрәкәтләре талгын, гайрәтле, һәр мизгелдә дошманы өстенә сикерергә әзер торган арысланныкы шикелле. Ул да тукталды. Гәзит-журналлар сатыла торган киоск янына басып, ипләп кенә карчыкны күзәтергә тотынды.

—Ходай сиңа ныклы сәламәтлек, озын гомер бирсен,—дип дәвам итте карчык.—Әткән-әнкәңне сөендереп, балаларыңның рәхәтен күреп яшәргә язсын. Амин!

Учлары белән битен сыпырып куйгач, янә киоск ягына карады. Теге ир анда юк иде.

—Ходайның галәмәте, әллә күземә күренә башлады инде,—дип үзалдына сөйләнде карчык. Күзләрен челт-мелт йомып алды.

Ул да булмый бер ханым янә учына акча тоттырды.

—Рәхмәт, кызым! Балаларыңның игелеген күреп яшә!

Фатыйма карчык бу юлы дога кылып тормады. Ул үзе дә сизмәстән теге ирне эзләде. Баскан урынында әйләнеп, дүрт тарафка да күз салып чыкты. Күрмәде.

Кинәт аңа тагын акча тоттырдылар. Карчык учына карап бер мизгелгә катып калды. Башта кулындагы акчаның кәгазь икәнен аңлады. Аннан соң, аның меңлек икәнен күреп, үз күзләренә үзе ышанмыйча торды. Һәм ни

[1] Журнал варианты

Марат КӘБИРОВ (1970) – *шагыйрь, прозаик; «Онытма таңнарны», «Серләшик әле», «Күңелле табын» исемле китаплар авторы. Уфада яши.*

әйтергә белмичә, хәер бирүчегә борылып карады. Ләкин янында беркем дә юк иде. Ул бары тик үзеннән ашыгып ераклаша барган ирнең аркасын гына күрде. Кара күн куртка. Бу нәкъ теге адәм иде.

Карчык бер мизгелгә һушсыз булып торды да теге ирнең артыннан иярде. Ләкин аны куып тота алуы бик тә икеле иде.

—Балам, тукта әле... Дога кылыйк...—дип эндәште ул, аптырагач. Әмма тавышы үзеннән ерак китмәде. Ир ераклашканнан ераклаша иде. Фатыйма карчык аның хәрәкәтеннән таныш чалымнар табарга тырышып озак күзәтте. Ир бер йорт почмагына кереп югалгач та аны күз алдыннан җибәрмичә таныш сыйфатларын табарга маташты. Әмма моның бер файдасы да тимәде. Кара күзлек, кара күн куртка кигән уртача буйлы, ирләрчә зифа гәүдәле бу кеше аңа бер тамчы да таныш түгел иде.

Бу бөтенләй ул көткән, ул өмет иткән кеше түгел иде.

Карчык янә учындагы акчага карады. Бу ирне ул беренче тапкыр моннан бер атна элек күргән иде. Хәер-фәлән бирмәде ул вакытта, бары тик ниндидер саклык һәм үҗәтлек белән теләнче карчык артыннан күзәтеп кенә йөрде. Ярты көн буе күзәтте ул шулай. Фатыйма карчык башта бик игътибар итмәскә тырышкан иде. Ни генә әйтсәң дә Казанда кызыксынучан кешеләрнең бетәсе юк. Кайберләре теләнчеләрне күзәтеп тә тәм таба торгандыр. Ләкин ир икенче көнне дә, аннан соң да күренгәч, куркуга калды. Хәерчеләрнең акчасын талаучы бандитлар да бар икән дип сөйлиләр бит. Шуның ише берәр явыз булмагае. Монауындый таза гәүдәсе белән бер дә юктан гына урам буен үлчәп йөрмидер. Хәзерге яшьләр бушка берни кылмас. Телләре кечкенәдән акча дип ачылган аларның.

Ләкин ирнең меңлек тоттырып китүе бу уйларын да себереп ташлады. Таларга йөргән кеше сиңа шулкадәр хәер бирә димени?! Тоттырыр! Берәр туганың-фәләнең генә булмаса. Ләкин Фатыйма карчык аның кыяфәтендә бернинди таныш чалымнар да тапмады. Бу кеше аның бернинди туганы да була алмый иде. Бу бөтенләй ят адәм.

Карчык беренче көн генә хәер сорашмый ич инде. Яшәренә пенсиясен генә җиткерә алмагач, ул әледән-әле шулай урам буенда йөрергә мәҗбүр. Икенче ел китте бугай инде. Кайберәүләр аны танып ук тора. Кемнәрнедер үзе дә белә. Исәнләшеп, хәл белешеп йөрүчеләр дә бар. Бу тирәдә шушылай итеп йөрүче бердәнбер татар әбие булгач, бөтен татар хәерне аңа бирергә тырыша. Зарплата алган көннәрдә махсус килеп йөзәр тәнкә тоттырып китүчеләр дә бар. Фатыйма карчык иренмичә һәркайсына атап аерым дога кыла. Тегеләрнең шуңа да күңелләре булып кала. «Әбекәй, сиңа хәер биреп юлга чыксам, гастрольләр гел уңышлы була»,—дип килүче бер танылган җырчы да бар әле. Башка милләт кешеләре дә сасы ис анкытып йөрүче бүтән теләнчеләргә түгел, ә нәкъ менә аңа хәер бирәләр. Әлбәттә, берсенең дә меңлек тоттырып киткәне юк. Ләкин көн озынына ярыйсы ук җыела. Икмәк-сөтлек була...

Берүзе генә яшәсә, хәер сорашкан акчасы тулысы белән җитеп барыр иде дә бит. Ашарына да, киярenә дә, тулай торактагы бүлмәсенә түләргә дә... Җитәр иде!

Әмма Радик-юньсез бар шул. Аңа җиткереп булмый... Шуның аркасында бурычтан башы чыкмый. Тулай торак өчен дә ел буе түләнмәгән әле. Комендант инде күргән саен куып чыгарам дип куркыта. Соңгы көннәрдә генә никтер дәшми.

Карчык меңлекне кесәсенә тыкты да тукталышка атлады. Бүгенгә җитеп торыр. Кулга эре акча эләккәндә бурычларны түләп куярга кирәк. Кичә пенсия дә биргәннәр иде. Иш янына куш булыр. Югыйсә, ул бүлмә бурычы

гына да егерме меңгә җиткән. Ничек түләп бетермәк кирәк.

Трамвайда кеше күп түгел иде. Карчык ишек төбендәге буш урынга кереп утырды. Трамвайда йөрергә яратмый иде ул. Ләкин маршрут таксиларына акча күп китә. Телисеңме-теләмисеңме, шушы нәстә кала. Монда инде яратам-яратмыйм дип тора алмыйсың.

Алайга китсә, ул шәһәр тормышын да бик өнәп бетерми иде. Авылда яшәп картайган кеше өчен түгел инде бу Казан. Һавасына кадәр икенче. Монда килүенең бердәнбер сәбәбе—Радикны адәм итеп булмасмы дигән теләк кенә иде. Соңгы елларда төпчеге бигрәк нык эчә башлады шул. Шул шайтан суына алданып бөтен дөньясын онытты. Хатыны түзде-түзде дә ике баласын ияртеп чыгып китте. Аны да гаепләп булмый. Болай да аз газапланмады килене, врачларга да аз йөртмәде. Усаллык белән дә, изгелек белән дә ипкә кертә алмагач, китәргә мәҗбүр булгандыр. Аннан соң, иреннән бер рәхмәт тә ишетмәде бит, бахырың. Күз төбенең күгәрмәгән чагы булмады. Соң, шулкадәр мәсхәрәгә түзеп яшәргә. Алма кебек хатын-кыз бит ул. Балаларын да үстерергә кирәк. Юк, берничек тә гаепли алмый ул киленен. Хәзер Чаллыга күчеп киткән, кияүгә чыккан дип ишетте. Ярый, бәхетле булсын.

Хатыны киткәч, улын авылга алып кайткан иде. Бер атна түзде Радик. Эчмәде. Эшкә дә чыкмады чыгуын, тик монысы вак нәрсә иде. Авылда да хәзер аракының кимен куймыйлар, кеше арасына чыкса тагын эчә башлар дип, Фатыйма карчык үзе дә ашыктырмады. Ә беркөнне малае авылда яшәргә теләмәвен әйтте дә салды.

—Шәһәргә китеп урнашам,—диде ул.—Монда бик үз итеп торган кеше дә юк. Акчасы да ташка үлчим генә.

Әлбәттә, авылда да менә дигән итеп дөнья көтүчеләр бар иде. Ишеп малын асрыйлар, итен-сөтен сатып тормыш итәләр. Шәхси трактор, йөк машинасы тоталар. Җинел автомобильләр турында сөйлисе дә түгел инде. Фатыйма карчык бу хакта әйтеп караган иде дә малае ипкә килмәде.

—Юк, әни... Казан Казан инде ул. Өйрәнгән җир.

Фатыйма карчык Радикны күргән фаҗигаләреннән сабак алгандыр дип уйлаган иде. Гаиләнне, балаларынны югалту уен эш түгел. Бик сиздереп тормаса да эченнән генә ут булып янадыр. Казанга китеп хатыны белән мөнәсәбәтләрен көйләп җибәрергә дә нияте бардыр, бәлки. Эчүеннән туктаса, алама малай түгел лә ул. Эчүен ташласа, хатыны да карышып тормас, янадан ярашып яши башларлар. Шулай уйлады карчык һәм улының теләгенә артык карышып маташмады. Ләкин улы гына өйрәнгән җиренә кабат килү белән өйрәнгән шөгыленә тотынды. Һәм карчык, улымны эзгә кертәлмәмме дигән исәп белән, үзе Казанга күченеп килде. Эчүен генә ташлатырга кирәк иде. Эчүен ташласа...

Им-томчылары да, башкасы да калмады, кодирауайт итеп тә, укол кадатып та карадылар... Булмады. Ахыр чиктә, карчык менә шулай хәер сорашып, җан асрарга мәҗбүр ителде. Ул акчаны да әле Радик йә урлап алды, йә талап дигәндәй... Кыскасы...

Дошманыңа күрсәтмәсен инде.

Трамвай туктады. Фатыйма карчык урамга күз салды да бер мизгелгә генә катып калды, ләкин бик тиз һушына килеп ишеккә ташланды. Тукталыш янындагы тәрәзәгә капланган кешене ул шундук таныды. Бу ул иде. Абына-сөртенә атлап киоск янына килеп басты да сулышын җыеп торды.

—Рәхмәт.—Кара күн курткалы ир сдачаларны кесәсенә тыкты да китәргә борылды.

—Пастуй, сынок!

—Ә-ә-ә, сез дә мондамыни?!—дип елмайды ир.

Карчык анын югалып, һич югы аптырап калуын көткән иде. Ләкин ир тынычлыгын югалтмагач, үзенең фикере таркалып китте. Нәрсә дип әйтергә соң әле?

—Балам, син ник мине күзәтәсең ул?—Фатыйма карчыкның тавышы шаян да, шелтәле дә иде. Һәм ул, тел ачкычы биргән өчен Ходайга күнеленнән генә рәхмәт әйтеп, дәвам итте.—Күзең төшмәгәндер бит?

Карчык анын елмаеп, хәтта көлеп җибәрүенә өмет иткән иде. Ләкин ир житдилеген җуймады.

—Мин сезне күзәтмим, әбекәй.—Ир бернинди дә тупас сүз әйтмәде, йөзен дә чытмады, әмма анын кыяфәтендәме, тавышындамы нинди дер канәгатьсезлек бар иде.—Сез кем беләндер бутыйсыз.

Карчык икеләнеп калды. Ирнең тавышы үлгән кешене үгетли алырлык иде.

—Ләкин менә бу акчаны сез бирдегез,—диде карчык теге меңлекне кабат кесәсеннән алып.—Сез мина мең сум хәер бирдегез.

—Гафу итегез, апа... Мин сезне кимсетергә теләмәгән идем...

—Бу кимсетү түгел. Ләкин мин сезнең якыннарыгыз рухына дога кылырга теләр идем.

—Минем якыннарым юк.

—Әти-әниең бардыр бит.

—Мин детдомныкы.

—Ләкин сез...

—Гафу итегез, апа...—Ир ашыгып тукталыш янындагы җинел машинага кереп утырды, карчык шул якка ике адым атлаганчы машина китеп тә барды. Бары тик анын магнитофонынннан агылган җыр гына колак төбендә яңгырап калды:

> Кайтырсыз әле бер, кайтырсыз, барыбер
> Таш булмаса, әгәр, җаныгыз...[2]

Ничек кенә исәплән карасаң да бу кеше начар уй белән йөрүче түгел иде инде. Хәзер монa шик калмады. Һәрхәлдә карчык артыннан күзәтүе хәер акчасына кызыгудан түгел. Ләкин ни өчен соң? Ник күзәтә иде ул? Ник шулкадәр акча тоттырып китте?

Фатыйма карчык тулай торак ишеге төбенә житкәнче шушы сорауга җавап эзләде.

Комендантның бүлмәсе ачык иде. Карчык анын күзенә чалынмаска тырышып ашыгып үтеп китте. Вахтер карт белән дә баш кагып кына исәнләште. «Хәзер үк төшереп бирермен, Алла боерса,—дип уйлады ул баскычтан күтәрелгәндә.—Аз булса да кими торыр.»

Бүлмәгә керү белән сасы искә борынын җыерып куйды. Алан-йолан каранып түргә узды да шкаф шүрлегендәге иске китапларына үрелде. Радик йоклый иде. Йоклый... Тагы ләх исергән инде ул... Акчалары шушында гына булырга тиеш иде. Радикнын китапка кагыла торган гадәте юк. Бөтен кесәләренне, табак-савытны, хәтта аяк киеменнең олтырагына кадәр тентесә дә китапка якын килми ул. Якын килми торган иде. Әмма бүген Фатыйма карчык акчасын тапмады. Кичә алган пенсия дә, җыепҗыеп килгән өч меңгә якын акча да юкка чыккан иде. Үз күзләренә үзе ышанмыйча, карчык китапларны янә бер актарып чыкты. Аннан соң караватта пошкырып яткан улына карады. Аны тукмап ташлыйсы, бәреп үтерәсе килде. Башкаларын өзеп алсаң да аз инде бу нәрсәнең... Ләкин ул теш арасыннан гына «Кабахәт!»—дип пышылдады да хәлсезләнеп

[2] Магнитофоннан Салават Фәтхетдинов җырлый. «Читләргә китәсез»

утыргычка ауды. Күз алдыннан әллә нинди куркыныч күренешләр үткән сыман булды. Бераз тынычлангач, кесәләрендәге тиеннәрне өстәлгә бушатты да, күз кырые белән улына карый-карый, чутлый башлады. Ваклары йөз сиксән сумга якын җыелган, Ходайның рәхмәте! Һәм теге мең тәңкә. Тагын бу мәлгуньгә эләгеп әрәм булганчы, комендантка төшереп бирергә кирәк.

Фатыйма карчык тагын бер тапкыр китапларын актарып чыкты да комендант бүлмәсенә төшеп китте. Бүгенге муллыкка күңеле булса да җыеп килгән акчасының югалуы өчен үкенә иде ул. Их,ниләргә генә алу белән төшереп бирмәде икән? Соң, улының ышанычсыз, юнсез икәнен белеп тора, ләбаса! Үзе гаепле инде...

—Фатыйма, бая әйтергә оныткантмын...—дип каршылады аны вахтер карт.—Сиңа бит хат бар иде...

Карчык бөтен булмышы белән комендант янында иде, шуңа аның сүзен игътибарсыз калдырып узып китте дә комендант бүлмәсенә килеп кергәч кенә дертләп куйды. Хат! Сиңа хат бар! Моннан бик күп еллар элек ул хат көтә иде. Авыл урамыннан узган почтальоннарга көн саен аркылы төшә:

—Хат юкмы, кызым?

—Юк шул, апа.

—Бүген дә юкмы, кызым?

—Юк шул...

—Ник берсе дә берәр сүз генә булса да язып салмый икән соң?

Почтальонның үткәнен күрмичәрәк калса, аның өеннән урарга да иренми торган иде. Хәтта кайбер вакытларда аңа балалары хат язадыр, бары тик шушы почтальон кыз гына аны тапшырырга онытадыр, яки юри тапшырмый йөртәдер сыман тоела иде. Шул сәбәпле, почтальоннар белән талашып беткән чаклары да булгалый иде.

Тора-бара өмете өзелде. Уллары инде исән түгелдер дип уйлады карчык, исән булсалар, кайтып күренмәгән хәлдә дә, берәр хәбәр җибәрерләр иде. Болай итеп яшәргә йөрәкләре җитмәс иде. Исән түгелләрдер. Төпчеге алай интектермәде. Армиядан да хат язып торды. Өйләнеп Казанда яшәгәндә дә кайтып хәлен белделәр, килене атнага бер шалтыратып хәл сорашты, айга бер булса да хат язды. Килене искиткеч иде дә бит аның. Эх, кадерен белмәде шул, юньсез малай. Килене киткәч, хат язучы да, хәлен белүче дә калмады. Карчык үзе дә элеккедәй өтәләнеп хат көтмәде. Кемнән көтсен инде.

Әле менә вахтер картның сүзе аңына барып җиткәч, күңеле тибрәнеп куйды. Хат! Кемнән булырга мөмкин? Балаларыннан дисәң? Юктыр... Юк...

—Балам, менә бер өлешен биреп куйыйм әле, калганын азрак хәлләнгәч төшерермен,—дип комендантка акча сузды. Ләкин тегесе акчаны алырга ашыкмады. Серле елмаеп кына куйды. Карчыкның коты очты. Әллә куып чыгарырга әйтәләр микән?

—Фатыйма әби, сезнең өчен акча түләделәр инде,—диде ул елмая төшеп.—Өченче көн бирделәр. Хәзер сез бер тиен түләмичә тагын ярты ел яши аласыз.

Карчыкның буыннары йомшарды. Ул якындагы урындыкка көч-хәл белән барып утырды да шаяртмыйммы икән дигәндәй, комендантка төбәлде.

—Чынлап әйтәсеңме, балам?

—Чынлап әйтәм, әлбәттә. Шаяра торган нәрсәмени?

—Бәй... Ни бит әле... Кем түләде соң аны?

—Белмим, апа. Исемен әйтмәде.

—Ир кешеме, хатын-кызмы диюем...
—Ир кеше.
—Кем булыр икән?! Бернәрсә дә әйтмәдеме?
—Юк
—Ниндиерәк иде сон? Кыяфәте ниндиерәк?
—Нинди дип... Ир кеше инде... Кырык яшьләр тирәсендә...
—Монарчы күренгәне юк идеме?
Комендант иннәрен генә сикертеп куйды.
—Радикка охшаган җире юк идеме?
—Радикка?!—дип көлемсерәде комендант.—Юк. Ана тамчы да охшамаган.
Карчык урыныннан торды да дәшми-тынмый гына ишеккә атлады. Соңгысын юкка гына ычкындырды ул. Радикны комендант адәмгә дә чутламый ич. Әнә бит ничек көлемсерәде. Әллә ничек, гарьлек булып китте. Оят. Берәр баласы-фәлән шаяртып йөрми микән дип уйлаганнан гына сораган иде, югыйсә. Улларының инде тереләр арасында юклыгына күптән ышанса да карчык бу юлы нәкъ шулар турында уйлады. Үле гәүдәләрен күрмәде ич, каберләрен белми. Ә бу тиклем күп акчаны үз баланнан башка беркем дә күчермәс. Бурычын гына түләмәгән бит ул, киләсе ел өчен дә исәп-хисап ясап куйган. Утыз меңгә якын акча дигән сүз бу! Әйтергә генә ансат.
—Фатыйма, сиңа хат бар.
—Ә?
—Хат килгән сина.
—Кемнән?
—Адресын таный алмадым. Үзен укырсың әле.
Карчык хатны алды да әйләндереп карый-карый бүлмәсенә атлады. Анын фикерләре чуалган иде. Бәлки, чынлап та берәр баласы исәндер. Акчаны ул күчергәндер, әлеге хатны да ул язгандыр. Бүлмәгә кергәч, тирә-якка күз салып торды да хатның почмагын ертты. Ләкин кинәт туктап калды. Ана рәхәт иде. Шушы рәхәтлекне озаккарак сузарга теләде. Хатны ачар да бөтенләй көтелмәгән яман хәбәргә юлыгыр сыман тоелды. Шулай да кызыксыну тойгысы көчле иде.
—Радик! Улым!
Исерек аны ишетмәде. Карчык бер мизгелгә генә тын калды да, калтыранган куллары белән хатны ачарга тотынды. Ләкин хатка күз салу белән ул монын үзе көткән изге нәрсә түгеллегенә төшенде. Адәм кулы белән язылмаган иде ул. Басма хәрефләр белән җыелган рәсми текст иде.
Фатыйма карчык кашларын җыера биреп аны укып чыкты да күзләрен челт-челт йомгалап алды. Башта анда язылганнарның нәрсә икәнен аңламый торды, аңлагач, ышана алмый азапланды. Хат Радик исеменә иде. Күңелен тибрәнергә мәҗбүр иткән юлларга ул тагын бер кабат күз йөгертте:
Сез «Алтын башак» спиртлы эчемлекләр заводы үткәргән лотерея уенында катнашып, 100 мең акча оттыгыз.
Йөз мең! Моңа кадәр кулга тотып та караган акча түгел. Әле дә чын икәненә ышанасы килми. Ләкин менә ич, акка кара белән шулай дип язылган. Бүләкне алу өчен кайда килергә кирәклеге дә күрсәтелгән. Петербургка! Юл хакы, торак, ашау-эчү тулысынча завод исәбеннән түләнә диелгән. Чын булса, бу шатланып туймаслык нәрсә инде дә, тик Фатыйма карчыкның күңелен көнләшүгә тартымрак тойгы кыздырып үтте. Ул гомере буена хәләл тирен түгеп эшләсә дә шул кадәр акча күрә алмады, ә монда

дөньясын оныткан бер эчкечегә... Хәер, юк... Күпсенергә кирәкмидер. Үз баласы ич.

Карчык янә йоклап яткан улына эндәште:

—Радик, балам!.. Тор әле!.. Уян әле!

Радик уянмады. Карчык уйга калды. Монын үзен генә җибәрергә ярамый инде, бөтен акчасын юкка чыгарып кайтыр. Кемне ияртергә соң?

* * *

*Ново-Михайловка. Мәскәү өлкәсе.*

—Хуш, Михаил туган! Ходай ярдәм бирсен сиңа!

—Хушыгыз, туганнар!

Чиркәүне әйләндереп алган тимер капкадан чыкканда ул тагын артына борылып карады. Кайчандыр күңеленә тынгылык биргән шушы урыннан китү аңа рәхәт түгел иде. Тик ул башкача монда да кала алмый. Җанында нәрсәдер үзгәрде, үзе тоткан юлның хаклыгына шикләнү көчәйде, мондагы тормышын тәмугка әйләндерде.

Чиркәү—изге урын. Ә Михаилнең үткәне изгеләр арасында яшәрлек түгел иде. Ул дин тәгълиматләрен өйрәнде, рухи туганнары белән дә яхшы мөнәсәбәттә булды, килүчеләр дә аны үз итеп тора иде. Кыскасы, монда барсы да әйбәт, барсы да изгелеккә корылган. Ләкин шушы изгелек аның җанын талады, көннәрен төн итте.

Урам чатына җиткәч, чиркәү гөмбәзенә янә күз салды да унга борылды. Монда аны барсы да диярлек танып тора. Хәзер чиркәүдән генә түгел, ә шушы шәһәрчектән дә китәргә туры киләчәк инде. Берничә көнен монда үткәрер дә юлга кузгалыр. Чиркәүдән киткәч, яшәп торырга дип, бер бүлмәле фатир да алып куйган иде.

Фатир хуҗасы Татьяна Сергеевна аны подъезд төбендә үк көтеп тора иде. Дөресрәге, ул аны түгел, ә моннан ике көн элек телефон аша фатирга заказ биреп, очрашу урынын сөйләшкән ирне көтә иде. Ә үзе аңа таба туп-туры атлаучы дин әһелен күреп, югалып калгандай булды. Михаилга да җиңел түгел иде. Ул үзе дә сизмәстән аркасындагы биштәрен төзәтеп куйды.

—Татьяна Сергеевна?—диде ул аптырабрак калган ханымга.

—Михаил?..—Хатынның бар кыяфәте әлеге мәлнең чынлыгын тануга карышкан төсле иде.

Михаил баш какты.

Хатын әлеге халәтен яшерергә теләгәндәй кинәт борылып подъездга атлады. Михаил аңа иярде. Берни дә сөйләшмәделәр.

Фатир беренче катта иде. Ишектән уздылар.

—Михаил атакай, сез үзегез генә булачаксызмы?—диде Татьяна Сергеевна үз соравыннан үзе уңайсызланып.—Савыт-саба да, урын-җир җиһазлары да бер генә кешелек алынган. Әгәр кунакларыгыз булса, савыт-саба менә бу шкафта... Ә постельне хәзер үк китереп китәрмен...

Михаил баш какты. Бай да, ярлы да булмаган бер фатир иде бу. Кирәге тиярдәй нәрсәләрнең барсы да диярлек бар, артыгы—юк.

—Яхшы,—диде Михаил, шкафка күз салып.—Ә костюм турында онытмадыгызмы?

Хатын залга атлады:

—Юк. Әйтергә генә онытып торам икән. Менә ул.—Татьяна Сергеевна кием шкафыннан костюм алып Михаилга сузды.—Үзегез киеп карарсыз. Ярамаса, шалтыратырсыз. Мин якында гына торам.

—Яхшы.

—Ярый, Михаил атакай, үзегез жайлап урнашыгыз. Берәр нәрсә кирәгеп куйса, телефонымны беләсез.

Татьяна Сергеевна чыгып киткәч, Михаил бүлмә уртасында бер мизгел катып торды да тәрәзә янына килде. Монда күренеш ямьсез түгел иде. Әмма Михаилның игътибарын шундук бүтән нәрсә суырып алды. Ул! Башта ышаныргамы-юкмы дип күзләрен ачып-йомып алды... Өстенә кара күн куртка, зәңгәрсу джинсы чалбар кигән кара күзлекле кеше югалмады. Киресенчә, ул Михаилның халәтен аңлап, аның кыланышларын күреп сизелер-сизелмәс елмаеп тора иде. Ләкин бу ягымлы елмаю түгел, бу ниндидер зәһәр, агулы елмаю иде. Михаил салкын су белән коенгандагыдай сискәнеп китте. Кем соң бу бәндә? Нәрсә кирәк аңа? Михаил кинәт ишеккә ташланды, ниндидер җинеллек белән подъезд алдына чыкты. Теге таныш түгел адәм торган урынга күз атты. Һәм катып калды. Беркем дә юк иде инде...

Фатирга кабат кергәч, ул Татьяна Сергеевна калдырып киткән костюмны карашлары белән генә үлчәде дә өстендәге киемнәрен салды. Аннан соң, биштәреннән кирәк-яракларын алып, ванна бүлмәсенә юнәлде.

Көрәктәй кара сакалын сыйпап көзгегә карап торды. Күзләрендә— чиксез моң иде. Бераздан катгый бер карарга килеп кулына кайчы алды. «Үткәннәрне дә шулай җинел генә кисеп ташлап булса икән»,—дип уйлады ул кайчы белән беренче чиртем ясап. Һәм үзенең кире уйлап куюыннан курыккандай ашыгып-ашыгып кисәргә тотынды.

Ул, әлбәттә, гөнаһлы иде.

Юк, чиркәүдән күңеле кайта башлаган өчен генә түгел. Әлбәттә, төрмәдән чыгып беркая да урнаша алмый йөргәннән соң, монда урнашып дөрес эшләде ул. Ялгыш юлдан тагы да тирәнгәрәк тәгәрәүдән сакланып калды. Күңеленә беркадәр тынычлык тапты. Аның үткәндәге гөнаһларын да дин әһелләре гафу иттеләр шикелле. Һәрхәлдә, аңа үзләренең тиңе итеп, бер изге зат итеп карадылар. Ләкин шушы тигезлек аны чыгырыннан чыгара иде. Чөнки аның күңел төбендә үзе генә белгән әрнүләр, үткәнендә фәкать үзенә генә билгеле булган вакыйгалар бар. Боларны ул беркайчан да, бернинди рухи туганына да белдерәчәк түгел иде. Әнә шул тойгылар туктаусыз уйлануга этәрде. Ә уйланулар чиркәүнең хаклыгына шикләнүгә китерде. Юк, аның гөнаһы динне шик астына алуда гына түгел иде. Алайга китсә, чиркәү үзе үк гөнаһ оясы. Хәзер ул моны яхшы белә инде. Һәм монда: «Начар заманда яшибез. Хәзер бер изге нәрсәне дә калдырмадылар»,—дип лаф оруларның кирәге юк. Заман бервакытта да аклыктан гына тормаган. Чиркәү дә шулай ук. Чиркәү үзе үк Христос Сүзенә каршы килә торган нәрсә әле ул. Һәм Михаил күңеленнән генә кабатлады: «Господу Богу твоему поклоняйся и Ему одному служи». Гадәтенчә, әлеге тәкбирнең чыганагын да күңелендә теркәп куйды: «Евангелие от Луки 4:8». Бер дә чиркәүгә, дин әһелләренә табыныгыз димәгән бит. Ходайга юл бары тик чиркәүләр аша гына дигән сүзе дә юк. Димәк, дин йортларыннан читтә торып та Ходайга тугры булып була. Ләкин чиркәү моны танырга теләми, читкә тайпылучыларны ул җәзалар белән куркыта. Ә үзенә тугрыларга үткәндәге, бүгенге һәм киләчәктәге гөнаһларын ярлыкауны вәгъдә итә. Кеше гөнаһларын бары тик Алла үзе генә ярлыкый ала, ләбаса. Кем әле ул чиркәү?! Ходайның үземе әллә?! Андагы гадидән-гади бәндәләрнең Ходай вазифасын үз иңенә йөкләргә нинди хакы бар?! Шушы яссылыктан караганда, чиркәү үзе үк Ходайга каршы эш алып баручы булып чыга. Алай гына да түгел, халыкның беркатлылыгына

таянып, аларның күңел кичерешләрендә акча күрәүче мошенник. Менә нәрсә! Моны бүгенге заманның начарлыгы белән генә аңлатып булмый. Бу гомер-гомергә шулай килгән.

Фикерләре дин белән каршылыкка кергән өчен ул үзен гаепле санамады. Хәтта шушы мошенниклар оешмасының тулы хокуклы бер әгъзасы булып яшәве өчен дә артык борчылмады. Ул инде сабый бала түгел һәм тормышта һәркемнең күпмедер дәрәҗәдә алдашып яшәвенә күнегә төшкән иде. Адәм үтерүдә гаепләнеп төрмәгә керүе өчен дә исе китмәде. Бу, әлбәттә, аның өчен зур тетрәнү булды. Аның тормышын, киләчәккә булган хыялларын мәңгегә дә мантымаслык итеп юкка чыгарды ул. Ләкин төрмәдә тиешле срогын тутырып чыкты егет. Һәм бу хакта онытырга тырышты. Үзе белә һәм Ходай белә—ул үтерүче түгел. Ул үз гомерендә беркемнең дә гомерен өзмәде. Ул бары тик кирәкмәгән вакытта кирәкмәгән урынга барып чыкты һәм үзенең гаепсезлеген исбатлый алмады. Кызык бу тормыш, бер уйласаң. Гаепсез булып яшәвең генә җитми, үз гаепсезлегеңне исбатларга да тиешсең... Ләкин барсы да үтте инде. Берсен дә кире кайтарып булмый. Кирәкмидер дә. Хәзер ул бөтенләй икенче кеше...

Сакалын кырып бетермәде. Бөтенләй шәрә итеп кырынса, әллә кемгә охшап китүдән куркып, бармак калынлыгы гына калдырырга булды. Күкрәгенә җиткән сакал иде бит! Хәзер ничек пөхтә әнә... Сакаллы икәне сизелгән кебек тә түгел. Ничектер бөтен барлыгы җиңеләеп киткәндәй тоелды. Ул башын әле уңга, әле сулга боргалап үзенең кинәт яшәреп калган йөзенә күнегә алмый торды. Һәм ни өчендер көләсе килде. Беркадәр вакыт бүлмәне яңгыратып шаркылдады да кинәт тынып калды. Күзләре моң белән тулды. Дымландылар. Менә-менә күз яшьләре тәгәрәп төшәр сыман тоелды. Ул карашларын түбән кадады һәм идәндә өелеп яткан күбек катыш кара сакалына карап тынып калды. «Гөнаһларымны да шулай җайлы гына кисеп ташлап булса икән!»—дип уйлады тагын.

Ул гөнаһлы иде.

Гөнаһ турында уйлауга, бая тәрәзәдән күргән кара курткалы ирне хәтерләде. Һәм кинәт бер ачыш ясады. Әлеге уйларының көчәюенә, гөнаһ турында ныклап, төн йокыларын калдырып уйлана башлавына шушы бәндә сәбәпче икән бит. Аны беренче кат күргәннән бирле Михаилның тынычлыгы югалды. Кара куртка ул көнне гыйбадәткә килгән иде. Үзенең үткән бөтен тормышын сөйләп, гөнаһларын ярлыкауны үтенде ул. Михаил атакай аны гөнаһлардан арындырырга тиеш иде. Ләкин кара куртка сөйләгән саен, ул үзенең хәлсезләнә баруын тойды. Һәм ахырда, моңарчы меңәр тапкыр әйткән сүзен көч-хәл белән кабатлап, үз бүлмәсенә узды. Ул агарынган иде. Һәм күзләрен бер ноктага текәп бер хәрәкәтсез озак утырды. Чиксез озак. Һәм шул көннән бирле керфегенә йокы эленмәде. Төннәре ерак үткәннәрне, бала чагын, туган авылын хәтерләп үтте. Күңелен чиксез сагыш биләп алды. Үзенең бүгенге халәте белән канәгатьсезлек тойгысы уянды. Һәм нәкъ шушы кара курткалы ир аны чиркәүдән китәргә мәҗбүр итте.

Әлбәттә, очраклы хәлләр дә еш була тормышта. Әмма әлеге кара киемле ирнең килүе очраклылык түгел иде. Һәм аның ярлыкау соравы да... Нәкъ менә Михаил атакай эшләгән көнне килеп ярлыкау соравы очраклы була алмый иде. Хәтта боларның барсы да очраклы хәл булганда да аның бөтен тормышы... Юк ла, үз тормышын сөйләмәде бит ул. Ул Михаил атакайның үткәннәрен сөйләде. Шулар өчен ярлыкау сорады. Ул хәтта Анна турында да белә иде.

Анна турында хәтерләүгә Михаил, уйларыннан арынып идәнне себерергә

кереште. Сакал-мыекларны пөхтә итеп төреп, чүп савытына салды да ваннага узып юынырга кереште.

Чыккач, чиркәү киемнәрен матурлап төреп капчыкка тутырды. Аннан соң биштәреннән алып эчке киемнәрен киде. Футболка белән трико да киеп алгач, көзге алдына басып елмая биребрәк үзенә карап торды. Гади тормыш киемнәре аңа шулкадәр килешәдер сыман иде. Бераздан биштәрендәге бөтен нәрсәне өстәлгә бушатты. Хәер, әллә нәрсәсе калмаган иде инде. Документлар, калын дәфтәр, полиэтилен капчыкка тутырылган эчке алмаш киемнәр, калын гына кәшилүк. Ул ярлы кеше түгел иде, кассада да акчасы җитәрлек. Әле кәшилүген калынайтып җибәрүе яңа тормышның көтелмәгән хәлләре алдында югалып калмас өчен иде. Аннан соң биштәрнең үзен дә баягы капчыкка салды да аны күтәреп урамга чыгып китте. Бераздан кире әйләнеп керде. Гаепле елмаеп куйды. Михаил атакай чиркәү киемнәрен чүплек башына ыргыткан дисәләр, моңа беркем дә ышанмас иде дер. Моннан берәр ай элек булса, үзе дә кимсенеп елмаеп кына куяр иде. Ләкин бүген...

Кухняга чыгып, чәй куюга, кесә телефоны шалтырады. Бу—Настя иде. Парикмахер.

—Мин килеп җиттем,—диде хатын.—Сезнең ничәнче фатир иде әле?

Бераздан Настя үзе дә күренде. Бу таза гына гәүдәле кыска буйлы мөлаем ханым иде. Керү белән хуҗаны таныырга тырышкандай карап торды да:

—Сез безнең шәһәрдән түгел, ахры,—диде елмаеп һәм шундук диярлек сумкасын ачып, кирәк-яракларын көйләп куйды.—Әйдәгез, эшне башлыйк.

Михаил дәшми генә көзге каршындагы креслога барып утырды. Настя аның иңнәрен япма белән төрде дә эшкә кереште.

—Нинди прическа?

Михаил иңнәрен генә сикертте.

—Сез рокер-фәлән түгелдер бит?

Михаил баш селкеде.

—Чәчегезне озыннан җибәргәнгә генә әйтүем,—дип акланды хатын.—Телевизордан күрсәтәләр бит... Ничек кисәбез соң? Кыскартабызмы?

—Спортивный. Кыска.

—Дөрес,—дип елмайды хатын.—Җәй көне чәчне кыска йөртергә кирәк. Кояш күрсен.

Бераздан көлтә-көлтә чәчләр идәнгә төшә башлады.

—Безнең якка нинди җилләр белән соң?

—Командировка.

—Кунакханәдә урын юк идемени? Мондый җирдә кыйбаттыр ич?

Михаил иңнәрен генә сикертеп куйды.

—Командировкалы эш яхшы инде,—диде хатын ниндидер хыялыйлык белән.—Күп җирләрдә йөрисең, яңа кешеләр күрәсең. Минем менә шушы шәһәрчектән унбиш ел инде беркая да чыкканым юк.

Михаил дәшмәде.

Хатын тагы нәрсәдер сөйләп маташты да, клиентның сүзгә бик һәвәс түгеллеген аңлап, башкача дәшмәде. Бары тик эш беткәч кенә сорап куйды:

—Ничек, үзеңә ошыймы? Бөтенләй башка кеше булып калдың.

Михаил елмаеп баш какты. Аның үзенә ошый иде.

—Мулла...

—Нәрсә?

—Укыганда бер ахирәтем белән аларның авылына, татар авылына, кунакка кайткан идек. Аларның мулласы бар иде. Сине күргәч, шуны

хәтерләдем. Яман булып ишетелсә, гафу ит.

Михаил елмайды. Әмма кинәт аның күзендә монсулык пәйда булды.

—Кайсы авылга?—диде ул үзе дә сизмәстән.—Кайсы авылга кайткан идегез?

—Исемен хәтерләмим инде хәзер. Казаннан ерак түгел иде ул.

Михаил дәшмәде.

Настя коралларын җыйды да акчасын алып чыгып китте.

Михаил һаман көзгегә карап утыруын белде.

—Мулла...—дип монсу елмаеп кабатлады ул үзалдына.—Мулла...

Хәзер ул чынлап та бөтенләй башка кешегә охшап калды. Үзенең болай үзгәрүенә сөенсә дә күнеленнән генә бер сорауны тукыды: « Ә Анна нәрсә дияр икән? Танырмы ул мине?»

Һәм үзләренең күрешү мизгелен күз алдына китереп елмаеп куйды. Кинәт кенә муллага охшап киткән адәмне күргәч Анна, әлбәттә, гаҗәпкә калачак инде. Танымый торачак, ә аннан соң гадәтенчә дөнья яңгыратып көлеп җибәрәчәк һәм кочаклап алачак. Сергей нишләр икән? Ике генә яшьлек бу теремек зат беркадәр ятсынып торыр инде. Аннан соң әнисенә охшатып шаркылдап көлеп җибәрер... Боларны күз алдына китерү рәхәт иде. Гомумән, шушы ике кеше турында уйлау Михаилга чиксез ләззәт бирә, хәтта чиркәү стеналары арасында томаланып яшәгәндә дә, хәтта гыйбадәт кылган чакларында да ул аларны күз алдына китерүдән тыела алмый иде. Баштагы мәлләрдә, азгынлык юлына тәгәрәп, гөнаһ җыюы өчен кыенсыныбрак йөрсә дә, соңыннан Анна белән таныштырган язмышына рәхмәт укып туя алмады ул. Әле дә, Анна бар аның тормышында. Әле дә, Сергей бар. Әлбәттә, аларның бәйләнеше хакында бу шәһәрчектә санаулы гына кеше белә. Ләкин тиздән, бик тиздән, бер гаилә булып, адәмчә яши башларлар. Һәм Сергей да аңа кайдандыр пәйда булган ниндидер әйбәт абый итеп кенә карамас...

Михаил янә көзгегә бакты. Юк ла инде, муллага охшап тормый ул. Хәзер бизнесменнар шушындыйрак чәч йөртә. Тагын әллә кемнәр...

Ул телефонын алып Аннаның номерын җыйды.

—Хәлләрең ничек, кадерлем?!

—Яхшы,—дип елмайды хатын. Михаил аның елмаюын күргән сыман булды.—Менә, җыенып беттек инде. Син кайчанрак килә аласың? Монда бер хат китерделәр. Синең исемгә.

—Нинди хат? Ничек минем исемгә?

—Белмим, Миша. Ачмадым. Үзең килгәч карарсың дидем...

—Тукта әле... Ничек ул хатны сиңа бирергә тиешләр? Үзең уйлап кара әле...

—Мин дә сәерсендем шул.

—Кем бирде соң аны?

—Бер ир кеше инде. Мин аны әллә синең берәр якын кешеңме дип уйладым әле. Синнән хат алып килгән икән дисәм, үзенә адресланган. Адрес дип инде, исем-фамилиян гына язылган.

—Нинди ир кеше?

—Гади бер ир инде. Кырык яшьләр тирәсендә. Матур гына. Кара күзлек кигән, киеме дә карадан иде бугай. Әйе, кара куртка, джинсы чалбар. Җәйге эсседә нигә кара куртка киде микән дип уйлап та куйдым әле... Уртача буйлы. Шундый танышың бармы?

Михаил бер мизгелгә тынып калды. Нәрсәдер эзләгәндәй бүлмә буйлап карашларын йөртеп алды. Һәм кинәт тәрәзәгә күзе төште. Юк, моның булуы мөмкин түгел. Ләкин күзләре аны алдамый иде.

—Кыска итеп алдырылган чәчләрен алга тараган, кара футболка, кара куртка, зәңгәрсу джинсы кигән, ә аякларында... Аякларында... Хәзер әйтәм...

—Син аны беләсеңмени?!

—Ул әле минем тәрәзә алдында тора...—Михаил ашыгып ишеккә атлады.—Мин сиңа аз гына соңрак шалтыратырмын. Ә әлегә бу серле кунак белән танышырга ашыгам. Хуш.

Ул аягына ни эләксә шуны гына элде дә урамга йөгереп чыкты. Минуттан да артык вакыт үтмәгәндер. Ләкин теге кеше урынында юк иде инде. Ул кайдадыр китеп югалган иде. Михаил тирә-якка күз атып торды. Күренмәде. Подъездлан ерак түгел генә күрше дворга чыга торган арка бар. Шушында гына юнәлгән инде ул. Башкача булуы мөмкин түгел. Михаил йөгерә-атлый шунда ташланды. Ләкин беркем дә юк иде. Янә тирә-ягын энә күзеннән үткәреп, беркадәр атлады. Ышыграк булып торган урыннарны карашлары белән капшап чыкты, подъезд ишекләренә күз салды. Ләкин ул юк иде. Нибары бер минут эчендә юкка чыкты да куйды. Болай була алмый. Жир ярылып, шунда төшеп китмәгән бит инде ул!

Михаил тирә-юньдәге бер генә күренешне, бер генә хәрәкәтне дә күзеннән ычкындырмаска тырышып кире борылды. Шул рәвешле әкрен генә фатирына керде. Карашлар әлегердәй бер генә сәер күренеш тә очрамады. Ишектән узгач бүлмә эченә күз йөгертте. Нәрсәдер үзгәргән сыман тоелды. Әлбәттә, барсы да үз урынында, бернинди үзгәреш тә юк иде. Бары тик кире кергәндә, ишеген ябарга онытканлыгын күреп кенә күнеленә шундый шик килгәндер. Бернинди дә үзгәреш юк. Шулай да... Михаил сак кына атлап кухняга чыкты. Шкафларга, юынгычка, савыт-сабага күз төшерде. Бары тик шуннан соң гына өстәлдәге конвертка игътибар итте. Ләкин аны алырга ашыкмады. Кабат залга чыгып, бүлмәне тагын бер тикшерде. Тәрәзәгә күз салды. Кара курткалы ирнең чагылышын күреп калырга теләгән иде. Тик анда беркем дә күренмәде. Бераздан ул кухняга кереп теге конвертны алды. Алды да куз тоткандай тетрәнеп китте. Арка үзәге буйлап ниндидер салкынлык узды.

Гади конвертка салынган гади хат иде бу.

Ләкин Михаилны сискәндергән нәрсә хатны алырга тиешле кешенең исеме иде. Конверттагы «кемгә» дигән юлда бөтенләй ят исем тора иде. Ләкин бу хат аңа иде. Михаилга. Һәм әлеге исем дә аңа таныш иде. Шултиклем нык таныш.

* * *

*Хәсәнбай. Башкортстан.*

Хәмит дертләп уянды да бернәрсә дә аңлый алмый торды, тирә-якка күз йөгертеп алды, татлы мышнау тавышыннан башка бернәрсә дә шәйләнмәде, өй эче күзгә төртсәң күренмәслек иде. Бераздан, тәрәзәдән кергән сыек яктылыкта чикләре җуелган шәүлә булып идәнгә тезелеп яткан балаларына карап торды да, аларга абынмаска тырышып хатыны яткан караватка килде. Сөялләнеп каткан бармаклары белән аның чәчләреннән сыйпады, бит очыннан үбеп алды. Хатын назлы мыгырданып борылып ятты. Уянмады. Йокласын, әйдә. Хәмит тын алырга да куркып аның янында тагы бераз басып торды. Карындагы баланың йөрәк тибешен ишеткәндәй булды. Елмаеп куйды. Хатынының корсагына кулын куеп улы белән «сөйләшергә» дә теләге зур иде, әмма тыелып калды. Карында бала юк иде инде. Хатынының авыры өч атна элек төшкән иде. Ләкин Хәмит кенә моның белән килешергә теләмәде. Аңа гел Лена авырлыдыр сыман тоелды.

Ишек төбендәге чөйгә эленгән сырмасын беләгенә асып, кәлүшен кулына тотты да ишекне шыгырдатмый гына ачарга тырышып өйалдына чыкты. Утны кабызып җибәрде. Сырмасын киде. Аның кесәсеннән папирус алып кабызды һәм абзар ягына юнәлде.

Сыер бозаулау—авыл кешесе өчен изге нәрсә. Кышкы салкын төн уртасында тәрәз шакып: «Сыерыгыз бозаулады!»—дигән тавышка уянып китеп тә чыгып караганы бар Хәмитнең. Сыерлары чынлап та бозаулаган, әгәр чыгып карамасалар бозаулары катып үләсе иде. Хәер, мондый чаклар еш була инде, һәм бер аның белән генә дә түгел. Шуңа да сыер бозаулау хакындагы мондый хәбәрләргә күнегеп беткән авыл халкы, аны гадәттән тыш хәл итеп түгел, ә табигый нәрсә итеп күрә.

Тәмәкесен сүндереп ташлады да Хәмит абзарга керде. Утны яндырып җибәрде. Сыер акрын гына күшәп ята иде. Хуҗасын күрүгә ул назлы мыгырданып куйды да күшәвен дәвам итте. Хәмит аңа бертын карап торды, аннан соң янына ук килеп муен астын сыпырып иркәләде дә исән-имин котылуын теләп, чыгып китте. Сыер күзләрен мөлдерәтеп аның артыннан карап калды.

Хайванның хәлен белеп чыкканда Хәмитнең күңеле әйтеп бетергесез наз, бөтен җан иясенә булган чиксез мәхәббәт белән тулган иде. Бу дөньяга туачак яңа җан иясе кем карынында ятуына да карамастан күңелне иркәли, тормышка якты күз белән карарга, аны яратырга мәҗбүр итә.

Хәмит янә тәмәке кабызды.

Һавадагы йолдызларга карап торды. Авыл өстенә нindидер һәлакәт, ләгънәт эленеп тора дип сөйлиләр... Йолдызлар якты яна, баш очында ләгънәткә охшаш нәрсә күренми иде. Бер генә томан заты да, болыт әсәре дә юк. Һавадан якты нур гына тарала.

Кинәт абзар артында гына ниндидер ыңгырашуга охшаш аваз ишетелгәндәй булды. Хәмит бер мәлгә катып калды. Тавыш кабатланмады. Ул инде өйгә керергә дип ишек тоткасына үрелгән иде. Тагын ниндидер тавыш ишетелде. Бу юлы пышылдап сөйләшүгә тартым. Ул тагы бераз тыңлап торды. Ишек тоткасына тагы үрелде. Әмма өйгә керү теләге сүрелгән иде инде. Сыер бозаулап ятмасын. Болай иртәнгә кадәр түзәрлек сыман тоела иде дә тоелуын. Хайван хәлен белеп була мени, әйтергә теле юк бит. Хәмит абзар ягына юнәлде. Һәм шунда кинәт абайлап алды, тавыш бит абзар эченнән түгел ә тыкрык яклап абзар артыннан ишетелә иде. Тыкрык буенда берәр исереге йоклап китте микән әллә? Хәмит шул якка атлады.

Атлаган саен тавышлар якыная барды, ул инде мышнау-ыңгырашу авазларын аермачык ишетә башлады һәм нәрсә булыр бу дип баш ватты. Берәр нәрсә урлап маташалармы? Төн уртасында бурлар гына йөрергә мөмкин инде. Ләкин авазларның берсе хатын-кыз тавышы икәнен һәм аның көчәнеп нидер күтәрүгә тамчы да охшамаганын тойгач, тукталып калды. Алар Хәмитләрнең абзар почмагындагы салам эскерте артында иде.

Эшнең нидәлеген аңлагач, Хәмит елмаеп куйды һәм кире борылып абзар эченә керде дә эскерткә чыга торган капканы аз гына ачып, аларның кем икәнен чамаларга теләп, күзәтә башлады.

Иң кызыгы үткән иде, ахры. Алар башкача ыңгырашмадылар. Ир ай нурында күт битләрен ялтыратып бер-ике генә ялкау хәрәкәт ясады да тынып калды. Бераздан тезенә басып чалбарын күтәреп куйды. Хатын аның кулына ябышты.

—Ашыкма...—дип пышылдады ул.—Миңа җитмәде.

Ир аның кулын тупас кына читкә этәрде:

—Китәргә кирәк.

Хатын үпкәләгән булып иркәләнде:

—Китмә инде...

Тик бу сүзләренен тәэсире юклыгын күргәч, янәшәдә генә торган шешәне капшап алды да борыныннан гына күтәреп уртлап куйды.

—Һу, беләш...—Кул аркасы белән авызын сөртеп иргә борылды.—Ә син чын ир кеше, Нәсим.

Ир инде торып баскан иде.

—Мин Нәсим түгел,—диде ул тупас кына.—Кая, берәр йотым калдымы?

—Ә син кем соң?

—Нинди аерма?! Кая?

—Монда бетте. Эчеп бетергәнбез. Түгелгән. Ха-ха-ха...

—Сау бул.

—Мине озатмыйсынмыни?!

—Нәрсә?!

—Ха-ха-ха... Эшләде дә китте... Ә миңа житмәде...

Ир инде аны тынлап маташмады. Ул тавыш-тынсыз гына атларга тырышып киртә аша чыкты да күрше урамга юнәлде. Ул исерек түгел иде. Хәмит атлап йөрешеннән анын кемлеген танып алды.

—Иди ты на...—дип сүгенде хатын һәм шешә борыныннан тагын уртлап куйды.—Ирләрнең юне бетте хәзер. Ни туда, ни сюда... Ә миңа житмәде. Житмәде...

Һәм ул саламга туңкаеп еларга тотынды.

Хәмит иргә ачулы иде. Хатын-кызны шул хәлгә житкереп исерт тә кемнендер абзар артында ташлап кит, имеш. Ләкин ачуы озакка бармады, аны бүтән тойгы алыштырды. Хәмит ач иде. Хатыны янына күптән инде якын барганы юк. Ярамый. Ул ач иде. Ә хатыннын ай нурында алтынсу төскә кереп балкыган шәрә очалары ымсындыргыч иде. Хәтта анын исереклеге дә, бернинди кануннарны санламыйча: «Ә миңа житмәде...»— дип үзе үк сорап торулары да канны аерым бер дулкында кайнарга мәжбүр итә иде.

Хәмит акрын гына шул якка атлады. Сулкылдап яткан исерек хатын анын якынлашуын сизми дә калды. Бу иргә тагы да ныграк дәрт өстәде. Ул назлы, әмма нык итеп анын беленнән эләктереп алды. Хатын бу көтелмәгән хәлдән дертләп куйды, карышып маташты, әмма үзен бер куркыныч та сагаламавын аңлап тынычланып калды, ә бераздан үзе үк очаларын уйнатып Хәмиткә ныграк ышкынырга тотынды.

Хәмит аны таныды. Бу моннан ике ел элек мәктәпкә рәсем дәресләре укытырга килеп, авылдагы мәктәпне япкач, эшсез калган Ләйлә иде. Шул ике ел эчендә кемнәрнең генә рәсемен төшереп бәхетле итмәгәндер. Кулы алтын иде анын. Йөргән егете Уфага китеп үзеннән ун яшькә өлкән бер хатынга йортка кергәч, кыз да эчештереп йөри башлаган дип сөйлиләр иде. Менә бит...

Ләкин Хәмит өчен боларның бер тиенгә дә кирәге юк иде әле. Ләйлә исерек булса да, яңа гына бер ир куенынннан калган булса да, анын яшь тәне әйтеп-аңлатып булмаслык саф гайрәт тарата, йөрәкне якты назга күмелеп тибәргә мәжбүр итә иде. Анын татлы ыңгырашулары, мизгел арасында гына гәүдәсен әллә нинди кыяфәтләргә кертеп боргаланып, тартышып алулары жанга изге бер ләззәт бирә һәм әлеге гамәлне азгынлык күренешеннән бигрәк, изге шөгыльгә, фәрештәләр биюенә әйләндерә иде.

Хәмит уйларын читкәрәк юнәлтергә, ләззәтне озаграк сузарга тырышып

караса да булдыра алмады. Наз упкынына башы белән чумды да эреп юкка чыкты. Һәм еш-еш сулап, тәне дә, җаны да таралып томанга әйләнгән бер халәттә эскерт төбенә сузылып төште. Ул үзен аз гына гаепле итеп тойды. Ләйлә тагын: «Миңа житмәде...»—дип әйтер сыман тоелды. Әмма хатын алай итмәде. Ул җанны тибрәндерер бер тавыш белән ыңгырашты да назлы итеп Хәмитнең күкрәгенә ягылып ятты. Тын калдылар. Олы бер гомер үтте. Хатынның назлы бармаклары Хәмитнең чәч араларында уянды.

—Рәхмәт сиңа!..

Назлы бу шыбырдаудан бөтен дөнья кабат сөю назына күмелде. Хәмит хатынны күкрәгенә кысып иркәләргә тотынды һәм бераздан алар ярсу хисләргә уралып, дөньяда бернәрсә белән дә исәпләшмәс давылга әйләнделәр. Кабат тойгы давылына...

Ләззәт дингезендә аркылы-буй йөзеп хәлдән тайгач, Хәмитнең дөньяга карашы да бераз үзгәрә төште. Әлеге төнге мажара аңа инде гомернең изге балкышы, күңелгә канат куяр якты тылсым булып тоелмады. Бу—азгынлык, әйтеп-аңлатып булмаслык кабахәтлек иде. Ул ниндидер күзгә күренмәс сызыкны атлап чыкты, ул ниндидер күзгә күренмәс пычраклыкка батты. Һәм моның сәбәпчесе Ләйлә иде. Уйнашлык һәм хәмер шаукымыннан мәлҗерәп төшеп аяк-кулларын җыялмыйча эскерт төбендә яткан азгын яшь хатын.

Хәмит баягы шешәне алып борынынннан гына эчеп куйды. Утлы көмешкә эчендәге әрнүләрен юып алып киткәндәй булды. Аннан соң көмешкәне учына агызып гаурәтен юарга тотынды. Хәмер чеметтереп әрнетсә дә түзде, бу әрнү аңа чистарынуның сиземләрлек билгесе булып тоелды. Спирт үз эшен эшли, димәк. Алла сакласын, мондый сөйрәлчек белән бәйләнеп чирчорга юлыгуың да бар. Болай уйлаудан йөрәге кинәт сикереп куйды һәм Хәмит янә эчеп җибәрде. Аннан соң шешәне җиргә утыртты да чалбарын эләктерде.

—Үкенәсеңме?..—диде Ләйлә. Ул урыныннан торып киенә башлаган иде инде. Хәмит дәшмәде. Ләйлә ашыкмый гына киенеп бетте дә чәчләрен төзәтергә тотынды.

—Гафу ит...—Ләйлә эскерт артына атлады.

Хәмит кинәт һушына килгәндәй булды.

—Тукта! Китми тор,—диде ул аның артыннан ияреп.—Сабыр ит.

Ләйлә туктап калды.

—Нәрсә?

Хәмит дәшмәде.

—Мин чирле түгел,—диде Ләйлә ниндидер бер ягымлы дошманлык хисе белән.—Мин синең хакта беркемгә дә әйтмәячәкмен. Ә син нәрсә телисең шуны уйла, ни телисең шуны сөйлә. Миңа пофиг. Сау бул.

Хатынның тавышы калтыранып куйды. Ул кинәт борылды да китәргә омтылды.

—Ләйлә! Тукта.

Ир аның беләгеннән үк эләктереп алды.

—Мин... Ни... Мин сине...—Хәмит кинәт туктап калды. Ниндидер бер ярсу белән Ләйләне куенына кысты да кайдан эләгә шуннан үбә-үбә пышылдады.—Рәхмәт сиңа!

Хатынның баштарак дошманлашып, читсенеп карышкан тәне йомшара төште, бераздан ул әйтеп бетергесез назлылык белән Хәмиткә сыенды да сулкылдап калтыранырга тотынды.

—Мин ярамаган эш эшләдем, гөнаһ кылдым,—дип пышылдады Хәмит.—Тик мин... мин үкенмим... Дөресрәге, үкенәм... Тик синең белән булганга түгел...

Ул үзенең болай дип әйтүенә үзе үк гаҗәпләнеп куйды. Ләкин сүзләре дөрес иде. Үзенең гөнаһ кылуына, хатынына хыянәт итүенә чиксез нык үкенсә дә анын нәкъ шушы гүзәл белән булуына ир шат иде. Бу Ләйләдә ниндидер сафлык, тән халәте белән бәйләнмәгән бер чисталык, күңел керсезлеге бар сыман иде.

—Бүген минем туган көн...—дип шыншыды Ләйлә.—Мин... Минем елдан артык инде ир күргәнем юк иде... Ә бүген... Бүген барсына да бирдем... Кем очрый... Мин ирләрдән издевалась, как могла... Мескеннәр... Беләсенме, нәрсә... Ирләр хатын-кызны әбрәкәй кебек кенә күрә. Эшен эшли дә китә һәм вәссәлам!..

Хәмит дәшмәде. Мәхәббәт сукмагына аяк басу белән үк җанын имгәтергә өлгергән кыз хаклы иде бугай. Ул үзе дә теләген канәгатьләндергәч, Ләйлә хакында шулайрак уйлады түгелме соң? Үз бозыклыгына сәбәп итеп Ләйләне күрсәтергә маташты.

—Син андый түгел...—диде Ләйлә бераз тынычлана төшеп.—Син үзең хакында гына уйлый торган түгел. Синең хатының нинди бәхетле!

Ире төн уртасында өеннән чыгып, кем беләндер уйнаш итеп йөргән хатын бәхетле була аламы? Хәмит тертләп китте. Моны хәтта Ләйлә дә сизде шикелле.

—Юк, ул чынлап та бәхетле,—диде ул.—Бүгенгесе чутланмый. Бүгенге төн очраклылык кына.

Бүгенге төн мажараларының очраклылыктан уза башлаганын ир тоемлый иде инде.

—Бүген минем туган көнем иде,—диде Ләйлә.—Син иң зур бүләк булдың.

Ул Хәмитнең ирененнән суырып үпте дә кинәт кузгалып китеп барды. Ир бернәрсә әйтәлми, берни кылалмыйча баскан урынында катып калды. Азрак һушына килгәндәй булгач та өенә керергә ашыкмады. Ят хатын-кыз исе тәненә, киемнәренә сеңеп калгандыр да өйгә керү белән бөтен дөньяга таралыр сыман тоелды. Беркадәр ихатада җилләнергә кирәк иде. Хәмит тәмәке алып кабызды. Куллары җинелчә калтырый иде бугай. Үзеннең йомшаклыгыңны, көчсезлегеңне тоеп үкенгәндә гел шулай була. Ник аз гына сонга калыбрак чыкмады инде ул?!. Ник тыелып кала алмады?!. Гөнаһ сызыгы аша узу гына җинел шул. Бер атлап чыктыңмы, кирегә юл юк. Ул күрше бакчасы гына түгел. Үз көчсезлегеңне, үз мескенлегеңне эченә йомып яшәргә мәҗбүр буласың.

Хәмит әлеге уйларын калдырырга теләгәндәй кинәт кенә капка ягына атлады. Тоткага үрелгәч, урамга чыгарга кыюлыгы җитми тукталып калды. Тирә-якка карангалап күз әләгер нәрсә, уйлар уй эзләде. Әмма бернәрсә дә күренмәде, баягы күренеш күз алдыннан китми интектерде. Аптырагач, ул урамга чыкты. Кеше-кара күренми бугай. Күренсен иде шул. Берәрсе белән бер-ике авыз сүз әйтешеп алырга иде. Тормышның һаман элеккечә акканына, дөньяның бер чите дә кителмәгәненә ышанычы артыр иде.

Ләкин кеше заты табылмады. Хәмит капка баганаларына карап, бәйләнерлек җир эзләде. Бәйләнерлек түгел иде. Ләкин сокланырлык та түгел. Матурын матур, әлбәттә. Тик мондый чакта сокланып булмый. Бер нәрсәгә дә. Кинәт почта яшнигенә күзе төште дә күнелен шатлык ялмап алды. Кичәге гәзитләрне алырга онытканнар бит! Яшник эченнән «Тулпар» журналы да килеп чыккач, сөенече тагы да артыбрак киткәндәй тоелды. Монда укып онытылырлык нәрсәне табарга була!

Карангы иде әле. Хәмит веранда утын яндырып куйды да тәмәкесен кабызып, күтәрмәгә утырды. Журналның беренче битен генә ачкан иде,

анда хат килеп чыкты. Хәмит тертләп китте. Үзе хат язарга яратмый ул. Гомумән, алар беркем белән дә хат алышмый. Ләкин кайдан да булса ниндидер сирәк хат килеп төшкән саен, Хәмит сискәнеп куя. Үзен чиксез гаепле итеп сизә. Әлеге хат эчендә аны мәңгелек утка салырдай кара хәбәр бардыр сыман тоела. Әле дә шулай булды. «Иртәгә үк китәм! Иртәгә үк!—дип уйлады ул хатны күрү белән.—Бүген үк! Бер минут та тормыйм...» Ләкин аны ачкач, ничектер тынычланыбрак калгандай булды. Бернинди дә кара хәбәр юк иде. Хәмит хатны укып чыкты да бернәрсә дә аңламады. Ул бары тик борчылырлык, газапка уралырлык нәрсә юк икәнен генә аңлады. Шул шатлыктан идәндәге кәлүшләргә текәлеп озак кына утырды. Аннан соң тагын хатка үрелде. Бу юлы игътибар белән укып чыкты. Укыган саен авызы ерыла барды. Һәм бөтен дөньясын онытып, күтәренке кәеф белән өенә атлады.

Бу вакытта ул абзар артында булган хәл турында тулысынча оныткан иде инде.

* * *

*Нью-Йорк. Америка.*

Ул өске палубага күтәрелде. Катер дулкыннарны ярып Манхеттенга юл алды. Ә Хәлил мизгел саен зурая барган биек йортларга карап, авыр сулап куйды. Ул да тормыш дулкыннарын ярып, үз бәхетен табарга теләгән иде бит. Шул бәхет хакына туган илен калдырып китүдән дә тайчанмаган иде. Рәсәйдә калса кем булыр иде икән бүген? Билгесез. Ләкин ул анда калырга теләмәде. Бернәрсәгә дә мохтаҗлык кичермичә иркен кеше булып яшисе килде. Һәм шушы теләгенә иреште дә бугай. Һәрхәлдә, бүгенге тормышы зарланырлык түгел. Нәрсә тели, шуны эшли ала. Ә илле биштән узып барган ир өчен бу алама күренеш түгел. Соң, шулай булгач... Ник әле күңелен әллә нинди сәер тойгы били?!. Палубадан түбәнге Манхеттен да, Бруклинның көньяк өлешендәге Нью-Джерси да, Сайт-Айленд та һәм еракта гы Верразано күпере дә ачык чалымлана иде. Хәлил бертын шулардан күз алалмыйча торды. Искиткеч гүзәл манзара иде бу. Кинәт ул каршыга килүче сәүдә карабына игътибар итте. Караб, әйтерсең, йөзми, ә күз алдында зурая бара иде. Ул дертләп куйды. Аны да кайчагында ниндидер сәер халәт биләп ала, онытырга, еллар томаны артында калдырырга теләгән тормышы еракта гы кечкенә нокта булып күз алдына баса да әлеге караб шикелле кинәт зурая башлый һәм бөтен дөньясын яулый. Әле дә шулай булды. Карабның күләгәсе бөтен дөньяның яктылыгын каплап алгандай тоелды. Тик ул узып китте. Ул үткәч, тирә-як тагын яктыра төште. Ә күңелдәге теге авыр тойгы үтмәде.

Сагыну дигәнең шулай тилертә микәнни инде?!. Әллә үзенне гаепләү тойгысы тынгы бирмиме? Хәер, икесе дә бардыр. Менә кадәр яшәвен юньгә салырга тырышып та, яшьлеге белән дә артык сизмәгәндер. Ә хәзер, тормышы көйләнеп, яше зурайган саен үткәннәренә күз сала да, хаталарын аңлап үкенәдер. Моны ачыктан-ачык таныргa теләмәсә дә, күңел дигәнең үзенекен итә торгандыр.

Башта ук дөрес эшләмәде шул. Беркемгә бернәрсә әйтеп тормыйча, чит илгә чыгып китте. Хәер, заманы да мондый нәрсәне кычкырып сөйләп йөри торган түгел иде. Әмма иң якыннарына гына серен чишәргә мөмкинлеге бар иде ич инде. Тик Хәлил алай итмәде. Соңыннан да бер хәбәр дә бирмәде. Баштарак гаиләсенә шик төшерүдән, аларның тормышын катлауландырудан курыкты, ә аннан соң үзенең бер хәбәрсез китүе өчен уңайсызланды. Аны күптән терелләр исемлегеннән сызып ташлаганнардыр инде. Югалуы белән

килешкәннәрдер. Хәзер үткәннәрне искә төшереп, күңелләрендәге яраны казып азапланмыйм дип уйлады.

Әлбәттә, аның кинәт юкка чыгуы гына гаиләләрендәге тормышны алама якка үзгәртеп җибәрмәгәндер. Ни генә әйтсәң дә, ул әти-әнисенең бердәнбер улы түгел, картайган көннәрендә кадер-хөрмәт күрсәтерлек тагын өч малай туганы бар. Ул яктан Хәлилнең күңеле тыныч. Ләкин...

Катердан төшкәч, Беттери паркы аша чыгып, машиналар һәм җәяүлеләр белән шыгрым тулы урам буйлап атлап китте. Бернәрсә турында да уйламады бугай. Җанында тик бушлык кына иде. Бродвейның очына килеп чыккач, тукталып калды, тирә-ягына күз салды. Мескен генә булып утырган чиркәүгә карап торды. Монда килгән беренче мәлләрендә аның өчен бердәнбер таныш нәрсә чиркәү иде бугай. Казанда да күп иде алар. Шуңадырмы, чиркәү янынннан узганда, күңелен ниндидер сәер хис биләп ала иде. Ул беркая да китмәгәндер, Казан урамында гына йөридер сыман тоела иде ул чакларда. Әле алай булмады. Хәзер ул мондагы тормышка өйрәнеп житкән иде инде. Шулай да урамнардан узганда, һич югы берәр тапкыр гына татар телендә сөйләшкән кешене очрату теләге тынгы бирми иде. Менә биш ел чамасы инде шушы уй тормышка ашмаслык хыял булып җанында яшәде. Хәтта бервакыт урам чатындагы кибетчек янында ике хатынның татарча сөйләшкәнен ишеткәндәй дә булды. Сүзләр агышы шулкадәр таныш, йөрәкне назлар дәрәҗәдә ягымлы иде. Ул ирексездән тукталып калды, колакларын торгызып тыңларга кереште. Ләкин болар төрекләр булып чыкты. Шулай да якын, рәхәт иде. Ә икенче вакыт базарда ир-ат тавышының татарча кычкырганын ишетеп дертләп китте:

—Унбер алла! Унбер алла!

«Нинди унбер алла булсын! Алла берәү генә!»—дип уйлады ул, әлеге тавышның таныш моңын тыңлап. Ләкин якынрак килгәч, арзанлы зонтиклар сатып торган пакистан картын күреп, тәгәрәп китә язды. Ә карт аны үчекләгәндәй, һаман сатып алучыларны чакыруын белде:

—Umbrella! Umbrella!

Моңа охшаш алданулар аз булмады, әлбәттә. Шуңа да әлеге теләге беркайчан да тормышка ашмаслык хыял булып тоела башлады. Аның акчасы житәрлек иде. Кайчакларда: «Урамда татарча сөйләшкән берәр кешене очратсам, ике дә уйлап тормыйча чек язып бирер идем»,—дип уйлаган чаклары да аз булмады. «Нәрсә теләсә, шуңа риза булыр идем», дия башлады соңрак, бу теләгенең тормышка ашудан никадәр ерак икәнен аңлый башлагач. Ләкин андый адәм очрамады. Әлбәттә, татарлар аз түгел иде монда. Алар берсен-берсе яхшы беләләр, еш кына очрашып та торалар. Андый чакларда татарча сөйләшәләр дә. Ләкин бу исәпкә керми. Урамда очрату—бөтенләй башка эш.

Баштагы мәлләрдә үзе көлемсерәбрәк күзәткән күренешләрне ул хәзер яхшы аңлый иде инде. Аның монда очраткан беренче татары Габдулла Хәмит булды. Герман сугышында әсирлеккә эләгеп, Сталин төрмәләрендә башын чертергә теләмичә башта Көнбатыш Германиядә яшәп, аннан соң Америкага килгән бу карт Хәлилгә бик кызык тоела иде. Ул татар җырын беркайчан да тыныч кына, еламыйча гына тыңлый алмый. Татарларның тарихы, мәдәнияте, әдәбияты турында тәүлек әйләнәсенә гәпләшергә мөмкин. Шуннан башка аны чын мәгънәсендә дулкынландырган бүтән тема юк та сыман тоела иде кайчагында. Казанга еш йөргән танышлары аша кайтарткан татар китапларын кычкырып укырга ярата иде. Шигырь түгел... Шигырь булса, аңлашылыр да иде әле... Шигырь түгел, ә хикәя китапларын кычкырып укый иде ул.

Һәм күзләренә яшь атылып чыга иде. Хәлил нәкъ менә шушы гадәтен сәерсенә иде анын. Ничек инде хикәяне кычкырып укып була?! Һәм ничек елап була ул хикәяне укыганда?! Гаҗәп! Ләкин хәзер чамалый инде, Габдулла бабайга китапта язылган вакыйгалар гына түгел, ә телнең агышы, аның ягымлы матурлыгы тәэсир иткән. Ул чакта мистер Хәмиткә сиксән яшь иде. Ә Хәлилгә күпме генә әле. Болай барса, ул да нәкъ Габдулла бабай кебек төшәчәк икән...

Ләкин тормышта могҗизалар булмый тормый икән. Кичә Хәлил ял алды. Эштән чыгып арыганлыктан түгел, әлбәттә. Улы Робертның да буш вакытлары. Бергәләп берәр кайда ял итеп кайтырбыз, дип уйладылар. Ялның рәсми вак-төякләрен хәл итеп чыгу белән, өенә җилдерергә иде исәбе. Кайда китәчәкләрен улы белән хәл итәрләр дә юлга җыена башларлар. Дөресен генә әйткәндә, Хәлилнең үзенә кайда барса да барыбер иде. Хатынын югалтканнан бирле, менә биш елдан артык инде, ялга чыкканы юк аның, эш белән онытылырга тырыша. Роберт кына озак сайлана, аңа әле Рим, әле Париж ошый...

Эш урыныннан чыгып, такси тотарга дип юнәлгән иде Хәлил. Кинәт колагына ниндидер ягымлы дулкын килеп бәрелде дә ул туктап калды. Юк, гәүдәсе генә түгел, ә бөтен барлыгы белән катып калды ул. Тәненең һәм җанының бөтен күзәнәкләре әлеге хәлнең чынбарлык икәненә ышанырга теләмичә карыштылар. Моның чынлап та булуы мөмкин түгел иде. Мондый хәл берничек тә була алмый иде. Булырга тиеш түгел иде. Ләкин ул бар иде. Һәм ул Хәлилнең бөтен булмышын катып калырга мәҗбүр итте. Ә таныш авазлар акрын гына бөтен барлыгына үтеп керде, күзәнәкләренә таралды, җанына үрелде. Һәм Хәлилнең җанын ләззәтле бер дулкында тибрәлергә мәҗбүр итте. Ул үзен авыл өенең матчасына эленгән бишектә бәүелүче бала сыман тойды. Менә-менә әнисенең ягымлы йөзе дә күренер төсле... Шундый рәхәт... Җанны назлаган дулкын акрын гына көчәя барды һәм Хәлил аның сүзләрен дә аермачык ишетә башлады. Ягымлы моңлы тавыш белән кемдер җырлый иде:

> Онытылмас һич тә. Төшәр әле искә
> Үзегезнең туган ягыгыз.

Бер мизгелгә Хәлил үзенең чынлап та Нью-Йорк урамында торуына шикләнеп куйды, бу төш кенәдер сыман тоелды. Төш кенә булса да бу шундый ләззәтле иде. Хәлил уянуыннан курыккандай бер хәрәкәтсез калып моңны йотты.

> Кайтырсыз әле бер... Кайтырсыз, барыбер,
> Таш булмаса, әгәр, җаныгыз.

Бугазына төер тыгылды. Сулышлары ешайды. Бөтен тәнен калтырану алды. Һәм Хәлил әлеге хәлнең чынлап та өндә икәненә, җырчының чынлап та үз артында гына икәненә ышанырга теләп, артына борылды. Хәрәкәте ничектер кискен килеп чыкты бугай, җырлаучы кинәт тынып калды. Бер мизгелгә генә тукталып, аңа текәлеп торды. Һәм елмайды:

—Нәрсә, буржуй,—диде ул шаян тантана белән.—Куркасыңмы безнең җырдан?!

Хәлил авызын ачарлык та көч тапмады. Ә теге адәм киң елмайды:

—Син курыкма. Матур җыр ул. Телисеңме, сине дә өйрәтәм?

Хәлил бер сүз дә әйтә алмады. Кара футболка өстеннән кара күн куртка, джинсы чалбар кигән бу адәм аннан унбиш яшьләр чамасына кечерәк иде. Чәчен алга тарап, кара күзлек киеп куюы аны тагы да яшьрәк итеп күрсәтә.

Һәм нииндидер таныш кешене хәтерләткән сыман... Ә елмаюы! Америка елмая торган кешеләр иле. Ләкин болай ихлас елмаю, күңелеңдәге ачып салып елмаю татардан башка беркемдә дә юктыр. Ул нәрсәдер әйтергә теләгән иде, тик тавышы чыкмады, шуңа да башын кагарга ашыкты. Ир кычкырып көлеп җибәрде:

—Икәү кычкырып җырлыйбыз, яме. Син җырлый беләсенме, мистер...

—Хәлил...—Ниһаять, ул сүз әйтерлек хәлгә килде.—Хәлил мин...

Хәзер теге ир аптырап калды. Ул Хәлилгә төбәлеп, үз күзләренә үзе ышанмагандай итеп катып калды. Аннан соң ун кулы белән аның инен капшап карады:

—Син дә татармыни?! Менә инәннен... бәрәнге тәкәсе!!!

—Туганым!—Хәлил аны кочаклап алды.—Татар малае!

Көтелмәгән очрашуның исерткеч шатлыгы узгач, Хәлил үзенең күңелдән кабатлаган нәзерен искә төшерде:

—Урамда татарча сөйләшкән кешене очратсам, аның нинди дә булса бер теләген үтәрмен дип вәгъдә биргән идем. Син бездә озак яшәмисең шикелле, нинди ярдәм кирәк, кыенсынып торма.

Кара куртка уйга калды.

—Нинди теләк булса да үтисенме?

—Кулдан килердәй булсын инде...—дип елмайды Хәлил.—Үтим, әлбәттә.

Кара куртка күз алдында балкып китте.

—Минем теләк берәү генә. Һәм кулыннан килердәй. Үтәрлек булсаң гына әйтәм.

—Ярый. Килештек.

Кара куртка бер мизгелгә тынып торды. Икеләнүле карашын Хәлилгә төбәп алды һәм тәвәккәлләде:

—Син безгә кунакка кил. Гаиләң белән.

Хәлил мондый нәрсәне көтмәгән иде. Ул аптырабрак калды. Һәм өстеннән авыр йөк төшкәндәй елмаеп куйды:

—Килештек.

—Вәгъдәме?

—Вәгъдә!—диде Хәлил елмаеп, һәм иргә текәлде.—Ә сез кайда яшисез соң?

—Казанда.

Хәлил бер мәлгә югалып калды. Ул аны Нью-Йоркта, һич югы Америкада яшидер дип уйлаган иде. Аның хәлен кара куртка да аңлады:

—Проблема бармы әллә?—дип елмайды ул.

—Юк. Юк!—дияргә ашыкты Хәлил.—Тик мин сезне Казанда яшисездер дип уйламаган идем.

—Димәк, килешү үз көчендә кала?

—Әлбәттә.

—Бик яхшы. Кайчан киләсез?

—Белмим... Без улым белән ялга җыенган идек. Бәлки, Рәсәйгә кайтырбыз да. Шунда сезгә дә...

—Яхшы. Алайса, болай сөйләшәбез. Сез бүген кайтып, гаиләгез белән киңәшегез дә, миңа шалтыратырсыз.

—Бик әйбәт булыр,—диде Хәлил елмаеп, һәм үзенең татар гадәтләреннән читләшә баруы өчен уңайсызланып өстәп куйды.—Бәлки, башта миндә кунак булырсың. Минем әле өйгә кайтыш иде...

—Юк,—дип елмайды кара куртка.—Рәхмәт. Башка вакытта.

Аның белән аерылышканнан соң да күңелдәге рәхәт тойгы таралмады.

Бары тик өенә кайткач кына ул әлеге кешенең исемен дә сорамавы өчен үкенеп куйды. Ләкин бу үкенеч озакка бармады. Роберт аның тәкъдимен ишетү белән үрә сикерде:

—Менә яхшы була! Казанны да күрәбез!

Бу көтелмәгән очрашуның тәэсире көчле булды. Хәлил төне буе йоклый алмады. Әти-әнисе, туганнары, авылы күз алдыннан китмәде. Бөтен дөньясын сагыш, моңсу бер яктылык биләп алды. Рәхәт тә, кыен да иде. Катердагы кичерешләре дә әлеге хисләр давылының хәлсезләнгән дәвамы иде.

Уйларына бирелгән Хәлил көтелмәгән тавыштан дертләп китте. Елмаеп басып торган яшь кенә ханымны күреп, үзе дә елмаерга ашыкты.

—Гафу итегез, мистер Хәлил,—диде ханым, кулындагы конвертны сузып.—Дустыгыз үзе килә алмады һәм кичерүгезне үтенде. Монда бөтен кирәкле нәрсәләр дә бар. Иртәгә юлга кузгаласыз. Көттергәнем өчен тагын бер кат гафу үтенәм. Хушыгыз.

Хәлил нәрсәдер әйтеп өлгергәнче ул китеп тә барды.

—Рәхмәт!—дип пышылдады Хәлил, конвертны куен кесәсенә салып.—Рәхмәт, сеңлем!

Татар егете белән очраша алмавына аз гына кәефе кителгәндәй булса да, ул шат иде. Ниһаять, ул үз иленә кайта. Утыз өч елдан соң! Унҗиде яшьлек улы белән. Әти-әнисе исән микән? Исән генә булсыннар иде. Америкада туып-үскән оныкларын күреп, аның да үз балалары икәнен тоеп сөенсеннәр иде. Хәлил елмаеп куйды. Елыйсы да, көләсе дә килә...

* * *

Ул кара курткасын салып урындыкка ташлады да йомшак креслога җәелеп утырды. Бераздан аякларын американча итеп журнал өстәленә күтәреп куйды. Мондый күренешне киноларда еш күргәне бар иде. Ничектер сәер булып тоела иде ул. Теләсә кайда йөргән ботинканны ничек өстәлгә куеп утырмак кирәк инде. Ләкин монда килгәч, сере ачылды. Барсы да гади генә икән. Урамнар монда бик тә чиста, аягыңа берниндн дә пычрак эленми. Һәм өстәлгә күтәреп куйган ботинканың пычрак булу ихтималы хакында бары тик Рәсәй кешесе генә уйларга мөмкиндер. Ләкин бераздан ул аякларын кабат идәнгә төшерде. Болай унайсыз иде.

Хәлилне шулай тиз генә, җинел генә эләктерермен дип башына да китермәгән иде. Ничектер бик тә беркатлы ялганга капты американлы. Хәер, аларның барсы да шундыйрак, ахры. Михаил Задорнов: «алар бар да лох,» —дип белмичә генә көлми торгандыр инде. Монда кешегә ышану көчле шул. Һәркемгә ышанычлы якты кеше итеп карыйлар. Шулай яхшырактыр да. Ышанычка корылган җәмгыятьтә генә тыныч күнел белән эшләргә дә, яшәргә дә мөмкин. Бары тик шул ышанычыңны югалтма гына. Ә бездә бүтәнчәрәк. Кемдер сине мактый башласа да, «Бу ник болай кылана әле, нәрсәгә өмет итә?»—дип шикләнә башлыйсың.

Уйланган эшләрнең барсы да уңышлы үтте. Ләкин бу артык сөендермәде. Хәзер ул үзенең бу юләрлеккә ни өчен тотынуына үкенә башлады. Кирәк түгел иде. Менә шушында Америкага килеп, тыныч кына ят, дөнья күр, яна кешеләр белән аралаш—шул җитеп ашачак иде. Юк, ул болай булдыра алмый. Ана нинди дә булса бер ахмаклык кылырга кирәк.

Башы җинел генә башланса да ахыры ни белән бетәчәген күзаллау кыен иде. Әгәр нинди дә булса фаҗига килеп чыкса, ул үзен мәнге дә гафу итәчәк түгел. Һәм башкалар да кичермәячәк. Ул бер дә юктан гына үз язмышын кыл өстенә куйды. Үз язмышы гына бер хәл иде әле, ул куркыныч адымнарга

барудан ләззәт кенә ала. Башкалар язмышын кыл өстенә куйды—менә монсы инде начар. Вакыйгаларның ничек тәмамланырын күзалламаган хәлдә, бу сәяхәттә катнашкан һәркемнең язмышы куркыныч астында иде.

Бәлки, тукталыргадыр?

Өстәвенә, Кояшлы күлдәге утраулар турында, чынлап та, төрле имеш-мимешләр йөри иде. Ул үзе дә бу турыда яман хәбәрне аз таратмады. Ләкин ул тараткан гайбәт бер нәрсә, ә шушы төбәктә буын-буынга яшәгән кешеләрнең сүзе бөтенләй икенче. Урындагы халык аның берсен «Әҗәл утравы» дип йөртә һәм якын барырга түгел, ә исемен телгә алырга да курка. Күлнең аркылысын-буен инләгән балыкчылар исә бу утрауда төрле сәер хәлләр булуы хакында сәгатьләр буе сөйли ала. Кемнәрдер аны шайтаннар оясы дип исәпли, кемнәрдер параллель дөньяларга керү ишеге шунда урнашкан дип уйлый, кемнәрдер вакыт упкыны шушында дип җибәрә... Ләкин ул боларга бик ышанып та җитмәде. Күптән түгел генә, әлеге сәяхәтне әзерләгәндә, шул утрауга барып берьялгызы җиде көн торып кайтты. Бик күп еллар элек кемдер төзеп куйган ике катлы зур гына йорт бар анда. Ләкин бернинди дә сәер хәлгә юлыкмады.

Әлбәттә, бу бернәрсәне дә исбатламый иде. Гаҗәп хәлләр, сәер күренешләр көн саен булып тормыйдыр. Бар да уңышлы үтәчәгенә ышанып кайткан иде ул вакытта. Бүген менә тагын күңелен икеләнү биләп алды. Утрау гадидән дә гадирәк булган хәлдә дә кешеләрнең нәрсә эшләрен алдан күреп бетереп булмый ич.

Бәлки, чынлап та, тукталыргадыр?

Тукталырга әле соң түгел иде. Барсын да җайлап кына, сиздермичә генә тәмамларга мөмкин. Хәтта сиздерсәң дә, әлеге матавыкның ни өчен оештырылганын аңлатсаң да, беркем дә гаеп итмәячәк. Әлегә барсы да контрольдә, безнең сәясмәннәрчә әйтсәк. Ләкин аның тукталасы килми иде. Вакыйгаларның нәрсә белән бетәре кызык иде. Һәм куркыныч иде. Ул соңгысы турында уйламаска тырышты.

* * *

*Санкт-Петербург. Рәсәй.*

Ниһаять, алар елга вокзалына килеп җитте. Таксидан төшүгә үк нindидер мөлаем ханым каршы алды. Роберт җинел сулап куйды. Бу ханым Рәсәйдә аларга ягымлы елмаеп караган беренче кеше иде. Ләкин бу ханым да аларны башка туристлар янына озатып кую белән юкка чыкты. Кояшлы күлдәге утрауга сәяхәт кылырга җыелучылар утыз-кырык кеше иде. Роберт тирә-ягына күз йөгертеп чыкты. Монда алар шикелле бер гаилә булып килүчеләр бармак белән генә санарлык. Калганнары уңлап кешедән торган төркем булып укмашканнар, кайсыларының кулларында сыра шешәләре. Кычкырышып нәрсәдер сөйлиләр, көлешәләр. Яшьрәк егетләр үзара төрткәләшеп, шаярышып та ала. Мондыйлар белән аның әтисе берничек тә уртак тел таба алмастыр шикелле.

—Әти, ә теге дустың үзе юкмыни?

—Белмим. Күренми бит әле.

Урамда очраган таныш түгел кешенең сүзенә ышанып юлга чыгуына Хәлил үзе дә үкенә иде булса кирәк. Роберт кабат сораулар биреп аны ялкытмаска тырышты.

Аның Рәсәйдә булганы юк иде. Әтисе ялны шунда уздырабыз дигәч тә шатланып ризалашты. Бу илдә монарчы беркайда да очрамаган бер могҗизага юлыгыр сыман тоелды. Әтисенең туып-үскән җирен, туганнарын да күрер. Истәлекле урыннарда да булырлар. Ул шулай уйлаган иде. Ләкин монда аяк басу белән күңелен бөтенләй башка уй, ник ризалашуына үкенү

сыманрак бернәрсә биләп алды. Барсы да ничектер чит-ят, кырыс сыман тоелды. Тирә-якның матурлыгын карап, ләззәтләнеп йөрергә бик вакыт та булмады, кайдадыр ашыктылар. Өстәвенә, көтелмәгән бәла килеп чыкты. Ул туры Татарстанга барырбыз, ә анда барсы да тик татарча гына сөйләшәдер дип уйлаган иде. Ләкин алар Санкт-Петербургка килеп төштеләр, аннан соң тагын такси белән хәтсез генә ниндидер поселокка килделәр. Ул поселокның исеме истә калдырырлык та түгел иде. Һәм Рәсәйгә аяк басканыннан бирле ул ни инглизчә, ни татарча бер сүз дә ишетмәде. Ә русча белми иде. Шуңа да үзен ниндидер ят, салкын дөньяга килеп эләккәндәй тойды. Житмәсә, мондагы халыкның йөзе үк ниндидер усал, кырыс булып тора.

Күзәтә торгач, мондагы кешеләрнең йөзендә ул усаллыктан бигрәк гаҗизлек өстенлек иткәнен аңлады. Нәрсәнедер өметләнеп көтеп-көтеп тә, көтеп ала алмаган кыяфәт иде боларда. Бәлки, теплоход көтү озакка киткәнлектән йончыганнар гынадыр. Әнә тегендәге эскәмиядә бер сакалтай ир белән хатын, кечкенә балаларын алларына аркылы салып, башларын бер-берсенә терәп утырганнар да шар ачык күзләрен билгесезлеккә төбәп катып калганнар. Баядан бирле шулай утыралар инде. Ник бер хәрәкәт ясасыннар. Робертның фантазиясе инде аларның тере кеше икәнлекләренә шикләнә башлаган иде, кинәт хатын иреннәрен генә хәрәкәтләндереп нәрсәдер әйтеп куйды. Егет аның «Михаил» дигәненнән башка сүзен аңламады. Ләкин ире елмаеп куйды. Ничектер күңелгә рәхәт булып калды. «Бу илдә күргән икенче елмаю.» Алар янындарак сәер генә киенгән бер ир башын күкрәгенә салындырып йоклап утыра. Янында кызыдыр инде, яшькә Роберт белән бер тирәләрдә. Ул әтисенең әлеге кыяфәтеннән кыенсынгандай, беркемгә дә карамаска тырышып, башын читкә борган. Иннәренә төшеп торган сары чәчләр. Ә кашлары кара. Тулышып пешкән калын иреннәр. Әгәр йөзендә үз халәтеннән кыенсыну, канәгатьсезлек чалымнары булмаса, ярыйсы матур гына кыз. Хәтта шушы көенә дә күз алырлык түгел. Ни өчендер монсулык килешә ул кайбер кызларга, назлырак итеп җибәрә, юатасы килү теләген уята. Арырак сумка-чемоданнарын уртага алып баскан дүртәү. Әти-әнисе белән сәяхәткә чыккан апалы-энелеләрдер инде. Болар башкалар шикелле боек та, ярсулы да түгел. Ара-тирә сүз кушышып, сабыр гына көтәләр. Әтиләре тыныч холыклы кешегә охшаган, әниләренең кыяфәтендә ниндидер тәкәбберлек сизелеп калган сыман. Ул гаилә хуҗасыдыр инде. Ара-тирә балаларына кисәтү ясап та ала бугай. Сүзләре ишетелми. Ләкин кыланышлары шуңа охшаган. Балалары икесе дә Роберт чамасы бугай. Алар арт белән басканнар, йөзләрен күреп булмый, әмма буй-сыннарына караганда шулай булырга тиеш. Менә болар белән аралаша алыр иде Роберт. Кызлары бик зифа буйлы күренә, калак сөякләренә кадәр төшеп торган кара чәчләрен таратып җибәргән. Әйе, монда Робертка иптәш булырлык өч кеше бар әле. Көтмәгәндә кыз артына борылып карады һәм карашлары Робертныкы белән очрашты. Бер мизгелгә алар икесе дә катып калдылар. Дөньяларын оныттылар. Беренче булып кыз һушына килде, ул гафу үтенгәндәй оялчан елмаеп кире борылды. Роберт әлеге мизгелнең өндә булуына ышанмагандай катып торуында булды. Ничектер күзләрен ала алмады шул яктан. Ахырда, очраклы бер елмаю өчен изрәп басып торуын килештермичә, карашларын ары күчерде. Һәм күз кырые белән генә күреп калды, нәкъ шул вакытта кыз аның ягына тагын бер кат борылып карады. Ялт итеп кенә. Бер генә мизгелгә. Ләкин карады. Монсы инде баягы елмаюның очраклы түгеллеге турында сөйли иде. Робертның бөтен барлыгын ниндидер ләззәтле дулкын тибрәндереп үтте. Һәм ул әлеге халәтен башкаларга сиздермәс өчен бөтен тирә-якны

шаулатып сөйләшеп-көлешеп торган төркемне күзәтергә тотынды. Болар егерме-утыз яшьләр тирәсендәге унлап кеше иде. Күптәнге танышлар, дуслар, күрәсең. Бәлки, хезмәттәшләрдер, ә бәлки... әйе, болар елларын бергә уздырырга уйлаган берничә пар иде. Бала-чагалары юк, бәлки, ирле-хатынлы да түгелләрдер...

—Роберт, син арымадыңмы әле?—Әтисенең тавышы кинәт бүлдерде.— Бәлки, маташып тормабыз бу сәяхәт белән? Бәлки, Казанга гына китәрбез?

Егет тә баягы кыз ягына борылып карады. Кыз ничектер җаен табып, әтисе янына килеп баскан, хәзер ул Робертка йөз белән тора иде. Һәм ул егетнең борылып караганын күрде. Сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды. Ләкин Роберт елмаймады. Ул житдилеген жуймаска тырышып әтисенә карады:

—Үзең ничек телисең соң, әти? Казанга баруга мин каршы түгел, ләкин әлеге утрауны карап китсәк тә зыян булмас иде. Вакыт бар бит әле безнең.

Әтисе яратып елмайды:

—Сиңа күңелсез булмасын дип әйтүем генә. Ничектер боегып киткән сыман булдың.

—Ә монда барсы да шундыйлар. Мин бер канәгать йөзле кеше дә тапмадым. Монда бары тик исерекләр генә елмая. Күрәсең, монда сыра эчмичә бәхетле булып булмыйдыр.

Хәлил кычкырып көлеп җибәрде.

—Юк... Бездә еш елмаялар, ансы дөрес. Ләкин мондагы елмаю бөтенләй бүтән. Монда сиңа берәрсе елмаеп карадымы, ул сине якын итә дигән сүз. Мондагы елмаю «син минем өчен бик тә якын кеше» дигән сыманрак яңгырый һәм аны бөтен кешегә дә әйтмиләр. Ә бездәге елмаю—ул нибары бер гадәт кенә. Сиңа карап авызын ерды һәм бер мәлдән дөньяда барлыгыңны онытты...

—Кызык...

—Рәсәй, гомумән, кызыклы ил. Ул сиңа ошаячак, улым.

Роберт сүз беткәнен аңлатып читкә борылды, ә бераздан, әтисе карашлары белән дустын эзли башлагач, теге кыз ягына карады. Кыз аны күзәтә иде. Һәм Роберт күңелендәге бөтен яктылыгын иреннәренә чыгарып аңа елмайды. Кыз бер мәлгә бу көтелмәгән хәлгә каушабрак калды, ә аннан соң үзе дә елмаю булып балкыды һәм янында торган якыннарыннан кыенсынып, артка борылды. Янындагылар аның халәтен сизмәделәрме, сизмәмешкә салыштылармы, игътибар бирүче табылмады.

Бары тик бераздан гына кыз янында торган егет Робертка борылды. Бәйләнчегрәк карашлары белән аны өйрәнгәндәй итте дә теләктәшлек белдергәндәй сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды. Роберт та елмайды.

* * *

—Ләйсән, син егетләр белән күз атыша да башладыңмы инде?..—дип пышылдады Ләис, әти-әнисе киоскка киткәч.—Кара аны...

—Үзеңне бел... Әнә теге йокы пиргүе янында утырган сарычәчтән күзеңне дә алмыйсың ич!—Ләиснең кинәт югалып калуын күреп, кычкырып көлеп җибәрде һәм аны үпкәләтүдән курыккандай өстәп куйды.—Ә ул ничауа гына күренә!

Ләис Роберт ягына ымлады:

—Аны әйтәсеңме? Ярарлык.

—Юк,—дип елмайды Ләйсән.—Синең сарычәчеңне әйтәм, матур кыз.

Ләис чынлап әйтә микән дигәндәй, бертын сынап торды да, елмаеп җибәрде:

—Теләсә кемгә күз төшереп йөрмим бит инде. Менә җингән дә итеп куярмын әле.

—Киленең диген, агач тел! Син миннән ярты сәгатькә кече әле.

—Ярты сәгать тә булдымы аерма.

—Канатлы ракета Америкага нәкъ ун минутта барып житә. Ә ярты сәгатьтә бөтен дөньяны шартлатып бетереп була. Димәк, син миннән нәкъ бер дөнья бетәрлек вакытка соңга калып тугансың. Энекәш!

—Ну, ярый, «килен» диярсең...

—Диярмен. Тик син башта таныш әле аның белән. Әйдә, бәхәс—шушы сәфәр азагына кадәр ул кызга бер сүз дә эндәшә алмаячаксың.

—Минме?! Хәзер барып танышам мин, кирәк булса.

—Булмый! Әйдә, бәхәс! Кәрәзле телефонымны сиңа бирәм.

—Ә мина телефон бик кирәкми дә...

—Куркасың шул. Кызлар алдында гомергә шул мәмәй авыз булдың инде. Бик беләсең килсә, кызлар алар кыю егетләрне ярата. Мин синең урынында булсам, ана хәзер үк барып эндәшер идем.

—Син бит ул...

Ләис сарычәч ягына тагын бер карап куйды. Башын да күтәрми, ичмасам.

Ул арада ялга җыенучылар арасында ниндидер хәрәкәт башланды. Кычкырып сөйләшкәннәр тынычланыбрак калды, йоклап утырганнар күзләрен ачты. Ләис моның сәбәпчесен тиз тапты. Алар арасында турагентство формасындагы мөлаем ханым пәйда булган иде. «Бу ханымга монда йөрисе түгел, ә һинд киноларында гына уйныйсы бар»,—дип уйлады Ләис, ана карап.

—Ничек, дуслар? Көтеп арымадыгызмы әле?!—диде ул яңгыравыклы якты тавыш белән.—Ярый, башларыгызны салындырырга ашыкмагыз.

Якынрак торганнар арасыннан кемдер канәгатьсезлек белдереп мыгырданып куйды. Ләкин ханым мона тамчы да ачуланмады:

—Хәлегезне аңлыйм. Барыгыз да ерак юлдан килгәнсез, йончыбрак та киткәнсездер,—диде ул ягымлы тавыш белән.— Ләкин күңелегезне төшерми торыгыз. Безнең сәфәр әле башланмады. Бүген теплоходка утыргач, иркенләп ял итәрсез. Ә иртәгә иртә белән сезне иң күңелле күренешләр көтә. Әлбәттә, сез матур урыннар күрми яшәгән кешеләр түгел, әмма мондагыдай хозурлыкны әле беркайда да очратканыгыз юктыр...

—«Кояшлы күлгә сәфәр» дигәннән бернәрсә дә аңламадым. Кая барабыз соң без, нинди күлгә?—баягы салмыш тавыш кабат ишетелде.

—Без барасы күл Европада иң зурлардан исәпләнә. Ләкин эш анда гына түгел, суы кристаллдай саф, су асты дөньясы аермачык күренеп тора. Ә су асты искиткеч бай монда. Үсемлекләрнең дә, җан ияләренең дә ниндиләре генә юк. Әгәр үзегез төшеп карарга теләсәгез, махсус җайланмалар ярдәмендә су астында да берничә сәгатьлек сәяхәт кылырга мөмкин булачак.

—Туйганчы сыра чүмерәсең дә, исергәч күл төбенә төшеп айнып чыгасың. Во, блин, кайф!—Яшьләрдән торган төркем бу сүзләрдән җиңелчә көлеп куйды. Ләкин ханым аңа игътибар итмәде:

—Күл шулай ук кечкенә оҗмах утрауларына да бай. Якын-тирәдә яшәүчеләрнең кайберләре монда үзләренең бал айларын үткәрә. Сезнең арада да икәүдән-икәү генә калырга теләгән гашыйклар бар икән, берәр тәүлеккә утрауда калу мөмкинлеге булачак. Анда махсус коттеджларыбыз

бар һәм хезмәтчеләребез теләсә нинди теләгегезне үтәргә әзер тора...

Ләис күз чите белән генә күреп торды, апасы сиздермәскә тырышып кына теге егет ягына күз салды. Ләкин егет үзе дә аннан күз алмый иде. Тагын карашлары очрашты да елмаешып куйдылар. Ләис сарычәчкә карады. Аның әтисе инде күзләрен ачкан иде. Дөньяның бернәрсәсе дә үзен кызыксындырмаган бер кыяфәт белән сыра чүмерүче яшьләр төркемен күзәтә. Ә кызы ничектер ачулы сыман. Юк, алай да түгел, монда килеп эләгүенә үкенгән шикелле ул. Әйтерсең, кемдер мәҗбүр итеп җибәргән. Эх, шуның күнелен күтәрерлек берәр нәрсә эшләргә иде!

Ханым һаман сөйли:

—Без барасы утрау Ярымай утравы дип атала. Аңлавыгызча, ул кыйгач ай рәвешендә. Ләкин мин аны җәннәт утравы дип атар идем. Монда сезнең бөтен хыялларыгызны да тормышка ашыру мөмкинлеге булачак. Затлы коттеджлар, рестораннар, сауна-бассейннар, уен заллары турында әйтеп тә тормыйм. Суда йөзәргә, су астына сәфәр кылырга теләүчеләр өчен махсус урыннар бар. Балык яратучылар өчен аеруча кызыклы булачак. Сез монда кармак салып, яки җәтмә тотып йөрмәячәксез. Эре-эре балыклар белән кочаклашып йөзү, шул халәттә кинога, яки фотога төшү мөмкинлегегез булачак. Шулай ук парашюттан суга сикерү, су чаңгыларында йөрү, зур тизлекле су мотоциклында узышу... Бу—күл белән бәйле нәрсәләр. Ә җирдә булырга яратучылар өчен махсус ял паркы бар. Ә анда нәрсә генә юк! Кыскасы, андагы хозурлыкны әйтеп-аңлатып кына бетермәле түгел. Җаныгыз нәрсә тели! Бу кечкенә әкият шәһәрчеге. Сезнең әкият иленә сәяхәт кылырга хыялланганыгыз бар идеме? Теләгегез кабул булу алдында тора дип уйлагыз...

Аның соңгы сүзе Ләиснең күңеленә сеңеп калды да беркая да ычкындырмады. «Теләгегез кабул булу алдында тора дип уйлагыз... Теләгегез кабул булу алдында... Теләгегез... « Егет башкача аны тыңламады. Ул әйтеп-аңлатып булмаслык моңсулык эчендә утырган гүзәлдән күзен ала алмады. Ничек кенә күңелен күтәрергә? Шушы халәтеннән ничек чыгарырга аны? Апасы дөрес әйтә, ул кызлар алдында гел мәмәй булды. Ләкин моңа кадәр шулай бар игътибарын үзенә тартырлык кыз очраганы юк иде дә инде. Кыю булырга кирәк. Янына барырга да нәрсәдер әйтергә. Ә ни әйтәсең: «Болай моңсуланып утырма, әйдә, башыңны күтәр, шатлан, чөнки мин сиңа гашыйк булдым!»—дисеңме. Нәрсә әйтергә була кызлар белән танышыр өчен? Шайтан белсенме аны! Ләкин ни дә булса әйтергә кирәк. Әнә теге егеткә рәхәт ул, аның апасына карап бер елмайды да—әсир итте. Хәзер сүзне нәрсә дип башласа да була. Ә Ләис... Юк инде, гомергә шулай «невезучий» булды. Башын күтәрсен иде шушы сарычәч. Ләискә карасын иде. Елмаешсыннар иде. Юк!

Ләис нинди дер кинәш ишетергә теләгәндәй апасына карады. Тик Ләйсәндә аның кайгысы юк иде, үз егете белән елмаешып торалар. Мин апа дип мактанырга ярата бит әле үзе. Бар син шул кыз янына, апа булсаң, үзең танышып ал. Кызларга кыз кеше белән танышуы күпкә җиңелрәк бит. Үзең таныш та энекәшең янына алып кил. Таныштыр. Юк инде, бу Ләйсәндә дә эләккән эш булмады.

Нинди дә булса ярдәм табарга теләгәндәй, Ләис тирә-ягына күз салды. Әтисе белән әнисе күренми иде әле. Менә шушы мизгелдән файдаланып калырга кирәк тә бит. Тик ни эшли беләсең. Кинәт аның күзе вокзал почмагындагы китап-журналлар сатыла торган киоскка төште. Әйе, шулай эшләргә кирәк. Берәр китап алып, кызга бүләк итәргә. Кызыклы китап

булсын ул, рәхәтләнеп көлеп укырлык булсын. Һәм кыз шуны укый башлар да бөтен моң-зарын онытып көлеп утырыр. Һәм көлгән саен Ләискә елмаеп карап алыр.

Егет киоскка элдерде. Тизрәк чамаларга тырышып китапларга күз салды. Әмма яраткан кызына берсүзсез бүләк итәрдәй нәрсә күренмәде. Детектив ул малайларга гына кызык буладыр. Мәхәббәт турындагы китаплар бар да, тик исемнәре әллә ниндиерәк. Секс буенча кулланмалар. Китап бүләк итәрсең дә, ә кыз аны алмас: «Рәхмәт, мин аны кичә генә укып чыккан идем. Ошамады»,—дияр. Юк инде, таныш булмаган кешегә китап биреп булмый. Кинәт ул катып калды. Чәчәкләр турында журнал! Менә нәрсә кирәк икән ана! Ул янә тирәягына күз салды да чәчәк кибетен күреп, шатлыктан адымнарын көчкә тыеп шунда атлады. Һәм иң матур булып күренгән букетны сайлады. Кыйбат иде, әлбәттә. Булсын! Акча килә дә китә ул, ә гомернең матур мизгеле мәңгегә кала.

Кыз һаман шул халәтендә иде. Таныш түгел егетнең янына килеп басуын ул сизмәде дә. Әтисе битараф караш ташлап алды да үз дөньясына чумды. Аннан махмыр исе килә иде. Менә ни өчен аралары салкын икән боларның. Ләис кыз каршына килеп туктады.

—Гафу итегез...

Кыз башын күтәреп карарга мәҗбүр булды. Ләис чәчәкләрне аның алдына салды да:

—Болар—сезгә!—дип китәргә ашыкты.

—Тик ни өчен?..

Егет бер сүз дә әйтә алмады. Кызның йөзендә гаҗәпләнү һәм рәхмәт хисе иде. Һәм кызыксыну. Ләис сүз әйтә алмады, бары тик елмайды гына. Ихлас йөрәктән.

Ләйсән янына килеп баскач та авызын жыя алмады. Апасы аның кайдадыр югалып торуын да сизмәгән иде бугай. Ләис елмаеп аның егетенә күз атып алды да, апасына эндәште:

—Китер телефоныңны.

Кыз аны ишетмәде. Ишетмәве яхшы булды да. Сарычәч аңа үзе карап тора иде. Елмаеп. Ләкин Ләйсәнне күрүгә йөзеннән аз гына күләгә үткәндәй булды да шундук юкка чыкты. Аларның туганнар икәнен аеру өчен әлләни кирәк түгел иде. Ләис тә елмаеп җавап бирде. Бераздан әтисе сарычәчкә нәрсәдер әйтте. Кыз теләр-теләмәс кенә җавап бирде.

* * *

Айгөл бу сәяхәткә үз теләге белән чыкмаган иде. Картыйсы килеп, эшнең нидәлеген аңлатып бирәч, ризалашырга туры килде. Башкача чара юк, әнисе дә, үги әтисе дә (кем үгирәктер әле) эштә, ә Радик әтисен үзен генә җибәрү куркыныч иде.

—Йөз мең тәңкә акча дип язганнар бит,—диде картыйсы.—Болай гына калдырсаң, булдыксызлык чиге. Бер егерме меңен Радик белән безгә бирсәгез, калганы үзегезгә булыр иде. Балалар хакы дигәндәй... Укырга да кирәселәре бар, азрак ярдәм булыр иде.

Шулай дигәч, берсе дә каршы килеп тормады. Хәер, болай да карышмаслар иде. Ни генә әйтсәң дә, картыйсын барсы да хөрмәт итәләр.

Айгөл дә карышмады. Ул аны болай булыр дип уйламаган иде. Барырлар да акча алырлар да кайтып китәрләр дип күз алдына китергән иде. Ләкин монда килү белән утрауга сәяхәт турында сөйли башладылар. Премияне шунда бирмәкчеләрдер инде. Кыз төпченеп

сорарга унайсызланды, ә әтисенә бернәрсә дә кирәкми иде. Ул үзенен ни өчен килгәнен дә бик анлап бетерми шикелле. Баштарак, озак кына күрми дә торгач, әтисе белән очрашу нindidер якты вакыйгага булыр сыман тоелган иде. Ләкин алай булмады. Ир аны бар дип тә белмәде. Һәм кызның күнелендә ярала гына башлаган якты хис шундук юкка чыкты. Кечкенә чагында анын көн дә исереп кайтып тавыш куптарулары, әнисен кыйнап ташлаулары хәтеренә килде дә әлеге адәм бөтенләй чит булып, дошман булып тоелды. Һәм Айгөл шунын белән тагын ничә көн бергә булырга мәҗбүр иде. Сәяхәткә җыенучылар арасында да танышып дуслашырлык адәм күренмәде. Хәер, кыз эзләмәде дә инде андыйларны, күнелен китек чагында кемгәдер башлап эндәшәсе килеп тормый. Ә үзләре килеп танышу өчен янындагы кешедән һич югы сасы аракы исе килмәскә тиеш. Гомернен үле көннәре башлану алдында иде. Юлга чыккач эчмәскә вәгъдә бирсә дә, әтисе сүзендә тора алмады. Поездга кереп утыру белән сырага ябышты. Кыз башта ана әйбәтләп әйтеп тә, әрләп тә карады, ләкин бер файдасы да тимәде. «Ярый, кызкаем, башкача борылып та карамыйм»,—дип авыз суын корыта да, качып-посып үз эшенә керешә. Шул рәвешле юл гизә торгач, йөз мен акча әлләни зур да булып тоелмый башлады. Үзеннән генә торса, ташлар да кайтып китәр һәм бу гамәле өчен тамчы да үкенмәс иде. Ләкин Айгөл картыйсын үпкәләтүдән курыкты. Әнисе анын сүзләре белән ризалашкандай тоелса да, бер тиенен дә калдырмыйча картыйсына тоттырачак инде анын. Ә картыйсы Айгөлгә бирәчәк, энесенә... Алмасалар үпкәләячәк, рәнҗиячәк. Бирмичә туктамаячак. Ул шунын белән үзен бәхетле итеп, оныклары алдындагы бурычын үтәгән итеп тоячак. Әгәр Айгөл кире борылып кайтса, ин әрнегән кеше картыйсы булачак. Юк, акча җитмәгәннән түгел, ә үзенен хыялын тормышка ашыра алмыйча калганнан. Менә бит ул кайларга барып җитә, уйлап карасан.

Менә шундый күнелсез уйлар эчендә чәбәләнгәндә, кинәт могҗиза булды. Нindidер таныш түгел егет ана чәчәкләр тоттырып китте. Нинди генә гөлләмә әле! Мондыйларны танылган артистларга да ин якын дуслары гына бүләк итәдер. Ә бу бөтенләй таныш түгел кызга. Бер алкаш баласына. Айгөл елап җибәрерлек хәлдә иде. Шуна да чәчәкләрне алгач, берара һушын җыялмыйча утырды ул. Тамагына төер тыгылды. Күз алдыннан теге егетнен ихлас елмаеп торган йөзе китмәде. Аны уйлаудан гына еламыйча калгандыр да инде. Аны уйлаудан җанына җинел иде шул, бөтен газапларны онытып үзеннен дә елмаясын килерлек иде.

Һәм ул тагын бер генә булса да күрергә теләп шул егет торган якка борылды. Егет аны күзәтә иде. Назлы күзләрен алалмыйча. Айгөл дә елмайды. Һәм юлга кузгалганнан алып беренче тапкыр ул үзен яхшы тойды. Монарчы гел кимсенә, шушы исерек адәм янында йөрүенә, шушы исерек адәмнен кызы булуына кыенсына иде. Әле үзенә бүтәнчәрәк карады. Шул халәтендә кемнендер игътибарын яулый алырлык булгач, бик начар түгел инде.

—Кем инде бу егет?—дип сорады әтисе бераздан.

—Ә сина барыбер түгелмени?!

Һәм үзенен мондый тупаслыгы өчен үкенеп куйды. Хәзер анын тупас буласы килми иде.

* * *

Нindidер сәер нәрсә бар, кешегә бер әйтәсен, ике, өч... Мен тапкыр әйтеп тә анламаган кеше, нindidер бер сәер халәт тәэсирендә, мен дә беренче кат әйткәнне анлый. Радик белән дә шулай булды. Кызынын әлеге

тупаслыгы аңа ничектер әйтеп-аңлатып булмас дәрәҗәдә авыр тәэсир итте. Һәм ул үзенең нинди түбәнлеккә төшүен беркемгә дә, хәтта үз баласына да кирәкмәгән артык җанга әйләнүен тойды.

Тирә-ягына күз салды. Монда барсы да парлы иде. Кемдер хатыны, кемдер сөйгән яры, кемдер баласы белән—ансы мөһим түгел. Алар парлы иде. Бер-берсенә карата ярату хисе бар иде алар арасында. Әнә, кечкенә балаларын уртага алып, эскәмиядә утырган икәүгә кара син. Сыра чүмереп, уйнаклашкан төркемгә кара. Һәр урында бер-беренә кирәк булу тойгысы ярылып ята. Әнә тегендәрәк, аталы-уллы икәү. Юньләп сөйләшмиләр дә, икесе ике якка караган, икесе ике нәрсә турында уйлый. Ләкин араларында якынлык барлыгы һәр хәрәкәтләреннән сизелеп тора. Ә Радик... Ул да кызы белән янәшә утыра, лабаса. Кызлар әтисен ныграк ярата диган сүз дә бар әле. Ләкин... Моны ул ничектер яна гына сизде. Бәлки, бөтенләй таныш булмаган теге әрсез егетнең чәчәк тоттырып китүе сәбәп булгандыр. Ләкин моңа кадәр дөньядан ваз кичеп утырган Айгөл, күр, ничек балкып китте. Елмая башлады хәтта. Ләкин ул да, Радик та, Айгөлнең күңелен күтәрә алган булыр иде бит. Кызының иң яраткан кешеләреннән берәү булыр иде ул бүген. Шулай булырга тиеш иде. Әмма барсы да бүтәнчә килеп чыкты. Ярый, үткәне үткән инде. Аны мәңгегә дә кире кайтарып булмас. Ә булганын сакларга кирәк. Айгөлне алай читкә җибәрергә кирәкми. Бердәнбер карап торганы—балалары, ләбаса. Ятратуларын яулый алмасаң да, ихтирам белән карарга мәҗбүр итеп буладыр әле. Соң түгелдер монысына. Соң түгелдер. Бары тик үзүзенә ихтирамың югалмасын.

—Кызым, мин юынып килим әле,—дип урыныннан кузгалды ул.—Адәм төсенә керер вакыт җитте.

Айгөл сәерсенеп кенә карап куйды да берни дә дәшмәде. Ул аны тагын эчәргә китте дип уйлый инде. Каршы килүнең файдасызлыгын аңлап, өнсез генә тора. Ярый.

* * *

Турагентство формасы кигән теге ханым утрауда көткән рәхәтлекләр турында сөйләп бетергән иде бугай инде. Ул хәзер сорауларга җавап бирә иде. Кинәт аның янына бер ир килде дә кәгазь сузды. Пышылдашып кына нәрсәдер сөйләштеләр һәм ханым тавышын көррәк чыгарып туристларга эндәште:

—Кадерле кунаклар! Көтелгән мизгелләр якынлаша. Ләкин сезгә бер яңалык бар. Без утрауга берничә төркемгә бүленеп барачакбыз. Мин хәзер путевкалар номерын әйтеп чыгам. Сез игътибар белән тыңлагыз. Исемлектә булганнар хәзер үк юлга кузгалачак. Ә калганнарның теплоходы чак кына соңрак киләчәк. Шулай итеп, игътибар белән тыңлагыз!

Моңарчы шау-гөр килеп торган төркем мизгел эчендә тынып калды. Исемлектә булганнар сумкаларын алып, кәгазь тотып килгән теге ир артыннан иярде. Калганнар канәгатьсезлек белдереп шаулашып алды. Кемнәрдер тәмәке кабызды, кемнәрдер сыра банкасын ачты.

—Аз гына сабыр булыгыз, дуслар!—дип тынычландырды аларны хатын.—Алар, әлбәттә, алдарак кузгала. Ләкин сезнең теплоход күпкә яхшырак. Сез рәхәтләнеп ял итә алачаксыз. Һәм ул тиздән килеп җитәчәк.

Халык бераз тынычлангандай булды. Кемгәдер синнән дә авыррак икәнен белү рәхәт нәрсә шул. Ул юата да, тынычландыра да, күңелне дә күтәрә. Бераздан туристлар янә шау-гөр килә башладылар.

* * *

*Казан. Татарстан.*

Фатыйма карчык трамвайдан төште дә кечкенә базар аша үтеп тар тыкрыкка борылды. Берәрсе килеп бәйләнмәгәе дигәндәй, алдын-артын карап алды. Усал ниятле кешегә охшаган кем дә күренми иде. Ул тынычланып ары атлады. Шушы тыкрыкны чыккач, унга борыласы да беренче йортның өченче подъездына кереп, жиденче катка күтәреләсе. Адымнарында ярсуы сизелгән кебек тоелмаса да күнеле белән ул ашыга иде. Тизрәк беләсе килә. Ярый, әлләни күп тә калмады инде. Хәдичә карчык өйдә булырга тиеш. Чират кына зур булмасын инде.

Йөз мең, әлбәттә, бәләкәй акча түгел иде. Фатыйма карчыкның андый акчаны тотып кына караганы да юк иде. Мондый мөлкәт өчен ниндидер куркыныч адымга да барырга мөмкиндер.

Ләкин Фатыйма карчык хәлләрнең болай килеп чыгуын көтмәгән иде. Радикны йә килене озата барыр, йә ире белән икәүләп иярерләр диебрәк өмет иткән иде ул. Хәер... Айгөлне жибәрергә булгач та артык карышмады, ансы... Унжиде яшьлек кызлар заманында сугышка да киткән. Ә бу үз атасы белән. Акча алырга. Башта шулай дип тынычланган иде. Ләкин тора-бара күнелен шик кимерергә тотынды. Беркемнең дә сүзен сүз итмәгән ачыган алкашка ияреп йөргәнче, сугышка китүең яхшырактыр сыман тоела башлады. Унжиде яшьлек кыз бала бит ул! Ә Радик—алкаш. Исереп алса, урлашырга да, холыксызланырга да күп сорамый. Ана ышаныч юк. Аракыдан күзе тонган мәлдә ни генә эшләп ташламас, чибәр булып үсеп житкән Айгөлне үз кызым дип тә тормас ул юньсез. Ансы да бик мөмкин. Хәтта алай булмаган очракта да, Айгөл аны эчүдән тыя алмаячак иде. Ә исерекнең беркайда да пачуты юк, акчасын бирмәскә дә, талап алырга да, алдарга да мөмкиннәр. Кайда акча—шунда куркыныч. Унжиде яшьлек оныгын шул куркынычка ташлау дөрес түгел иде.

Һәм Фатыйма карчык тынычлыгын жуйды.

Айгөл баштагы мәлләрдә телефоннан шалтыратып торса да, китүенә икенче көн дигәндә, эндәшми башлады. Кайчан гына шалтыратсаң да, телефон гел: «Абонент находится вне зоны действия» дип тора. Кем белә, бәлки, трубкасын гына югалткандыр, ә бәлки...

Ләкин анын өчен генә борчылмады карчык. Ул инде яшисен яшәгән, дөньяны күп күргән кеше иде. Баштарак дәрманы кузгалса да, бераз тынычлана төшкәч, уйлары үткенләнде һәм шул тиклем зур акчаны бер дә юктан гына тоттырып жибәрүләренә бик ышанасы да килмәде. Ун мең булса, ни әйтер идең әле. Йөз мең бит! Ун тапкыр ун мең дигән сүз! Ул бизнесменнарны төн йокламый чаба, бер тынгылык күрми яши, диләр. Баер өчен шулай кылана бит инде алар. Мөлкәт жыю өчен. Шул кадәрле малны бер алкашка тоттырып жибәрерлек булсалар, алай итмәсләр иде. Хәтта үзләрен күрсәтергә, башкаларны кызыктырырга була шулай кылансалар да Радикны түгел, ә берәр арурак бәндәне сайларлар иде. Үзләренә файда китерә торган кешене. Ә моның... Радикның аның телевизорга төшереп мактанырлык та кыяфәте юк бит. Өч көн эчми торса мескенгә әйләнә, эчеп алса, өч сүзне дә ялгый алмый. Шуңа йөз мең тоттырып жибәрү өчен сантый булырга кирәк.

Бу уйлары дөрес иде аның. Көтмәгәндә килеп төшкән отыш бернинди канунга да туры килми иде. Ләкин ул отыш бар һәм аны барып алырга кирәк—монсы да хак иде. Менә шушы ике дөреслек, бер-берсенә каршы килә торган ике хакыйкать тынгы бирмәде карчыкка.

Әгәр акча отуы дөрес түгел икән, ни өчен чакырып хат язганнар соң?! Эшкуар затларның болай да вакыты тар була. Хәтта әниләренә дә хат

җибәрә алмыйлар. Ә болар язган. Куллары кычытканга күрә генә түгелдер бит инде. Ни өчен соң?

Уйлап-уйлап та фикерләренең очы-очка ялганмагач, карчыкның күнелен шом басты. Шунда ул Хәдичә карчыкны исенә төшерде. Аның белән былтыр базар почмагында танышканнар иде. Фатыйма карчык ул чакта менә бер атнага якын инде кызыл прәннек алып ашарга кызыгып йөри иде. Бәләкәй чакларында ахирәт кызлары белән алып рәхәтләнә торганнар иде. Хәзер дә тәм-том сата торган бүлектә шуны күргәч, авызыннан сулар килде, кыз вакытлары исенә төште. Тик аның акчасы җитми иде. Әлбәттә, бөтен кайгың бер прәннек кенә булса, алыр да идең. Алай гына түгел шул, бүлмә бурычы да хәттин ашкан, башка нәрсәсе дә кирәк. Бер атна буе әлеге урыннан үтеп-сүтеп йөрде ул. Күреп кенә калса да күнеле тынычлангандай тоелды. Ул көнне аның хәер акчасы хәтсез җыелган иде. Шуңа да уйланып торды-торды да тәвәккәлләргә булды. Ярты гына кило, ике генә йөз грамм булса да алыр, тәмләп карар. Базар почмагында үзалдына елмаеп тәм-том кибетенә китеп бара иде. Көтмәгәндә кемнеңдер тавышы ишетелде:

—Акчаңны әрәм итмә. Ул прәннек безнең теш үтмәле түгел.

Фатыйма карчык куркып китте. Уйларын беркемгә дә белдермәгән иде, ләбаса. Колагына гына ишетелгәндер. Үзен шулай тынычландырырга тырышса да тирә-ягына борылып карамыйча булдыра алмады. Аның артында гына диярлек бер карчык атлый иде. Фатыйма карчыкның аптыраулы йөзен күргәч ул гаепле елмаеп куйды.

—Бер дә куркытырга теләмәгән идем, малай. Ачуланма,—диде аннан соң карлыккан тавышын ягымлырак итәргә тырышып.—Акчаңны әрәм иттерәсем генә килмәгән иде...

—Ә син... Син каян белдең?

—Прәннек алырга теләгәнеңнеме?—Карчык тагын тешсез авызы белән елмаеп куйды.—Белмим, малай. Үзем шундый мин. Кайчагында үземә кирәкмәгән нәрсәләрне беләм дә башыма бәла алам, дигәндәй...

—Шулай диген, ә...—Фатыйма карчык ни әйтергә дә белмәде.—Ярый, рәхмәт инде нәрсә булса да.

—Үзеңә рәхмәт. Рәхмәтең өчен. Югыйсә, мина гел үпкәлиләр генә. Борыласың да мени?!. Теләсәң барып кара. Чәйдә йомшартып булса да ашарсың...

—Шушы якта яшисеңме әллә?—диде карчык сүзне бөтенләй икенчегә борып.—Алай дисәң, монарчы бер дә күргәнем булмады.

—Юк, мин бөтенләй икенче җирдә...—Шунда карчык адресын әйтте.—Монда берәүне дәваларга дип килгән идем дә... Хәле аруланмас, ахры.

—Син имчемени?!.

—Шул чамарак инде... Хәдичә минем исемем. Бәлки, ишеткәнең дә бардыр әле...

Фатыйма карчык иңнәрен генә җыерып куйды.

—Алай икән... Мин бик ерак тормыйм, чәйгә кереп чыкмыйсыңмы соң?—диде Фатыйма һәм үзенең ник болай диюенә үкенеп куйды. Прәннек алырга баруына кадәр сизеп торгач, Хәдичә карчык аның: «Кермәсә ярар иде»,—дип кенә әйтүен дә аңлар да рәнҗер төсле тоелды. Ләкин менә болай, ордым-бәрдем генә дә китеп булмый иде. Ни әйтсәң дә, алар хәзер олы кешеләр, бармак белән генә санарлык калып баралар, бер-берсенә хөрмәт күрсәтмичә торырлыклары юк. Һәм фикерен шомартыбрак куйды.—Әллә нинди сыем юк югын да... Сөйләшеп утырсак та күңелле булыр иде...

—Башка вакытта, Фатыйма малай,—диде Хәдичә ягымлы карап.—

Бүген үзеңнең дә тынгылыгың бик булмас төсле... Башка вакытта. Очрашмый тормабыз әле. Әдрисемне беләсең, килеп чык, сөйләшеп утырырбыз.

—Рәхмәт инде чакыруың өчен. Ходай насыйп итсә, бармый да булмас әле.

—Ярый, Фатыйма малай, хуш иттек.

Шул очрашудан соң, башкача күрешкәннәре юк иде. Бер танышы Хәдичә карчыкка дәваланырга баруы турында сөйләп, бик мактаган иде. Тик аның янына үтү кыен, кешедән бушап тормый дигән иде.

Фатыйма карчык шуларны искә төшерде дә адымын тизләтте. Бер генә кешегә булса да алданрак керер. Бик озак та атлыйсы калмады инде. Бары тик өйдә генә булсын. Өйдәдер әле ул, өйдәдер. Күңеленә гел шулай сыман тоела.

Ишек төбенә җиткәндә сулышы капкан иде. Баскыч терсәгенә тотынып беркадәр хәл алып торды. Бары тик тынычланып калгандай булгач кына кыңгырау төймәсенә үрелде.

Бераздан башмаклар шуышканы ишетелде дә ишек ачылып китте.

—Уз, әйдә, Фатыйма малай...

Хәдичә карчык исәнләшеп тә тормады. Башмакларын сөйрәп кенә атлап түргә узды да җәелгән урынына барып ятты.

—Авырып киттем әле соңгы арада. Ятып кына торам. Бер дә юктан да хәлем бетә. Картлык шатлык түгел инде...—дип тезеп китте ул.—Син кыенсынып торма, әнә теге урындыкны якынрак шудырып утыр. Менә шулай. Китер әле монда уң кулыңны. Син бер дә бирешмәгәнсең әле. Былтыр ничек булсаң, әле дә шулай. Чир алып килмәде инде миңа сине. Балаларың турында борчылып килдең инде.

Фатыйма берни дип тә эндәшә алмады. Кулын Хәдичә карчыкның учына салу белән нindiдер сәер халәт кичерде ул. Бөтен гәүдәсе, бөтен күзәнәкләре таралып тибрәнгәндәй булды. Нindiдер җиңеллек биләп алды. Ул хәтта тирә-яктаниләр барлыгын да, хәтта Хәдичә карчыкның үзен дә күрмәде. Бары тик аның тавышын гына ишетте.

—Әй мин менә сиңа тиешенчә ярдәм итә алмамдыр. Бирешебрәк киттем соңгы арада. Элеккедәй барсын да күрә алмыйм, күңел күзләрем томаланды. Мин менә су күрәм. Чиксез-кырыйсыз су. Моның диңгезме-күлме икәнен дә әйтә алмыйм. Әй бәлки, ул бөтенләй су да түгелдер әле. Бәлки, ул галәм, яки вакыт диңгезедер. Һәм шуның уртасында бер түгәрәк күрәм. Бу түгәрәкнең дә ни-нәрсә икәнен әйтә алмыйм. Ләкин балаларың шул түгәрәк эчендә бикләнеп калган. Бу түгәрәк эчендә—синең балаларың. Сиңа аларның кайда булуыннан бигрәк, исәнлекләре мөһим инде. Әлегә исән алар. Исән. Әлегә. Тик алларында бик зур сынау тора. Зур сынау. Алар...

Кинәт Хәдичә карчык туктап калды. Тирән-тирән сулап куйды. Бераздан дәвам итте:

—Менә шул, Фатыйма малай. Күргәннәремнең барсын да әйттем. Авыр нәрсәләр булса, мине гаепләмә. Алдамадым. Артыгын күрә алмыйм. Хәзер хәлем элеккечә түгел. Элек мин күпкә кодрәтлерәк идем. Ә син... Син, Фатыйма... Син бит элек минем сәләтемә ышанмагансың. Шикләнебрәк карагансың. Син шушы көннәрдә генә минем мөмкинлекләрем турында исеңә төшергәнсең икән. Ярый, рәхмәт ышанычың өчен. Рәхмәт. Элегрәк булса, мин сиңа күп нәрсәләр сөйли алган булыр идем. Хәзер хәлем яман. Фатыйма, бик кыен булмаса, кухняга чыгып берәр чәшке су бир әле, малай. Бакыр чәйгүндәгесен агызып бир, ярармы.

Фатыйма карчык, Күрәзәченең йомышларын үтәде дә чыгып китте. Хәдичәнең хәле авыр иде, ул Фатыйма белән үзе хушлашты:

—Гаепләп калма инде, малайкаем... Миңа азрак ятып торырга кирәк... Сөйләшеп утырып булмый инде бүген... Файдам тисә, мин бик шат булырмын, файдам тимәсә, рәнжеп китмә... Хуш булыйк, малайкаем...

Урамга чыккач, Фатыйма карчык монда килүенә үкенеп куйды. Бернинди дә якты хәбәр ишетмәде ич. Авыр уйларын таратырлык бер генә нәрсә дә булмады. Карчыкның буталчык сүзләре күнелгә шом гына өстәде. Аларны ничек теләсәң, шулай боргалап була иде. Әмма Айгөл белән Радикның авыр юлга чыгулары һәм бәлагә юлыгачаклары бәхәссез иде. Хәдичә карчыкның сүзе аермачык булып колагында яңгырады:

—...балаларың шул түгәрәк эчендә бикләнеп калган. Бу түгәрәк эчендә—синең балаларың. Сиңа аларның кайда булуыннан бигрәк, исәнлекләре мөһим инде. Әлегә исән алар. Исән. Әлегә. Тик алларында бик зур сынау тора. Зур сынау.

* * *

*Нева—Кояшлы күл. Россия.*

Алар бөтен уңайлыклары булган теплоход көткәннәр иде. Утрауга илтергә тиешле нәрсә кечкенә катер булып чыкты. Монда юынып, ашап, туйганчы йоклап бару турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Бөтен уңайлык—как эскәмияләр һәм катерның борынындагы кечкенә мәйданчык иде.

—Без шушының белән төне буе барабызмы инде?!—диде яшь бала күтәргән маржа күнеле кайтып.—Ял итәрсез, йокы туйдырырсыз имеш...

Пассажирларның барсы да шулай уйлый иде. Ләкин алар сүзгә кушылырга ашыкмады. Бары тик күзләрендә генә теләктәшлек нуры балкып китте.

—Берәр адәм аягы басмаган утрауга илтеп ташласалар да аптырамам хәзер...—теге хатын иренә борылды.—Карале, Миша... Чынлап та безне шундый утрауга илтеп ташласалар, ә?!

Ире дәшмәде. Сизелер-сизелмәс елмаеп кына куйды.

—Ә анда кыргый татарлар урдасы безгә һөҗүм итсә!..

Бер мизгелгә генә чебен очканы ишетелерлек тынлык урнашты.

Ире аны буш кулы белән муенынннан кочаклап үзенә тартты да маңгаеннан үбеп алды.

—Тынычлан, Анна. Барсы да тәртиптә булыр...

Чынлап та Анна тынычланды. Башкача аның тавышы ишетелмәде.

Ләкин аның сүзе эзсез үтмәде. «Кыргый татар» сүзе ишетелү белән Лена балаларына һәм иренә күз йөгертеп алды да пышылдауга күчте:

—Татарча сөйләшмәгез. Авылдан икәнебез болай да күзгә бәрелеп тора. Өстәвенә «Кыргый» дип тә көлүләрен теләмим.

—Ә нигә...

Хәмит каршы килмәкче булган иде. Хатыны шундук авызын япты:

—Тискәреләнмә инде, бәгърем. Үзебез бер хәл, балалар бар бит.

Хәмит елмаеп куйды.

—Ярый, синенчә булсын...

—Исемнәребезне дә русчалатып кына әйтербез.

—Синең болай да урысныкы бит инде. Елена. Ә минә без нишләргә тиеш? Урыс телендә «Х»—га башланган исем юк. Сүгенү сүзеннән башка.

—Әти, ә сине Митя диярбез.—Ләйсәннең күнеле күтәренке иде.—Туры килә бит—Ха Мит...

—Юк белән баш катырмагыз әле...

Аннаның сүзе Хәлилне дә уйга салды. Күптин күп үзгәрешләр булса да Рәсәй һаман шул икән әле. Татарга булган караш үзгәрмәгән. Шовинизм дигән нәрсә күсәк күтәреп тукмамаса да менә шулай астыртын гына чеметеп тора. Ярый, болар арасында татар булып күкрәк сугып йөреп булмас. Роберт, барыбер, русча белми. Инглизчә генә сөйләшерләр. Нәрсә генә дисән дә, американнар ич әле алар. Ә американнарга русиялеләрнен карашы бөтенләй башка. Һәм ул малаена борылды.

—Роберт, бирерәк кил әле. Сиңа әйтер сүзем бар...

Катер ярдан кузгалып китте.

Елга вокзалында каршы алып, озатып җибәрүче ханымның бер сүзе дә дөрескә чыкмады. Беренчедән, аларны бөтен унайлыклары булган теплоход көтмәде, икенчедән әлеге «иске тагарак» Нева ярларының матурлыгын карап барырга ирек бирмәде, ярдан кузгалып беркадәр ара үтү белән, жан-фәрманга алга омтылды һәм зур суга кереп, офыкның дүрт читендә дә тик су гына күренгәч тә, тизлеген киметмәде. Күл эченә кергәч кайда барганыңны аңларлык түгел иде. Пассажирларның кайберсе хәтта катер йөртүчеләр үзләре юлны белә микән, адашмаслар микән, дигәнрәк шик белән дә баш ватты. Тик башкаларның көлүеннән куркып, әлеге сүзләрен кычкырып әйтергә курыктылар. Хәер, сәбәбе ул гына да түгел иде. Әле алар беркем белән дә ныклап аралашмыйча, берберсен читтән генә күзәтәләр иде. Юл озын, кирәк булса, танышырга өлгерерләр. Ә әлегә...

Бу өлкәннәргә кагыла иде.

Күнелләре мәхәббәткә бөреләнгән яшүсмерләр, әлбәттә, алай уйламады. Һәм өлешләренә шушы «иске сал» эләгүенә алар сөенделәр генә. Беренчедән, монда каюталар юк иде. Һәркайсы үз бүлмәсенә кереп бикләнмәгәч, бер-берсен күрү, күзләр белән генә булса да аралашу мөмкинлеге бар. Икенчедән, катер бик тиз бара һәм караңгы төшкәнче, бәлки, җәннәт утравына килеп тә житәр. Ә анда инде күзең төшкән кеше белән туйганчы аралашырлык аулаграк урыннар да табылыр.

Утрауның матурлыгы күреп туймаслык диделәр бит.

Елга буйлап барганда катер бик кызу җилдергәндәй тоелса да зур суга кергәч, тизлек сизелмәде. Моторның ялкыткыч бертөрлелек белән гүләве астында вакыт бик акрын үтте. Кайчагында алар бу халәттән мәңгегә дә чыга алмаслардыр, гомерлеккә шушы суда дулкын яруга хөкем ителгәннәрдер сыман тоелды. Юлга кузгалганда нииндидер күтәренкелек белән балкыган йөзләр акрынлап сүрәнләнде.

Хәлил телефонын алды. Нью-Йорк урамында очрап кунакка чакырган кешегә шалтыратырга иде исәбе. Ләкин антенналар шкаласында бер шакмак та күренмәде. Шулай да ул аның номерын жыеп карады. Файдасыз. Ахырда, трубканы кесәсенә кире салып куйды да тәрәзәгә капланды.

Хәмит гаиләсенә күз салды. Хатыны башын аның иңенә терәп күзләрен йомган иде. Ләйсән белән Ләис икесе ике якка карап тынып калган. Бар да нидер көтә. Ул балаларына нәрсәдер әйтмәкче булды да, әйтмәде.

Кинәт ул үзләре ягына кемнендер карап торганын тойгандай булды. Шунда борылды. Эскәмиядәге кыз аларга бөтенләй карамый иде. Ә янындагы адәм башын күкрәгенә салындырып йокы симертә. Гомумән, салонда уяу пассажирлар калмаган иде бугай. Хәер, алай түгел. Әнә бит баягы хатын иренә нәрсәдер сөйләп бара. Аның кыяфәтендә арыганлык та, күңел кайту да сизелми. Алар янындагы ир белән хатын да пышылдашып кына нәрсәдер турында гәпләшә.

Бераздан Анна бөтенесен дә уятырлык көр тавыш белән:

—Әфәнделәр һәм ханымнар!—диде. Пассажирлар башын күтәреп

шул якка карагач, елмаеп куйды.—Сез ялга барасызмы, әллә үлемгәме?! Бернинди дә күтәренкелек сизмим. Бәлки, юлны кыскартыр өчен берәрсе берәрнинди кызыклы нәрсә сөйләр?!.

Әлбәттә, һич югы шулай иткәндә тамчы да начар булмас иде. Әмма тынларга әзерләр булса да сөйләргә җыенучылар күренмәде.

—Үзегез сөйләсәгез генә инде...—диде кемдер авыз эченнән генә.—Без ни ул...

—Безнең арабызда бөтен җир шарын аркылыга-буйга урап чыккан мәшһүр сәяхәтче Андрей Николаевич бара,—дип күршесендәге иргә борылды Анна.—Бәлки, ул күргән-белгәннәре белән уртаклашырга теләр?

—Белмим, нәрсә турында гына сөйлим микән...—дип иннәрен сикертте Андрей Николаевич.—Күп җирләрдә йөрелде инде.

—Һиндстан турында сөйләгез!—дип кычкырды Ләйсән, мәхәббәт темасын өмет итеп.

—Әйе, иң куркыныч вакыйганы!—дип элеп алды Анна.—Менә болай йоклап барырга түгел, ә күзне йомарга да куркырлык булсын.

Пассажирларның берише елмаеп, берише кул чабып куйды. Андрей Николаевич кыенсынып кына уртага чыгып басты да тынып калды. Бу уртачадан калкурак буйлы, ныклы гәүдәле ир иде. Күрер күзгә утыз биш яшьләр тирәсендә генә булса да кыяфәтендәге ниндидер сыйфат олпат кеше итеп карарга мәҗбүр итә. Бәлки, дөнья гизеп, күпне күргән, күпне кичергән затларның барсы да шулайдыр.

—Куркыныч нәрсә дисез инде...—диде ул тамак кыра биреп.—Куркыныч нәрсәләрне күп күрдем мин. Әмма шуларның берсе мәңгегә дә онытылмаслык булып күңелемә кереп калды. Мина Непалдагы Кали алиһә храмында булырга туры килде. Анда керү бары тик индусларга гына рөхсәт ителә, ә башкаларга бөтенләй мөмкин түгел диярлек. Аннан соң, аяк киемнәренне салып, тездән кан елгасы буйлап атларга кирәк. Иртәдән кичкә кадәр монда чират өзелми. Килүчеләр үзләре белән корбан китерә. Әйтик, кәҗә алып киләсең икән, аны ишек төбендә үк су белән коендырасың һәм мәхлукның ризалыгын сорыйсың, бары тик ул ризалык белдереп кагынса гына дин әһеленә тоттырасың, ә ул аны шунда ук чала да каны белән храм стеналарын юа. Киселгән башын шундагы шүрлеккә утыртып куялар. Храмнан ерак түгел изге ут янында китерелгән корбанның итен ашарга мөмкин. Монда көненә әллә ничәшәр мең хайван чалына. Һавада кан пары, кан һәм үлем исе. Мин анда, урындагы гадәт буенча, ап-ак киемнән барган идем. Кинәт артымда нәрсәдер чыжлап узды, ул да булмый өстемне нәрсәдер юешләп үтте—кемнеңдер корбанын суйдылар. Урындагы халык мондый нәрсәләргә тыныч карый. Барысы да кан эчендә йөри, стеналар канга каткан, храм үзе дә ерактанрак караганда кан парына күмелеп утыра. Стенада куерган кан кичкә кадәр уч яссылыгы булып ката. Кич житкәч аны су белән юып алалар. Кали алиһә культына меңәрчә еллар. Элегрәк бу храмда кешеләрне дә корбанга китергәннәр. Ниндидер житди эштә зур уңышка ирешергә телисең икән, үгез белән генә алдырып булмый, монда инде зуррак корбан кирәк. Корбанга адәм затын китерү алиһәдән җаның теләгәнне сорарга мөмкинлек бирә. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Һиндстанда һәм Непалда кеше корбан итүләр катгый тыела.

Непалда мин житәрлек озак яшәдем. Үзем дә буддизм һәм индуизм нигезләре белән таныш булгач, акрынлап ышанычлы кешеләрнең берсенә әверелдем. Сүз арасында урындагы бер егеткә мин алиһәгә «житди корбан» китерү күренешендә катнашырга теләвемне белдердем. Ул башта куркуга калды. Чит ил кешесенең анда катнашуы башка сыймаслык хәл.

Әгәр сизеп калсалар, мине дә, аны да юк итәчәкләр иде. Ләкин мин өч мең доллар турында сүз кузгаткач, ул уйлап карарга вәгъдә бирде. Бу алар өчен чиксез зур акча һәм аның хакына гомеренне куркыныч астына куярга да мөмкин. Бер атна үтте, ике, өч... Мин инде бу сөйләшү турында онытa да башлаган идем, көннәрнең берендә әлеге егет килде дә үзе хәбәр салды:

—Синең теләгенне үтәргә мөмкинлек бар. Әгәр акчанны күрсәтсәң, әзерләнә башлыйбыз.

Акчаны ул бармакларын төкерекли-төкерекли җентекләп санады да кире бирде. Мин ничек булырын күз алдына да китермәгән идем. Зоопаркка, яки берәр театрга барган шикелле, хәзер барырбыз да карарбыз төсле тоелган иде. Егет миңа мәктәп баласына карагандай итеп карап куйды да аңлатырга тотынды:

—Синең йөзенне үзгәртергә кирәк. Дүрт көн чамасы кырынмыйча торсаң, сакал-мыек басар да каралык өстәр. Ә чалма белән чапанны, гомумән, кием-салымны үзем алып килермен.

Бер атна чамасы вакыттан соң, килешенгән урында мине искедән иске машина көтеп тора иде инде. Егет хәтта акчаны кабаттан чүтлап та тормады, калтыранган куллары белән кесәсенә яшерде. Без таулар арасына барып җиткәч кенә туктадык. Минем кыяфәттән ул канәгать калды. Кырынмаган, юынмаган, кара тузанга баткан, өстәвенә беркадәр ябыккан да. Ярты сәгатьләп барганнан соң без ярымҗимерек храмга җиттек. Егет шунда пышылдап кына әйтеп куйды:

—Әгәр тотылсак, мине үтерәчәкләр.

Мин бу эшкә ник тотынуым өчен үкенә идем инде. Храм эче ярымкараңгы иде. Бары тик бүлмә уртасында гына яктырак, анда торымбашлар яна, җимерек түшәмнән яктылык төшә. Калганын юньләп хәтерләмим. Нindидер сәер халәттә идем. Гипнозланган сыман. Якында гына кемдер бала күтәреп тора иде. Нindидер чүпрәккә төрелгән шәрә кыз. Ул тигез сулап йоклый, куллары салынып төшкән, чәчләре җилкәсенә җыеп таралган иде. Кызга алты яшь тә, уникене дә бирергә мөмкин иде. Кали алиһәгә корбан китерү өчен кызлар кулайрак санала. Аларны кечкенә чакларыннан ук сатып алалар да билгеле бер яшькә кадәр үстерәләр. Үндүрткә җиткермиләр, куркыныч...

Мин икегә бүленгәндәй булдым. Монарчы бер генә аурупалы да күрмәгән нәрсәне күрәсе килә иде, әлбәттә. Шул ук вакытта мин моның үтереш икәнен яхшы аңлыйм һәм әлеге җинаятькә каршы төшәсем килә иде. Ләкин бармак очын селкетерлек тә көчем юк сыман иде. Йола ни рәвешле үткәнен ачык хәтерли алмыйм. Башта нindидер җырулар, дога укулар булды, аннан соң кайдадыр якында бик матур хәнҗәр ялтырап китте. Кызның бугазын шул тиклем пөхтә итеп кистеләр ки, бернинди тартышу-чәбәләнү дә, кычкыру да булмады. Каны да теләсә кайда чәчрәмәде, махсус касәгә генә акты.

Көмеш белән йөгертелгән бу касә кечкенә баланың баш сөягеннән ясалган иде. Бераздан кызның өзелгән башын, югарыга күтәреп, читкә алып киттеләр. Мөлдерәмә тулы касәне түгәрәк буйлап җибәрделәр. Кемнендер дога укыгандагы кебек тавышы ишетелде. Теләк телиләр иде булса кирәк. Бераздан касә миңа да җитте. Мин, әлбәттә, эчмәдем. Иренемне касә читенә тидереп, йоткан хәрәкәт ясадым да ары җибәрдем. Һәм бернинди теләк тә теләмәдем. Миндә бер генә теләк котыра иде—моннан тизрәк чыгып качу һәм кабат беркайчан да, беркайчан да килмәү теләге.

Касә түгәрәк буйлап әйләнеп чыкканнан соң, кызның гәүдәсен алып

киттеләр. Мин инде косар чиктә идем. Аякларымны киереп бастым, ә алар калтырыйлар иде. Шунда юлдашым миңа кагылды. Китәргә вакыт иде.

Пассажирлар дөньяларын онытып тынлыйлар иде. Сөйләүченең теле бик үткен булмаса да вакыйгалар кот очарлык бар иде. Шуңа да алар һәр нәрсәне күз алдыннан үткәреп, үзләре күргән шикелле итеп тыңладылар. Һәм Андрей Николаевич тынып калгач та нииндидер хәрәкәт ясап, тынлыкны бозарга җөрьәт итмәделәр.

—Бетте,—дип елмайды Андрей Николаевич, мондый чиркангыч нәрсәне сөйләүдән котылуына шатлангандай.—Бетте.

—Берәр күңеллерәк нәрсә турында сөйләсәң булмый идеме инде,—дип шелтәләп алды хатыны.—Болай да билгесезлек эчендә йөзгән кешеләрнең йөрәген кузгатмасаң.

—Шулай шул, карчык...—дип елмайды сәяхәтче.—Гафу итәсез инде...

—Ә Кали алиһә кем була ул?—Бу Радик иде. Ул әле махмырдан чыгып житмәгән, аңа болай да куркыныч. Ләкин әлеге сәяхәтчегә ул рәхмәт укыды. Андрей Николаевич пассажирлар арасында курку атмосферасы тудырып, аны, Радикны, ялгызлыктан коткарды ич. Әгәр Николаевич булмаса, ул берьялгызы гына курку эчендә чәбәләнергә мәҗбүр булыр иде. Ә хәзер барысы да курка, шулай булгач, барысы да бертигез. Радикның әлеге халәттән чыгасы килми иде, ул куркынычлар темасын дәвам итәргә теләде.

—Кали алиһәме?!—Андрей Николаевич куркыныч нәрсәләр сөйләргә теләми иде инде. Ләкин кыскача гына аңлатып бирерлек сүзләр дә таба алмады.—Кали алиһә... Ягез, кем аңлатып бирә?!

Лена алгарак омтылып куйды:

—Хәзер...—Ул рөхсәт сорагандай, Хәмиткә күз ташлады.—Миңа әле күптән түгел генә индуизм белән кызыксынырга туры килде. Белүегезчә, һинд мифологиясендә борынгы дәвер, явызлык белән изгелек көрәше сурәтләнә. Бу алышу бик тә аяусыз булган һәм һәр ике яктан да меңләгән корбаннар таләп иткән. Бу хакта «Деви Махатмья» китабы җентекләп сөйли. Шушы ук трактатта алиһә хакында да әйтелә. Дөньядагы барлык явызлыкны юк итүче алиһәнең исеме берәү генә түгел. Шакти, Лолита, Деви... Хәтта «Аллаһ» дигән сүз дә аның бер исемен аңлата. Ходайның кодрәте чиксез һәм ул явызлык белән дә, изгелек белән дә идарә итә ала. Аның нәфрәте коточкыч көчкә ия. Моны күз алдына китерү өчен «Коръән»дәге Кыямәт көнен, яки «Библия»дәге заман ахры күренешен исегезгә төшерү дә җитә. Шулай итеп, алиһәгә бирелгән исемнәрнең күплеге ачыклана төшә. Аны Нәфрәт чыганагы, Галәм ләгънәте дип әйтү дә, шул ук вакытта Шатлык дингезе, Бәхет бирүче дип әйтү дә дөрес булып чыга... Кали—Ходайдагы җимергеч көчнең бер чагылышын аңлата. Кызганычка каршы, динне дә үз мәнфәгатьләре өчен файдаланырга тырышучы кешеләр бар. Кали культының барлыкка килүенә шундыйлар сәбәпче. Авыл халкының наданлыгыннан файдаланып, аларны алиһә хөрмәтенә адәми заттан корбан китерүгә кадәр этәргәннәр. Әлбәттә, дин әһелләренең Ходай хакына үтерүне акларга тырышуы яңалык түгел. Мөселманнарның шаһитларын, христианнарның тәре йөртүчеләрен генә искә алу да җитә. Ләкин Кали культы вәкилләрен бары тик сатанистлар белән генә чагыштырырга мөмкин.

Хәмит хатынына карап мыек астыннан гына елмаеп куйды. Укытучы. Чир китә, гадәт китми дигәннәре шушыдыр инде. Һәркайда үзенең өстенлеген исбатларга күнеккән хатын канәгать иде. «Үзебез авылдан гына булсак та менә нинди нәрсәләрне беләбез әле без!»—дигәнрәк

кыяфәт белән басып тора иде ул. Бәлки, Лена дөрес сөйләгәндер. Хәмит ул кадәресен белми. Ләкин хатыны ана аз гына кызганыч булып тоелды. Үзен башкалардан өстенрәк итеп күрсәтергә тырышканда, ул гел шулай тоела иде.

—Рәхмәт!—диде Радик, әлеге теманың туктамавына күнеле булып.—Ләкин нигә без гел чит илләр турында сөйлибез әле, шайтан алгыры! Бу төбәктә дә җан өшеткеч хәлләр еш булып тора бит...

Андрей Николаевич аңа рәхмәтле караш ташлап алды. Коточкыч вакыйгалар турында сөйләшү аның өчен дә кирәк иде.

—Ә сезнен «Әҗәл утравы» турында ишеткәнегез бармы?—диде ул үзалдына елмая биреп.—Безгә турагентство хезмәткәре «Мәхәббәт утравы» турында да, «Оҗмах утравы» хакында да күп сөйләде, әлбәттә. Ләкин шушы күлдә, кайдадыр Әҗәл утравы дигән урын да бар бит...

—Анда, мөгаен, җен-пәриләр оясыдыр инде...

Бу тагын Радик иде. Әтисенең күнелсез күренешләрдән тәм табып утыруын Айгөл өнәмәде. Акрын гына урыныннан торды да палубага чыгып китте. Радик нидер әйтергә дип укталып куйды, әмма эндәшмәде.

—Кызыклы утрау ул. Анда адәм баласына яшәү өчен нәрсә кирәк, барсы да бар. Ризык та, куыш та... Хәтта алтын-көмешләр дә тулып ята. Ләкин утраудан бер нәрсә дә алып чыгарга ярамый икән. Нәрсәдер алып кайтырга теләгән кешеләр һәрвакыт фаҗигагә юлыга...

Ләис инде күнеле белән бөтенләй пассажирлар арасында түгел иде. Ул урыныннан кузгалды да акрын гына ишеккә юнәлде. Туганының кайда киткәнен чамалаган Ләйсән ялварулы карашын Робертка төбәде. Күзләре очрашкач, ул да Ләис артыннан иярде. Роберт русча бөтенләй диярлек аңламый иде. Ул да әтисенә карап алды да, тегесе ризалык биреп баш каккач, ишеккә атлады.

—Сезнең анда да булганыгыз бармы?—дип сорады Анна, елмая биребрәк. Ул йоклап барган пассажирларны кузгата алуына шат иде бугай. Ләкин Михаил гына әлеге сөйләшүләрне бик өнәп бетермәгәндәй тоела иде.

—Юк, минем анда булганым юк. Булырга да язмасын. Чөнки соңгы елларда ул утраудагы хәлләр бигрәк куркынычка әйләнгән дип сөйлиләр. Монда ниндидер сәбәп белән килеп эләккән кешеләр кире кайта алмый, алар ничектер кинәт юкка чыгалар икән... Элек алай булмаган. Хәзер исә... Мина кунакханәдә берәү сөйләп торган иде. Күл буйлап сәяхәткә чыккан бер гаилә, катерлары ватылып шушы утрауга эләгә. Яннарында балалары да була аларның. Биш бала. Һәм һәр кич саен аларның бер баласы юкка чыгып тора. Биш көн эчендә боларның бер баласы да калмый. Һәм ничек кенә эзләмәсеннәр, бернәрсә дә таба алмыйлар. Ә балалары югалып беткәч, кинәт катерлары төзәлә дә ниндидер көч боларны шунда куып кертә, кире өйләренә кайтырга мәҗбүр итә...

—Йә, Ходай!..

—Әгәр без дә шунда эләксәк?!.

Андрей Николаевич пассажирларның котын ала алуына шат иде бугай. Ул бик тәкәббер кыяфәт белән иннәрен генә сикертеп куйды.

—Кем белә?!. Барсы да Ходай кулында...

Анна инде үзе башлаган уенның шулай куркыныч тонда тәмамлануына үкенә иде шикелле. Ул таяныч эзләгәндәй Михаилга карады.

—Без бит анда эләкмәячәкбез, Михаил? Эләкмәячәкбез бит?

—Юк, кадерлем...—Михаил елмаерга тырышты, ләкин авыз еру гына килеп чыкты. Ахырда ул үз йөзен күрсәтмәс өчен хатынын куенына кысарга мәҗбүр булды.—Юк, без андый хәлгә юлыкмабыз.

Ләкин Анна тынычланмады.

—Син үзгәрден, Миша. Син дулкынланасың. Мин беләм, син нәрсәдер сизенәсең... Син һәрвакыт алдан сизәсең...

Михаил карышып нидер әйтмәкче иде, тик тиешле сүзләр табалмады. Хатыны хаклы иде. Михаилның күңеле тыныч түгел, җанын нәрсәдер кимерә кебек иде. Ләкин моны хатынына белдерергә ярамый, ниндидер җылы сүз табып, аны барсы да яхшы икәненә ышандырырга кирәк.

—Юк, кадерлем... Бары тик гөнаһ сүз сөйләшкәнегезгә генә эчем поша. Ходай андый сүзләр сөйләшергә кушмый бит...

Аларның сүзен барсы да ишетте һәм барсының да күңеленә шом оялады. Лена Хәмиткә карап куйды:

—Балаларга күз-колак булырга кирәк.

—Алар бит яшьләр...—дип каршы төште ир.—Үз тиңнәре белән, үзләренә кызыклы темаларга сөйләшсеннәр. Әллә син аларның шушында әллә нәрсәләр ишетеп торуын теләр идеңме?!

Хәмит, әлбәттә, дулкынлана иде. Тыныч чагында ул бу тиклем озын сөйләми. Лена дәшмәде. Хәзер ул ире белән килешергә тиеш иде. Шулай яхшырак була.

Хәлил ишеккә күз салды, ләкин тышка чыгып китәргә кыенсыныбрак калды. Бары тик балаларның дүртәүләшеп гәпләшеп торганын тәрәзәдән күреп алгач кына тынычлангандай булды.

Радик та күзләрен кая куярга белми азапланды. Ул курка иде. Нәрсәдән икәнен дә белми хәтта. Махмыры интектергәндә гел шулай була. Әле шуның өстенә ниндидер куркыныч һава бар иде. Сулыш алганда да салкынлык булып тын юлларына урала ул, бала йоннарын кабарырга мәҗбүр итә. Бая теманы тирәнгәрәк җибәрергә тырышып дөрес эшләмәде. Үзе генә курыкса, бу халәте озакка барачак түгел иде. Хәзер барсы да куркуга калды һәм дөнья чынлап та куркыныч сыман тоела башлады.

Андрей Николаевич белән аның хатыны гына тыныч иде бугай. Һәрхәлдә, аларның йөзендә башкаларныкындагы шикелле шүрләү галәмәте сизелми иде. Ләкин куркыныч белән тулы бүлмәдә тыныч кала алу үзе үк шомлы сыман тоела иде.

Пассажирлар бер мәлгә тынып калды.

Мотор гүләгәне һәм тыштагы яшьләрнең катер тавышын күмәргә тырышып нәрсәдер сөйләгәне генә ишетелде.

—Сәлам!

Айгөл колак төбендә генә яңгыраган тавыштан дертләп китте дә артында кем торганын күреп елмаеп җибәрде:

—Рәхмәт сиңа...

—Леон...—Ләис үз сүзеннән үзе елмаеп җибәрде.—Леон мин.

—Рәхмәт сиңа, Леон. Ә минем исемем Ай... Аида була...

Кыз назлы елмаеп кулын сузды. Ләис кыздан күз алмыйча гына иелде дә үбеп алды.

—Ниһаять!—диде ул, җиңел сулап.

—Нәрсә «ниһаять»?

—Мин инде синең белән танышудан өмет өзә язган идем. Һәм менә, ниһаять...

—Мин дә бик шат,—дип елмайды кыз.

—Кара әле боларны! Кияү белән кәләш!—Елмаеп әйтелгән бу сүзләрне икесе дә шатланып кабул итте. Ә Ләйсән аларның янына ук килеп икесенә дә сокланулы караш ташлады.—Нинди бәхетле парлар! Хәерле сәгатьтә!

Айгөл-Аида аз гына уңайсызлангандай тоелды.

—Ә мин Люда,—диде кыз, һәм Ләискә күрсәтеп өстәп куйды.—Менә бу иптәшнең бертуган апасы.

—Бу иптәшнең исеме бар. Картлыгың белән хәтерләмәсәң, исеңә төшерәм, мин синең Леон абыең булам. Ә бу—Аида...

Ул арада ишектән Робертның башы күренде. Ләис-Леон апасына карап күз кысты. Айгөл-Аида аңлап елмайды. Люда-Ләйсән егеткә карап кул болгады:

—Кил монда.

Роберт елмаеп алар ягына атлады. Килеп житү белән кызларга елмаеп карады да, Леонга кул сузды:

—How do you do! My name is Robert.

Бер мәлгә барсы да аптырабрак калды.

—Леон...—диде егет тагы нәрсә әйтергә белмичәрәк,—Ле-он...

—Ә мин—Люда,—дип кул сузды Ләйсән.—Танышуга шатмын.

—Аида...

—Excuse me, but I do not talk on russian

—This bad,—дип елмайды Ләйсән.—My english simply terribly...[3]

—You are an american?—дип елмайды Ләис.—Never saw the alive American! Dead too...[4]

—You all speak in english?

—Yes! Signifies, all shall talk in english...

Дөнья кызык, әти-әниләре яныннан китү белән бөтенесе дә руска әйләнде. Ә Робертны күргәч, барсы да инглизчәгә күчте. Һәм алар танышуны дәвам иттеләр...

Коточкыч вакыйгалар хакындагы хикәяттән куркып тынып калган өлкәннәр дә бераздан һушларына килде. Дөресрәге, аларны бу халәттән Радик алып чыкты. Арада иң нык курыкканы ул иде. Ничектер авыр иде аңа. Нindидер бәлагә юлыгыр да һәлак булыр, ә аның дөньяда кайчандыр яшәгәнлеге хакында бернинди дә хәбәр-хәтер дә калмас сыман иде. Ә аның бу дөньядан бер эзсез үк китәсе килми иде. Шуңамы, кинәт торып басты да барсы да ишетерлек итеп:

—Минем исемем—Роман!—диде. Юк, ул кыланмады да, алдашмады да. Ул бу дөньяда әнисе өчен генә Радик иде. Ә калганнар инде унсигез яшеннән бирле Роман дип йөртә. Ул үзе дә моңа күнеккән иде.

Бер мизгелгә тынлык урнашты. Һәм бераздан берәм-берәм исемнәрен атарга керештеләр:

—Минем исемем—Елена. Ә ирем—Николай. Улыбыз—Леон, кызыбыз—Люда.

—Минем исемем—Хенк. Нью-Йорктан. Улым—Роберт. Инглизчә генә сөйләшә...

—Андрей. Хатыным—Ольга.

Кинәт бөтен дөньяны яңгыратып тыштан тавыш ишетелде. Бераздан ишек ачылып китте һәм анда яшьләр күренде. Алар шатланышып кычкыралар иде:

—The Land! The Island!

Өлкәннәр берни аңламыйча аптырап калды. Бары тик Хәлил-Хенк кына елмаеп тәрәзәгә бакты һәм башкаларга тәржемә итте:

—Жир! Утрау!

Барсы да бер булып тышка атылып чыкты.

—Жир!—дип кабатладылар барсы да бер тавыштан.—Утрау!

Михаил гына бернәрсә дә дәшмәде. Баштарак кечкенә бер нокта булып күренгән утрау котылгысыз тизлек белән якынлаша иде. Хәзер инде андагы таулар да, тау итәкләрендә үскән агачлар да аермачык күренә. Утрау әлләни зур түгел иде. Ләкин анда бернинди дә ял итү комплекслары да, парклар

[3] Начар. Мин инглизчә бик яхшы белмим (инглизчә)

[4] Сез Американданмы? Беркайчан да тере американлы күргәнем юк иде. Үлесен дә..

да, затлы коттеджлар да юк, бары тик ярдан ерак түгел урында бердәнбер ике катлы йорт кына бөршәеп утыра. Моңа әле беркем дә игътибар итмәде бугай, әмма Михаил барсын да искә алып бара һәм аның күңеле тыныч түгел иде.

Ул елга вокзалындагы мөлаем ханымның сүзләрен искә төшерде:

—Без барасы утрау Ярымай утравы дип атала. Аңлавыгызча, ул кыйгач ай рәвешендә. Ләкин мин аны җәннәт утравы дип атар идем. Монда сезнең бөтен хыялларыгызны да тормышка ашыру мөмкинлеге булачак. Затлы коттеджлар, рестораннар, сауна-бассейннар, уен заллары турында әйтеп тә тормыйм... Сезнең әкият иленә сәяхәт кылырга хыялланганыгыз бар идеме? Теләгегез кабул булу алдында тора дип уйлагыз...

Бер мизгелгә генә барсы да аермачык булып күз алдына басты.

Әмма бу вәгъдә ителгән утрау түгел иде. Бу бөтенләй башка утрау иде. Хәер...

Ник шулай шомлы уйларга бирелә әле ул?! Теге ханым бит кечкенә утраулар турында да сөйләгән иде. Бәлки, бу шуларның берсе генәдер?! Әлбәттә, шулай. Һәм ул озатучы ханымны кабат күз алдына китерде:

—Күл шулай ук кечкенә оҗмах утрауларына да бай. Якын-тирәдә яшәүчеләрнең кайберләре монда үзләренең бал айларын үткәрә. Сезнең арада да икәүдән-икәү генә калырга теләгән гашыйклар бар икән, берәр тәүлеккә утрауда калу мөмкинлеге булачак. Анда махсус коттеджларыбыз бар һәм хезмәтчеләребез теләсә нинди теләгегезне үтәргә әзер тора...

Бу ханымны әледән-әле исенә төшерүе, бәлки, аның таныш кебек тоелуыннан гынадыр. Беренче күрүдә үк ул кемнедер хәтерләткән сыман тоелды бит...

Михаил янындагыларга күз салды.

Бөтенесе дә алга карап илаһи бер халәттә катып калган иде. Утрау, әлбәттә, матур иде. Әллә кайдан серәеп торган бердәнбер йортны исәпкә алмаганда, монда адәм кулы кагылган нәрсәләр сирәктер кебек күренә һәм шуның белән ул җир шарының яшь чагын хәтерләтә сыман иде. Утрау үзе дә ерактан караганда ярымтүгәрәк рәвешендә, әйтерсең җир шары суга баткан да аның иң матур бер өлеше генә күренеп калган. Зур да түгел, түбәтәй хәтле генә. Шушы кечкенә урынның чиксез зур матурлыгы сине телсез итә, күңелеңне әллә нинди хисләр белән бизи. Хәтта үзеңне җирдә дә итеп тоймыйсың, ә галәмнән галәмгә күчеп яңа планеталар ачып йөрүчедәй күренәсең. Үзең ачкан матурлыктан үзең сафланып каласың. Моны аңлап та, аңлатып та булмый, бары тик тоеп, кичереп кенә буладыр. Син бөтенләй яңа үлчәмгә күчәсең...

Тик Михаил тулысынча тынычлана алмады.

Әлбәттә! Үзеңне алданган дип хис итәргә, күңелеңне төшерергә бер генә сәбәп тә юк иде. Барсы да туры килә. Озатучы ханым да иртәгә иртән генә билгеләнгән урында буласыз диде ич. Ә бу утрау бары тик юлда очраган вак утрауларның берсе генә. Шулай булырга тиеш. Һәм тамчы да борчылырга, шомланырга ярамый.

Ләкин аның күңеле шомнан арынмады. Барсы да мантыйк буенча булса да, монда җанга тынгылык бирми торган нидер бар иде.

Пассажирлар чемоданнарын һәм башка кирәк-яракларын алып, утрауга төшәргә җыена башлады. Аларның күңеле күтәренке иде. Катер тизлеген киметә барды, бөтенләй әкренәйде һәм бераздан сул як кабыргасы белән ярга килеп төртелде.

—Әйберләрегез белән ярга чыгыгыз!—дигән көр тавыш ишетелде.—Килеп җиттек.

Барсы да трапка атладылар. Бары тик Михаил гына капитан янына килде:

—Ләкин бу безгә вәгъдә ителгән утрау түгел...—диде ул, болай дигәне өчен үзе гаепле сыман.—Без чынлап та дөрес килдекме?

—Без дөрес килдек,—диде капитан аны үчекләгәндәй.—Әйберләрегезне алыгыз да, ярга чыгыгыз. Озакламый караңгы төшәр, шунарчы әнә теге йорттан бүлмәләр алып, урнашып куегыз. Монда электр уты да, башкасы да юк.

—Ничек инде?!

—Шулай. Ә иртәгә таң белән тагы юлга кузгалырсыз. Сезне икенче теплоход килеп алыр. Без ары баралмыйбыз, тагарак авыр хәлдә. Көтелмәгән унайсызлыклар өчен гафу үтенәм.

Һәм ул Михаилны култыклап дигәндәй ярга чыгарды да кире күтәрелде. Шундук трапны алдылар. Моторлар гүләве көчәйде. Катер кузгалып китте.

—Ә безне беркем дә каршы алмыймени?!—диде Анна барсына да ишетелерлек итеп.—Каршы алучылар булырга тиеш бит инде.

Беркем дә эндәшмәде. Зур тизлектә ераклашкан катерның кире борылуын көткәндәй, барсы да күл ягыннан күз алмады. Хәтта ул кечкенә ноктага әйләнеп күздән югалгач та урыннарыннан кузгалырга ашыкмадылар. Күңелләрне шомлы тынлык басты.

—Ә Сережа һаман уянмый...—дип иренә елышты Анна.—Ишә генә йокыны...

* * *

*Санкт-Петербург. Россия.*

Ир кара курткасының түш кесәсеннән конверт алып хатынга сузды:

—Бар да сөйләшенгәнчә. Санап алыгыз.

—Рәхмәт. —Лолита конвертны ачып та тормыйча портфеленә салып куйды. Елмайды. Өстәл артыннан күтәрелде. Ул инде турагентство формасында түгел иде. Кара озын чәчләрен иненә таратып салган, һәр ирне әсир итәрлек гәүдәсенең бөтен матурлыгын ассызыклап торган кофта, кыска итәк кигән, шоколад төсендәге тәне дә бөтен булмышына ниндидер татлылык өсти, ирексездән аны тәмләп карыйсы килә, ә кара кашлары астыннан ягымлы нур сирпеп балкыган күзләре аның ихтыярына берсүзсез буйсынырга мәҗбүр итә, өлгергән чиядәй тулышкан иреннәре, ул иреннәрдәге серле елмаю аңа искиткеч назлылык өсти, бу ханымның янында торуы гына да жанга рәхәтлек биргән сыман тоела иде. Номердан чыгарга итеп бер-ике адым атлагач, туктап калды. Өстәл артыннан торып өлгермәгән ир янына кабат борылып килде.—Бер генә нәрсәне сорарга мөмкинме?

Ир сагаеп калды. Хатынны беренче күргәндәй баштан-аяк күз йөгертеп чыкты. Елмайды. «Мин сезне юк-бар сораулар биреп баш катырыр өчен ялламаган идем. Ләкин матурлыгыгыз хакына рөхсәт итәм инде...»—аның кыяфәте шулай дигән сыман иде.

—Нәрсә инде тагын, Лолита?

Хатын бер мәлгә икеләнеп калды.

—Ә сез курыкмыйсызмы?—диде аннан соң сүзләренә икесенә генә аңлаешлы яшерен мәгънә салып.—Курыкмыйсызмы, әллә бернәрсә дә белмисезме?

—Нәрсәдән?—Бу сүзләр беркатлылык белән әйтелсә дә, иренең тавышындамы, кыяфәтендәме, аның нәрсәдән куркырга кирәк икәнен яхшы төшенгәнлеген сиздерә торган бер чалым бар иде. Ләкин хатын качышлы

уйнап тормаска булды. Ул портфеленнән кечкенә файл алып ирнең алдына салды һәм карарга кушып баш какты.

Ир файлга күз салды да елмайды.

—Гәзит укырга кушасынмы?—диде ул файлны кире этәреп.—Рәхмәт. Тик мин үземә кирәкле мәгълүматләр белән нәкъ үз вакытында танышып барам.

Хатын файл эченнән берничә гәзит тартып алды да аларны ачып ирнең алдына тезде. Мәкаләләрнең исемнәрен ул кызыл каләм белән түгәрәк эченә алып куйган иде.

—«Әҗәл утравы»нда булып кайтканнан соң, бер хатынның чама белән өч айлык көмәне үзеннән-үзе юкка чыга...»—диде ир, күзенә эленгән беренче гәзитне укып.—Шуннан нәрсә?! Бу әллә сезнең хактамы?

Лолита анын шаяртырга маташуын игътибарсыз калдырды.

—Сез әле генә бер төркем кешене шул утрауга җибәрдегез.

—Ә монда утрауның ни кысылышы бар?

—Ә көмәннең үзеннән-үзе югалуы сезгә гаҗәп булып тоелмыймы?

—Бер тамчы да! Ана карынындагы бала яралгысының башлангыч чорда юкка чыгуы гайре табигый нәрсә түгел. Мондый мисаллар тулып ята. Табиблар аны «әле житлегеп бетмәгән яралгыны организм кире үзенә сеңдерә»,—дип аңлаталар. Бары тик шул гына.

Хатын мондый җавапны көтмәгән иде бугай. Бер мәлгә югалып калгандай тоелды. Ләкин ул үзен тиз кулга алды:

—Ләкин... Ләкин өч айлык баланың юкка чыгуы... Һәм бу бер генә очрак түгел... Сез башкаларына да күз салыгыз.

Ир аңа акылы зәгыйфләнә башлаган кешегә карагандай кызгану катыш елмаеп кына җавап бирде.

—Көлмәгез миннән. Менә нәрсә дип язалар: «Күлгә чыккан балыкчылар төркеме, көймәләре ватылып, «Әҗәл утравына» туктала. Монда алар берничә төн кунарга мәҗбүр булалар. Беренче көннәре тыныч кына үтә. Ә икенче көннән кешеләр югала башлый...»

Ир кычкырып көлеп җибәрде.

—Ә сез беләсезме, кунакханәнең бу бүлмәсе нәрсә белән дан тота. Әлбәттә, анын хакында бик кычкырып сөйләшеп бармыйлар. Әмма нәкъ шушы бүлмәдә төннәрен өрәкләр йөри. Ә теләсә нинди ир-егет монда бер кич кунганнан соң, шушы бүлмәгә кергән чибәр ханымнарны кочлап, кыйнап, үтереп ташлый торган маньякка әверелә.

—Сез миннән көләсез.

—Көлмим, Лолита. Бу хакта әлегә гәзиттә бернәрсә дә язмадылар, дисезме?! Гаеплемен. Иртәгә үк редакциягә илтеп бирәм, һәм ул берәр атнадан канынны суытырлык исем белән басылып чыгачак.

—Житте.

—Гафу итегез. Ләкин гәзиттә басылган һәртөрле әкәм-төкәмгә ышана башласан, акылдан шашарга мөмкин. Акча, тираж хакында гына баш ваткан журналистлар хәзер теләсә-нәрсә уйлап чыгарырга әзер тора. Ә сез шуларның сүзенә чынлап ышанасыз.

Хатын бер мәлгә тын торды. Әйткән сүзләренең әлеге бәндәгә бер тамчы да тәэсир итмәве анын хәтерен калдырды бугай.

—Сез безнең як кешесе түгел. Шуңа күрә барсына да көлеп кенә карыйсыз...—диде ул өметсез бер тавыш белән.—Әгәр мондагы хәлләрне белсәгез, утрау турында нинди хәбәрләр йөрүен ишетсәгез, алай итмәс идегез.

—Мин сезне аңлыйм, Лолита. Кисәтүегез өчен рәхмәт.

—Рәхмәт...—диде ханым, үчекләгәндәй итеп.—Сез бернәрсә дә аңламыйсыз.

Иргә ул кызганыч булып китте.

—Мин әлеге адымга барыр алдыннан ул утрауда ялгызым бер атна яшәдем. Һәм бернинди гадәттән тыш хәлгә дә юлыкмадым. Кунакларым да исән-имин булыр. Сез бернәрсә өчен дә борчылмагыз.

—Ходайдан ялварырга гына кала инде... Ә ни өчен кирәк соң боларның барсы да?!. Сезгә ул нәрсә бирә?

Ир тын калды.

Бу хакта ул үзе дә уйламады түгел. Ләкин канәгатьләнерлек җавап кына таба алмады.

—Белмим. Мин шулай телим.

—Әгәр берәр көтелмәгән алама хәл килеп чыкса?

—Чыкмас. Чыкмаска тиеш.

—Ярый...—Хатын тагын ишеккә борылды.

Нәкъ шушы мизгелдә ир бернәрсәне аңлады. Бу гүзәл ханымның китүен теләми иде ул. Ир үзе дә аралашуга, аңлауга мохтаҗ иде. Ул үз хаклыгына үзе дә шикләнә, ялгыз төн аны куркыта.

—Миңа китәргә вакыт...

Хатын аңа монсу карашын төбәп бер мәлгә тынып калды. Ул да китәргә теләми иде.

—Ә сез ни өчен миңа барысын да сөйләдегез?—диде хатын бераз кыюсызланып торганнан соң.—Кемнәрне каршы алып, кайда утыртып җибәрергә кирәген әйтү дә җитә иде бит...

—Белмим, Лолита.—Ир урыныннан кузгалды.—Сез беркая да ашыкмыйсызмы?

Хатын дөрес ишетәмме дигәндәй карашларын аңа төбәде.

—Тагын берәр эш бармы әллә?

Ир аның каршына ук килеп басты. Бер-берсенә карашып катып калдылар.

—Сау булыгыз...—диде хатын, үз сүзенә үзе дә ышанып җитмәгән бер халәттә.

—Сау булыгыз...—Аның тавышы карлыккандай иде.—Лолита...

Ир акрын гына аның чәчләреннән сыйпады. Һәм назлы гына итеп үзенә тартты да иреннәренә үрелде. Ханым карышмады...

## 2. Саташулар төне

* * *

Бераздан Андрей Николаевич тынлыкны бозды.

—Дөнья булгач, төрле хәлләр була инде. Әйдәгез, чынлап та йортка кереп урнашыйк. Караңгы төшәргә дә күп калмады.

—Монда безне беркем дә каршы алмый микәнни?!—дип һаман үзенекен сөйләде Анна.—Шул тиклем утрауда без үзебез генә. Кызык.

—Әйдә, кадерлем,—Михаил сумкаларны алды да йортка табан атлады.

Башкалар аңа иярде.

Тар сукмак буйлап берәмләп кенә үргә күтәрелделәр. Йөкләре дә авыр гына, юл да текә иде. Шуңадырмы, сөйләшүче табылмады.

Билгесезлек һәрвакыт авыр тәэсир итә. Оҗмах кебек урынга эләгәм, гомер буена хәтердә калырлык матур урыннарда ял итәм, күңел ачам дип барганда, менә шундый адәм аягы басмаган җиргә килеп кабу беркем өчен дә күңелле хәл түгел иде. Утрау, әлбәттә, матур иде. Зур да түгел. Ләкин анда барысы да бар, тауны каплап үскән куе агачлар да, агачлар арасыннан ыржаеп торган текә таш ярлар да... Күңелгә, бәлки, шунсы да шом саладыр әле аның. Гомум мәйданы дүрт-биш чакрымнан артмаса

да, куе агачлык үз куенында ниндидер сер яшергән шикелле. Тоташ бер тауны хәтерләткән утрау әллә нинди сәер уйларга этәрә. Тавы булгач, мәмерҗәсе дә бардыр һәм анда күз өйрәнмәгән куркыныч затлар яшидер сыман тоела.

Беренче күргәндә чиксез матур булып тоелса да берничә минут үтүгә утрау үзгәрде. Үз тәнендә чит-ят затлар барлыгын тоеп, алардан котылырга тели сыман иде ул. Әлбәттә, болай дип уйларлык бер генә үзгәреш тә булмады әле. Утрау элек ничек булса, шулай калды. Әмма бу тыштан гына шулай тоела, ә асылда... Юк, утрау үзгәрми иде, ул бары тик кешеләрнең күңелен үзгәртә һәм үзеңне монда бөтенләй үги итеп сизәргә мәҗбүр итә иде.

Бәлки, Михаилга гына шулай тоелгандыр. Хәер, аңа гына түгелдер... Әнә бит, барсы да ничектер кечерәеп, басылып калган. Берсе-бер сүз дәшми.

Бәлки моңа утрау да гаепле түгелдер әле. Кешеләр юлдан килеп арыганнардыр гына. Һәм тиешле урынга бүген барып җитәбез дә рәхәтләнеп ял итәбез дигән өметләре белән хушлашу авырлыгы гына моңаебрак калырга мәҗбүр иткәндер. Бүлмәләргә урнашып, тамак ялгап, ял итеп алганнан соң барсы да үзгәрер һәм утрау яңадан үз төсендә, искиткеч матур булып күренер.

Беркадәр вакыттан йорт урнашкан кечкенә тигезлеккә менеп җиттеләр дә барсы берьюлы тукталып, ачык ишеккә карап тын калдылар. Бу агачтан салынган ике катлы иске зур йорт иде. Иске булса да горурлыгын югалтмаган, дөньяның тулы хокуклы бер әгъзасы булып күкрәгән киереп тора.

—Кызык, ә кем монда йорт салып куйды икән?!—диде Ләис-Леон.—Ә бит начар түгел...

Беркем дә эндәшмәде. Иңнәрен генә сикерттеләр.

—Ә ни өчен ташлап китте икән?—дип шомлы елмайды Андрей Николаевич бераздан.—Ә бит матур урын, югыйсә!

—Ә бәлки, ташлап та китмәгәндер...—Ольга иренә карап куйды.—Бәлки, ул монда оныткандa бер генә килеп йөри торгандыр... Якын җир түгел бит.

—Андрей Николаевич.—Елена алгарак чыкты.—Сез күпне күргән кеше бит инде, белмисезме... Ә бу утрау ничек атала икән?

—Юк, бүген әйтмим... Иртәгә, юлга кузгалгач, әйтермен...

—Ә хәзер әйтсәгез, ни була?

—Ярамый. Әйдәгез, монда вакыт үткәрмик... Кереп урнашыйк...

Алар шуны гына көткәндәй, алга атладылар.

Йорт тыштан караганда җыйнаграк күренгән икән әле. Эченә кергәч, ул бик иркен һәм уңайлы иде. Бүлмәләр дә барсына да җитәрлек булып чыкты. Һәркайсы үзенә ошаганын сайлап алгач, сумкаларын куеп кире чыктылар. Адәм аягы басмаган утрау сыман күренсә дә монда шактый уңайлы иде. Су кергән, газ плитәсе бар, хәтта туалет бүлмәсе дә өй эчендә. Болары көтелмәгән куаныч булып чыкты, боларны ачыклаганда алар балаларча гаҗәпләнү белән бер-берсенә хәбәр салдылар:

—Карале, газ плитәсе! Әшли!

—Хәтта су да бар!

—Туалет! Гомеремдә ышанырлык түгел, ул өй эчендә!

—Монда менә дигән итеп яшәргә була ич!

—Телевизор да булса!

—Яки радио...

—Тик монда электр юк...

—Кызлар, табын корып җибәрергә кирәк булыр...

—Ә нәрсә пешерәбез?

—Әлегә үзебез белән алып килгән ризыкларны күмәк табынга куярбыз. Капкалап алгач, берәр жай табылыр. Әнә, ирләрне балык тотарга, ауга чыгарып җибәрербез...

Чынлап та, кереп урнашкач, утрау алама урын булып тоелмады. Һәрхәлдә, монда яшәргә, күнегелгән шау-шулы тормыштан ял итәргә мөмкинлек бар сыман иде. Ә чәй кайнатып, булганы белән бераз капкалап алгач, күңелләр дә күтәрелеп киткәндәй тоелды. Тормыш ямьсез дә, салкын да түгел иде.

* * *

Табындагы күтәренкелек озакка сузылмады. Кайсы балыкка барырга, кайсы ауга чыгарга, кайсы җиләк-җимеш карарга дип урыннарыннан кузгалсалар да, бераздан бу фикерләреннән кире кайтып, утрау белән танышып чыгарга уйладылар һәм ахырда тәннәрендә нииндидер изрәү тоеп, өй тирәсендә беркадәр буталып йөрделәр дә, ял итеп алырга булдылар. Ул арада инде караңгы төште. Бу беркемнең дә кәефен кырмады. Утрау буйлап сөйрәлеп йөрү мәшәкатеннән шулай җинел генә котылуларына сөенеп, барсы да үз бүлмәләренә таралды.

Роберт белән Ләйсән өчен моннан да кулайрак хәлнең булуы мөмкин түгел иде. Алар башта ук, бөтенесе дә ишек алдына чыгып, якын-тирә белән танышып йөргәндә үк, ничектер бергә туры килделәр дә бүтәннәрдән аерылыбрак калдылар. Бу үзеннән-үзе килеп чыкты. Анда барсы да бер-берсенең күз алдында булгач, әллә нәрсә сөйләшә дә алмадылар. Ә сөйләшәсе, аңлашасы килә, бер-берсенә сөйләр серләре мәңгегә дә бетмәс шикелле тоела иде. Кеше арасында алай серләшеп булмый, әледән-әле юк-бар сүзләр алышып тору канәгатьлек бирми, канны гына кыздыра иде. Шуңа да алар аулаккарак тартылдылар, әмма очрашканның беренче көнендә үк, әти-әниләре алдында, урманга кереп китү ничектер уңайсыз кебек тоелды. Бәхеткә каршы, караңгы төшә башлау белән барсы да акрын гына өйгә шудылар. Иң ахырдан ишекне япкан Елена да кызына бары тик бер генә мәгънәле караш ташлап алды да, сүз әйтмәде. Гадәттә, әнисе малайлар мәсьәләсендә каты тора торган иде. Бу юлы Робертны ошаттымы, башка нәрсә сәбәпче булдымы, белмәссең.

Ләкин икәүдән-икәү генә калу белән, дөньяда алар сөйләшерлек сүз беткәнлеге ачыкланды. Хәзер юк-бар нәрсәләргә тел әрәм итәсе килмәде. Ә әйтергә теләгәнен әйтер өчен кыюлык та, сүз запасы да житмәс сыман тоелды, һәм алар, икесе ике агачка сөялгән хәлдә, тагы нинди хәрәкәт ясарга белмичә басып калдылар. Ләкин аларга кыен түгел иде. Бергә булу, икәүдән-икәү генә калып, берең дә бер сүз әйтмичә, бернәрсә эшләмичә һәм беркая китәргә теләмичә тору үзе үк нәрсәдер турында сөйли иде. Сүзләрдән аңлаешлырак итеп. Бары тик «Ә аңа минем белән болай тору уңайсыз түгелме икән, күңелсезлектән ялкып, өйгә кереп китмәсме икән?»—дигән шик кенә нәрсәдер әйтергә этәрде. Әмма кирәкле сүз, барыбер, табылмады. Хәер, нәрсә әйтүең мөһим дә түгел иде инде.

—Ә мин Россиядә беренче тапкыр,—диде, ниһаять, Роберт.—Моңа кадәр бер дә булганым юк иде.

Ләйсән эндәшмәде. Робертның тавышы ягымлы иде, сөйләшкән кебек түгел, ә иркәләгән кебек.

Тын тордылар.

—Мин хәтта русча да белмим,—диде егет.—Бер сүз дә... Син мине өйрәтерсеңме?

—Өйрәтермен...—Кинәт кыз җанланып китте.—Әйдә, хәзер үк башлыйбыз.

—Башлыйк.

—Я тебя люблю!—диде кыз Робертның күзләренә туп-туры карап.—Я тебя так сильно люблю!

Егет бер сүз дә аңламады. Әмма кызның нindидер изге нәрсә әйтүен ул төшенде.

—Я тэбэ льубью!—дип кабатлады ул, җитди итеп.—Ә нәрсә дигән сүз бу?

Кыз кычкырып көлеп җибәрде. Чын күңелдән, ихлас итеп көлде. Роберт та аңа кушылды. Ул көлде һәм бераз тынычлана төшү белән тагын кабатлады: «Я тэбэ льубью!» Бераздан кыз көлүеннән туктап җитдигә әверелде һәм чиксез наз белән янә Робертның күзләренә текәлде:

—Мин сине яратам!

Мондый көтелмәгән хәлдән егет, үз колакларына ышанырга куркып, катып калды. Ышангач, ничектер җитдигә әйләнде, кулларын акрын гына күтәреп бармак очлары белән кызның чәчләренә кагылды. Аннан соң елмайгандай итте.

—Мин дә сине яратам...

Робертның назлы бармаклары кызның чәч араларына үтте һәм әкрен генә назлап, аны үзенә якынайтты. Ләйсәнгә рәхәт иде. Һәм уңайсыз да. Кыз кеше аз гына горуррак булырга тиеш. Болай беренче күрүдән үк эреп төшәргә ярамый. Ләкин егетнең кайнар сулышы инде янакларына бәрелеп иркәли. Буыннарда нindидер кайнар дулкын тибрәлә. Робертның тулы иреннәренә иренең белән кагыласы килә. Тик ярамый. Юк.

Инде битләр биткә терәлә язгач кыз бармагын егетнең иренена куйды:

—Юк, Роберт... Син мине дөрес аңламадың...

Роберт туктап калды. Ул да онытылып киткән иде бугай. Һушына килгәндәй күзләрен җемелдәтеп алды. Һәм гаепле елмаеп, сизелер-сизелмәс кенә баш кагып куйды.

—Я тебя люблю!—диде кыз елмаеп.

—Я тэбе льублю!

—Мин сине яратам. Инглизчәсе шулай була.

Роберт бер мәлгә исәңгерәп торды да кычкырып көлеп җибәрде.

—Ә мин, сантый...

—Юк, Роберт...—дип аңа мөлдерәп бакты кыз.—Син сантый түгел...

Ул ялгыш сүз ычкындыруын аңлап бер мизгелгә катып калды. Моны Роберт та сизде. Кыз елмайды. Егет үзе дә сизмәстән аңа талпынып куйды да елмаерга мәҗбүр булды.

—Син сантый түгел,—дип үз хатасын төзәтергә ашыкты Ләйсән.—Син телне тиз үзләштерәсең. Тагын нинди сүз өйрәнәбез?

—Россия—матур ил.—Роберт елмаеп кызга текәлде.—Чөнки анда Люда бар.

Кыз елмайды.

—Син килгәч кенә матурланды ул.—Монсын кыз татарча әйтте.—Син Россияне генә түгел, дөньяны матурладың.

Роберт телсез калды. Беренчедән, кызның сүзләре тилерткеч иде. Икенчедән, аның татарча белүе. Ул да кызга татар телендә нәрсәдер әйтергә теләгән иде, бер мизгелдә балкып сүнгән уй тыелырга мәҗбүр итте. Әлегә сиздерми торырга кирәк. Кызык булсын.

—Аңламадым,—диде ул кызның күзләренә туры карамаска тырышып.—

Тагын бер кабатла әле.

Кыз мут елмаеп куйды да Россия турындагы сүзләрне русча кабатлады. Ижекләп. Ә «Чөнки анда Люда бар» дигәнен әйтмәде.

—Люда!

Көтмәгәндә ишетелгән тавыштан кыз сискәнеп киткәндәй булды. Бу Ләис иде.

—Люда!—дип пышылдады ул тагын.—Сез кайда?

—Нәрсә, адаштыңмы әллә?

—Сине эзлим.

—Аиданны чакырырга кирәкмени?

—Юк, сиңа керергә куштылар.

—Хәзер... Син керә тор...

Бераздан Ләис артыннан ишек ябылганы ишетелде.

—Үзең күрдең инде,—дип гаепле елмайды Люда.—Ярый, дәресне иртәгә дәвам итәрбез.

—Аз гына тор инде...

—Юк, Роберт... Әни үзе чыкса, яхшы түгел...—Кыз Робертның күкрәгенә башын терәде дә шундук кире тартылды.—Иртәгегә кадәр...

—Карале...

Инде китәргә атлаган кыз тукталып калды.

—Нәрсә инде?—дип назлы елмайды ул, һәм кире килеп егетнең яңагыннан сыйпап алды.—Тыныч йокы.

—Тыныч йокы. Бикләнеп ятма, яме.

—Урларга киләсеңмени?!

—Юк, төшеңә керәм.

—Ярый. Төштә очрашканга кадәр.

Кыз ишеккә йөгерде.

Люда кереп киткәч, Роберт шатлыгын кем белән уртаклашырга белмичә бертын басып торды да бая кыз сөялеп торган каенны кочаклап алды. Агачта сөйгәненең җылысы калгандыр төсле тоелды. Ул яңагын каенга терәп күзләрен йомды. Рәхәт иде. Шушы рәхәтлектән айный алмыйча озак торды. Ләкин өйгә керергә кирәк иде. Таныш түгел урында беренче төн. Әтисе борчылып ятадыр. Өйгә керергә кирәк. Ул күзләрен ачты һәм нәкъ үзенең каршысында кемнеңдер басып торуын күреп дертләп китте. Тәне эсселе-суыклы булды, бала йоннары кабарып чыкты. Әллә күземә генә күренәме соң дип керфекләрен җемелдәтеп алды—теге сын юкка чыкмады. Ул тавыш-тынсыз гына якыная иде. Качарга, яки кычкырырга—нәрсә дә булса эшләргә—кирәген белсә дә егет тамыр җәйгән агач хәлендә иде. Ул бер хәрәкәт тә ясый алмады...

* * *

Радик бүгенге көненнән канәгать иде. Ул үзен кеше итеп тойды. Ул бүген көне буе махмырдан интекте һәм кичкә кадәр бер йотым да капмады. Дөрес, иртәнге якта азрак шаярыштырып алган иде, әмма кызы белән булган теге чәкәшүдән соң үз-үзенә эчүне ташларга, Айгөлнең ихтирамын кайтарырга дип вәгъдә биргәннән соң, хәле ничек кенә мөшкел булмасын, хәмер турында уйлап та карамады. Юк, монысы дөрес түгел, уйлады, әлбәттә. Тагы да төгәлрәк әйткәндә, ул бары тик хәмер турында гына уйлады. Бүтән уйлар башына килгән икән, алар бары тик аракы турындагы хыялдан читкә тайпылу өчен генә иде. Ул көнозын баш төзәтү, бер илле грамм гына эчеп, ашказанын сөендерү турында уйлап йөрде. Әмма эчмәде. Ә монысы батырлык иде. Җиңү!

Әлбәттә, аның башка вакытларда да айнык баштан йокларга яткан чаклары булгалый иде. Ләкин монысы бөтенләй бүтән. Башка вакытларда ул акчасызлыктан, аракы алырга мөмкинлеге юклыктан гына айнык килеш кала һәм урынга яткач та йокыга китә алмыйча боргалана иде. Көне әрәмгә үткәндәй тоела иде ул вакытларда. Һәм үзен кимсетә башлый иде. Мужик башың белән көн озынына бер яртылык та рәт тапма инде. Юкка гына Машаларга кереп карамадым, аның, билләһи, запассыз торган чагы юк. Тәмле телемне кызганмый сорасам, ярты рюмка булса да чыгарыр иде әле. Шулай өзгәләнә иде. Ә бүген ул үзен чынлап та җинүче итеп сизде. Бүген аның кесәсендә бераз акчасы да, аракы алырлык мөмкинлеге дә бар иде. Хәтта алай гына да түгел. Пинжәгенең түш кесәсендә яссы шешәле бер чүл бар иде. Теләсә нинди почмакта эчеп була. Ләкин ул алай итмәде. Түзде. Җинде. Хәтта үзендә теге чүлне форточкадан ыргытырлык көч тапты! Болай булгач, эчүен ташлый алачак ул. Кабат адәмчә итеп яши башлаячак. Кара әле, Айгөле нинди чибәр кыз булып үсеп җиткән. Шундый балаң бар көенә болай адәм мәсхәрәсе булып йөрергә ярыймыни?! Беренче очрашкан мәлләрдә ул әтисен ничектер үз итебрәк тә торган сыман иде. Бары тик юлда исереп, тиеш-тиешсезне сөйләп килә башлагач кына карашы үзгәрде. Дөрес эшләмәде Радик. Һич югында юлдан урап кайтканчы гына түзәргә кирәк иде. Кызының хәтеренә әйбәт әти булып кереп калса, нәкъ шушы вакытта гына кала ала ул. Аннан соң, бер өметен өзденме, баламны югалттым дип уйла. Һәм Радик бүген үзеннән канәгать иде. Ул үзен бик тә көчле итеп, ни теләсә шул кулыннан килерлек итеп тойды.

Эчеп йөргән чагында Радик нindidер зур акча откан, имеш. Әле шуны алыр өчен барулары икән. Бик зур акча! Йөз мең! Кара исәп белән генә дә, бу акчага мең шешә яхшы аракы тия, ә аны өч ел чамасы эчеп ятарга була. Ләкин Радик аңа якын да бармаячак. Акчаны алу белән Айгөлнең кулына тоттырачак ул. Теләсә нишләтсен. Үзенә булсын. Бала өчен бернәрсә дә җәл түгел. Ул елмаеп куйды. Киң күнелле булудан да рәхәтрәк нәрсә юк дөньяда. Үзеннең әйбәт кеше икәнеңне тоюдан да ләззәтлерәк хис юк. Радик бәхетле иде.

—Кызым...

Җавап бирүче булмады. Һәр гаилә берәр бүлмәгә урнашкан иде. Беренче катта барлыгы биш бүлмә, өчесе ике урынлык, икесе дүртәр урынлык иде. Алар дүрт урынлыкны алдылар. Бу бүлмә такта стена белән үзе үк икегә бүленгән һәм бала-чагалары белән бергә яшәргә теләүчеләр өчен бик кулай иде. Мондый бүлмәләрнең икенчесен Николайлар алды. Калганнар ике урынлыкка урнаштылар. Икенче катка беркемнең дә менәсе килмәде.

—Айгөл...

Стена аша йокласа да Айгөл аны ишетергә тиеш иде. Ләкин ул эндәшмәде.

—Кызым... Син мине барсы өчен дә гафу ит, яме... Мин башкача ... Эчүемне ташларга булдым, кызым... Синең өчен... Ишетәсеңме мине, кызым...

Җавап булмады.

Айгөл йоклыйдыр инде. Үпкәләп яткан гына булса, берәр ничек җавап бирер иде. Йоклыйдыр. Ярый йокласын.

—Тыныч йокы, кызым...

Бераздан Радик та бәхетле йокыга талды.

Әмма бәхетлелек хисе озакка сузылмады. Тәрәзәдән нindidер караңгы томан керде дә аны төреп алды. Бу, әлбәттә, төш кенә иде. Томанны ул төшендә генә күрде. Һәм ул томан Радикны юргандай төреп алды да, бер

мизгелдән үк юкка чыкты. Кайда югалганлыгын да аңларлык булмады. Әмма шул хәлдән соң кинәт нәрсәдер үзгәрде. Радик инде үзен бәхетле итеп тоймады. Юк, алай да түгел... ул бөтенләй икенче дөньяга күчте. Ул бөтенләй бүтән кешегә әверелде. Караңгылык кешесенә...

—Мин яктыга чыгарга телим!—дип кычкырды ул.—Яктыга чыгачакмын! Кызым хакына! Яктыга. Күпме караңгыда яшәргә мөмкин инде! Яктыга!

—Әти! Әти!!!

Кемнеңдер көчле селкетүенә ул уянып китте дә бернәрсә дә аңлый алмый ятты.

—Әти!. Уян! Әти!

Радик бераз айнып киткәндәй булды. Алар кызы белән утрауга килгәннәр иде, ләбаса. Аны уятучы Айгөл иде.

—Айгөл... Кызым...

—Әти, барсы да тәртиптәме? Син нык саташтың...

—Кызым...

—Су эчеп ал, әти... Мә...—Кыз аңа чынаяк сузды.—Тынычлан.

Радик комсызланып су эчте. Һәм кинәт күнеле тулып китте.

—Кызым. Балакаем минем...—Ул кызының учын яңагына кысты да сабый баладай үксеп елап җибәрде.—Гафу ит мине, кызым... Гафу итегез, берүк... Болай булырга тиеш түгел иде. Мин сезне бәхетле итәргә тиеш идем. Кызым...

Кинәт кемнеңдер кычкырганы ишетелде...

*Дәвамы киләсе саннарда*

---

## «Казан утлары» елъязмасы



*Журналыбыз 1922-1930 елларда «Безнең юл», 1930-1932 елларда «Атака» һәм «Яңалиф», 1933-1965 елларда «Совет әдәбияты», 1965 елдан «Казан утлары» исеме белән дөнья күрә.*

**85 ел элек** (1927) «Безнең юл»ның гыйнвар санында Хәсән Туфанның «Урал эскизлары» исемле шигыре;

**75 ел элек** (1937) «Совет әдәбияты»ның гыйнвар санында Нәкый Исәнбәт тәрҗемәсендә А.С.Пушкинның «Бакчасарай фонтаны» поэмасы татарча;

**65 ел элек** (1947) «Совет әдәбияты»ның гыйнвар санында Габдрахман Әпсәләмовның «Ак төннәр» повестеның башы;

**55 ел элек** (1957) «Совет әдәбияты»ның гыйнвар санында Нәкый Исәнбәтнең «Муса Җәлил» трагедиясе, Мирсәй Әмирнең «Ялантау кешеләре» романының икенче китабыннан өзек;

**45 ел элек** (1967) «Казан утлары»ның гыйнвар санында Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» повестеның башы, Илдар Юзеевнең «Тынлык белән сөйләшү» поэмасы дөнья күрде.

# «Казан утлары» архивыннан



Президентлык алда әле. Хәзер исә Минтимер Шәймиев һәм Рәис Беляев (сулда) – партия өлкә комитеты секретарьлары. 1984 ел.



1991 елның 12 июненнән М.Шәймиев – Татарстан Президенты. Бу вазифаның иң четерекле ягы Россия белән мөнәсәбәтләрне көйләү булса кирәк.



Тарих президентларның һәр сүзен искәреп бара.



Татарстан Президенты референдум алдыннан Россия телевидениесенең «Без ретуши» дигән тапшыруында чыгыш ясый. 1992 ел.



*М.Шәймиев Татарстан язучыларының XII съездында чыгыш ясый. 1994 ел.*



*Президент «Казан утлары»ның баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин белән гәпләшә. 2006 ел.*



*Китапка карап уйланырлык, әйе. Татарның әдәбияты, фәне, мәгарифе туган телләрендә дүрт кенә класс укыганнар кулына калса, нишләрбез?*



*«Татар җыры» фестивалендә Алсуны М.Шәймиев котлый.*



Илдус
Гыйләҗев

# ҮЛЕМСЕЗ ДАН ҖИҢЕЛ БИРЕЛМИ

## Туган җир

*И туган тел, и матур тел.*
Габдулла Тукай

**И туган җир, и матур җир,**
**Кендек каным тамган җир.**
**Ата-анам гомер иткән,**
**Бабамнардан калган җир!**
**Суларында коендырган,**
**Туендырган җайлы җир.**
**Иген уңган, җәнлек тулган,**
**Кара һәм ак майлы җир.**
**Татар җанлы вә иманлы**
**Оныкларга калыр җир.**
**...Бөтен гөнаһларым белән**
**Куенына алыр җир!**

## Нишләмәк кирәк

*«Так неуважительно, как в Казани,*
*к творческим людям не относятся нигде».*
Фуат Мансуров

**Урын кысынкымы, күңел тармы,**
**Нәрсәдән бу җүнсез гадәтләр?**
**Зыялылар әллә артык күпме,**
**Тирәндәрәк микән сәбәпләр?**
**Җитәкчеләр аңлап бетермиме?**
**Дөресрәктер монсы, күрәсең.**

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ (1946) – *шагыйрь; «Җир китабы», «Күкрәгемә тургай оялады», «Үземә кил!» һ.б. шигырь китаплары авторы. Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һ.Такташ исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Азнакай районы Туйкә авылында яши.*

Үз шәүләсеннән үзе куркып
Яши бездә татар түрәсе.
Дәүләтенә хуҗа халык кына
Талантларны сөйгән, күтәргән.
Ә коллар бит, гладиаторларча,
Берсен—берсе кыйнап үтергән.

## Үрнәкнең дә үрнәге

Ышанмыйча тордым башта,
Шатлык эчкә сыймады:
Төрекләрнең Ил башлыгы
«Туган тел»не сөйләде.
Үзебезчә, чын татарча!
Күзләр генә тимәсен,
Бездә шундый түрәләрне
Килеп китте күрәсем...

## Төштә дә эзәрлеклиләр

Әллә нинди кара төшләр күрә,
Җәфаланам куркып уянып.
Салкын тиргә батып, борсаланып
Таңга кадәр ятам уйланып.
Нәрсә соң бу? Кемнәр бимазалый?
Күп сөйләнгән өчен җәзамы?
Җирдә чактук әллә башланамы
Тәмуг—җәһәннәмнең газабы.
Гөнаһлар күп, ансын кабул итәм,
Ә нигә дип телне кисәләр?
Бирешмәс, дип, әллә уйлыйлармы
Якты чакта, көндез килсәләр?!

## Ике юл

*«Барлык юллар да Римгә илтә».*
Борынгыдан килгән әйтәм.

Дөнья башкаласы булган шул ул,
Кулай урын байлык тупларга,
Җан җылысы табар өчен бездә
Шигъри юллар илтә Тукайга!

***

«Харап булам ташлап китсәң»,—дигәч,
Күз яшеңне сөрттем, юаттым.
Исән калдың бит, әй. Мин дә яшим!
Мәхәббәтне генә югалттык...

## Шул гына каламы?

Акыл җыйдым бик күп гыйлем эстәп,
Ә үзем соң нәрсә калдырам?
...Алганнарың китә үзең белән,
Биргәнеңнән кала... чардуган...

## Кулыңда ни, авызыңда шулмы?

*(Рәсәйчә хосусыйлаштыру)*

Беришләре чумды девонгача,
Кемдер—завод басып алды.
Галим–голәмәләр, мөгаллимнәр
Кәгазь–каләм тотып калды.

## Алар акыллыракмы?

Көзлар җитеп, көннәр салкынаеп
Җай калмагач нектар җыярга,
Бал кортлары җылы умартадан
Сорыкортны куып чыгара.
Табигатьнең кырыс хөкеме шул:
Файдаң булса гына хакың бар!
Бездә генә сәрхуш ирен асрап
Иза чигә бик күп ханымнар...

## Илең киң булса да

Дәүләтсезлек яман нәрсә,
Хакимнәргә кирәгең юк.
Аквариум балыгыдай:
Үзең суда, ирегең юк.

## Ришвәт димәсәләр

Элек дәүләт–хөкүмәткә
Шагыйрьләр кирәк иде.
Шуңа каләм иясенә
Кадер дә күбрәк тиде.
Комсыз кавем өскә чыгып,
Бетергәч илне талап,
Очын–очка ялгый алмый
Интегә хәзер талант.
Керемнәрен санаганда
Укырлар бәлки күреп:
Шигырьләрне карыйкмы әллә,
Акчага язып биреп?

## Көндәш тә юк ичмасам...

Авылларның шагыйрьләре
Шәһәргә күчеп киткән.
...Беткән саланы язарга
Мин үзем дә бик җиткән...

## Йоклап йөргәч

Бозау чаклы этем төнлә белән
Чылбырыннан качкан ычкынып,
—Әбрик, Әбрик, кая олактың,—дип,
Урам буйлап йөрдем кычкырып.

**Күңелемнән әрнеп бәхилләштем:**
**Кайтмас инде, дусны югалттым.**
**—Әллә кая китмәс, кайгырма,—дип,**
**Оныгымны алдап юаттым.**
**Таң алдыннан чынлап кайтты бит бу,**
**Ачыкканмы, арган-талганмы;**
**Карышмыйча ятып көтеп торды**
**Муенына мунчак салганны.**
**Ирек шартларында яшәү өчен**
**Әзерлекле булу кирәктер.**
**...Мөстәкыйльлек даулап йөргән еллар**
**Үзебезне шуңа өйрәтте.**

## Бәйрәм ашы—кара-каршы

**Әүвәл дөнья миңа ошамады,**
**Үзгәртергә йөрдем тырышып.**
**Ул борынгы, минем яшь вакытым,**
**Яшәп булсын ничек тынышып.**
**Бүген инде аңа мин ошамыйм,**
**Үзгәртергә ныклапябышты:**
**Чәч югары, караш тоныклана...**
**Үчле икән, белми ялгыштым.**

---

## «Казан утлары» елъязмасы




**40 ел элек** (1972) «Казан утлары»ның гыйнвар санында Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романының башы, Сажидә Сөләйманова шигырьләре;

**35 ел элек** (1977) «Казан утлары»ның гыйнвар санында Гариф Ахуновның «Идел кызы» романының башы, Гамил Афзал шигырьләре;

**30 ел элек** (1982) «Казан утлары»ның гыйнвар санында Атилла Расихның «Ямашев» романының башы, Нури Арслановның шигырьләре;

Моннан **25 ел элек** (1987) «Казан утлары»ның гыйнвар санында Миргазиян Юнысның «Таңда Босфор аша» повестеның башы, Равил Фәйзуллинның «Таулар» циклыннан шигырьләре дөнья күрде.



Айдар
Хәлим

## ХИКӘЯЛӘР

### Үрнәк эшелон

*Җырчы Мәгафур
Хисмәтуллин истәлегенә*

Сарытауга җитәрәк бер станца кисәгендә—татар урдасының җимерелгән башкаласы Хәрәбәлеме, әллә Колтүбән янындамы шунда, эшелонны янә дә туктаттылар. Акмәчеттән кузгалып китүләренә җиденче тәүлек дигәндә, гадәттәгечә, бары көндез, күз бәйләнгәнче, бары тик яктыда, кеше карашы дүрт тарафка шәрран-яра ачылган төштә, инде җиденче тапкыр тукталуы иде бу 007 литеры белән килгән эшелонның. Төннәрен исә мылтык көбәкләре белән энәле керпе шикелле тирә-якка тырпайган бу олау күзенә ак-кара күренми чапты да чапты.

Эт эчәгесе шикелле сузылган тимер юл олавы туктап та өлгермәде, һәр тарафтан лызгылдаган авазлар яңгырады, озак та үтми мал ташый торган монсыз вагоннарның ачылган ишекләреннән һау-һаулап бурзайлар, бурзайлары артыннан мылтык көбәкләре белән тыныч һаваны тишеп, кайнатып, сакчылар, аларның бойрыкларына буйсынып, иң әүвәле яшь жилкенчәк, үсмерләр, аннан өлкәнрәкләр—хәлләләр коелды; бар тирәне акырган-бакырган, эт ырылдаган авазлар басты, илтифат итеп тыңламасаң, этләр ырылдыймы, әллә сакчылар бакырамы икәнлеген аеру да мөмкин түгел иде; менә табаннары белән җирне тоеп өлгергән хәллерәкләр, гүя тупрактан көч алып, канатларын кагынгандай, кулларын җәеп, эчтән, бик тирәннән, ташкүмер караңгылыгыннан тәмам хәлсезләнгән карт-корыларны, урын өстендә яткан гарип-горәбәне, буйлары кендектән үтмәгән сабыйлары белән хатын-кызларны суырып алып, җиргә төшерә башлады...

Ялан зәңгәр галифеләр белән зәңгәрләнеп, кызыл кикрикләр белән кызарды. Хәрбиләр үзләре сулар һавада да, басып торыр җирдә дә мохтаҗлыклары булмаган гасаби кыяфәттә авызларын турсайтып, борыннарын маңгайдан да югары чөеп, мискин мәхбүсләрне божрага алып, бары бер шөгыль белән шөгыльләнә: күзәтәләр.Читкә сибелмәсеннәр. Суга кермәсеннәр. Комга сеңмәсеннәр. Исән генә була күрсеннәр. Сан өчен. Мал абзарын хәтерләткән вагоннар эченнән карабодай кебек коңгырт карайган, тирдән пешенгән адәмнәр исә, тегеләрнең киресе булгандай,

жиргә аяк баскач та, тынсыз исәнгерәгән балыктай, күкрәк киереп тын алырга тырыша, мона кадәр, ирektә, жир кадерен белеп, туйганчы йөреп калмаган, һава кадерен белеп, туйганчы һава сулап калмаган рәвештә жиргә басып, жир буйлап йөреп, һаваны иснәп карый иде. Ул гына дисенме, бу анлашылмаган халык, бигрәк тә эшелон командованиесен тәшкил иткән урыс командирлар уйлавынча, фанатик кавем, олысыннан кечесенә кадәр, жиргә аяк басып өлгерми, борынын төртеп, намазын укый башлый һәм берничә сәгатьлек ял вакытын да гыйбадәттә үткәрергә тырыша. Сакчыларга халыкны намаздан аерырга кушылган. Аларның кайбер кансызлары, Тажи Гыйззәтнең «Чаткылар»ындагы Әтүтән Дәүли кебек ләббәйкәләре, намазлык өстендәге яшен-картын мылтык түтәсе белән төрткәли-эткәли,чырылдатып кыйнарга тотына. Әмма гади сакчылардан барысы да алай артыгын зәһәрләнеп бармыйлар. Алар, урыннарыннан куптарылган халыкның сизенүенчә, үзләре дә мөселман балалары, алай гына дисенме, тугандаш кырым татарларын жирләреннән сөрү өчен махсус рәвештә Татарстан һәм Башкортстан НКВД-ларыннан куып китерелгән татар-башкорт милиционерлар, йөзләрен чалшайтып булса да үзләренең тел-иман теләктәшлекләрен сиздерергә тырышып, кайвакыт боерыкларын татарча дә әйткәлиләр...

Инде жиде тәүлектә житмеш жиденче тапкыр туктаган мәхбүсләр өйрәнеп беттеләр: вагоннан коелу белән карана башлыйлар: ачык яланмы? Кергәрне элеп киптерергә, башка вак хажәтләрне үтәргә куак-мазар, чишмәлек-сулык бармы? Аларны урманлы жирләргә туктатканнары юк әле. Күрәсен, ярамый. Бу юлы да шулайрак бугай: вак таллык, сары комлык һәм бераз арырак елга ишарәте күренә—Аллага шөкер!.. Намазларын ашык-пошык булса да үтәп алган хатын-кызлар үз эшләренә керештеләр: гадәттә биш сәгатьтән дә артык бирелми торган вакытны тиешенчә файдаланып калырга, барысына да өлгерергә—бала-чага, ата-ана, бием-биатайларның тамагын туйдырырга, булган керләрен чайкатып эләргә, жиллэтергә, кая ди үтүкләү, ярым-йорты килеш кул аясы булса да сыпыргалаштырып,таслагандай итәргә кирәк.

Күз ачып йомганчы су буе учаклардан ишелеп чыккан төтен арканнары белән зәңгәрләнеп өлгерде. Кайдадыр чәй дә кайнап чыкты,савыт төбендә шалтыраган кашык тавышлары ишетелде. Жиргә беренчеләрдән булып сикереп төшкән Бекир жиде яшьлек улын житәкләп, бер читкәрәк китте һәм, намазын башкарып алганнан соң, бу көтелмәгән сәфәр буенча күршесе Мәмдүдәне эзләде. Аларның вагондагы сакчысы, аты буенча Шиһабетдин, Аллага шөкер, миһербанлы гына күренә иде. Мәмдүдәне каядыр кумагандыр бит? Кая булды ул? Бергә төшкәннәр иде. Хәер, бу мәхшәрдә очраклы гына, юлда, дөресрәге, шушы мал абзарында гына танышкан-табышкан кешене табарлыкмы?

—Баба, анады!..—дип кычкырып жибәрде улы Морад һәм Мәмдүдәнең кызларына кулын селкеде.—Рәшидә! Сәгыйдә! Без биредәмез!..

Мәмдүдәнең берсеннән-берсе сылу, һәркайсы колачына сыйдыра алганчы чыбык-чабык колачлаган дүрт кызы аларның артыннан йөгереп килеп тә житте.

—Анабыз су китерәдер!..

Рәшидә, Сәгыйдә,Зәбидә, Кагыйдә. Дүртесе дә бер үк тукымадан тегелгән зәңгәр күлмәктә. Гүя бер төп, бер тамырдан үскән дүрт чәчкә. Алар елмайганда да бергә елмая, елаганда да бергә елыйлардыр кебек.

Морад, уянып, күзен ачарга өлгерми, алар инде шушы сасы вагонда да чәчләрен тарап үреп, нindидер ислемай белән майлап та куйганнар. Кызларны табу куанычыннан мавыккан Морад кинәт йөзен чытты. Яланаякларын очлы таш суерды. Әмма малай сиздермәде.Елмайгандай итте.

Мондый курчактай матур кызлар каршында жиде яшьлек малайның да үзен ир итеп тоярга тырышуы да бер ядкарь иде. Улының сыкрануын Бекир сизмәмешкә салышты. Бала—бала инде ул. Ә менә аның сабый зиһененә барып житмәгән кайгысы Кара-Даг таулары кебек ифрат та зур. 18 май иртәсендә, көтмәгәндә, Карасу-Базардагы йортларына бурзайлы солдатлар бәреп керде һәм ерак юлга җыенырга кушты. Җыенырга нибары ике сәгать вакыт бирделәр. Ни сәбәпле? Җавап юк. «Хатыным ике нарасыем белән ата-анасын күреп кайтырга Җанкайга китте. Көтик»,—дип кат-кат ялынган булды ул, беркатлы. Юк. Сөйләшмәделәр дә. «Борчылмагыз. Сезне Акмәчет вокзалында кавыштырырлар». Бар, кавыштырдылар. Акмәчет вокзалы ул минутларда халык яшендә йөзде. Халык кадәр халыкны менәрләп рәткә тезделәр дә, кырымтатар милләтенең сатлык җан милләт булуы, аларның мәңгелеккә туган җирләреннән куылулары турында хөкүмәт карарын укыдылар. Һәм мал кебек шушы эшелоннарга куып кертеп, каядыр алып киттеләр. Кая? Әйтү юк. «Барып житкәч күрерсез». Нинди сатлык булсын алар? Нигә сатлык җан? Әтисе сугышның башында ук Ржевта ятып калды, үзе, юл эшендә чатан калып, берничә көн элек кенә хезмәт фронтыннан кайтты. Аларда һәркайда фронт. Хәтта гаилә түшәгендә дә фронт. Нишләтәсең, язмышлар шундыйдыр. Әнисе дә, инде иллегә якынлашып килүенә карамастан, Севастопольдә оборона эшләрендә җәфа чигә... Менә жиде көн, жиде төн ут йота Бекир хатыны һәм кызы, улы турында уйланып. Моратына ничек кенә дә җавап бирә алмый. Әни кая да, апам кая? Әни кая да, энем кая? Табышырлар, кавышырлар микән алар? Бекирнең кара уенча, бу эшелонда гына иллеләп вагон. Һәр вагон саен йөзәр кешедән генә дә биш мең кеше дигән сүз. Әгәр кырымтатар халкының санын сугышка кадәр хисап буенча ике йөз меңнән генә алсаң да бу кырык шушындый эшелон дигән сүз. Каян табасың? Кайчан? Кайда?

Бекирнең үкенечле гарьлектән күңеле тулып, елыйсы килеп китте. Ул һушын җуяр дәрәҗәдә тетрәнеп, үз гомерендә беренче тапкыр үз хатыны, үз туераларыннан, аларның җир өстенә төртеп чыгып, яңадан җиргә кереп качкан тамырларыннан сорамакчы булды: кайда аның Фирдәвесе? Өч яшьлек Сабиры, биш яшьлек Каракүзе кайдалар икән, илаһым?!

Ярый әле, каяндыр бер кулына су тулы чәйнек, икенче кулына су тулы кечкенә кара казан тоткан Мәмдүдә килеп чыкты. Бекир тиз генә, ир-ат җәһәтлеге белән таллардан таган корапштырып, учак тергезде. Ярый әле, үзе белән шырпысы бар. Тәмәке тартмаса да, шырпы алырга онытмады ул өеннән. Песиләре, этләре кычкырып, абзарларында савылмаган сыерлары бакырып калды. Һәммәсенең дә шулай. Ватан, гомер буе җыйган-туплаган мал-дөнья калды.Кайберәүләр каушауларыннан малын гына түгел, кияр күлмәк-чалбар, ут тергезергә шырпы, ипи-тозлык акчасын алырга да оныткан.»Сез хәзер дәүләт хисабыннан яшәячәксез»,—дисәләр дә, боларга акчасыз юлга чыгарлык ышаныч бар диме? Мәмдүдә—ярый ла ушлы хатын. Балаларына юлга кием-салым да, ашарга бераз азык-төлек тә хәстәрләп өлгергән. Менә хәзер ул эшелон житәкчелеге тарафыннан һәр җан иясенә берәрдән таратылган балык консервысын ачты, эчендәге ризыкны инде кайнап та чыккан суга салды... Мәмдүдә кешегә карарга яратмый. Ул казанда кайнаган суга караган да каткан: мөмкин булса казанга төшеп, су урынында үзе кайнаган булыр иде. Ябык, бик тә ябык тәнле ул. Йөзе саргайган булса да мөлаем. Яулык астыннан икегә аерылып күренеп торган чәче чалара башлаган. Бар, чалармассын ди. Ирең, Кызыл Армия офицеры, өлкән лейтенант, фронтта кан коеп йөресен, сине дүрт балаң белән куып алып китсеннәр, ирең бу хакта белмәсен дә!.. Кайгылардан шулай кипкәнме ул?

Әллә нәселеннән шундый какчамы? Кая ди сорашырга? Кешедән, бигрәк тә биш-алты көн элек кенә, вагонда урыннарының янәшәдән туры килүе нәтиҗәсендә генә танышкан хатын-кыздан, шундый нечкә нәрсәләрне сорашып буламы? Урынлымы?

Шунысын гына белешеп өлгерде—Бакчасарайдан икән алар. Чыгышы белән Казан тарафларыннан. Ире утызынчы еллар башында шул Казанның татар-башкорт хәрби мәктәбендә укыганда танышып, өйләнешкәннәр. Ә менә Мәмдүдәнең Бекирдән гаиләсе турында бер нәрсә дә сорашканы юк. Тартынамы? Урынсызга кузгатып, күнелен яралармын дип уйлыймы? Әллә гадәте-холкы белән шундый тыйнак-сабырмы? Кайвакыт аның ул сорамаса да сөйлисе, күнелен бушатасы килә. Менә ашы да пешеп өлгерде. Монда һәр минут исәптә. Ике сәгать үтеп өлгерми, конвоирлар һау да һау кычкыра башлый. Мәмдүдә шуна күрә ашыга.

—Балалар, киленез! Утырыгыз!..

Ул җәһәт-җәһәт кенә калай тустаганнарга шулпаны салып та өлгермәде, аның дүрт «күгәрчене» бишенче чыпчык кыяфәтендә ияргән Морад тустаганнар алдына килеп тә тезләнделәр, төпләреннән кашыклары белән тормыш тавышларын актарып чыгарып, менгезә дә башладылар. Читтән караганда балалар гына утырган бу табын зәңгәрдән ялган дүрт асыл яшме ташын һәм алар уртасындагы бер ир бала—таш балбалны хәтерләтә иде. Елга буендагы биек өянкеләрдән булса кирәк, ач каргалар каркылдашты. Мондый каркылдау кешеләр табырындагы куркыныч тынлыкны тагын да фаҗигалерәк итте. Бар тирә-як, биш мең кеше, тавыш-тынсыз, куркытылган мал кебек, күзләрен күрше-күршесенә сирәк-саяк аларткалап куеп, мышнап тын ала һәм күши иде... Морад аптырады: мондый киеренке тынлыкның бәлки төрмәдә дә булуы мөмкин түгелдер. Үзләре ректә, әмма алар төрмәдәгеләргә караганда да хокуксызраклар. Шуна да сакчылар алардан ныграк курка кебек.

—Син үзең дә аша...—диде тәмам хәлсез күренгән Мәмдүдәгә.—Барасы юл ерак...

—Ю-у-ук, ашыйсым килми...—диде хәлсез генә Мәмдүдә.—Син үзең аша. Син ир кеше...

Балалар ашаган унайда Бекир юл капчыгыннан кечкенә төенчек чыгарды. Талкан ярмасы ул. Җир йөзендә иң җинел, иң туклыклы ризык. Борынгы төркиләр ашы. Аны бодай орлыгын бүрттереп, Фирдәвесе 1944 ел уразасын тотканда сәхәр ашы итеп әзерләгән иде. Кем уйлаган, татар-мөселманның сәхәр ризыгы мәхбүсләрнең юл ризыгына әверелер дип? Ул төенчеген чиште һәм Мәмдүдәгә сузды. Мәмдүдә эченнән генә бисмилласын пышылдап, сөяк буынлы бармаклары белән төенчек авызыннан эчкә үтте һәм аннан ике кушуч кызгылт талкан ярмасы чыгарып, җәйпегә салды.

—Күбрәк ал...

—Җитәр. Кем белә. Әле юл ерак...

Ул чак-чак кына түзде. Нәрсә сөйли бу Мәмдүдә?! Авызыннан җил алсын! Юллар моннан да ерак була күрмәсен! Бекир аңа ачуланып карагандай булды. Моны балалар да сизенгәндәй итеп борыннарын мышкылдаттылар. Мәмдүдә ул-бу булмагандай талканны чайкады һәм уч төбеннән кара казанда кайнап торган суга сала башлады... Балаларга монардан да тәмлерәк азык булмаячак иде. Талканны пешерергә күп вакыт кирәкми, ул, кем әйтмешли, яхшы кеше кебек тиз пешә. Бекир тагын да бер тапкыр каяндыр Казан якларыннан килеп, тугандаш кырымтатар халкының язмышын уртаклашкан язмышташы Мәмдүдәнең йөзенә игътибар итте: ул йөздә татар хатыннарында гына була, дала халкыннан гына кала торган җир-су хәсрәте, кояш чилләсенең янып бетмәгән ялкыны

бар иде. Ул аның корыган камыштай кипкән беләкләренә, чут төймәсе кебек йөгергән сөяктәй каты бармак буыннарына игътибар итте. Һәм тетрәнде: алар яратмыйча эшләгән, җәфалы хезмәт кенә бар итә ала торган гариплекнең үзе бер сәнгать әсәре иде. Күпме алар үткәнендә кырымтатар кавеме белән кушылып,бүген аның каһәрле язмышын уртаклашкан төрки һәм башка милләт вәкилләре?! Бекир Мәмдүдәнең озак еллар Бакчасарай банкында баш бухгалтер булып эшләгәнен белә иде инде. Аның өчен җир йөзендә болардан да бәхетсезрәк куллар булмагандыр кебек күренде. Гүя алар халык яше—халыктан башкалар, бары читләр өчен талап алынган салым акчасын санап изелгән, кипкән, үзенә түгел, халыкка бер тиенен дә кайтарып бирә алмау фаҗигасеннән корыган иде. Каяндыр әкрен искән җил белән җыр ишетелгәндәй булды. Табаклардан балалар ашаган тавыштан чәп-чәп итеп килгән авазлар арасында җилдә,төтен ысында өзлегеп, чак кына ишетелерлек итеп көйләнгән көй колакка шәйләнә иде. Балалар да колакларын шомрайттылар. Әмма бу җырны беркем дә бүлдермәде.Аны чак кына ишетелерлек итеп шушы дүрт асыл кыз баланың аналары, Бекирның сабырлардан-сабыр язмышы, кем белә, бәлки ничә генә көн яшисе калган Мәмдүдә җырлый иде:

Үтәсең лә, әй, гомер, әй, үтәсең,
Картаеплар хәрап итәсең.
Картаеплар, әй, хәрап итәсең,
Ашыктырып ла гүргә кертәсең...

Балалар белән бергә кайчандыр газиз хатыны хәстәрләгән талкан боткасын Бекир дә капкалаштырды. Башкалардан калган шулпаны һәм талканны Мәмдүдә үзе ашаштыргандай итте. Тимер вагонның чырайны киптерә торган һавасыннан киң яланга чыккан балалар тамак туйдырганнан соң башка балалар белән уйнаштыра башладылар. Әгәр дә шушы киң тугайлардан төртелеп торган мылтыкларны, акырып торган конвоирларны, өреп торган бурзайларны алып китсәң, бу берәр айдан печәнлеккә әвереләчәк иркен дала шундук халык җыены,сабантуй, бәйге мәйданына чыгарга тиеш булмаган боҗраны сызып куйганнар иде шул. Ял вакытында бер күзләре йокымсырап китсә, икенче күзләре кизүдә—дежурда тора аларның. Кайдадыр еракка сузылган табырның очында шарт-шорт аткан тавышлар да ишетелеп куя. Берәр юләрбаш качарга маташканмы, әллә куркыталар гынамы? Шуңа яктылык та караңгы иде биредә. Бар идеме монда кояш, әллә ул юк идеме—беркем кояшны да эзләп маташмады, чөнки кояш та, Мәмдүдәләр һәм шушы сабыйлар кебек, сакчылар боҗрасы эчендә корый-коргаксый иде...

Табак-савытларын күз ачып йомганчы елгада чайкатып та өлгергән Мәмдүдә, әллә балалар мәшәкатеннән арынган шушы мәлне көткәнме, табындагы әйбер-сәйберне кире вагонга алып керер өчен төйнәштерә башлаганда Бекиргә якынрак килде һәм:

—Гаиләң бардыр бит? Кайдалар соң?—дип сорап куйды.

Сорау көтелгән булса да, сөйләр вакыт көтелмәгән иде. Гүя аңа бу соргылт далада бар дөнья, барлык татар карап, аны тыңлап тора иде. Юк, ул үз кайгысын монда, яктыда сөйли алмый иде. Моның өчен караңгылык кирәк! Ул нишләргә белми карашы белән балаларны эзләде.

Инде уйнап та туйган балалар исә сирәк-сарак үлән яшеле төртә башлаган комлыкка җәелгән җәймә өстенә түшәлеп, әвен базарына китәргә җыеналар икән. Чабып-көрәшеп арыган Морадының инде күзләре дә йомылып маташа түгелме? Йокласыннар, иркен һавада тын алып калсыннар! Иртәгә кадәр туктамаячаклар бит алар!..

—Вагонга утыргач сөйләрмен, Мәмдүдә апа...—диде Бекир.

Һәм җәйменең бер иркен почмагына балалар белән беррәттән урын алып, башын төртте.Күктә болытлар да, кошлар да юк иде.Күктә бернәрсә дә юк иде...

Кинәт ул чаң суккан тавышка уянып китте. Ул айный алмыйча торды. Кайда алар? Нинди котсыз ялан бу? Аh, шулай бит әле!.. Кана, кай арада йокымсырап та киткән! Тукта, беренче генә чанмы әле бу? Әллә? Гадәттә, кузгалып киткәнче чанны өч тапкыр сугалар. Төннәр-көннәр буе йокысыз килеп кызарган, ком тулгандай авырткан күзләрен ул авырлык белән ачуга, аңлады: кузгалырга боерык булган икән. Кемнәрдер төенчекләрен әләктерә салып, инде вагоннарга таба йөгерешә дә башлаганнар. Куркуга төшкән Бекир тирә-ягына күз салды: зәңгәр күлмәкле кызлар урында, җәймә өстендә, ә менә Мәмдүдә дә, аның әнисенә охшап кызгылт чәчле, сипкелле улы да юклар!.. Конвоирларның каты кычкырып боерган тавышлары ишетелде. Ул нишләргә белмичә әйбер-сәйберне җыештыра, сабыйларны юлга ашыктыра башлады. Юк, кем, нәрсә? Улыңны эзлә, акыллы баш! Ул кулындагы төекчекләрен кызларга тапшырып, иксез-чиксез далага таралган табыр буйлап йөгерә башлады:

—Мор-рад!.. Мор-рад!..

Һәркем үз кайгысы белән мәшгуль булган бу мәхшәрдә ата улны, инә кызны табарлык түгел иде. Менә теге аяусыз чаң икенче тапкыр сукты.Бу кансыз аһәң Бекирнең буыннарына салкын боз булып утырды. Аның мие яшен тизлегендә эшли иде. Кире урынына кайт, диде аңа нindидер тавыш. Кайтса, кулларына юылган керләрен тоткан Мәмдүдә елга ягыннан йөгерә, әмма Морад аның белән дә түгел иде!

—Морадны күрмәдеңме, Мәмдүдә апа?!

—Яһ-һү-ү!.. Жоктыр!..—диде үзе дә куркуга төшкән хатын.—Мин керләрем артыннан киткәндә монда калган иде!.. Су керергә дип шылмады микән? Яһ-һү-ү!..

Бик мөмкин! Бекирнең исенә төште, улы бернichә тапкыр мондагы елгада су кереп чыгу, балык тоту турында тенкәсенә тиеп алган иде. Әтисе аны кола яланда ялгызы торып калуы белән куркыткан һәм бу хакта бүтән сүз кузгатудан да тыйган иде. Димәк, тыңламаган шайтан малай! Ул, тере адәм баласы, балалыгы белән үзен тере табигатьтә яши, бу тере табигать аның өчен яратылган, аның үзенеке дип уйлый, күрәсең. Юк шул! Табигать тере, әмма алар өчен һәм аларныкы түгел!

Инде сакчылар барысын этә-төртә вагоннарга да куа башладылар.

—По ваго-на-а-ам!...

Тәмам кайгыга төшкән Бекир кулындагы төенчекләрен шытырдатып кысып, акылдан язган болан шикелле тасырдап, күз карашы җиткән кеше дингезе буйлап янадан йөгерергә тотынды:

—Мор-ра-а-ад! Бал-ла-ка-а-ем!..

Менә чаң өченче тапкыр сукты. Эшелон буйлап ишекләр ябылган, лызгылдап йозаклар бикләнгән авазлар савылды. Баласыз да калган ата үз кайгысын Шиһабетдингә татарча аңлатса да, ул аларган күзләре белән берни эшли алмаган кыяфәттә каткан иде. Нишләсен, ул үзе дә үз туганнарын читкә куып алып китү өчен куып китерелгән колларның колы иде!..Башкалар да әллә аңламагач, әллә аңларга теләмәгәч, белер-белмәс урысчасы белән төшендерергә тырышты, әмма һәр секунды кеше затына каршы куелган эшелонның тимер тәртипле тегермәнендә кая ди аны аңларлык, аны аңларга теләгән кеше дә юк иде.

Менә ул күзен елга ягыннан алмыйча башта кызларны, аннан Мәмдүдәне эшелонга сикертте, инде тагын бар тапкыр «Эзләп кенә килим!» дип

анлатырга тырышкан икенче бер сакчы анын җилкәсеннән тотып, вагонның ишек кашагасына деңкетте:

—Сикер диләр сиңа!..

Менә ул соңгы секундларны да үз файдасына кулланырга тырышкан ата теләр-теләмәс кенә, ыңгыраша-ыңгыраша, кайчандыр төрки бабайларыбызның дәүләт башкаласы булган Хәрәбәле туфрагында җир йөзенең иң каһәрле, иң имансыз, иң кешелексез империясенең мал абзарының караңгы карынына шуышты...

Аһ! Бекирнның инде бу улы да үзе белән түгел иде.

Менә тимер ишекне тәгәрмәчләрендә тәгәрәтеп яба башладылар. Улы һаман анын янында юк иде. Инде состав кузгала да башлады. Улы мылтыктагы курокта да, офыкта да күренми иде, Ходаем!..Состав инде йөгерә дә башлады. Ишекне яптырмаска тырышып, Бекир аркылы ятарга тырышты, әмма ике сакчы аны эчкә сөйрәделәр. Нәкъ шул чакта таллыктан чыгып, алар артыннан сабый күзгә чалынды. Әйе, ул Бекирнның светофор кебек җиз чәчле, сипкелләре әллә кайлардан яктырып торган улыкае—Морады иде!

—Әт-ти!.. Әт-те-кә-ә-ем!..

—Тукта-а-а!..

Әмма эшелон туктамый, әллә машинист бу хәлне күрми, әллә күреп тә туктатмый, әллә җитәкче команда биш мең мәхбүс өчен бер тамаша—онытылмаслык сабак күрсәтә иде. Аңа әллә ни каршылык күрсәтмәгән Шиһабетдингә ярдәмгә дип вагонга күтәрелгән ике өстәмә сакчының үзен кыскан куләшчәсен ике якка селтәп ыргытып, Бекир вагонның почмагындагы стоп-кранга ташланды һәм аны аска тартты, вагоннар туктар-туктамас хәлдә берсе икенчесе өстенә менәрдәй булып тартылды. Бекир исә әле бикләнеп тә өлгермәгән ишекне шәрран-яра этәреп, җиргә сикереп төште һәм улына таба йөгерде. Ул бу минутта аңа җиргә төшәргә мөмкинлек биргән Шиһабетдингә ул чиксез рәхмәтле иде!..

Сабый йөгереп хәле бетүгә караганда күбрәк атасын куып җитә алмаудан куркып хәлсезләнгән, алҗыган иде. Малайның йөрәге, күкрәк читлегенә сыя алмагандай, дарс-дарс типте. Анасыз, бертуганнарсыз калган сабыйның атасын табу куанычы тәмам хәлен алды. Шатлык тезенә сукты. Бу нечкә күңелләр белән аеруча шулай була. Алар кайгыны җинел күтәрсә дә, шатлыкны күтәрә алмый. Һәр омтылыш анын хәлен алды, тынын куырды. Күз аллары караңгыланды. Әтисе моны сизенгәндәй, колачларын җәеп, аңа якынлашты. Улын коткара алсын өчен аңа мөмкинлек биреп, анын артыннан җай гына мылтыклы Шиһабетдин теркәлди иде... Инде тәмам туктаган паровоз ни сәбәпледер йөрәк ярып кычкыртты. Бу тавыштан анын җанында ниндидер кыл өзелгәндәй итте, күз аллары караңгыланды, йөрәге инде күкрәген ташлап чыгардай сикерде. Атасы аңа, ул әтисенә якынайганнан якыная иде. Кем белә, кем үлем белән яшәү арасындагы бу хәлиткеч араны аршыннар белән үлчәгән? Биш йөз, өч йөз, ике йөз адым?.. Менә ул, бәлки, егерме омтылыш калгач, атасы белән кавышып, анын кулларына авам дигәндә генә лап итеп җиргә егылды. Бар нәрсәсен оныткан, әмма үзенең дә хәле беткән Бекир, малай табылды, инде ашыгасы юк дигән уйда сыман, туктады, көткән эшелон көтә бирсен, дигәндәй, үзенә карап торган меңләгән караш алдында улының өнсез яткан гәүдәсенә ашыкмыйча гына атлады, ниһаять, килеп җитте һәм бер җинүче кыяфәте белән тынсыз гәүдәсен күкрәгенә кысты:

—Улым!..

Малай «ыһ» дип тә җавап бирмәде. Анын лычма киемнәреннән шарлап су агып торган, кызгылт чәчле, сары сипкелле Морады тынсыз иде. Үз

күзләренә үзе ышанмаган Бекир сабыен жиргә сузып салды һәм колагын йөрәгенә куйды. Йөрәк исә типми, урлашып булса да су керергә уйлаган малайның йөрәге олаудан торып калу кайгысыннан чаба-чаба һәм бер әтисен күрү шатлыгын күтәрә алмыйча шартлаган иде...

Бекир сабыйны күтәрде һәм бүтән беркая да аягымны атламаячакмын дигән рәвештә туктап калды. Күзләре кызарган Шиһабетдин дә ана бер сүз эндәшмәде. Алда, аларның вагоны каршында, Бекирләргә ярдәмгә дип жиргә сикереп төшкән Мәмдүдәне, анын зәнгәр яшмегә охшаган дүрт кызын сакчылар, каз бәпкәләре кебек чыркылдата-чыркылдата кыйный, кире вагонга ыргыталар иде...

Кинәт ату тавышлары янгырады.

Ата һәм атасы кочагындагы жиде яшьлек сабый гөрселдәп жиргә аудылар. Алар артыннан милиционер Шиһабетдин дә гөрселдәде.

Бекир Мәмдүдәгә үзенең нәсел-гаилә шәжәрәсен, Фирдәвесе белән ике йөрәк парәсенең югалу тарихын тынычлап сөйләргә өлгермәде.

Паровоз янә йөрәк ярып кычкыртты. Бу өч кеше—өч колнын гәүдәләрен күмеп торырга вакыты булмаган күп кешеле эшелон Рәсәйгә, Самара тирәләрендә югалып калган Кинәле борылышларына таба юл алды.

Үз жирләреннән куып алып кителгән ике кырымтатар баласы—Бекир һәм Морад Нематуллаевларның һәм аларны куу өчен куып китерелгән Казан татары Шиһабетдиннәрнең гәүдәсе күмелмичә-нитмичә үз жир-тупракларында—кайчандыр Алтын Урда ханнарынын жәйге башкалаларының берсе Хәрәбәле сәхраларында козгыннарга азык булып калды.

Ярты сәгать тә үтмәде, эшелон начальнигы полковник Кравченко вагонында әле генә булып узган кечкенә инцидент буенча кечкенә кинәшмә үткәрелде.

—Без аларны исемлектән сызарбыз, иптәш полковник,—диде эшелон начальнигы урынбасары подполковник Сухоруков.—Расхутка. Ике чучмектан илгә зыян килмәс.

—Ә өченчесен?—диде көлемсерәп полковник.—Ул бит кырым татары түгел.

—Барысы бер нәсел этләре, иптәш полковник. Бакчасарай этләрен куып алып китеп барабыз, Казан этләре чиратын көтә... Бу очракта хәрби командование боерыгын үтәгәндә батырларча һәлак булды, дип гаиләсенә хәбәр итәрбез...

—Монысы белән килешәм... Шулай да кисәтеп куям. Чучмек үлеменнән илгә зыян килмәсә дә, үзегезгә зыян килүе бик мөмкин,—дип төзәтте аны полковник.—Казан татары үлеме бушка төшсә, кырым татарлары өчен түләргә туры киләчәк. Репрессантларны Үзбәкстан органнарына тапшырган вакытта шушы ике кырым татары урынына вагонга исәп өчен адъютантыгыз Стукачев белән үзегезнен кереп утыруыгыз бик мөмкин.Онытмагыз, безнен эшелон—007 литерлы үрнәк эшелон!.. Тимер тәртип!.. Социалистик ярыш!.. Кырым татарларына бүленгән житмеш эшелон арасындагы ярышта кан коссак та беренче булырга тиешбез!.. Үрнәк эшелонда үлмиләр. Үле жаннар Николай Васильич Гоголь әсәрләрендә генә була!..

Бу минутта бу хәлләрне күреп торган елга агуыннан туктаган, комнар кеше чәче кебек агарган иде.

Дистә еллар үтте, әмма елганың да, ком бөртекләренең дә әле булса үз хәлләренә кайтканы юк.

# Viktoria

*Балачак дустым Вәрис Сөләйманов истәлегенә*

Уздылар.

Инде байтаклар узып китте. Куян Сәйфетдин дә... Ул аны биш тармактан камчы үрергә өйрәткән иде. Күпис Гомәр улы Фаикъ та узды. Анысын өрәнге чаңгыларны мунчада ничек итеп пешекләргә, бөгәргә өйрәткән иде. Кемнәр уза бит!..Кызлар уза!.. Аларга үзләре ясаган җинел чаңгыларда рәхәт шул. Янәшәдән юртаклаган ат юлыннан үткән-сүткән юлчылар, танып, «Һи-и, Сабирҗанның төпчеге бөтенләй дә күтәрәмгә калган икән, диләрдер инде»,—дип, Канәгать гарьлеген кая куярга белмәде.

Карда пыяла кискән тавышлар чыгарып, тагын кемдер узып маташа. Малай боз сарган керфекләре аша кистереп карады.Үтерерлек дәрәҗәдә ачы нәфрәт бар иде бу караштa. Песи Хәнифе икән, хөрәсән. «Башындагы тазын кашыйсы урында... «—дигән ачулы фикер узды малайның башыннан.

Ә аның эшләре чынлап та хөрти, хәле хәл өстендә иде. Мондый көлке халәттә калыр диеп кем уйлаган? Таң сарысы түгелмәс борын уянган улына әнисе еландай телләрен чыгарып әйтте түгелме? «Авыр бу чаңгылар, улым, аларны өстерәү өчен генә бер ат көче кирәк. Үзеңнең иске чаңгыларыңны алмыйсыңмы?»—дип артыннан ялынып калмадымы? Әмма сер бирмәде Канәгать. «Үзем беләм!—дип масаебрак та җавап биреп куйды әле житмәсә. —Менә, көт тә тор, авылның иң җитез чаңгычысы данын алган улың бүгенге ярышта беренче урынны яулаячак! Мине алда район, Уфа күләмендәге ярышлар көтә, әни!»

Ә чаңгылары шумый. Алар барган саен чуен кебек авырая, алга талпынган саен артка шуышалар кебек.Үзенә-үзе чыккан ачуыннан иреннәре чүбектәй чәйнәлеп бетте. Ә ул һаман талпына да, талпына. Аның белән бергә чачакланган, чачакларына аяк җылысыннан төймәләнеп кар сарган иске чабаталары да, чаңгыларының нәфис итеп уелган, сыртларына нимес хәрефләре белән «VIKTORIA» дип язылган очлары да, ак әлүмин аеллы, карап торуга матур, шыгырдавык, чучка каешыннан юнәтелгән өзәңгеләре дә талпына, табаны астында сабый бала кебек чыелдап, кар елый—тик алга гына бара алмый, гүя талпынган саен урынында таптана.Тыны бетеп, аптырап, артына борылып карый. Юк, шуышкан була икән анысы. Артыннан бердәнбер анарда гына булган чын, «фабричнай» чаңгылардан гына кала торган матур сызыклар да кала калуын. Аларның табаннары буйлап шундый уем уелган. Арттан элемтә чыбыгы кебек сузылып бара. Тотып карыйсы килә. Ә менә үзләре ясаган авыл чаңгыларыннан андый эз калмый. Канәгатькә кыйммәткә төшә бу үзе салган нәфис сызыклар. Ул гынамы — алар ана каршы эшлиләр иде. Матур эзләрдәмени эш? Төкерә Канәгать эзләренең матурлыгына, финишка беренче булып килмәгәч!.. Тик шунысы: бу чаңгылар авыл чаңгылары кебек тар түгел, алар киң, бәлҗерәгән чабаталардан да кинрәк, алар теге, жирле, үзләре юнган чаңгы эзләренә сыеша алмый, лап-лоп уйнаклап, артка сөйриләр кебек. Мондый чаңгыларны ул үзе генә түгел, авылда, мәктәптә, Миякәдә, Уфада бер генә кешенең, хәтта физкультура укытучылары Гариф абыйларының да күргәне юк. Габдрахман бабасы аларны «нимеский чангылар» дип кенә җибәрә. Ниткән «VIKTORIA» икән ул? Нәрсәне аңлата? Нимес сүзе булган булса нимес теле укытучысы булган шул ук Гариф абыйлары да белми икән...

Янәшәсендә генә ниндидер туң агачка суклыгып коры шакылдау авазы шәйләнде. Аркасындагы букчага салынган утын түмәре шулай шакылдамыйдыр ла? Юк ла. Аркадан берниндн тавыш-тын ишетелми.

Ярдәмгә йорт ихаталарындагы Ат Башы килгән мәллә?! Малайга көч кергәндәй булды.Тирә-ягына каранды: юк, бернинди дә баш сөяге күренмәде. Әле сугыш алдыннан әтисе элгән булган ул Ат Башын казыкка. Мин кайтканны көтеп тор, дип фронтка киткәндә ул Баш белән хушлашып та киткән. Кайтмады әтисе сугыштан. Ә менә Ат Башы ярсу җилләрдә, шулай әлеге кебек, коры шакылдап, бар ихатаны сискәндереп куя. Әнисе сөйләвенчә, картәтиләренең мал-туары белән бергә «Ак аргамак» дигән нәселле бияләрен дә тартып алганнар. Колхозның тиле-миле ат караучысы бер мәлне «тыңлаусыз кулак малы» дип биянең башына тимер башлы тәртә белән орган. Миенә кан савып мингерәүләнгән бия иске хәтере белән иске ихатасына кайтып, колынын салган да җан биргән. Казыкта шул нәсел биясенең башы шакылдый. Бүген таңда мәктәпкә дип ишектән чыкканда да казыгында шулай шак-шок чайкалып озатып калган иде...

Канәгать үзеннән һич кенә дә канәгать түгел иде. Хәле бетүдән еш тын алган малайга тез буыннары белән бергә менә-менә биле дә шартлап өзелер кебек.Таңнан кәтрә дә азык күрмәгән ашказаны да суыра башлады. Үзен бер җинаятьчедәй тоеп, тирә-ягына карарга куркып, таеш табанлы чаңгыларыннан күзен алмыйча алга сөрлеккәндә күз аллары элҗе-мелҗе килеп карангыланып куя. Өсте-өстенә явып торган карлар җил себертмәсе һәм аның үзеннән килгән җилдә буранга әверелеп ала, ап-ак кар кан булып кызара, әле генә Гариф абыйларының аягындагы яхшы күн итек кебек аяк астында шыгырдаган, он кебек порхылдаган карлар бер караганда кинәттән җепшегән, юеш ләтчәгә, икенче караганда киредән коры онга әйләнә сымак. Ул таштан авыр тоелган чаңгыларына бер карап, бер, ике карап, ике җылый иде.Җыларлык та шул: менә бүген, 1955 елның 22 февралендә, Эстәрле белән Ырымбур урталыгы, дөресрәге, Камышлы һәм Олы Кәркәле авыллары арасында яткан чана юлы янәшәсеннән йөгергән нәзек чаңгы юлы, урманнар-таулар, юл буендагы көрттән тырпаеп торган маяк-чыбыклар, ботакларын бәс сарган агачлар, моны күргән һәм күрмәгән, бу хакта белгән һәм белмәгән җәнлек-җанварлар—барысы иртәгә булачак Совет армиясе бәйрәме хөрмәтенә, өйләдән соң, соңгы дәрес итеп үткәрелгән мәктәпкүләм чаңгы ярышы вакытында җир йөзен таң калдырырлык, ин кискен, драматик, кем белә, бәлки сирәклärдән-сирәк фаҗиганең сүзсез шаһитлары иде. Мәктәпнең иң житез чаңгычысын, кая ди беренче урынны яулау, икенче, унынчы, хәтта илленче урынны яулый алмау гарьлеге, бары тик беренчелеккә ирешү комары, туйганчы дан туртасын эчү, танылуны тансыклау аркасында финишка да барып җитә алмау хурлыгы көтә иде...

Арттан лапы-лопы килеп тагын да кемнеңдер куып килгәне ишетелә. Малайның туры йөзе чалшайды, чырае сытылды. Сунарчыдан качып килгән боланмыни!..Менә-менә куып җитәр, җинел авыл чаңгысы белән аның авыр чит ил чаңгыларына басар һәм ул сөрлегеп авар кебек тоела Канәгатькә. Күзләрен генә түгел, арка үзәкләрен әчетеп, кара тир йөгерде. Ул бүген үзендә беренче тапкыр сәер, ят тойгы яратылганын сизенде: бу тойгы ярату-яратмаудан өстен иде.Беренче буласы килү никадәр көчле булса, аны узып китәргә үзләрендә көч һәм батырчылык тапкан дусларын күрә алмау, алардан кара көнчелек белән көнләшү, нәфрәт тә шулкадәр көчәя кебек иде. Арттан йөрәк маен сызып килгән теге чаңгы тавышы аны куып та җитми, ни өчендер узып та китми. Кем булыр? Борылып карарга курка, караса—йөрәге шартлап чыгар кебек. Кинәт Канәгатьнең туктыйсы, әнисенең бертуган абыйсы урманчы Габдрахманның келәтеннән алынган бу мәгънәсез, зыянлы, үзе йөгертү түгел, йөгерергә бирмәүче шайтан тактасын, бу авыр чуен булып өстерәлгән яссы түмәрләрне, чучка каешлы елтыр аеллары белән бергә салып ыргытып, кыйныйсы, йодрыклап төясе,

аннан, болгап-болгап, чүплек башына томырасы... Дулкынлануыннан малайның өсте-өстенә менгән фикерләре бүленде, тыны тыгылды, йөрәге дарс-дарс тибә башлады... Нимес чаңгысы, имеш! Матур, унайлы, үзе шуа, тирә-якта күрелмәгән, тагын да әллә нинди серле сыйфатларга ия булган «трофей малы», имеш...»Трофей» дигәнен дә әнисе генә аңлатты бит әле. Җиңелүчеләрдән җиңүчеләр талый торган мал шулай атала икән. «Безнең Габдрахман абзый да җиңеп кайтты инде, ичмасам!—дип өзгәләнде әнисе бер тапкыр.—Юньләп сугыш та күрмәгән әтрәк-әләмнәр машиналар, машиналарына төяп, йөк-йөк мануфактур, кием-салым алып кайтсалар, безнең абзый Берлинга барып җитеп, калхуз трахтырына магнита дигән туң тимер һәм үзенә, лисничигә кирәк булыр дип, шушы урман чаңгысы дигән туң түмәр күтәреп кайткан, адәм тәганәсе! Анысы да келәтендә аунап ята!..» Әйе, аны көлкегә калдырган трофей чаңгылар урынына «Сәнкә» урманнарыннан кар ерып, үзе алып кайткан, үзе юнган, мунча парында үзе бөккән, инде дә шушы минутларда бәлки җылый-җылый аны чоланнары почмагында көтеп утырган, гади юкә баулы, майсыз да майлагандай итеп шуа торган иске өрәңге чаңгыларын тагып, барысын да узып китеп, беренче булып киләсе килеп китте...И-и-их!.. Кая ди ул! Ахмак!.. Юләр!.. Җитәр-җитмәс!.. Кая ди монда узу? Финишка барып егыла алсаң, рәхмәт! Сыйныфташлары, мәктәбе нәрсә уйлый икән?

Менә авыл үре текәсендәге «Фәтхулла чишмәсе» дә күренде. Сабырлыгыннан иренен тешләгән Канәгать артына борылып, нәфрәтле карашы белән яланны көйдереп алды: аны узудан тыелып килгән малай... якын дусты Кыяметдин үзе иде!

—Уз!—диде ул туктап.—Узып кит!..

—Мин сине узалмыйм, Канәгать!—дип кычкырды Кыяметдин.—Син беренче булырга тиеш идең!.. Әйдә, мин синең арттан, бергә барыйк!..

—Уз дим мин сиңа!—дип зәһәрләнеп кычкырды күзләреннән коры яшеннәр очырган Канәгать.—Минем аркамда гына артка тәгәрәмә, парин!..

Кыяметдиннең Бәләкәй Авыл малайларының атаманы булган җан дусты Канәгатьне тыңламый көченнән килми иде. Ул аңардан шөлли дә иде.

—Ярар, үзең әйткәч...—диде ул җирдән карашын күтәрмичә.—Ярар, үзең кушкач... Син барыбер дә беренче!..—Ул теләр-теләмәс кенә читкә чыгып, янадан эзгә төште һәм үпкәчел тавыш белән мыгырданды.—Әйткән идем мин сиңа...Тыңламадың...

Кыяметдин ботак үзәгенә керергә теләми кәкрәйгән кадак кебек, боргалана-сыргалана, аңардан ераклаша башлады.Дусларның аралары якын, максатлары ерак иде шул.

Канәгатьнең гарьлегеннән анавы каеннарга эленгән ап-ак бәсле чук булып салкында катасы, шушы яланнарда мәңгегә торып каласы килде Ул җылый-җылый авыр сабан тарта, авыр сабан тарта-тарта җылый иде. Җылаганда күзләрендәге зәңгәре юыла һәм җиргә коелгандай итте. Шулай, әнисенең «чаңгы дигән түмәр»нең бабасы келәтендә аунап ятуы бик нык хәтеренә сеңеп калган иде малайның. Күрде ул аларны бабасы келәтендә бер тапкыр форсатын табып. Дөрестән дә шулай икән шул. Аунамыйлар аунавын. Бабасы аларны тагып, сирәкләп булса да төлке, куян сунарына чыгып кергәли. Табаннары киң, бер карыш булыр, үзләре уймак башлы, май сылангандай мыймылдап торган чаңгыларны күреп, малай ул чакта ук «И-их, бер генә тапкыр шушыларда җилдерәсе иде!» дип ымсынып та куйган иде югыйсә. Бирәсе килсә колына, чыгарып куяр юлына дигәндәй, мондый форсат та туып куйды бит әле. Әмма дә үз кулы белән келәттән алып чыккан шушы «нәмәстәләр» аны бөтен мәктәп алдында хурлыкка

калдырыр дип уйлаган идеме? Юк!.. Ничегрәк килеп чыгуын кара син анын, ә? Физкультура укытучысы Гариф абыйлары житеп килгән Совет Армиясе бәйрәме хөрмәтенә мәктәпкүләм чанғы ярышлары үтәчәген хәбәр итеп, ярышка «пулный баявой выклад» килергә кушты.Бусы нәрсә була икән тагын дип аптырап торганда тагын да шул Песи Хәнифе:

—Абый, пулный выкладны анлатыгыз әле?—дип сорап куймасынмы!

Үткән жәйдә генә хезмәттән кайткан, шуңа хәрби киемнәрен дә салып өлгермәгән абыйлары сүзне кыска тотты:

—Пулный баявой выклад—итты афтамат, если ес, ыручный пуләмүт, дискы-патрун, гранат, противогаз, вчә амунитсия, сухой паюк, консервы, ызначит...

– Абый, аларнын берсе дә бездә юк бит!—дип шаулашты балалар.—Алар бездә юк!..

—Разговорчики! —дип кырт кисте абыйлары.—Итты не имет никакой эзнәчинйе.—Сез будущымда салдат. Вишмишугыгызга груз урынына утын түмәре салсагыз дә мужны, ызначит!..

—Ә кәнсирвәсе нәрсә? Аны каян алыйк?

—Ну и ышту кәнсирвә?..—дип тешләрен ыржайтып көләргә тырышты укытучылары.—Әтнә кәнсирвә—дела нет, два кәнсирвә—тела нет...

Шунын белән сөйләшү беткән дә булыр иде, әгәр аны Канәгать озайтмаса. Теленә тилчә чыккыры!..

—Ә менә чын...фабрик чаңгысы белән килергә ярыймы, Гариф абый?—дип сорады ул бабасы келәтендәге үзләре очыртып йөгертә торган чаңгыларны исенә төшереп.

—Хет йортыгыздагы чуртыгызны жигеп килегез!—диде укытучылары.—Первый гына булыгыз, панятны? Бу—вапирвых. Вафтарых, Сибгатуллин, сездә никакуй фабричный чангы быть не може. Этта —Аз-зия. Этта тибе —ни Яврупа....

Шулай серле, әллә нинди, һич кенә дә кеше аңламас сүзләр кулланып сөйли дә, шулай иткән саен башкалардан акыллырак саналам дип, күрәсең, араларны бутый аларның абыйлары. Үзе гел генә урысча сөйләргә тырыша. Шунын аркасында ана армиядән кайткач та «Урыс Гариф» дигән ләкаб тә ябешеп калган. Халыкнын теле сөяксез, бер сөйли башласа, туктатып булмый бит инде аны. Имеш, авылга кайткан көннәрендә туганнары белән дә татарча сөйләшмәгән. «Әни, сөт бир!» дип әйтәсе урында «Мошмыйка, дай малака» дип кенә жиффәргән, имеш. Дөрестерме-түгелдерме, Фәйзулла бабайларнын улы үзен армиядә Гриф Фәмич дип кенә йөрткән икән. Булыр, булыр.

Шулай иткән саен хикмәтлерәк, акыллырак күренәм дип уйлыйдыр инде, күрәсең. Канәгать бу юлы да бер нәрсә аңламады. Шулай да:

—Юк, Гариф абый, ялгышасыз! Бар бездә андый чаңгы!.. Андый чаңгы бары бездә генә!..—дип әйтеп өлгерде.

—Не пәнимәю!..

Абыйларының чәчәк авыруыннан калган шадра йөзе ярмаланды. Әгәр моңа кадәр анын үзен аңламасалар, хәзер ул үзе башкаларны аңламый иде. Ул аптыраган кыяфәт белән кулбашын сикертте.

—Ә менә «VIKTORIA» дигәне нәрсә була анын, абый?—дип сорады Канәгать.

—Ызнат та я ызнаю. Вәт син, малайка, күпне белмә, тиз картаерсың!—диде ул урынында таптанып.—Ышту за писсимизм? Ты давай оптимизм!.. Ысмәтри, кәк билый эсниг тичут!..

Әмма укытучы тарафыннан булган бу тузыну башкаларга житә калды. Китте Канәгатьне сораулар белән кысрыклаулар: син нәрсә юкны сөйлисең?

Нинди була ди ул «чын чаңгы»? Фабрикныкы, имеш? Тапкан!..Каян чокып чыгарган, диген? Әй, шыттырса шыттыра инде бу Колтамак ярпачы!..

Канәгатьнең үз кайгысы үзендә иде. Чын чаңгылар турында ни дип кузгатты икән инде ул сүзне?

Алар Олы Авыл белән Кече Авыл арасындагы өч чакрымны җәяү йөреп укыйлар. Чын чаңгы турындагы өстәмә сораулар белән үзен газаплаттырмас, иртәгәсен шулай тыныч кына, тыйнак кына итеп жир йөзендә күрелмәгән чаңгыларда беренче булып килеп таң калдырырга уйлаган Канәгать мәктәптән туган авылларына гадәттәге олы юлдан сыйныфташлары белән түгел, ә бәлки алардан аерылып, иртәгәсен дә, күренмичә, шушыннан гына барырмын дигән нияттә кар ерып, җәйге сукмакны табаннары белән капшый-капшый, эз салып кайтты.

Әле генә урманнарын әйләнеп кереп, бурлы атын тугарып маташкан бабасы аны, син нәрсә аяк астында чуаласың, дигәндәй:

—Нишләп йөрисең, бугашап?..—дип, гадәтенчә, кырыс каршылады.

Бабасы бу бүрегендә киналардагы япун самураена охшаган. Бүреген салса, чебен шуып төшәрлек дәрәҗәдәге шома пеләше ачылачак, ул маңгае белән бергә кушылып, озын, ат танавы кебек озын, очлы танавына килеп тоташачак. Орлык та орлык, бабасы да орлык. Нәкъ Канәгать кебек. Күзләре исә кояшка карарга ярамаган кешенекедәй кысыклар. Күз дә түгел, бер сызык кына.Шундый да кысык күзләре белән урмандагы кырмыскаларга кадәр ничек шулай яхшы күрә икән ул? Канәгатьнең күзләре дә нәселдән-нәсәптән кысык. Әмма ул яхшы күрә.

—Безнең мәктәптә... иртәгә... пулный буявай выклад... чаңгы ярышлары...—дип этенә-төртенә аңлатырга тотынды малай.—Җиңүчеләрне башта районга, аннан Уфага, аннан Мәскәүгә, аннан...—Малай нәрсә әйтергә белмичә бөтенләй төртелеп калды.—... әллә кайларга алып барачаклар!..

—Пулный выклад, дисең. Әмунитсиягез бармыни?

—Бар, бар!—дип кычкырып җибәрде ул, бернәрсә аңламаса да.—Булмый, диме!..Тулып ята ул!..

—Нәрсәгез, мәсәлән?

—Юк дисәң, бар... Бар дисәң, бернәрсә дә юк инде ул. Афтамат та юк. Кәнсирвә дә юк. Ашарга ипекәй дә юк. Абыйга бу хакта әйттек. Ул вчарауна яхшылап ашарга, аркабыздагы вишмишукка утын түмәре салырга кушты.

Бабасының йөзен биләп алган кырыслык шундук юкка чыкты. Ул пырхылдап көлеп җибәрүдән чак тыелып калды.

—Ә синең, чыпчык чәчкәсе, бик җиһәсең киләме?

Күзе жете зәңгәр булганы өчен аны бабасы шулай дип атый. Барлык нәселләре белән янып торган зәңгәр күзле булгач, нишләсен инде?!

—Әйе, бабай, бик килә!—дип кычкырып җибәрде кар өстенә лапылдап төшкән камытны күтәреп, ничек булса да ярдәм итәргә тырышкан малай бабасын сүзеннән эләктереп алып.—Бик тә җиһәсем килә! Мин бит мәктәптә беренче чаңгычы!..

—Йә-йә. Мактанырга дигәндә...сине куш. Ә менә миннән сиңа ни кирәк?—Инде чана тәртәләре дә, кулыннан ычкынып китеп, тунгалакка төшеп доңгырдаган уңайга бабасы аңа укталып калды.

Эш уңа, димәк. Бабасы эреде. Була бу болай булгач.Малай тулган айдай елмаеп җибәргәнен сизми дә калды.

—Мин синнән, бабай, ярышка... әнә теге...—Канәгать кулын сузып келәткә күрсәтте.—Фабрик чаңгыларынны биреп тормассын микән, дип килгән идем... Ватмам-сындырмам, өф итеп кенә тотармын...

—Ватмам-сындырмам...—Бабасы тагын кеткелдәгәндәй итте.—Алар синең үзеннең биленне сындырмасын. Авыр алар. Кәк-никәк, нимесләрнен

урман-тау гаскәрләре өчен ясаткан чаңгылары...

Бу яналыктан соң малайның шатлыгы эчен тишеп тышка чыга башлады. Менә нинди чангыларда барачак ул иртәгәсе ярышка!..Белеп торсыннар, күреп торсыннар. Мондый чангылар бөтен ЫСЫСЫРда башка беркемдә дә юк!..

—Кем үткәрә соң ул ярышларны?

—Гариф абый.

—Ә-ә-ә. Урыс Гариф. Армиягә Гариф Фәйзуллович булып киткән иде, Гриф Фәмич булып кайтты, дунгыз. Пашпортына да, ваянбилетына да шулай яздырган. Аны әле халыкта «Макаруныч» та диләр...

Монысы малай өчен яңалык иде. Әмма ул аңа игътибар итмәде.

—Әйе. Аны Олы Авылда чынлап та Урыс Гариф дип йөртәләр икән...— дип кенә куйды ул.—Безгә дә урысча гына сөйләшергә куша. Берәр нәрсә булса, «Азия!» дип авызны каплый.

—Алары нәрсә була тагын?—диде бабасы атын лапас астына таба житәкләп.—Гарифныкы аныкы борчак ашы кебек булыр: өсте гөбердәп кайный, асты—туң борчак...

—Бу уку елы башыннан безгә география керә башлады. Аннан да Гариф абый укыта. Без Азия дигән жирдә яшибез икән. Ә ул безгә «Азиядә яшәмәгез, Яврупада яшәгез! Жирнең кендеге—Яврупа!—дип кычкыра.—Настояшный акыл Явропадан чыккан, ә менә сезгә, Азиягә, килеп житмәгән!»

—Ә ул үзе кайда яши? Кайда басып тора? Әзиядәме, Аурудамы? —Бабасы атын аранга кертте, утлыгына чанасыннан яшеле коелып торган хуш исле печән ыргытты. Аннан, ат алдындагы күбәдән бер учма печән учлап, бурлысының янбашларындагы карны сыпыра башлады.—Урысча гына сөйләшкәч, нык алга киткән кеше була инде ул... Сак булырга кирәк!..

—Белмим,—диде малай беркатлылык белән.—Сорармын әле. Безгә ул өч фәннән керә. Физкультура, география һәм нимес теле.

—Нимесчә беләме соң? Сөйлиме?

—Сөйли дип... Ярты елда хәрефләр өйрәтте. Капут. Зер гут. Хенде хох дигән сүзләрне, киналардан ишетеп, үзебез дә белә идек. Ә ул... ачуы килгәндә... нимесчә бик яхшы сүгенә икән!..

—Ничегрәк итеп?

—Күп инде алар. Иң еш кабатлаганы - дие муттер, шварцен пульзен... Нәрсә була икән ул, бабай?

—Каян беләсең аны. Болай ук булгач, белә инде, нибуч. Мин үзем бу кадәресен белмим. Кара син аны, биш класс кына белем белән киткән Гариф!.. Укыткач та укытканнар икән бу армиядә!...—Бабасының авыз читендә елмаю яктырып сүнде.—Юкка макарунник булмаган, димәк...

Бу Каңәгатьнең ишеткән сүзе түгел иде. Келәттән күзен алмыйча шушы ук келәткә юлны күрсәтергә ашыкмаган бабасының күңелен йомшартыр өчен үзенә кирәкмәсә дә сораштырган булды:

—Кем ул макарунник, бабай? Кешеме? Әллә ашый торган нәрсәме?

—И-и, бәлеш авыз!..Һәрхәлдә ботка-мазар түгел, ымсынма. Ашый торган камыр азыгы да!.. Кеше дә!.. Мин ул макарун дигән кипкән, тишекле камырны беренче тапкыр Кавказ фронтында итальян гаскәрләрендә күрдем...—дип сөйләп китте бабасы ачыла төшеп.—Каһәр тәмле нәрсә ул. Авызны ачып өлгермисең, шуып кереп тә китә. Сугыштан соң безнең армияне дә Сталин бабаң макарун тәрбиясенә күчертте...

—Ә макарунныгы кем?—дип кыешты малай.—Гариф абыйның макарунга ни катнашы бар?

—И-и-и, ничек кенә бар әле!..—дип кычкырып жибәрде бабасы.—Гриф Фәмич сугыштан соң ач авылына кайтудан баш тартып, шул макарун ялына

ун ел чамасы армиядә яшьләрне айт-двага өйрәткән кеше. Белеп тор!.. Үз теләге белән хәрби хезмәткә ялланып, яшьләрнең иманын сауган сержант-старшина халкын «макарунник» дип йөртәләр...Син аларның камчыларын сыртыңда тоярсың әле!..

Ләкин малайның бөтен уе һаман кулга төшмәгән чаңгыларда иде.

—Күзең очлы синең. Әнә шунда, келәттә!..—диде бабасы ниһаять.—Мәтри аны, тыебрак бар! Германның үзеннән. Трофей!.. Синнән алдан йөгереп, үзеңне йөгендереп куймасыннар!..

Булды болай булгач! Ике сикереп, бер атлап, Канәгать келәткә керде, төрле капчыклар, әрҗәләр, мунчага дигән каен себеркеләре, җиләк тәлгәшләре, дару үләннәре бәйләмнәре арасыннан почмакта аны көтеп саргайган, сыртына «VIKTORIA» дип язылган дөньядагы иң матур, уймак борынлы, шома, җыйнак, кар өстеннән йөзеп кенә очачак, аны Уфаларга, ил буенча ярышларга алып барачак чаңгыларны эләктереп, килеп тә чыкты. Аңа бабасы чаңгыларны менә-менә кире тартып алыр кебек иде. Аныкын белмәссең. Тәртәсе - зирек. Минуты - кадерле! Тоткарланмаска! Шалт, Мөхәммәтҗан!..

Әмма ниндидер тойгы аны туктатты, гүя ул бабасына әйтәсе рәхмәт урынына бер кечкенә сорау биргәнен сизми дә калды:

—Бабай, «VIKTORIA» дигән нәрсәне аңлата икән?

—Ычкын моннан, малың кулыңда чакта...—диде гадәти кырыс хәленә кайткан бабасы.—Ул кадәресен үк белергә мин сиңа прафисыр түгел. Анысын шул макарунычыгыздан сорашырсың!..

Малай бабасының «макарун» дигән гыйбарәгә нинди аерым тирән мәгънә салып, нинди киная, кимсетү белән әйтүен эләктереп җиткерә алмый иде, әлбәттә. Ул татарлардан мондый армия «комыклары» —«макаруныч»ларның сан ягыннан, урыс белән кахулдан кала, өченче урында торуларын, татар авылына еш кына «сөйкемле» маржа, тәмәке, аракы, урысча сүгенү, чит-ят сүзләр, гадәтләр алып кайткан, күн итек-пәртүпи шыгырдатып фарчит иткән, ил-тел, милләт казнасын шактый җимереп, дәүләттә тоташ бер катлам булып яшәгәнлекләрен белә алмый иде...

—Син, улым, артык яктылыкка ашыкма,—диде инде болдырга ук күтәрелеп, кожаның сала башлаган бабасы.—Син энгер-менгердәрәк торырга тырыш, ярыймы? Яхшы кеше—дару кебек: караңгыда бозылмый...

Кояштай балкыган малай яшен тизлегендә урыс капка аша урамга атылып чыкты. Булды бу!.. VIKTORIA!.. Шунысы кызык, үз телләрен нечкә белгән, үзара кошлар кебек сайрап аңлашкан бала һәм баба, күтелмәгән шартларда—авылга килгән чутсыз-сансыз эрвәлүтсияләр, сугышлар, кулак калдыклары, дошман элемент буларак, чит-ят якларга куылып, урман кисү, торф чыгару кебек эшләргә күпләп китү-кайтулар аша кергән ят тел сүз-атамаларының шактый булуы аркасында алар, икесе бер милләт баласы,туганнан туган, чит кешеләр кебек, бер-берсен аңламыйлар һәм бу хәлгә аптырамыйлар да иде...

Ул чаңгыларны мәктәпкә барып җиткәнче беркемгә күрсәтмәскә тиеш. Беркемгә. Күрсәтсә дә, Кыяметдингә генә. Анысын да яшерен һәм башка беркемгә дә әйтмәскә дип кисәтеп кенә. Килде аңа кич белән Кыяметдин. Чаңгыларның ышанычлы ныклыгы аның һушын алды. «Авыррак түгел микән? Моны сөйрәр өчен кимендә бер пот ит йомдырырга кирәк...—диде дусты шикләнә төшеп.—Шуып карадыңмы соң?» «Юк,—диде Канәгать эре генә.—Потлап ит ашарга миндә Әндри казнасы юк. Ярышка чыкмый торып, мәгънәсезгә хәлемне бетермәячәкмен. Иртәгә мин мәктәпкә туры юлдан, «Бүләк» урманы аша җәйге сукмактан барачакмын. Мине олы юлда көтмә.» Ярышта беренче булып килү теләгеннән исергән һәм үзен шундый

сынаулар алдына куйган дустын Кыяметдин ничек кенә кире кундерергә тырышса да, ниятеннән кайтара алмады.

Менә ул, шушы үзе күтәргән фетнәнең корбаны, чак-чак юлдан сөйрәлә. Әнә, арттан аны тагын да кемдер куып житеп килә. Тагын да кем булыр?! Ә малайның хәле чынлап та мөшкел иде. Тирә-якта кул сузып ярдәм сорарлык, ул ярдәмне бирерлек бернинди көч юк иде. Аның иң ачуын китергәне —иске чаңгыларда алда килеп, трофей чаңгыларда артка калуы иде. Ул юлның иң кискен урыны «Фәтхулла» чишмәсенә якынлашып килә икән килүен. Их, ничекләр менеп житәргә дә, ничекләр генә финиш таягы каршында тунган күзле олы түмәр булып басып торган физкультура укытучысы янына барып житәргә?! Барып житәрме? Юлда егылып калмасмы? Мәктәп ихатасына кереп азапланыргамы? Аның колак төбендә ихахайлап көлгән тавышлар яңарды. Әйе, кичә—алдынгы, бүген—иң соңгысыннан иде. Кайчандыр матур, жыйнак күренгән яссы чаңгылар аңа хәзер ямьсездән дә ямьсез, шөкәтсез, ботаклары тазартылмаган бүрәнәләр булып күренде. Аларга карап, чаңгыларны гына түгел, башкаларны яратуы да нәфрәткә әверелде. Бу гади көнләшү генә түгел, ирләр корына кереп килгән малайның жанынннан әрнеп чыгып, көч-кодрәттән яратылган житезлек намы—ир-ат горурлыгыннан туган чәм иде. Йөрәге күкрәк читлегенә сыя алмастай булып дулый, котыра, колаклары шаулый, чәчләреннән, маңгаеннан агып төшкән тозлы тир күзләрен әчеттерә. Үзенә көч бирмәс микән дигәндәй ул мәктәп ихатасында күн итекләренең кап-кара борыннарын кара тычкан булып ак кар эченнән борынлатып чыгарган һәм «бөек оештыручы» кыяфәтендә басып торган укытучысының чыраен күз алдына китерергә тырышты. Әнә, күр, ул сине көтеп, кулындагы дәфтәр битенә ах та ух килеп утын күтәреп килүчеләрне теркәп тора: «Первай!.. Фтаруй!.. Третий!..» «VIKTORIA» чаңгысында беренче килергә тиешле Канәгатебез генә күренми!»—дип тә жибәрәдер әле ул. Юк, ярдәм итми иде Гариф абыйсының жилдерелгән ат эчәгесе кебек коңгырт чырае. Инде хәзер чаңгылары астында кар да шыгырдамый, бары песи баласы кебек мыяулый гына иде. Ул сытып өзәрдәй булып чаңгы таякларын кысты. Телендә нииндидер жылы, тозлы тәм тойды. Ул тешнәлгән ирененнән саркылган канны читкә төкерде.

Ни өчендер Тукайның «Шүрәле»се исенә төште.

> Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе,
> Урта бармак буйлыгы бар маңлаенда мүгезе...

Мү-ү-гез-зе!.. И-и-их!

«Фәтхулла чишмәсе»нә күп дигәндә ике йөз адым калгандыр. Чаңгы юлы сирәк каеннар арасынан килде-килде дә , текә үргә күтәрелә башлады. Алга, Канәгать, алга! Аны куып килгән авазлар да күтәрелә иде аның белән бергә. Бу куркыныч мизгел иде. Малайның күз алдында Рух —үз ихаталарындагы Ак Аргамак башы пәйда булды. Карлар камалышыннан алып чык, Ат Башым!..Ул баштан өстәмә көч, дәрман көтте. «Алга, Канәгать, алга!—диде Ат Башы.—Көч-куәт үзеңдә генә!» Юк, аңа Ак Аргамак башы да ярдәм итә алмады. Канәгатьнең бу минутта чаңгы эзенә бер күз алмасы төшеп челпәрәмә килгәндәй булды.Артыннан килә теге пыяла кискән тавыш, куып житеп килә. Кем булыр? Малайның алдына йөзен дә күрми үскән атасының рухы килде. Ул кырынмаган һәм йолдызлы пилоткада иде. «Алгамы, әти, арткамы?» «Алга!» диде әтисе. «Туктыйммы, әти, туктамыйммы?» «Туктама!»,—диде әтисе. Юк, ничек кенә талпынып, очынып карамасын, очыну, хыял, коры теләү-ярпачлык белән генә максатка ирешеп булмый икән; хәлсезләнеп, камыш кебек сыгылып төшкән буыннар аны барыбер дә

тыңламый иде. Юк, Ак Аргамак башы, Ата Башы рухлары да йөзгә бәреп яуган карларда юкка чыктылар. Моңа кадәр бик көчле булса да, хәзер ул көчсез, бик көчсез иде.Аңа бары көч, үз көче кирәк иде. Канәгатьнең инде икенче күз алмасы чаңгыларына төшеп челпәрәмә килгәндәй булды...Әнә кемдер.. нindердер шәүлә... узгандай итә...Канәгатьнең күзен кан басты. Шәүлә сул тарафтан аны узып та бара, әнә, инде уздым дигәндә генә шәүләнең карчыганыкыдай елтыр күзләре «Менә шулай да була ул!» дигән сыман утлы кылычлар айкатып, инде Канәгатьнең иңеннән башын кыеп алгандай итте дә, чаңгы эзләренә төшеп туктап калды.

Бу Хәдичә иде. Аның элек киез итекләрен тутырып, бүлтәеп чыга торган нәфис аяк балтырлары бу юлы малайга фил боты кебек юан күренде. «Хәдичә түгел, Хәдичурт син!» —дип пышылдады ул. Инде аңа хәзер чаңгы юлына чамасын белми сөйләгән теле өзелеп төшкәндәй тоелды. Киләчәктә аны кем дип атаячаклар? «Чатан Хәдичә узган Канәгать» дип. Нокта шунда куелачак.

—Син юк өчен бетеренмә...Син болай да беренче!..—диде аңа таба борылган Хәдичә йомшак кына итеп.—Мә, минем чаңгыларымны киеп ал да!... Ә мин синекеләрне күтәреп кайтырмын...

Канәгатьнең бу рәхимле сүзләрдән соң башы әйләнеп китте. Ләкин кеше чаңгысын киеп башкаларны узу бәхете инде аңа тәтеми иде.Ул инде гарьлекнең икенче казанында кайнады.

—Рәхмәт, Хәдичә...—диде ул сүзләрне авырлык белән сайлап.—Онытмам, Хәдичә...Син бүген үзең беренче!.. Син бүген беренче тапкыр чаңгыга басып, безнең барыбызны да җиңдең...Юлыңны дәвам ит!..

—Шулай дисеңме? Ярар, алай булгач...—диде кыз һәм акчарлак сыман талпына-талпына ераклаша да башлады...

Артта аны узачак кеше калмаган иде.Ул кола яланда япа-ялгыз иде.

Инде ашыйсы да килми, ашказаны бербөтен ташказаны булып каткан, бар дөньяга һәм үзенә нәфрәт белән тулган иде.

Ул урынында чайкала-чайкала аркасындагы токчаен салды, утын түмәрен чыгарып, каен төбенә томырды. Аңа авызларын ерган сыйныфташлары алдында «буш чаңгы» күтәргән хәлдә финишка барып, көлкегә калырга ярамый иде. Бүген таңда беренче булам дип уянган, беренче булам дип авылыннан чыккан, карлар ярып, мәктәбенә беренче булып килгән, җиңү хакына стартка баскан Канәгать авылына җинелүче булып кайтырга мәҗбүр иде...Чабаталарын әлүмин аеллардан арындырып, җансыз тактага әйләнгән чаңгыларын иңенә күтәрде һәм кып-кызыл кан булып күренгән җирдән карашын алмыйча, авыл очына, дөресрәге, мәктәпкә кереп тормыйча, Бәләкәй Авылга алып чыга торган юл чатына таба юнәлде.

«Иске бай кызганчык була, яңа бай мактанчык була»,—дип юкка гына әйтмәгәннәр, күрәсең. Макталды!..

Аңа бүген җил дә каршы иде. Башка кайгыларын онытып, ул дөньядагы барлык кешеләргә каршы барлык җилләрне каһәрләде.Ат тояклары, чана эзләре белән тапталган юлдан «Бүләк» урманы түбәсенә житкәч, нәрсәдер тезенә китереп сукты, кендек җебе өзелгәндәй итте һәм ул иңендәге трофей чаңгылары белән юл уртасына ауды. Чамадан тыш авыр, күтәрә алмаган йөкне күтәреп, адәм көлкесенә калудан хәл өстендә йөгенгән малай берме-икеме секундка аңын югалтты. Бу секундлар ел шикелле озак тоелды. Менә ул аңына килде һәм канын ялаган эт баласы шикелле шыңшып кына елый башлады. Юк, бу гадәти елау да түгел иде. Бу гарьлектән, үкенүдән, үзенең иске, көмеш ярымай кебек матур, җыйнак өрәңге чаңгыларын сагынудан, тормышның әле аңа билгеле булмаска тиеш булып та, үз тырышлыгы, ашыгуы нәтиҗәсендә иртәрәк билгеле булган кануннарының үзенә китергән

газапларын аңлаудан яратылган инрәү, үксү иде. Аның белән бергә тирдән тунган юка әдрәс бишмәте, чачакланып тузган чабаталары, «сугышка барырга һәрчак әзер» токчай-вишмишуты, ярсу жилләрдән гүләгән «Бүләк» урманнары да инри,үкси иде. Башкаларны жиңелсән дә, үзеңне жиңеп булмый икән. Аңа бу таулар, бу урманнар бу мизгелдә матур булудан бигрәк, нинди дер куркыныч, аһ-зар мәхшәре вакытында яратылган табигый байлык буларак күренә һәм кыр өстендә япа-ялгыз яткан малайны үзләренең гел канәгать барлык-муллыклары белән кимсетәләр иде. Син жир йөзендәге иң матур кыз Хәдичәне генә ал. Хәлиткеч мизгелдә хәлиткеч сүзен таба алган кызый аңа хәзер матурлык чыганагыннан бигрәк үзендә булмаган акыл чыганагы булып күренде.Кем уйлаган? Аһ, бу немесләр! Алар аның әтисен генә түгел, елтыр аеллы чаңгылары белән жиңүен дә тартып алдылар! Беркем белмәгән-аңламаган VIKTORIA, имеш? Шушымы Гариф абыйларының жир кендеге булган мактаулы Яврупасы?! Шушымы аның әле ул туң бозлар өстендә кендек жебен өздереп яткан Азиясе?!

Кинәт аның колагына чек-черек килеп чыелдаган авазлар ишетелде. Ул яткан жиреннән сагаеп кына башын күтәрде. Анда, чана табаннары белән каезланып беткән ат юлында, үзе белән янәшәдә генә, әле туңып та өлгермәгән жылы ат тизәге алкаларында чыпчыклар типченә иде. Аның кысык күзләре бу түгәрәк алкаларны энә күзеннән үткәзде һәм аларда ат ашказанында эшкәртелеп тә исән калган ак солыларны шәйләп алды. Чыпчыклар ат карыныннан чыккан тере солыларны берсеннән икенчесенә калдырып, тибешми-тешләшми, талашмый-гаугалашмый гына бүлешеп, тыйнак иман, түзем белән чүплиләр иде.Жир йөзендә алардан да шат, алардан да канәгать жан ияләре булмагандыр. Малай көлемсерәп куйды. Куе кара карлы томаннар яктыргандай итте. Дөнья матур, төгәл, бөтен иде. Ул үксүеннән туктады. Аның өчен Жир уртасы, аның Яврупасы менә шушы жылы, парланып-буланып яткан алкаларда чүпләнеп азапланган чыпчыкларда, шушы алтын солыларда иде. Шушыны аңлау аның өчен гүя бүгенге жиңүнең иң зурысы иде. Жир йөзендә унөч елга якын яшәп, шушы яңа чаңгылар һәм шушы секундлар аны ир-егет итеп житештерде түгелме? Әгәр шулар булмаса, ул бу морадка кайчан ирешкән булыр иде икән?

Ниһаять ул авызы колагына житкәнче елмайды. Аның күз сызыклары очында яшь бөртекләре жемелдәде. Бу яшьтә гүя әлеккеге кайгы шатлыкка, нәфрәт мәхәббәткә, хөсет-көнчелек ихлас теләктәшлеккә, искелек яңалыкка, яңалык искелеккә әйләнеп кайтып, һәркайсы үз урынына утырган иде. Аның бар дөньяны, барлык кешеләрне кызганасы, кочасы килде.Йә, әйт, тыштан гына кырыс күренгән Габдрахман бабасы искиткеч хикмәтле, үзенчә бер әкәмәт жан иясе түгелме? Аның белән урманда һәр бүре, төлке, куян кулларын сузып исәнләшеп китә... Шушы трофей чаңгыларын биреп, ул сине шушы үлемсез чыпчыкларга якынайтмадымы? Гариф абыйлары нинәрсәсе белән начар? Шулай ук үзенчә кабатланмас зат, тел белмәгән татар баласы, сугышларны үтеп, дошманны жиңеп кайтып, армия макарунында әл-хәл алып, ачлык-ялангачлыктан чыга алмаган туган авылында аларны, йөзләгән Канәгатьләрне, хәленнән килгәнчә Яврупага таба өстерәмиме? Жан дусты Кыяметдин хәзер мәктәптә аның өчен кызармыймы? Кызарма, дустым! Жиңү безнең якта!..Хәдичәсен ал. Нинди дә матур, нинди дә акыллы син, Хәдичә!..! Аның күзенә тагын да яшь типте. Үпкәләтмәде микән? Аны берәр юеш борын кыерсытмый микән? Кемнәндер якларга кирәкмиме?

Күктән карк-карк итеп каркылдап кар коелгандай итте. Бу тавыштан дерт итеп үзенә килгән малай урынында чалкан әйләнгәнен сизми дә калды. Күктә, каракучкыл куерымда, нәкъ аның өстендә, юк, карга түгел, канатларын колач итеп жәйгән галәмәт зур кош тирбәлә иде. Менә ул жай

гына чайкалып, түбәнәйгәннән-түбәнәя барып, аңа якынлаша. Канәгать инанды: бу бөркет һәм Ырымбур далаларыннан аларнын тарафларына, Габдрахман бабасы әйткәнчә, бары тик кышын кышлауга килә, гадәттә эре мал үләксәсе белән туклана, карыны ач вакытында корбанына томырылып, томшыгында каз-үрдәкне генә түгел, бозау, сарык бәрәне кебек вак малны да күтәреп алып китә ала торган иң дәһшәтле бөркетнең бер төре —лачын, лачын-сапсан иде. Сәер хәл: аяк асларындагы тизәктәге тере солылардан башка бернәрсәне күрмәгән чыпчыклар янында «чыпчыклар күп—ул ялгыз, ятим» булган булса, хәзер ул галәм куначасыннан бар дөньяны тигез күреп, үзенә таба төшеп килгән бердәнбер лачын астында ятимлектән котылып, күкрәгендә нindидер бергәлек, күмәклек, мәгъруранә сабырлык тойды. Куркудан түгел, нindидер галәми дулкынланудан малайның тамагы кипте. Ул үзе дә сизмәстән, яткан уңайдан капшанып, калтыранган бармаклары белән чеметеп, кар очтыгын капты. Аңа хәл кергәндәй итте.

Лачын түбәнәя иде.

Малай күз ачып йомганчы сикереп торды. Аяк астындагы чыпчыклар өере фырылдап юкка чыкты. Ул тау текәсендәге урманнарны яңгыратып, чаңгы таягы белән селтәнә башлады:

—Юк, мин үләксә түгел! Мин үләксә түгел! Мин үләксә түгел!..

Лачын яңадан күккә күтәрелә башлады. Озак та үтми, ул андагы хәрәкәтсез ноктага әверелде.

Канәгать чаңгыларын киде, әлүмин аелларын ипле итеп каптырды, күкрәген тутырып тын алды һәм тау текәсеннән таш булып түбәнгә—Бәләкәй Авылга томырылды.

***

**Өстәмә**

Киләсе ярышларда яңа чаңгыларда урынсыз калган Канәгать иске чаңгыларында беренчелеген кире кайтарыр.

Анисы шулай, тик без «VIKTORIA» дигән сүзнең мәгънәсен ачыкларга онытып җибәргәнбез ләбаса. Канәгать тә оныткан аны. Бу вакыйгалардан соң байтак еллар үткәч—этисеннән соң бик иртә әнисен дә югалтып, калын урманнар, биек таулар аша инде егерме чакрым җәяү йөреп, урта мәктәпне тәмамлап, аннан ерак шәһәрдә, һөнәрчелек мәктәбендә махсус белем алып, аннан Каспий дингезе буйларында нефть эзләүдә катнашып, аннан өч ел армиядә хезмәт иткәннән соң, Казан дәүләт университетында укый башлагач кына форсат тияр аңа бу риваяти төшенчәне ачыкларга:

VIKTORIA—ул латинчадан «Җиңүче» дигән сүз булган икән лә.

*7 ноябрь, 2010 ел,*
*Кисловодск.*



Рөстәм
Сүлти

# ИДЕЛ-ЙОРТЫМ МӨЛДЕРӘПЛӘР ТОРА КҮЗ ТӨБӘП

## Сәлам, Каләм!

**Нинди көч вә нинди серләр**
**Саклыйсың син, әй, каләм?**
**Гомер узган, күбрәк язган**
**Саен күбрәк өркеләм.**

**Миңа килгән әмер: «Укы!»—**
**Укып туйгысыз галәм,**
**Тик язарга лаекмы мин,**
**Телгә кил дә, әйт, каләм!**

**«Язып өйрәтүче Раббың**
**Исеме белән укы!»**
**Сүрә-сүрә, аять-аять,**
**Иләһи—Раббыңныкы!**

**Лаек күргән ант итүне**
**Каләм-әл-Каләм белән,**
**Лаекмы мин аңа, диеп,**
**Уйланып калам гелән.**

**Каләм ияләре күп тә**
**Кәлям иясе сирәк,**
**Кол Гали һәм Кол Шәрифтәй**
**Коллык иясе кирәк.**

**Йә туктап кал яки яздыр**
**Бары тик гүзәл кәлям,**
**Әй, каләм, әй көчле каләм,**
**Әс-сәлам сиңа, сәлам!**

Рөстәм СҮЛТИ (1969)–*шагыйрь; «Мин-шигырьдән» исемле китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Лондонда яши.*

## Көзгедәге чагылыш

*Йакутлар табыладыр вакыт белән.*
Г.Кандалый

**Әй, халкымның «саф вә раушан көзгесе»,
Кемдер, әйтче, бу халыкның изгесе?**

**Кемдер аның мөкатдәсе, йакуты,
Йакутларның табылырга вакыты.**

**«ЙАКУТ» язып тоттым—«ТУКАЙ» чагылды—
Вакыт житте, асыл йакут табылды!**

**Йа Тукай, дәртле Тукай, нурлы Тукай,
Йакуттай, жәүһәр Тукай, туры Тукай!**

**Бер нәби күк чык, чагыл, сукыр хәтсез
«Без аны кайдан белик» кәрамәтсез[1]?!**

## Хаталары гына...

**Кайсы жүләр әйткән: Шагыйрь, диеп,
Үз халкының, имеш, пәйгамбәре...
Миңа мирас булып нәбиләрнең
Калган бугай хаталары бары.**

**Пәйгамбәр дә, әүлия дә түгел,
Кәрамәт тә көтмим, могҗиза да,
Юныс пәйгамбәрнең бер хатасы
Минекенә бераз охшаса да.**

**Таш атканда миңа газиз оям,
Татар илем – минем Ниневиям[2],
Ташлап киттем, ләкин кире кайттым,
Таш атса да аны шашып сөям.**

**Кире кайттым нәби Юныс кебек,
Пәйгамбәрлек намы тик бу бары,
Тагын, бәлки, бардыр йөземдәге
Пәйгамбәр аптыраулары...**

**Ассириям, Ниневиям дә бу,
Атлантидам да бу, Андалусиям дә,
Үпкәм дә бар, үз дә сыман, ят та,
Мәҗнүн сыман шашып сөям дә...
Атилланың, Чыңгыз ханның аты
Белән телгә кергән «Бөек Дала»,
Берән-сәрән, эре-ваклы, анда-монда,
Утрау-утрау, авыл-авыл, кала-кала...**

**Казан, Кырым, Әстерханым монда,
Себер, Нугай, Тау ягы, мишәр иле дә...**

[1] Кәрамәт (гар.) – изге кешеләр тарафыннан күрсәтелгән гадәттән тыш хәл, могҗиза.
[2] Ниневия – Ассириядәге борынгы шәһәр.

Монда минем Болгарымның җәмале[3],
Монда минем Алтын Урдам җәлале[4] дә...
Туфаннан соң Нух пәйгамбәр ни кичерсә,
Кавемемә карыйм шулай мин дә,
Пәйгамбәр дә түгел, әүлия дә,
Һич җиңел дә түгел, теләмим дә.

Үз бәһамне беләм, ничә тиен,
Әүлия дә түгел, пәйгамбәр дә.
Ләкин нәби Йосыф сыман идем
Кардәшләрем миңа таш бәргәндә.

Кардәшләрем аткан коелардан
Җиде ятлар алгач, кемнәр сатты?
Әле кое, әле сарай, әле зиндан,
Әле тәхет—менә бүген кайттым.

Кавемемдә бар Нух кавеме эзе,
Бәни Исраиллек, Ниневиялык,
Мин пәйгамбәр түгел, хатам пәйгамбәри–
Йотып ала мине олы балык...

Туфаннан сон туган тәүге таңда,
Урыс океанында татар утраулары.
Мин пәйгамбәр түгел, миндә бары
Нух пәйгамбәр аптыраулары...

Әле коеларга сала мине кавемем,
Әле суга сала, әле утка,
Юк ихтыяҗ бәни Исраилгә,
Карун, Фиргавенгә, ни Нәмрутка...

Үпкәлим дә, рәнҗим, аптырыйм да,
Мәҗнүн кебек шашып мин сөям дә.
Ассириям, Ниневиям монда,
Атлантидам монда, Андалусиям дә...

Офыклардан офыкларга чаклы
Урыс океанында татар утраулары...
Пәйгамбәрлек кая, миңа бары
Хаталар вә аптыраулары...

## Идел–Йорт

Идел белән Чулман кушылган да,
Хасил иткән нәни бер йөрәк.
Шәкле[5] генә түгел, җылы, җанлы –
Йөрәк булып тибә ул төбәк.

Көн–төн, җәй–кыш, яз–көз дими тибә,
Бертуктамый тибә ул йөрәк.
Дөп–дөп итеп тибә, бәгыремне
Телем–телем телә ул төбәк.

---

[3] Җәмал (гар.) – матурлык, гүзәллек.
[4] Җәлал (гар.) – бөеклек, олылык.
[5] Шәкел (гар.) – форма.

Хәританы[6] алып сәгатьләрчә
Утыралам шулай күз төбәп,
Ишетәм, күрәм, беләм, сизәм, тоям—
Шундый үзгә, үзәк, үз төбәк.

Кан тамыры кебек, вена кебек,
Тулып аккан сыман тоташ кан,
Ничә елга, ничә дәрья суы
Йөрәк тәшкил итеп тоташкан.

Йөрәк шәкелендәге Идел–Йортым
Мөлдерәпләр тора күз төбәп,
Әллә миңа гына шулай инде,
Әллә чынлап шулай ул төбәк.

## Балчык!

Катырак бас балчыгыңны, чүлмәкче,
Басуыңнан күп гыйбрәтләр күрмәкче.

Катырак из балчыгыңның измәсен,
Беркем «чүлмәк начар булган» димәсен.

Ул күлмәкләр кайда калды, әй, чүлмәк,
Ул чүлмәкләр кая китте, әй, күлмәк?!

«Мин—мин микән, мин кем икән?» диделәр,
Аллы–гөлле күлмәк кенә киделәр.

Кая китте ул күлмәкле чүлмәкләр,
Кая китте ул чүлмәкле күлмәкләр?!

Бу дөньяны шулкадәрле сөйделәр,
Мәңгелеккә килгән кебек иделәр.

Балчык идең, аслың балчык, мактанчык,
Китәсе җирең дә янә шул—балчык!

---

[6] Харита (гар.) – географик карта.

Печән Базары

*Сатирик әсәрләр конкурсы*

Фәварис Гали

## ЧӘНЕЧКЕЛЕ РОБАГЫЙЛАР

**Языйм микән мин дә әллә робагыйлар?**
**Йөрәктәге хисләр шуңа кодалыйлар.**
**Тик, барыбер, Гомәр Хәйям булалмам мин,**
**Булсаң иде, һич югында, Мөхәммәтшин,**

***

**Әйтешәләр: «Бусы фәлән бай мәчете,**
**Бусы менә, яңа татар—Хан мәчете.**
**Күңелләрне тырный шунда шикләр корты—**
**Түгелмени мәчет хәзер Алла йорты?**

***

**Кәнәфигә куйды аны халык «сайлап».**
**Сайламыйча! Эшне кыла түрә–байлар!**
**Эшчәнлекне башлады ул ипләп–җайлап;**
**Түрәләрнең кайсын сайлап, кайсын майлап.**

***

**Тулып ташкан кяфер булса да, урысҗан**
**Чит–ят телгә кыйбла тотып кылмый дога.**
**Безгә ярый—чит–ят телдә Аллаһ сүзен**
**Сеңдерәбез башны җиргә ора–ора.**

***

**Әй, комсызлар! Комсызлыкны саклар өчен**
**Ялламагыз сез газраиллар–киллерләр.**
**Киллерләрнең иманы да, җаны да юк,**
**Сезнең җанны алырга да бер килерләр.**

***

**Ошбу җирдә туып һөнәр, гыйлем алгач,**
**Чит илләргә оча алар «кыйгак–кыйгак».**
**Саз булса да, туган җиргә кайта кошлар,**
**Ә бу «кошлар» кайда акча—шунда кышлар.**

***

**Ерткычлыкта тиң юк безгә—инсаннарга,**
**Сыйдырып булмый аны хәтта кыйссаларга.**

Бу гамәлдән гарык инде озын тарих,
Тарихта да урын бетсә, кайда барыйк?

***

Сүтеп була һәр нәрсәне бик тиз генә,—
Менә дигән зур илне дә сүттек, әнә!
Шул «шатлык»тан без йөрибез инде менә
Дөнья буйлап хәер эстәп, ава-түнә.

***

Басуларың кара Рәсәй—вәт тамаша!
Авылларың бетеп, урының чүп-чар баса.
Чит җирләрне туп аттырып туздырганчы
Үз җиреңне сөрсәң иде лә ләбаса!

***

Крәстиән җиргә хәзер үзе «хуҗа»,
Аңа карап кимемәде һич тә нужа;
Элек аны чыбыркылап фиркә куса,
Хәзер, әнә, һәр инвестор таптап уза.

***

Милләтпәрвәр: «Уян, татар!»—дип кычкыра,
Бу шау-шуга милли бурлар сикереп тора.
Өч-дүрт татар тел турында гәп корганда,
Милли бурлар катлы-катлы кәттиж кора.

***

«Ил тоткасы—ир», дип әйтү хәзер хата—
Сөлектәй ир бүген күлмәк-ыштан сата.
Маңкорт ирләр ирлекләрен сатып эчеп,
Чүптәй сасып, анда-монда аунап ята.

***

Милли «босс»лар, ник нечкәрде тавышыгыз,
Мәскәү «бас»ыннан бөрештеме авызыгыз?
Милли «имезлек» булып калса сабырыбыз,
«Суверен»нан «гөбернә»гә дә калырбыз.

***

Үтте тыйнак заман, килде үзгәрешләр,
Пычранды дөнья, ахыры... мин дә буялдым.
«Үзгәргәннәр» шашып илне талаганда,
Беркатлы гөнаһсыз булудан... оялдым.

***

Ышана идек уйлап: хаклык—прокурор,
Баксаң, ул да икән астыртын бур.
Сул кесәгә туплый байлыкны тәм табып,
Угры түрәләрне кат-кат савып.

***

Күпне күрдең, Казансу, үз гомереңдә:
Сәүдәгәрләр, илбагарлар, илбасарлар.
Хәзер, әнә, ярларыңны мәсхәрәли
Илне талап, байлык җыйган юлбасарлар.

# ГАФФАРИЗМНАР

- *Сезгә мин кирәк чакта мин – бар, миңа кирәк чакта сез – юк.*
- *Үлүе авыр, яшәве - авыррак.*
- *Беркем дә безнең өчен үлмәс, үзебезгә туры килә.*
- *Сукыр әби әйткән: күрше тавыгы керсә, куып чыгармагыз, дигән.*
- *Лев Толстой үзенең "Сугыш һәм тынычлык" романын әллә ничә тапкыр күчереп язган. Кешелек тә шулай: сугышын да, тынычлыгын да кабат-кабат яза.*
- *Эшеңнең тар-мар ителүен теләсәң, аны югарыда килештерә башла.*
- *Бәрәкәтсез тотсаң, чишмә дә корый.*
- *Үлем сәбәбен үлемнән эзләмә.*
- *Кайдандыр җил иссә, татарның яфрагы леперди.*
- *Аерылышуы җиңел, бергә торуы авыр.*
- *Уй белән уй, йөрәк белән йөрәк, җан белән җан арасына төннек кирәк.*
- *Куркак адәм гел батырлык турында сөйләп йөри.*
- *Тарих янганда – үткәннәр үлә.*
- *Су ташырга – иләк, сүз ташырга – чиләк.*
- *Сөембикә манарасы үз астындагы кешеләр кайгысына чыдашмый авышкан.*
- *Дөреслек ялгышсыз гына була, ә ялгышуда бернинди дөреслек юк.*
- *Ымның мәгънәсе мең.*
- *Халык табагыннан ашаганнар кашык яламый.*
- *Һәрбер тантаналы фаҗига – мескен бәет.*

**Әхәт ГАФФАР**

---

## Рәсем—бездән, җавап—сездән



*Шушы фоторәсемгә җилле генә исем табыйк әле!*



Туфан
Миңнуллин

# ҮЗГӘРҮ

ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҮЗЕМ

## Кереш сүз.
## Дөньяны таный башлау

Такташ әйтмешли, мин үз гомеремдә бик күп төрле анкеталар тутырдым. Тормыш юлыма кагылышлы истәлекләр, уйланулар да яздым. Аларны игътибар белән укыган кеше минем кем баласы, үземнең кем икәнлегемне шәйли аладыр. Бу язмам да үткән гомер, узган юл турында. Ләкин бу, башкаларыннан аермалы буларак, үземә читтән карабрак языла. Бәлки, әле ул минем турыда гына да түгелдер. Минем мисалда безнең буын үткән юлга бер карап алудыр.

Адәм баласы якты дөньяга пәйда булган мизгелдән минутлап, сәгатьләп, көнләп, айлап, еллап үзгәрә. Хәер, бу процесс ана карынында яралгач чакта ук башлана диләр. Мин үземдәге үзгәрешне, әлбәттә, иң беренче тапкыр «Нигә алай?» дип сорау биргән көннән башларга тиешмендер. Кеше тирәягына кайчан күзен тутырып карый, кайчан аның башына уй керә—шул чакта ул кеше дигән исемгә таба адым ясый. Дөрес, аның өчен баштарак бүтәннәр уйлый әле. Бүтәннәр уйлаганда кеше дигән җан иясе беркем түгел ул. Үзе уйларга тотынгачкына кешедә мөстәкыйльлек башланадыр. Берәүләргә уйлый белү сәләте иртәрәк бирелә, кайберәүләр исә уйларга өйрәнә алмыйча озак интегә. Дөресрәге, ул интекми, башкалар аның өчен уйлап мазалана. Уйлап азапланмыйча, гамьсез генә яшәүчеләр шактый, өлкән яшьтәгеләр арасында да юк түгел. Аллага шөкер, мин андыйлар исәбенә кермим. Бөтен гомерем сорауларга җавап эзләүдән гыйбарәт.

Дөньяга күземне ачып карап, «Нигә?», «Ник?» «Ни өчен?» дигән сорауларны мин ничә яшемдә бирергә өйрәндем икән? Өч-дүрт яшьләр булгандыр, абый белән икебезгә прәннек бирделәр. Абыйга күбрәк бирделәр шикелле, «Нигә аңа күбрәк бирдегез?»—дип тавыш чыгарганым истә калган. Хәтеремдә икенче сорау да калган: «Абыйга ботинка алдыгыз, нигә миңа юк?» иде ул. Шул көннән башлап, дөньяның тигез түгеллеген бәлки сизенгәнмендер. Тизрәк үсәсе килү теләге дә шуннан башлангандыр. Киләчәктә дә «Нигә аңа бар, миңа юк?» дигән сорау гомер буе эзәрлекләп, уйда бөтерелеп торды. Бүген беләм инде—андый уй һәр кешедә яши. Шул сорауга дөрес җавап таба алмасаң, гомер итүләре

Туфан МИҢНУЛЛИН (1935) – *Татарстанның халык язучысы, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе; Станиславский (Россия) һәм Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты. Күпсанлы пьесалар, китаплар (шул исәптән ун томлы «Сайланма әсәрләр») авторы. Казанда яши.*

кыендыр. Бәлки, җинаятьләр дә, сугышлар да шуннан башланадыр. Барныкын урлау, тартып, яулап алу теләге юкның күңелендә коткы уятадыр. Миндә дә ул теләк уянды—абый күрмәгәндә мин аның ботинкасын киеп урамга чыктым һәм пычракка батып кайтып кердем. Моның өчен миңа әнидән эләкте. Ә мин аңа үч итеп, беркөнне абый ботинкаларын бакчадагы кычыткан арасына ыргыттым. Үземнән таптырдылар. Гаделлек эзләүнең беренче адымнары шул көннән башланды. Аннары гомер буе мин аны эзләдем һәм бүген дә таба алганым юк. Димәк, йөз процент гаделлек, тигезлек бары тик хыялда һәм әкиятләрдә генә була икән шул. Әкияттә дә гаделлек иң соңыннан гына табыла.

«Нигә аңа бар, миңа юк?» дигән сорау күңелдә хасил булса, барныкын тартып алу уен уйламыйча, аңарда булганны үзеңдә булдыру өчен тырышу кирәклеген аңлау кешедән Кеше ясый. Ходайның биргәненә шөкер, мин шул хакыйкатьнең асылына төшендем шикелле. Аллага шөкер, кешеләрдә бары миндә дә булды. Мин аңа урлашмыйча, таламыйча, намусымны пычратмыйча, кешелек дәрәҗәмне таптатмыйча ирештем дип әйтә аламдыр. Абый ботинкаларын пычак белән кискәләү уе да килгән иде бугай, ярый әле тыелып калганмын. Һәм ярый әле бүтән уй яман уйны алыштырды—үскәч абыйныкыннан әйбәт ботинка алачакмын дип үземә сүз бирдем. Бүген бар минем затлы аяк киемнәрем, күрсәтеп куанырга абыем гына юк.

Югары очта торучы Вәлиев Габдрахман абый малайларының кәкре башлы тимераяклары бар иде. Ул олтан салынган киез итеккә бау белән беркетелеп куелган иде. Шуны киеп бозда шуарга хыяллана идем. Үскәч тимераяк алырга да ниятләп куйган идем. Алдым мин аны, ләкин шуарга туры килмәде, кызык та түгел иде инде. Авылга бер диңгезче кайтты. Аның бинокле бар иде. Шул бинокльдән бер карау өчен аңа бер данә «Пушка» дип аталган папирос бирергә кирәк иде. Тавык оясыннан бер йомырка чәлдерә идек тә, шуны кибеттә бер папироска алыштырып, бинокльдән дөньяга карый идек. Урман-басулар якын булып күренә иде. Үсеп акча эшли башлагач бинокль алам дип сүз биргән идем, алдым. Икене бүләк итеп бирделәр. Яталар өстәл тартмасында. «Зәңгәр шәл»не күреп шаккаткан идем, пьеса язу теләге туды. Аллага шөкер, ул теләгем дә үтәлде. Тырыштым, тырмаштым. 5-6 яшемдә дөрес уй уйлаганым гомеремне мәгънәле итте. Югыйсә барлык кешеләрдән көнләшеп, аларга үч саклап, хөсетлек чире белән интегеп юкка чыккан булыр идем.

«Нигә?» дигән сорауның иң катлаулысын алты яшемдә әтигә биргәнмендер, мөгаен. «Әти, кояш нигә чыга, нигә бата?»—дип сораган идем. Әти озак итеп җирнең әйләнгәнен аңлатты шикелле. Мин аңламадым: «Җир нигә әйләнә?»—дип сорадым. Әти: «Үскәч белерсең»,—диде. Менә үстем, Җирнең нигә әйләнгәнен һаман белмим. Уйлап-уйлап торам да, белмәгән нәрсәләр бихисап икән. Хәзер инде үземне юатам—дөньяның бөтен хикмәтләрен белеп бетерү мөмкин түгелдер, кайберләрен белмәсәң дә хәерлегәдер, дим. Әйләнә икән Җир, әйләнсен, ул әйләнгәндә төшеп калмаска гына кирәк.

Мәсәлән, Айның өстенә кешеләрнең аяк басуы минем өчен фаҗига кебек булды. Без сокланып карап торган Айны, төннәрен караңгы авыл өстенә сихри яктылык сипкән Айны таптый башладылар. Айның гап-гади җир җисеме икәнен белү миңа мәгълүмат өстәде, бәхет өстәмәде.

Ә иң мәгънәсез сорауны мин күрше кызына биргән идем. Урамда уйнап йөргәндә аның пес иткәнен күреп: «Нигә чүгәләп пес итәсең?»—дигән идем. Ул миңа җирдән туфрак алып сипте. Шул сабак булды—бүтән андый сораулар бирмәскә тырышам. Ләкин барыбер ычкынгалый. Дәүләт Советы сессиясендә «мәгънәсез» сораулар бирергә туры килә. Әйтик, нигә гомере буе бушка эшләгән авыл кешеләре бүген дә иң аз пенсия ала? Нигә Россиядә татар теле урыс теленнән кайтыш санала? Һәм башкалар, һәм башкалар...

Сугыш безне балачакның матур, самими гамьсезлегеннән мәхрүм итте. Сугыш башланганчы да без сугыш-сугыш уйный идек бугай. Акларга һәм кызылларга бүленеп уйный идек. Без—акларны күрми үскән буын. Кызыллары—безнең бабайлар, әтиләр. Шуңа күрә кызыл булырга теләүчеләр арабызда күп иде. Ак булырга теләүчеләр булмаганлыктан, ул рольгә көчсез малайлар куела иде. Аларны кызыллар, әлбәттә инде, дөмбәсли иделәр. Мин, көчле малай

булмасам да, ни сәбәпледер кызыл була идем. Хәтта анда командир ролен дә үти идем. Күрәсең, миңа лидерлык сәләте салынгандыр. Үземне, Ходайның биргәненә шөкер, берәүдән дә кыйнаттырмадым. Беренчедән, берәүне дә кыйнарга алынмадым (бәйләнчек түгел идем). Икенчедән, кыйнарга тотынган малайның кайсы җиреннән эләктереп алып каравыл кычкыртасын белә идем. Аңа мине әнинең иң олы абыйсы—Яшь бабай өйрәтте шикелле. «Елап әниең янына кайтасы булма, берәүгә дә тимә, тисәләр, күкәйләрен чәйнә»,—дия иде.

Без аклар-кызылларны безнең яклы һәм безгә каршылар дип кенә белә идек. Шуңа күрә пионер булыр яшькә җиткәч, пионерның кызыллар яклы булуына кызыгып, кызыл галстук тагарга ашыктык. Хәер, аңа чаклы октябрят булдык бит әле. Дөнья, ач булсак та, кызык иде. 1941 елда башланган сугыш безнең балачакның кызыклы якларын урлады урлавын, әмма безне исән кала белү фәненә дә өйрәтте. Ашарга ярый торган үләннәрне күбрәк таный башладык. Кузгалак, кәҗә сакалы, балтырган, какы ише үләннәрне таный идек инде, бәрәңге яфрагы, кычыткан, имән чикләвеге, алабута орлыгын да ашап була икәнлеген белдек. Мәккә охшатып тилебәрән орлыгы ашап, беребез үлде, шуннан тилебәрәннең агулы икәнен ачыкладык. Аксыргак дигән үлән кабып сиерыбыз чирләде, ул үләннең дә агулы икәнен әниләр әйтте. Тик менә гөмбәләрне генә танымый үстек. Гөмбә җыеп йөрүче марҗалардан көлә идек. Нигә без ашамадык икән? Анысы ачык—татарлар ашамаганга ашамаганбыз. Үзебез дә татар бит. Нигә татарлар гөмбә ашамады икән—бүгенгә чаклы белмим. Бүген татарлар да гөмбәне җыялар да, ашыйлар да, үзем исә һаман әле шикләнеп ашыйм.

Яхшыны, яраганны өйрәнү белән бергә ярамаганны да өйрәндек. Сугыш башлану мине, мәсәлән, тәмәке тартырга өйрәтте. Бабаебыз тәмәке тарта иде, аны үзе чәчеп үстерә, күләгәдә киптерә иде. Без туганнан туганым Мөнир белән кипкән тәмәке яфракларын, сабакларын вак-вак итеп турый идек. Бабайга (без бабай дими идек, баба дия идек) дигәнен тәмәке капчыгына тутырып, үзебезгә дә өлеш чыгара идек. Чия арасына качып, шуны тәмләп тарта идек. Беренче сыйныфка укырга барганда без әчкә алып тартучылар идек инде. Тәмәке тартучы бабайлары булмаганнар куян тизәге, мүк тартып азапланалар иде, без чын тәмәке тартып агуландык. Кызларның малайлардан ни белән аерылганын да мәктәпкә барганчы ук белдек. Исеме кем булды икән, онытылган, шуны чишендереп карадык. Гөнаһыбыз юк, үзе чишенде. Аңа да, безгә дә кызык иде бит. Дөньяны тану чорында фаҗигале хәлләр дә була. Тәмәке тартучы бабабызның шырпыны чырт итеп кабызганын карап торып кызыга идем. Бер тапкыр, кабызып карыйм әле дип, бабадан сорадым. «Кит моннан, ярамый әле сиңа»,—диде. Нигә ярамый? Аңа ярый, миңа ярамый, имеш. Бабай йоклаганда кәчтүне кесәсеннән шырпысын алдым да ишегалдына чыгып, шырпы сызып уйный башладым. Сызам да җиргә ыргытам, сызам да ыргытам. Ишегалдына абзар башы ябарга дип салам алып кайтып өйгәннәр. Шул яна башлады. Мин куркып, бәрәңге бакчасы аша Түбәноч урамына чаптым. Мине әни куа китте. Читән аша сикергәндә мине эләктереп алды. Әни кулына эләккәч ни буласын белгәнгә, мин кычкырып еларга тотындым. Ярый әле әти килеп җитеп: «Тимә малайга»,—дип, мине әни кулыннан тартып алды. Шуннан бирле янгыннан куркам һәм саклана торган булып калдым. Әтинең кирәклеге дә ачыкланды.

Татарча яңа сүз өйрәнгәнем дә хәтердә. Сугыш башлангач, әти район үзәгенә—«Камски Устие»гә каралырга китте. Әни әйтте шулай дип: «Әтиегез каралырга китте»,—диде. Мин «каралырга» дигән сүзне кара төскә буялырга дип кенә белә идем, икенче мәгънәсе дә бар икән. Район бүлнисендә әтине дуктырлар карыйлар икән дә сугышка гуденмы, негуденмы икәнен әйтәләр икән. Соңыннан беленде, ул «медосмотр» дип атала икән. Көннәр, айлар үткән саен дөнья киңәя, зурая барды. Аны тану формасы да үзгәрә торды һәм бүгенгә кадәр дәвам итә. Тормыш күп кырлы. Аны бөтен кырларына берьюлы карап аңлавы читен. Шуңа күрә мин кырларның һәрберсенә аерым карап, шуларга үз мөнәсәбәтемне белдерергә тырышырмын һәм, бәлки, шуннан соң минем ничек үзгәрә баруым да ачыкланыр. Язмам әле тәмамланмаган.

Бераз бу якты дөньяда яшәп алырга өметләнәм. Димәк, үзгәрү дәвам итәчәк. Ә хәзергә... Тормышның кайсы кырыннан башларга икән? «Ватан» дигән төшенчәдән башларга кирәктер. Катлаулы сорауларга җавап эзләүнең башы шул сүздәдер.

## Ватан

Ватан сүзе татарга гарәптән кергән бугай. Төркиләрдә ул ил дип йөртелә. Бу өлкәгә инде мин галимнәрчә тирән керергә җыенмыйм. Бала чакта безгә ватаны да, иле дә авыл иде. Мәктәпкә йөри башлагач, туган ил дип атала торган сүз барлыгын белдек. Аның СССР дип аталганын да аңлаттылар. Соңрак ватан дигәне телебезгә керде. Ул хәтта туган ил дигәнне дә алыштырды шикелле. Чөнки ул ничектер серле ишетелә, китапча яңгырый. Ә китапта язылган һәр сүз - акыллы сүз, кирәкле сүз. Китап сүзе дигән төшенчә безгә укырга кергәнче үк инде сеңдерелгән. Әбиләр телендә ул бөтен бәхәсләргә дә чик куя торган дәлил.

Туган ил турында безгә бик күп җырлар өйрәттеләр.

*Нинди иркен минем туган илем,*
*Елгалар күп анда, кырлар күп*
*Кеше болай иркен сулый торган*
*Башка илләр әле җирдә юк.*

Без бу җырны класста да, сәхнәләрдә дә җырладык. Соңрак беленде—ул җыр урысчадан тәрҗемә икән. Урысчасы болай икән. Анысын да җырлаттылар:

*Широка страна моя родная,*
*Много в ней лесов, полей и рек.*
*Я другой такой страны не знаю,*
*Где так вольно дышит человек.*

Әйе, мәгънәсен аңлап бетермәсәк тә, җырладык.

Урман, кырлар, суларның күплеге аңлашыла иде безгә, ә «Где так вольно дышит человек» дигәне аңлашылып бетми иде Бүтән илләрдә кешеләрнең сулышы кысыла микәнни, диебрәк уйлый идек. Укытучылар аңлаткандыр инде анысы. Ләкин тотып карамагач, кабып карамагач, безгә ул барыбер аңлаешлы булмагандыр. Икмәк менә аңлашыла иде. Аның изге нәрсә икәнлегенә дә тиз төшендек. Чөнки без ачлар идек. Бер сынык ипидән дә кадерле ни-нәрсә бар? Ә туган ил безгә булды ни дә, булмады ни. Авыл булгач, бик җиткән. Хәтта район үзәге «Камски Устие» дә безгә ят. Олыларга ияреп Камскига бару кызык үзе. Анда Идел, пароходлар. Пристендә базар. Салам башлы марҗа кызлары, көрәк сакаллы урыслар урысча гына сиптерәләр. Урысча сөйләшкән кеше безнең өчен бөек кеше инде ул. Камскига баргач берәр сүз өйрәнеп кайтабыз да,мактанышып йөрибез. Мәктәптә дә укыталар урыс телен. Тик мәктәптә укыткан тел кызык түгел. Базарда өйрәнгәне кызыграк та, кирәгрәк тә. Бәрәңге сатканда безгә киләләр дә: «Почем картошка?» дип сорыйлар, син чартлатып «Один ведра тристы рублей», дисең. «Дорого» дисә, «Дурыгы булса, не бери» дип, кистереп куясың.

Авыл күңелгә якын булса да, без авылда тууыбыз белән түгел, СССРда тууыбыз белән горурланып үстек. Бигрәк тә сугыштан соңгы елларда. Әтиләребез сугышка киткәч, аларны зарыгып көттек. Фашистларга ләгънәт укыдык. Әтиләр җиңеп кайткач, ватаныбызның көче белән чын күңелдән мактандык. Әтиләре кайтмаганнарга «Ватан өчен барган изге сугышта батырларча һәлак булды» дигән язу килде. Бу сүзләр кордаш малайларның кайгысын бераз киметә дә төшкәндер, ахры. Күршебез Фәннурның: «Минем әти батырларча һәлак булган, ә синеке кайткан гына»,—дип әйткәне хәтердә. Күрәсең, мин малайлыгым аркасында әтием барлыгы белән кәпрәйгәнмен.

Ватанны олылау, ватанга фидакарьләрчә хезмәт итү, аны саклауның изге

бурыч икәнлеген һәрдаим безгә төшендереп тордылар. Патриотизм дигән сүзнең ватанга бирелгәнлек икәнен кайсыдыр укытучыбыз бик кызык итеп аңлаткан иде. Патриотизм—ул «патер» сүзеннән килеп чыккан икән. Ә «патер» латин телендә әти дигән сүз икән. Монда бераз бәхәс тә булып алды шикелле. Чөнки без ватанны әни белән тиңләргә өйрәнгән идек, Ватан—ана, Родина—мать дия идек, ә монда әти дә килеп кысылды. Урыс теле укытучысы Рәхимә апа ватанның родина дип тә, отечество дип тә йөртелгәнен төшендергәч, ватанга әтиләрнең дә катнашы барлыгы беленде.

Авылыбызга Германиядә әсирлектә булганнар да кайтты. Аларны без кешегә санамадык. Чөнки аларга ватанны сатучылар дигән тамга ябыштырылган иде. Андыйларның малайларын «плинни малае» дип атап, арабызга кертмәдек. Шулай дип әйткәнем өчен Гафият абый малае Хикмәттән миңа нык кына эләкте дә. Өйгә елап кайткач, әтинең: «Алай әйтергә ярамый»,—дигәне истә калган.

СССР ватаныбыз булгач, авыл безгә тарайды, аннан тизрәк чыгып китеп, ватанны урап кайтасы килә башлады. Өстәвенә, авылда тормыш авыр, әниләрнең безне тизрәк авылдан чыгарып җибәрәселәре, кеше итәселәре килә. Ләкин авылдан җибәрмиләр шул, документ бирмиләр. Бүгенгечә әйтсәк, крепостное право инде. Аннан качуның ике юлы бар: берсе—армиягә китү, икенчесе—укырга керү. Армиягә китү авылдан качу саналмый, ватанга хезмәт итү дип атала. Шуңа күрә яше җиткәннәр шатланып, горурланып китәләр. Минем дә бик хезмәт итәсем килде. Күзең начар күрә дип алмадылар. Ничек кимсенгәнемне үзем генә беләм. Күзлекне аяк астына салып таптыйсыларым килә иде. Җитмәсә, кызлары да «кәҗә билеты» дип мыскыл итәләр. Авылдан китү минем төп максатыма әйләнде. Шулай итеп, авыл миңа туган ил булудан да, ватан булудан да туктады. Университетка керергә имтиханнар биреп карадым, нимес теленнән «икеле» куйдылар. Әле ярый «икеле» генә куйдылар, без аны «берле»лек тә белми идек. Нимеснең бер сүзен дә аңламаган килеш, безгә аның грамматикасын өйрәтеп азапладылар. Нәтиҗәдә, тегесен дә, монысын да белмәдек.

Мәктәптә укыганда әти янында бухгалтерия һөнәренә өйрәнгән идем, сельпода хисапчы булып эшләдем. Шуннан мине Казанга сельпо бухгалтерлары әзерли торган курсларга җибәрделәр. Аны тәмамлагач, чирәм җиргә озаттылар. Поездларга төялеп, Казаннан чыгып киткәндә миннән дә бәхетле кеше юк иде. Алма-Атага, аннан Кустанай дигән шәһәргә поезд белән ватаныбыз буйлап ничәшәр тәүлек барганда мин чыннан да СССР дигән ватанымның зурлыгына шаккаттым. Чирәм җирдә СССРның төрле төбәкләреннән җыелган ватандашларым белән очраштым. Дөнья белән танышу миңа кызык иде. Миңа егерме яшь тә тулмаган иде шул әле. Аңламаган нәрсәләр дә күп иде. СССР ватаным булса да, мине нигәдер туган як сагындырды. Бер елдан соң, әллә ни уйлап-нитеп тормыйча, кайттым да киттем.

Мәскәүдә театр училищесында укыганда да СССР баласы идем. Биш ел ватанымның башкаласында укып кайткач, анда-монда буталып йөргәннән соң кулга язучы каләме алгач, каләмдәшләр белән сөйләшеп утырганда, съездларга делегат итеп сайланып, бүтәннәрне тыңлаганда нәрсәнең нәрсә икәнен аңлый башладым. Ватан дигән төшенчә бик үк изге түгел икән. СССР дигән ватанда бөтенебез дә тигез түгел икәнбез ләбаса. Беренче сортлы, икенче сортлы, хәтта өченче сортлы халыкларга бүленгән икәнбез. Кемнәргәдер нәрсәдер рөхсәт ителә, кемгәдер—юк. Нигә алай? Ни өчен, әйтик, союздаш республикаларга әллә ничә журнал чыгарырга рөхсәт ителә, безгә—юк? Ни өчен аларда киностудияләр бар, бездә—юк? Югыйсә халык саны буенча без СССРда алтынчымы, җиденчеме урынны билибез. Яшәгән саен сораулар кимемәде, арта гына торды. Бер-бер артлы татар мәктәпләрен ябалар. Хәтта республиканың төп гәҗите «Социалистик Татарстан»ны да урысчадан тәрҗемә итеп калдырырга җыеналар. Ни өчен? Ун миллионга якын татарның ни гаебе бар? Сугышта арысланнар кебек көрәшеп татар солдатлары СССР дигән ватанны якладылар. Геройлар саны буенча без дүртенче урында торабыз. Күпме татар яу кырында ятып калды. СССРның рәхмәте шушымыни? Җитмәсә, Тукайны игътибар белән укый башладым. Аның язганы безгә ятларга кушылган

«Сорыкортларга» гына түгел икән. Татарның Русия дигән илдә хокуксызлыгы турында ачынып яза бөегебез. Димәк, Русия дә, гәрчә аны Тукай уртак ватаныбыз дисә дә, ватан түгел, Казан ханлыгы Мәскәү тарафыннан яуланып алынгач, татарлар яшәргә мәҗбүр булган ил генә.

Гомер үтә торды, минем җаным СССР дигән ватаннан читләшкәннән читләшә барды. СССР халык депутаты булып сайлангач, съездларда, комитет утырышларында законнар кабул иткәндә мин СССР дигән ватаным һәм гомумән андый илнең юклыгын аңладым. Ул илдә шактый республикаларның яшәргә теләмәүләре мине куркуга салды хәтта. Латвиядән сайланган бер депутат белән сөйләшүем хәтергә сеңеп калды.

—Сез нигә СССР составыннан чыгарга шул кадәр ашкынасыз? Сез СССРдан башка яши алмаячаксыз, сезнең казылма байлыкларыгыз да юк. Машиналарыгызга салырга бензиныгыз да булмаячак,—дидем.

—Җәяү йөрербез. Тик СССРда түгел,—диде ул.

Украина депутатлары белән сөйләшкән булды. СССРны алар кебек яратмаган бүтәннәрне белмим мин. СССР таркала башлагач, «Украина белән Белоруссия китмәячәк», дигән сүзләр ишетелде. Шунда мин: «Америка СССР составына кергән чакта да Украина анда булмаячак»,—дип көлдергән идем. Кыскасы, СССР дигән ватан турында бөтен иллюзияләрем юкка чыкты. Ул Россия империясенең яңача аталышы гына булып чыкты. Бүген Ленинны эт итеп сүгәләр. Октябрь революциясен түнтәрелеш кенә дип атыйлар. Империя тарафдарлары югыйсә Ленинга рәхмәт әйтергә тиешләр. Ул СССР дигән исем астында Россия империясен саклап калды. Чөнки большевиклар властька килгәндә Россия империясе таркалыр дәрәҗәгә җиткән иде. Инде Россия минем ватаным булырга тиеш иде. СССР таркалган беренче чорда миндә андый өмет уянды. Күп иркенлекләр туган кебек булды. Бер ватанда төрле милләтләр тигез хокуклы булыр дип фаразларга мөмкинлек туды. Ләкин Россия хакимиятенең гасырлар буе чирләгән чире кабат үзен сиздерә башлады. Әкренләп кыса-кыса, безне телебездән махсус закон белән яздыруга хәтле килеп җиттеләр хәтта. СССРда, ни әйтсәң дә, туган телдә укытуны закон нигезендә тыюга барып җитмәгәннәр иде. Мине, СССРны ватаным дип күзе ачылган баланы, Россиядән тәмам биздерделәр. Бүген Россия минем ватаным түгел. Мин анда халык буларак үлемгә хөкем ителгән кавемнең бер баласы. Мине бетерергә җыенган илне мин ватаным дип атый алмыйм.

25 август—Җәлилчеләр фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелгән көн. Шул уңайдан Муса Җәлил һәйкәле янында митинглар уза. Анда, ватан өчен гомерләрен бирделәр, дигән сүз еш кабатлана. Шулай, әлбәттә. Ә мин уйланам: фронтта Россияне яклап гомерләр бирү хисабына без ни алдык соң? Азатлыкмы? Нинди азатлык? Балаларыбызны туган телебездә укытуны закон чыгарып тыю азатлык дип аталамы? Мин, мәсәлән, митингта ватан сүзен кулланмас идем. Дөньяда фашизмнан да куркыныч нәрсә юк, кешелекне шул афәттән коткару өчен башларын палач балтасы астына салдылар, дияр идем. Ватан мәсьәләсендә әгәр минем генә карашым бәхәсле булса, әлләни зур бәла булмас иде Россиягә. Бер татар ятратты ни дә, яратмады ди ул илне.

Миннән башкалар да бар бит әле. Бигрәк тә яшьләр. Бервакыт миңа бер төркем егетләр, кызлар сөйләшүенең шаһиты булырга туры килде. Алар 20—24 яшьләрдә. Чит илдә укучылар. Укып бетергәч, Россиягә кайту-кайтмау турында сөйләшәләр. Җиде-сигезләп кешенең берсе генә дә Россиягә кайтам димәде. Швейцариядә укучы бер кыз: «Мин укыган илемдә урам себерсәм себерәм, әмма Россиягә кайтмыйм»,—ди. Рус телендә әйтте ул сүзләрне. Болар - төрле милләт яшьләре: рус, яһүд, татар. Алар ун классны Казанда русча укып тәмамлаганнар. Ун ел буе аларга патриотизм турында акыл сатканнар. Шунысы да игътибарга лаек: аларның чит илдә калырга теләүләре матди тормышка бәйләнмәгән, барысы да акчалы кешеләрнең балалары. Сәбәп нидә? Димәк, үзен бөек милләт вәкиле дип атаган, бертуктаусыз русның бөеклеге турында сөйләнеп, язылып торган рус кешесенә дә яшәү кызык түгел, рәхәт түгел монда. Аларга да бу ватан кирәкми.

Монда милләтләргә генә түгел, кешеләргә дә хөрмәт юк. Әле күптән түгел генә бер коточкыч сүз ишеттем. Иделдә «Булгария» пароходы бату сәбәбен бер ханым: Бу Ходай каргаган ил, ди. Чөнки халыкларны иленнән куган, миллионнарны бер сәбәпсез аткан ил, ди. Ә Иделебез өстендә Сөембикә каргышы ята, ди. Казаннан көймәгә салып алып киткәндә каргамаган дисеңме аны, ди. Шуңа күрә явызларның явызлыгы өчен бүген бер гаепсез кешеләр, балалар харап була, ди. Мин аның белән килешмәдем, катастрофалар, фаҗигаләр Россиядә генә түгел, бүтән илләрдә дә булып тора, монда Сөембикәнең катнашы юк, дигән идем, ишетмәгәнемне ишеттем. Сәбәбе—яратмый ул бу илне, канлы тарихын яратмый, бүгенге әхлаксызлыгын яратмый, киләчәген күрми. Бу ханымны кыйнарга була, юк итәргә була, әмма Россияне яраттырып булмый. Яратмаган ире белән яшәүче хатын һәр минутта хыянәт итәргә әзер торган кебек. Сәбәбен Мәскәү эзләми бу куркыныч симптомның, ул «уничтожим, мочить будем в сортире» дигән сүзләрне генә белә. Баш бетләгән өчен башны кисмиләр, бетләүнең сәбәпләрен эзләп, тиешле дәвасын табарга тырышалар рәтле илдә.

Иң куркынычы—дәүләт белән дәүләт мөнәсәбәтенең кеше белән кеше мөнәсәбәтенә дә күчүе. Без Берлинда бер атна яшәп, «Данке шөн», «битте» дигән сүзләрне ишетергә күнегеп җиткәч, Мәскәүгә кайтып төштек. Казанга поезд көткән арада вокзалда сыра эчеп алырга уйладык. Сыра сатучы ханымнан: «Какое пиво хорошее?»—дип сорадык. «Откуда я знаю, пила что ли?»—дип бакырды апабыз, хәтта куркып та калдык. «Әллә яңадан Германиягә китәбезме, Туфан абый?»—диде Разил Вәлиев. Менә ул безнең ватандашыбыз. Мин дә бу илдән бүген үк чыгып качар идем, Ходайның биргәненә шөкер, Татарстан дигән Ватаным бар. Ул да Россиянең законнарыннан бер миллиметр да читкә чыкмыйча яшәүче буларак, күңелдә ризасызлыклар тудыра. Ләкин монда минем бабамнарның рухы яши әле. Ул рух җиребезгә тир булып та, кан булып та сеңгән. Аңа тел тидерергә минем хакым юк. Аннары авылым бар бит әле минем. Авылымны уратып алган Көянтә басуы, Ышна җире, Идән җире, Имәнлек дигән басулары, Карамал тавы, Кәҗә тавы, Умарталы Куак таулары бар, Сөби ермагы, Мулла кабыргасы, Бөтерек күле, Әхтәри күле, Моратый чишмәсе кебек урыннар бар. Алар инде минем ватанымның символлары. Алар күңелем бәргәләнгәндә дә, җаным кыйналганда да яшәргә таяныч булып торалар. Болар инде чын Ватан. Алар мине беркайчан да үги итмәсләр. Үзем исән чакта аларга мөнәсәбәтем үзгәрмәячәк, Алла боерса. Бу дөньядан киткәч тә җаныма сыенып урын шунда булыр. Мин кулыма язучы буларак каләм алганда беркайчан да авылымны, районымны хурлап бер нәрсә дә язмаска сүз бирдем. Җитешмәгән якларын күргәндә ул турыда авылдашларымның, райондашларымның үзләренә генә әйтә киләм. Үз өендәгесен урамга чыгып сөйләгән адәми зат буласым килмәде һәм килми. Ватаным Татарстан турында да ятларны сөендерерлек нәрсәләр язмадым һәм язмаячакмын. Кайберәүләр безнең бәгыребезгә кагылган ялгышларыбызны рус гәҗитләрендә бастыралар. Янәсе, аның резонансы киңрәк була. Мин аның белән дә килешмим. Әгәр үзегемә үткән җитешсезлекләрне күрсәм һәм аның турында язасым килсә, татар гәҗитләре бар. Үзебезнеке үзебезгә—ятлар кысылмасыннар. Безнең буынның хәтере үткәннәрне саклый. Без әле хәтерлибез, әтиләребез сугышка киткәндә:

*Әй, туганнар, туган җирнең*
*Белегез кадерләрен,*
*Герман границасында*
*Булмасын каберләрем, –*

дип җырлап киттеләр. Сакладык шул СССР дип аталган Россия империясен, гомерләребез бәрабәренә сакладык. Тик безнең генә аңа кирәгебез булмады һәм бүген дә юк. Менә шуны аңлау дәрәҗәсенә җитеп үзгәрдем мин. Үзгәрттеләр.

## Халыклар дуслыгы

Гомерем буе ишетеп ускән, үзем еш кабатлаган әлеге төшенчәгә дә мөнәсәбәтем нык үзгәрде минем. Минем генә дә түгел. Бүгенге вәзгыятьтә аңа караш икенче төрле. Сүз белән әйтелсә дә, урамнарда «Яшәсен халыклар дуслыгы!» кебек лозунглар күзгә бәрелеп тормый кебек. Аның сәбәбе дә ачык бугай. Элек Советлар Союзы вакытында бу илдә яшәүче бөтен халыклар да тигез хокуклы дип тәкрарладылар. Шуны исбатларга теләп, һәр җиргә «Совет халкына дан!» «Яшәсен СССР халыкларының какшамас дуслыгы!» дигән лозунглар да модада иде. Бүген, күрәсең, «Яшәсен Россия халыкларының дуслыгы!» дигән шигаре Россиядәге милли сәясәткә туры килми. Бүген Россиядә бер генә халыкка өстенлек бирелгәне турыдан-туры әйтелә. Бер генә халыкка өстенлек бирелгәндә исә халыклар дуслыгы турында кычкыру урынсыз икәнен аңлыйлар бүгенгеләр. Ул яктан алар мактауга лаек—ичмасам алдашмыйлар. Без исә СССР вакытында алданып яшәдек. Безне балачактан ук халыклар дуслыгы дигән буш имезлекне суыртып тәрбияләделәр. Советлар Союзында без, эреле-ваклы милләтләр, «дус булып, тигез булып, җырлап-биеп яшәдек». Халыклар дуслыгына ышандык. Ышанмаслык та түгел бит, чыннан да шулай. Минем бабай янына Антоновка авылыннан Ястәгнәй атлы рус агае килә, бергә аракы эчәләр, төрепкә тарталар. Бабай урысча сөйләшә, Ястәгнәй дәдәй татарча сукалый. Шунысы кызык—бабай Ястәгнәй дәдәйгә друг дими, ызнакум ди. Ястәгнәй дәдәй дә бабайга дустым дип әйтми. Ләкин аларның мөнәсәбәте дустанә. Әмма бу гәҗитләрдә язган, радиодан туктаусыз шапырынган халыклар дуслыгы түгел. Бу дуслык-знакумлык бергә яшәргә мәҗбүр булган, бергә-бергә яшәгәндә ызгышып, сугышып яшәп булмаганны аңлаучы гади кешеләр мөнәсәбәте. Ул сәясәтчеләр тарафыннан хәйләкәрләрчә ширма итеп файдаланылган «Халыклар дуслыгы»ннан аерыла. Асылда сәясәтчеләргә халыкларның чын дуслыгы кирәкми. Хәтта андый дуслык зарарлыдыр да әле. Халыклар үзләре теләгәнчә яшәсәләр, үзара мөнәсәбәтләрен үзләренчә көйләсәләр, халыкларны җитәкләргә алынган хакимнәрнең кирәге калмый. Үзләренең кирәклеген күрсәтер өчен хакимнәр халыклар арасын бутый, бер-берсенә каршы котырта, өстерә. Берсен бөек дип үсендерә, икенчеләрне түбән сортлы итеп мыскыллый. Әнә бит Кавказ халыклары мең еллар буе бер-берсенә җайлашып, тату яшәүнең үз формаларын табып гомер иткәннәр. Империя барып тыгылды да китте катавасия. Ә сәясәтчеләр һаман халыклар дуслыгы турында матур сүзләр сөйләшеп, низагны тирәнәйткәннән тирәнәйтәләр. «Бүлгәлә һәм хакимлек ит» төшенчәсе сәясәтчеләр уйлап чыгарган иң мәкерле нәрсә.

Боларны мин яши-яши аңладым. Үз күзем белән күргән «Халыклар дуслыгы» уйланырга мәҗбүр итте. Ястәгнәй бабай турында яздым. Ләкин, урыс-татар мөнәсәбәтләренең бик үк дустанә түгеллеген белмәсәк тә, сизенгәнбез. Марҗа кызларыннан «руски бабы без ыштаны, комары кусаются» дип көлә идек, урыс малайлары «урыс малай бик якши, татар малай бук аши» дип безне мыскыл итәләр иде. Әмма болар дошманлык түгел, бары тик үртәшү генә иде. Марҗа кызларының чәчләре салам төсендә булганга, аларны салам башлар дип атасак та, чибәрлекләре күзне кызыктыра иде. Аларны күрер өчен Антоновка, Урыс Тенешенә барып кайта идек. Яшерен-батырын түгел, борынга кызлар исе керә башлагач, алар белән үбешкән чаклар да булды. «Урыс белән дус булсаң, билеңдә балтаң булсын» ише мәкальләрне безнең буын балалары оныта язган иде. «Незваный гость хуже татарина» дигәнне дә Пушкиннан укып кына белдем. Бик күп урыс кешеләре белән аралашып, ул халыкка карата начар сүз әйтә алмыйм, һәрхәлдә, юлымда начарларына караганда яхшылары күбрәк очрады. Руслар белән татарлар, никадәр генә якынайтырга тырышсалар да, икесе ике халык. Аерымлык диндә генә түгел. Холыклар башка, яшәү рәвешләре, хәтта ашаган ризыклары да башка. Дус булып яшәр өчен охшашлыклар күп булырга тиештер. Ә «знакум» булырга болар һич кенә дә комачауламый. Урыс бәйрәм итәргә ярата. Татар өчен бәйрәмнәр—«эш калдыру». Аның җилкенеп алырга бер Сабан туе һәм җыены (элек) бар.

һәм аңа шул җиткән дә. Безнең дини бәйрәмнәребез дә җыелып «гүләйт итү» түгел.

Кабатлап әйтәм, һәм әле тагын да кабатланыр, безнең араны хакимнәр бозып тора. Аларга ярдәм итеп тамак туйдыручы галимнәр бер халыкның өстенлеген исбат итәр өчен «фәнни нигезләмәләр» уйлап чыгаралар. Бөек тел дигән нәрсә уйлап таптылар. Асылда бу көлке теория, ә тормышта куркыныч нәрсә. «Халыклар дуслыгы» дигән сүзнең ялган икәнлеген мин беренче мәртәбә нәкъ менә шул тел аркасында күрдем. Казанда трамвайда ике татар татарча сөйләшкәндә берәүнең: «Эй, вы, говорите на человеческом языке»,—диюе үртәшү түгеллеген аңладым. Димәк, кемнәр өчендер минем әниемнең теле кеше теле түгел икән. Мин хәзер беләм, безнең телне шулай мәсхәрә итүче рус агае Рәсәйдәге милли сәясәтнең корбаны гына булган. Ул месkенне шуңа ышандырганнар. Шуңа ышанган рус агай-энеләр бүген нишләргә белмиләр—кайсылары төрле экстремистик оешмалар оештырып, «читләрне» эзәрлеклиләр. Иң аянычы—урысны бер җирдә дә яратмыйлар.

Рәсми телдәге «Халыклар дуслыгы» ни икәнлеген мин икенче тапкыр «Чирәм җир»дә күрдем. Безнең яшьтәшләргә мәгълүм: 50нче еллар башында Чирәм җирләрне үзләштерү дигән нәрсә барлыкка килде. Казакъстан һәм Оренбург далаларын сөреп, иген үстерергә керештеләр. Анда эшләү өчен кешеләрне комсомол путевкасы белән дә, «партия чакырды» белән дә ташыдылар. Мин Казакъстанның Кустанай өлкәсенә эләктем. Кайсы гына милләт кешеләре юк иде анда. Халыклар дуслыгы бит. Ул дуслыкның ни икәнен мин эшли башлаган көнне үк ишеттем. Совхозрабкоопта баш бухгалтер идем. Рабкоопның рәисе Панченко дигән адәм миңа законда тыелган эшне эшләргә боерык бирде. Мин үтәүдән баш тарттым. «Я тебя научу, поганый татарчонок»,—дип кычкырды ул. Ләкин мин барыбер аның боерыгын үтәмәдем. Шуннан минем исем татарчонок кына булды аның өчен. Аңа илле яшьләр тирәсе, миңа унтугыз гына яшь. Шунысы яхшы: мине алып ыргытырга аның хокукы юк иде. Шулай итеп, берничә ай аның белән «дустанә» эшләдек. Безнең рабкооп урнашкан Каенлы күл (казакъча—Кайнды күл) авылында Сталин тарафыннан илләреннән сөрелгән ингушлар, Кырым татарлары яши иде. Мин аларның ни өчен сөрелгәннәрен белми идем. Үз яшемдәге егетләре белән аралашканым өчен Панченко «С изменниками родины дружишь» дип шелтәли иде. Бүтәннәр дә миңа ингушлар, Кырым татарларын хыянәтчеләр дип аңлаткач, мин танышларымнан читләштем. Шул наданлыгым өчен мин бүген ингушлардан, Кырым татарларыннан гафу үтенәм. Һәм мин бүген Россия империясен җитәкләүчеләренең дә илләреннән сөрелгән бу халыклардан гафу үтенүләрен көтәм. Алар, бәлки, без гаепле түгел, диярләр. Ләкин алар Россияне бөтен тарихы белән кабул итеп алдылар һәм ул тарих белән горурланалар. Шул куылган, изелгән, мәсхәрәләнгән халыклардан дуслык өмет итеп буламы? Ул коточкыч хәлләр өлкәннәр тарафыннан буыннан буынга сөйләп калдырыла. Һәр яңа туган баланың канына күчә. Чеченнарның күтәрелеп чыгуы, Кавказдагы чуалышлар шуның нәтиҗәсе түгел дип кем әйтә ала? Илне бомбага тотып, аннан җимерек илне төзәтергә акча биреп кенә ул җинаятьләрне, ул гөнаһларны юып була микән? Мин, мәсәлән, ышанмыйм. Ничә гасыр үткән, ә минем җанымда 1552 ел һаман яши.

Менә Казакъстанда миңа сабак биргән тагын бер хәл. Беркөнне мин коточкыч вакыйганың шаһиты булдым. Безнең кибетләр тимер юл вагоннарына урнаштырылган иде. Шунда нидер саталар. Чират тезелгән. Чиратта бер казакъ агае да бар. Аның янына бер адәм килде дә (милләтен белмим):

—Ты чего здесь стоишь, чучмек? Магазин только для целинников. Ну-ка, освободи место,—диде. Казакъ селкенмәгәч, теге аның җиңенә ябышып, тарткалый башлады. Казакъ үз дәрәҗәсен белүче булып чыкты, тегенең мордасына саллы гына итеп бер сылады. Теге бер-ике метр читкә тәгәрәде. Ярый әле җәнҗал зурга китмәде. Әмма барыбер чиратта торучылар казакъка килеп бәйләнгән әшәке җанны түгел, казакъны гаепләп мыгырдандылар. Шуны да әйтергә кирәк: кайбер товарларны «местному населению не продавать» дигән күрсәтмә бар иде безгә.

Мәскәүдәге ике еллык Югары әдәби курсларда үзбәк драматургы Абдукаххар Ибраһимов белән бергә укыдык. Еш кына кара-каршы утырып сөйләшә, серләшә идек. Дөньяга тәнкыйть күзе беләнрәк карый торган кеше иде. СССР дигән илне өнәп бетерми иде. Анда рустан башка халыкларны милләт буларак бетерергә планнар корылган, дия иде. Мәсәлән, бездә, ягъни көньякта гына үсә торган җимешләрне безнең авыздан алып төньякның читендә яшәүче чукчаларга, ненецларга җибәрәләр. Ә аларның организмы безнең җимешләрне ашарга көйләнмәгән, шуңа күрә алар кырылалар, без дә үзебезнең ризыктан мәхрүм калып, безнең организм күнекмәгән ризык белән тукланырга мәҗбүрбез, ди торган иде. Бервакыт, матур гына сөйләшеп утырганда, мин аны-моны уйламыйча, кемнәндер ишеткәнемне әйтеп ташладым: «Безнең бабайлар, әтиләр Урта Азиягә культура алып бардылар», дидем. «Әгәр дә мин сине хөрмәт итмәсәм, әйткән сүзләреңнең тарихны белмәгәнлектән икәнен аңламасам, синең белән сөйләшмәс тә идем, диде ул шунда.—Сез татарлар—урысларга сатылган халык, сез үз туганнарыгыз янына сыенып урын эзләп килгәндә урыс ияртеп килдегез, безгә басмачылар дигән яман кушамат тагып, безнең бабаларыбызны бергәләп үтереп йөрдегез, диде. Сезнең культурагызга мохтаҗ түгел идек, бездә цивилизация булганда Россия кыргыйлар иле әле, диде. Аның сүзләрен кире кагарга минем бер генә дәлилем дә юк иде. Шунда ук Шамил Усманов комиссар булган татар бригадасының Урта Азиядә кылган гамәлләре искә төште. Ул гамәлләр арасында коточкыч бер эпизод та бар. Дивизиягә «басмачы»ларга каршы хәлиткеч һөҗүм ясап, аларны юк итү бурычы куела. Кызыллар берничә тапкыр атакага күтәреләләр, ләкин «басмачылар» илбасарларны чигенергә мәҗбүр итә. Шулвакыт бер татарның башында гениаль план туа. Солдатлар тәкъбир әйтеп атакага күтәреләләр. «Басмачы»лар «Аллаһ әкбәр! Алла әкбәр!» дигәнне ишеткәч, аптырап-каушап калалар. Шуннан файдаланып кызыллар «басмачы»ларның позициясенә бәреп керәләр һәм үз җирен яклаучыларны кырып бетерәләр.

Мин ул көнне безнең алданган бабаларыбыз, әтиләребезнең вәхшилеге өчен Абдукаххардан гафу үтендем. Менә ул халыклар дуслыгы. Мондый «дуслык» хөкем сөргән ил ничек таркалмасын!

«Халыклар дуслыгы»ның ни икәнен СССР халык депутаты булган чакта да күп күрдем мин. Автономия республикаларының икенче сорт икәнен рәсми рәвештә, ачыктан-ачык әйтәләр иде. Ә мине иң гаҗәпләндергәне—төрле милләт депутатларының Мәскәүгә мөнәсәбәте иде. Мәскәүне яратмаганнарын күреп аптырый идем. Украиннарның мыскыллы кыяфәт белән «москаль» дип әйтүләрен төшенә алмый идем. Югыйсә безгә аларны бик якын туганнар дип аңлаткан иделәр. Ә инде Балтыйк буе халыкларын әйтеп тә торасы юк. Алар бары тик СССРдан котылу турында гына сөйлиләр иде.

Шул уңайдан кызыклы һәм гыйбрәтле бер вакыйга. Литвадан сайланган депутат СССР Югары Советы утырышында СССРдан чыгу турында сөйли, Литваны оккупацияләнгән ил дип атый. Шунда безнең янда утыручы бер рус депутат: «Не пустим!»,—дип кычкыра. Мин күршемә: «Да-а-а... Как вы их любите»,—дидем. «Я? Я их ненавижу»,—ди. «Почему же тогда не отпускаете,—дим.—Я вот их не люблю, пусть уходят». Шуннан бу «өлкән туганым» миңа нәфрәт белән карады да, ямьсез итеп сүгенде. Менә ул нинди безнең дуслыгыбыз. Бүген миңа боларның берсе дә гаҗәп түгел. Чөнки мин инде анык беләм—Мәскәүгә без халык буларак кирәкмибез. Безне юкка чыгару өчен Мәскәү ачыктан-ачык тырыша. Хәтта туган телләребездә укытуны тыя. Халыкларның табигый дуслыгын бетерү өчен бөтенесен эшли Мәскәү. Һәм моны Халыклар дуслыгы дия-дия эшли. Ләкин мине һәм бүтәннәрне бу ялган лозунг белән алдап булмый инде. Мәскәүнең безне яратмаганын, безгә ышанмаганын без инде күреп торабыз. Җавап итеп без дә Мәскәүне яратмыйбыз һәм аңа ышанмыйбыз. Моңа без түгел, империя исереклегендә яшәп реаль тормышны белмәгән Мәскәү гаепле. Юк ул Рәсәйдә Мәскәү куерергә хыялланган «халыклар дуслыгы». Хәер, ул сүз, әйткәнемчә, бүген әллә ни еш кабатланмый да бугай инде.

Кыскасы, мин үзгәрдем. Мин инде бүген үррә катып, горурланып: «Союз

нерушимый», «Дружба народов—надежный оплот», дип җырлаучы наив малай түгел, халыклар дуслыгының ялган лозунг икәнен үзем күреп аңлаган кеше. Чуртан белән кызылканат, бер суда яшәсәләр дә, дус була алмыйлар. Әгәр дә без бергә яши алуның серләренә төшенмәсәк, чуртаннар янында уяулыгыбыз җитмәсә, «Халыклар дуслыгы» буш сүз булып кына калачак. Безгә, ерткыч булмаган халыкларга, аеруча сак булырга кирәк. Чуртанның үзгәрүен өмет итмик.

Әле язганнарымны кабат укып чыктым да, нәрсәдер әйтелмәгән кебек калды. Халыклар дуслыгы җирдә юк һәм була алмый кебегрәк фикер калды сыман. Юк, мин һич кенә дә андый уйда түгел. Әгәр халыклар дошманлашып кына яшәсә, кешеләр җирдә бу чаклы үрчемәс иде. Кешеләр телендә дуслык дигән сүздән тыш татулык дигәне бар. Татулык ул—бер-береңне аңларга тырышып, дөньяда син генә түгел, бүтәннәр дә барлыгын исәпкә алып яшәү. Бабай белән Ястәгнәй дәдәй мөнәсәбәте—татулык үрнәге. Мин һәрвакыт язылмаган законнар язылганнарына караганда әһәмиятлерәк дип яшәүче адәм баласы. Әйткәнемчә, кешеләр бергә яшәр өчен җайлашканнар. Аларның бергә яшәү рәвешен кешеләр өстеннән хакимлек итәргә алынучылар боза. Мине кайберәүләр «национал» дип гаепләргә, бүтәннәргә, бигрәк тә русларга каршы татарларны котыртучы дип атарга маташа. Аллам сакласын! Мин бары тик үз халкымның бүтәннәр арасында тигез хокуклы булып яшәргә хакы бар дип кенә саныйм. Татар җирдәге бер генә халыктан да өстен дә түгел, ким дә түгел. Рус халкы да, кытай да, чукча да шулай. Барыбызга да бер кояш. Кем моңа каршы икән, мин аның белән фикердәш була алмыйм. Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче чын рус егете Николай Алешков миңа мондый култамга язып китабын бүләк итте: «Туфану Миңнуллину, любявщему свой народ и уважающему другие народы». Миңа иң дөрес бәя бу.

Теләгем шул гына: халыклар үзара килешеп яши белә, сәясәтче хакимнәр кысылмасыннар иде арабызга. Халыкларны бер-берсенә кайбер дин әһелләре дә каршы куя. Алардан да сак булырга кирәк. Бу турыда мин «Дин» дигән бүлектә язачакмын. Ә хәзер минем тормышымда бүтән милләт вәкилләре белән булган берничә вакыйганы теркәп куярга телим. Аларның кайберләре матбугатта дөнья күрделәр шикелле. Монда да кабатланса, урынсыз булмастыр.

Үткән гасырның сиксәненче еллары бу, кибеттә чират торам. Ул көнне түбәтәй кигән идем. Бер адәм бәйләнде бит үземә.

—Чё ты надел чаплашку, сними,—ди.

Мин инде:

—Что, она вам мешает что ли?—дим.

—Мешает, сними,—ди. Китми генә бу янымнан. Түбәтәйне һәм татарны мыскыллап әллә ниләр әйтеп бетерде. Катырак сөйләшергә дә куркыныч—кыяфәте җанварныкы шикелле, әзмәвер гәүдәле. Җанвар һаман узына—төрткәли үк башлады. Шунда чираттан берәү чыкты да, тегене якасыннан эләктереп алып, ишеккә таба сөйрәп китте. Ишеккә җиткәч, бик әйбәтләп кенә арт ягына типте. Теге йөзе белән асфальтка барып төште. Яклаучым яныма килде дә:

—Извини, брат, не все русские такие свиньи,—диде.

Безнең районда татарлар һәм руслар кушылып яши торган Тенеш авылы бар. Элегрәк Сабан туйларында салмышлар күбрәк була иде. Шулар сугыш чыгара иде дә, авылга авыл чыгып бәргәләшәләр иде. Бервакыт кайсыдыр бер авыл егетләре белән Тенешләр сугышты. Урысы, татары бер булып теге саф татар авылына каршы сугыштылар. Күпме яшәп, безнең районда милләтара низаг булганны хәтерләмим мин.

Районыбызда янә Мәсте, Чыршалан, Мукшы Каратае дигән мордва авыллары бар иде. Бүген аларның икесе юк инде. Нык аралаша идек ул авыл кешеләре белән, кунакка йөрешә идек.

Бервакыт Казаннан кайтышлый Лабыш дигән рус авылында кунарга туры килде миңа. Ул чакта Казаннан авылга икешәр тәүлек кайта идек. Шул авылда мин ике көн кунак булып яттым. Туй вакытлары иде. Болар минем балачагым,

яшьлегем истәлекләре генә. Бүгенге көнгә хәтле минем юлымда башка милләтләрдән, шул исәптән руслардан да искиткеч кешеләр очрады. Әшәкеләре дә очрады, ләкин алар аз иде һәм андыйлар арасында үз милләтемнең имгәкләре дә юк түгел иде. Инанганнан инана барам—шовинизм бары тик теге яки бу дәүләт хакимнәренең империячел сәясәте генә. Шулар котырта халыкларны. Үз-үзен якларга тырышучыларга «националисты» дигән ярлык тагып, шовинистлар маташтыра. Национализмның ортодоксаль формалары бары тик шовинизм булган илдә генә була. Мин моны үзем күреп, үзем яши-яши аңладым. Беркем мине өйрәтмәде, котыртмады да.

Адәм балалары бик әйбәтләр, алар дус булып яши беләләр дип кешеләрне идеаллаштырырга җыенмыйм. Дуслар арасында да низаглар булып тора, ләкин һәр халыкның акыллы кешеләре бу низагларны сөйләшеп-аңлашып хәл кылырга ярдәм итәләр. Хакимнәр исә еш кына, киресенчә, низагны ызгышка әйләндерергә җай гына эзлиләр. Дөньяга хуҗа булырга алынган хакимнәрнең иң ачы дошманнары - тату яшәүче халыклар. Олыгайган көнемдә булса да моны аңлауның миңа ярдәме тия. Минем яшьтә эйфория дөньясында яшәп, ялган лозунгларга ышанып яшәү килешмәс иде. Иң куркынычы—ул ялган әсәрләремә күчәр иде. (Бәлки, күчкәннәре дә бардыр). Дуслык дигән иң кадерле сүзне арзанайтыр идем. Берзаман бүтән илләр белән «тыныч яшәү» дигән сүз модага керде. Хәзер ишетелми шикелле. Ә ул сүзне мода итеп кенә калдырмыйча, яшәү рәвеше итсәк иде. Халыкларга шуннан артыгы кирәкми. Бары тик тыныч һәм аңлашып яшәп кенә була.

## Дин

Диннең нәрсә икәне, аның килеп чыгуы турында акыл сатарга җыенмыйм. Дөресен әйткәндә, күп нәрсәне белеп тә бетермим. Мин бары тик үз-үземне аңлый башлаганнан алып бүгенге көнгәчә яшәү арасында диннең миңа йогынтысы турында гына, ягъни мәсәлән, диннең мине ничек үзгәртүе хакында гына язарга телим. Дин кеше тормышында иң нәзберек урынны били. Шуңа күрә ул турыда язу да аеруча җаваплы гамәл, сакланыбрак эш итәргә кирәк булыр. Дин әһелләре белән дә бәхәскә керәсем килми. Ни кызганыч, алар арасында да Мәрҗани, Курсави кебек тирән белемле руханилар юк диярлек. Үз карашларын дәлиллисе, мине ышандырасы урында гаеп тагарга гына торучылар бар.

Мин—тәһарәтсез буынның бер вәкиле. Безнең әти-әниләребезне диннән биздерү, безне динсез итү өчен Совет хөкүмәте, Коммунистлар партиясе бөтен көчен куйды. Һәм үз дигәненә ирешә язды. Авыл кешеләренең үзләреннән мәчет манарасын кистерү факты үзе генә дә ни тора! Дөрес, манара кисүчеләр элек дин юлында йөрүчеләр түгел. Аларның күбесе әтрәк-әләм булган. Әмма шул әтрәк-әләмнең арт сабагын укытырлык көч тә табылмаган, күрәсең. Авыл халкы өчен манара кисү күтәрә алмаслык фаҗига саналмаган. Хәер, Сталин режимы вакытында миллионлаган кешеләрне ату, сөргә каршы да халыкның бердәм баш күтәрүе булмаган. Шуңа күрә халыкны кирәгеннән артык идеаллаштыру да ярамыйдыр. Халык бар, гавәм бар. Гавәм халыкның күпчелеген тәшкил итә. Бу турыда фикер йөртү өчен аерым бер фәлсәфи хезмәт язарга кирәк. Кыскасы, мин үсеп җиткәндә безнең авыл кешеләре мәчетсез яшәргә ияләшкәннәр, күнеккәннәр иде инде. Һәм, кызганыч ки, бүген дә аларга мәчетнең әллә ни хаҗәте юк шикелле. Ярый әле авылыбызның мулласын сөрмәгәннәр. Гайсә мулла үзебезнең авылда 100 яшенә җитеп вафат булды. Кирәкле кеше булып яшәде. Мин хәтерлим әле, аны һәрдаим авыл халкы ашка чакырып, дога кылдыра иде. Дога укып мәетне теге дөньяга озатыша иде ул. Ярый әле өстән кушканны арттырып үтәүчеләр моны тыймадылар. Мәетне җирләгәндә без бала-чагалар да өлкәннәргә ияреп бара идек. Баруыбызның максаты дингә бәйле түгел, җирләүчеләргә сәдака таратканда безгә дә өлеш чыга иде. Ләкин дога укыганда «бисмилла, бисмилла, Аллаһы әкбәр, Аллаһы әкбәр»,—дип эчтән генә кабатлап тора идек. Әйе, кыссалар да, динсез итәргә тырышсалар да,

безне имансыз итә алмадылар. Әбиләребез, әниләребез сакта торды. Мин үз-үземне белә башлаганнан бирле кашык белән ашка үрелгәндә «бисмилланы әйттеңме?», өстәл яныннан торып киткәндә «Аминьны тоттыңмы?» дигән сүзләрне ишетеп үстем. Югыйсә безнең гаиләдә дин тотып намаз укучылар юк та иде. Нәселебездә дә дин таләп иткән фарызларны үтәп яшәүчеләр булмаган. Бабабызның нигезе мулла бабай өе белән янәшә булганга, нигез хуҗасы күршесенә еш кына ярдәм иткән, әмма мәчеткә бәйрәм көннәрендә генә барган. Бабам: «Син ачуланма инде, хәзрәт, җомга намазларына йөри алмыйм»,—дигәч, мулла абзый: «Хафаланма, Габделгани, вакыты җиткәч йөрерсең»,—дигән.

Әтиебез Казанда туып, үсмер яшенә чаклы шунда яшәгән, мәдрәсәдә укыган. Күрәсең, мөгаллимнәре белемле кешеләр булгандыр, әти, мәдрәсә тәмамламаса да, гарәп язуын бик яхшы белә иде. Коръән сүрәләреннән дә хәбәрдар булгандыр, Гайсә бабайдан соң мулла булып саналган авылдашларның дога кылганда Коръән сүзләрен ялгыш әйтүләрен белгәндер. Бервакыт Гарифулла абыйлардан Коръән ашыннан кайткач, әнигә көлеп сөйләгәне хәтердә. «Аларның укуын тыңласаң, Алла юк дигән мәгънә килеп чыга»,—дигән иде. Ул мин әтидән: «Алла бармы?»—дип сорагач: «Үскәч белерсең»,—дигәне истә. Шуның белән ни әйтергә теләде икән ул, вакытында сорамаганмын. Бүген уйландыра. Һәрхәлдә, юк дип әйтергә теләмәгәндер, бала акылы мин әйткәннәрне аңларлык түгел, башын бутамыйм дип уйлагандыр. Чөнки безнең баш нык буталган иде шул, аны ерып чыгарлык түгеллеген тойгандыр әти.

Үсә-үсә диннән бөтенләй читләшелде. Хәтта бисмилла белән аминны да әйтми башладык. Аларны әйтмәсәк тә, «Әлхәм» белән «Колһуалла»ны яттан белә идем. Балачактан өйрәнгәнгә күрә хәтердә ныклап сакланган. Җае туры килгәндә шуларны укып, «гыйлемемне» күрсәтеп мактангаладым да хәтта. Дин белән алыш-бирешем булмаса да, намаз укучы әбиләргә хөрмәтем зур иде. Әлбәттә инде, Ислам динендә булмаганнарның гыйбадәт кылуын карап тору күңелдә ризасызлык тудыра иде. Нишләтәсең, акыл белән күп нәрсәне аңласаң да, күңел дигән нәрсәгә каршы тору җиңел түгел шул. Ислам дине бабайлардан канга сеңеп калган, бәлки, бу геннар эшедер дә. Шуңа күрә, дин алыштыручыларны өнәмим. Хәтта башка диннән Исламга күчү динебездә хупланса да, мин андыйларны хупларга ашыкмыйм, дөресрәге, аларның ихласлыгына ышанып бетмим. (Әгәр бу гөнаһ саналса, гафу үтенәм).

Әйе, мин әлек үк Ислам дине тарафдары булып, үземне мөселман дип санаган кеше. Мәскәүдә укыганда Вольтерның «Мөхәммәд» дигән пьесасын укып чыгып, пәйгамбәребезне хурлаган өчен авторын каһәрләгән идем. Шул вакытта Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәр турында пьеса язарга алынган идем. Шуңа әзерләнү өчен Мәскәүнең Ленин исемендәге китапханәсенә йөри башладым. Ислам диненә кагылышлы күп китаплар укыдым. Крачковский тәрҗемәсендә Коръән Кәримне укып чыктым. Ләкин берни дә аңламадым. Аңлашылмавы белән ул миңа нык тәэсир итте, хөрмәт уятты. Бер укып чыгуда ук аңлашылган китап изге китап була алмыйдыр ул дип уйлап, берничә тапкыр укыдым, әмма барыбер аңлашылмады. Хәзер дә аңлап бетерә алмыйм. Күрәсең, фикере тирән яшерелгәндер, аңлар өчен гомереңне сарыф итәргә кирәктер һәм укыган саен үзеңә бер ачыш ясыйсыңдыр. Ислам дине турында зур-зур акыл ияләренең фикерләре белән таныштым. Аеруча истә калганы Лев Толстой сүзләре булды. «Попробуйте придумать такую идеологию, в которую верили бы миллионы людей в течении нескольких столетий» дип язып калдырган ул Ислам динен олылап. Дин турында күбрәк белгән саен миндә пьеса язу теләге сүнә барды. Бу хәтле йөкне күтәрә алмасыма төшендем. Өстәвенә, режиссер Габдулла абый Йосыпов, минем уемны ишеткәч: «Юк эш белән маташма, ул теманы син түгел, синнән битәррәкләре дә күтәрә алмый әле»,—диде.

Мәскәүдә югары әдәби курсларда укыганда безне Мәскәү янындагы Загорск шәһәренә алып бардылар. Анда Христиан дине руханиларын әзерли торган

«Духовная академия» бар иде. Барганда безне кисәтеп куйдылар: «Академиядә укучылар белән бәхәскә кермәгез»,—диделәр. Без аны безнең ирекне кысу, безне «дин сөреме»ннән саклау дип бәяләгән идек. Соңрак аңлашылды—безне көлкегә калдырмас өчен шулай эшләгәннәр икән. Чөнки без философия һәм теология фәнендә чеп-чи наданнар, ә академиядә белем алучылар ул фәннәрне су кебек эчәләр икән. Анда укучыларның күбесе башта Мәскәү университетының философия факультетын тәмамлап, Академиягә килгәннәр икән. Безнең Ислам университеты өчен үрнәк алырлык нәрсә бу. Ислам диненең нечкәлекләрен аңлау өчен бисмилла әйтеп, бернičә Коръән сүрәсен ятлау гына җитми. Идеологик көрәштә «син—дурак» дип әйтү үз ахмаклыгыңны гына күрсәтә. Дин ул Алланың берлеген танып, аңа табыну гына түгел, ул—идеология. Бер мисал. 48 еллар элек Г.Камал театры Уфага гастрольгә барган иде. Шунда Уфадагы Диния нәзарәтенә экскурсия оештырдылар. Анда мөфти белән очрашу булды. (Кем булгандыр ул вакытта мөфти, хәтердә калмаган). Без үзебезне белемле, мөфтине исә наданга санап, бәхәсләшергә тотындык. Кеше Космоска менә, күкләрне айкап йөри, кеше акылы шул дәрәҗәгә күтәрелгәндә бөтен нәрсәне Алла кодрәтенә кайтарып калдыру артта калганлык галәмәте түгелме, дидек. Мөфти безне гаепләргә ашыкмады, елмайды гына. «Алайса, сез миңа әйтегез әле, кешегә шул хәтле акылны кем биргән?»—диде. Без телебезне тешләп тын калдык. Надан галимнәрне (бу сүзләрне янәшә куюым өчен гафу үтенәм. Надан булгач, галим була алмый ич инде. Әмма, ни кызганыч, бездә галим саналучы надан фән докторлары бар) төп башына утыртыр өчен тирән белемле дин белгечләренә без бүген бик мохтаҗ. Мин үзем, мәсәлән, Ислам динен җаным белән генә түгел, акылым белән кабул итәм. Дөньяда мантыйк дигән фән бар. Ислам дине мантыйк ягыннан иң камил диндер. Дәлилләү өчен мисаллар да бар.

1. Ислам динендә «Лә Иллаһ, иллә Аллаһ» дигән сүзләр мөселманлыкның төп нигезе. Әйе, «Алладан башка Алла юк». Аның анасы да, атасы да, улы да була алмый. Ул—рух, бары тик рух кына. Әгәр Алланың әнисе һәм улы бар дип санийбыз икән, үзебез дә Аллалыкка дәгъва кылучылар булып чыгабыз. Чөнки Христиан динендә Алла анасы (Богоматерь) һәм улы (Сын божий) кешеләр. Дөньяда иң куркыныч нәрсә—кешедән Алла ясау. Ул гөнаһлы җан булганга күрә, «Алла» булып алгач, күрсәтә күрмәгәненңне. Ә рухка хаким ролен үтәүнең хаҗәте юк. Кешедән Алла ясауның фаҗигасен СССР заманында халык үз җилкәсендә татыды. Сталинга табынып, миллионнарның башына җиттек.

2. Христианнар икона дип рәсем ясый да, үзе ясаган рәсем каршында тезләнеп гыйбадәт кыла. Өстәвенә әле, үзе ясаган рәсемне ниндидер могҗизаларга ия дип тә саный. Хәтта күп кенә иконаларның исемнәре дә бар. Бу—наивлык. Монда Алланың—бөек затның һич катнашы юк. Исламда исә син Бөек зат алдына гына тезләнәсең, хәтта башыңны җиргә орасың. Бу инде сине уратып алган рух белән очрашу, аны олылау. Бу—бөек философия. Монда һәртөрле бәхәскә урын калмый.

3. Адәм баласы гөнаһ кылмыйча яши алмыйдыр. Гөнаһ кылмыйча яшәү өчен Алланың үзе кебек булырга кирәк. Бу - ирешә алмаслык нәрсә. Ходай дөньяны матур итеп, яшәргә кызыклы итеп яраткан, анда безне сынар өчен алдавыч нәрсәләр дә шактый. Тора каршыңда, мин сиңа әйтим, бер секс-бомба, итәге бот төбеннән, кендеге шәрә, имиләренең яртысы ачык, килә бит шуны кочаклыйсы. Барып кочаклар идең, батырлык җитми. Батыраер өчен бераз кәгеп аласың. Кыскасы, гөнаһ кыласың. Соңыннан айнып китәсең, китүен, ләкин инде эш узган. Христиан динендә шул гөнаһны кичерүен сорап руханига барасың. Ул синең гөнаһыңны кичерә ала. Ярый ла ул рухани гөнаһсыз булса, ул да бит адәм баласы—аның да тамагы һәм бүтән нәрсәләре бар. Әгәр дә минем гөнаһларымны җирдә кичерә алучы булса, миңа тагын, тагын да гөнаһ кылу берни тормый. Кичерүче рухани белән һәрвакыт уртак тел табып була. Ә Исламда гөнаһларыңны тик бер Ходай гына йә кичерә, йә кичерми. Монда инде сак булырга кирәк. Астан да, өстән дә, уңнан да, сулдан да, алдан да, арттан да сине күзәтеп торучы рух бар. Гөнаһ кылу кызык, рәхәт, файдалы булган очракларда да тыелыбрак калырга мәҗбүр буласың. Ә бит әле гөнаһларның

кичерелми торганнары да бар. Әти-әниеңне рәнҗетү, ил-халкыңа хыянәт итүне Ходай кичермәячәген алдан ук белеп торасың. Мин белеп бетермим, бәлки, бүтән диннәрдә дә әлеге гөнаһлар кичерелми торгандыр. Дин мәсьәләсендә минем башымда һәм күңелемдә туган үзгәрешләр күп. Мин аңлар-аңламас бисмилла әйтүдән, Алланың барлыгын әбиләрдән ишетүдән башлап, бүген акылым белән дә, күңелем белән дә Бөек затның барлыгына инанган кеше. Үземне мөселман дип санаган хәлдә, динне идеология дип атаучы кеше. Дин идеология булгач, аның идеологлары да булырга тиеш. Бу хезмәтне үтәүче дин әһелләренең дәрәҗә буенча ничек аталганнарын санап тормыйм. Хәзрәтләребез дип әйтсәм, ялгыш булмастыр. Аларга да минем мөнәсәбәтем үзгәреш кичерде. Малай чакта мәктәп динсез итеп тәрбияләргә тырышса да, авылыбызның муллася на хөрмәтебез зур булды. Бала-чага өчен хөрмәт дигән сүз урынсызрактыр, ул, бәлки, шүрләү дип аталадыр. Мулла бабайдан шүрли идек шул. Юк, ул усал, явыз булганга түгел, тәртип сакчысы иде бит мулла бабай. Безгә—тәртип бозучыларга шүрләргә генә кала. Дөрес, без укырга кереп мәктәп баласы булган елларда мулланың дәрәҗәсен төшергәннәр иде инде. Күпләрен сөргән, аткан булганнар. Ни хикмәттер, безнең мулла бабабыз безнең янда калды. Йортыннан куылып, карчыгы белән бәләкәй генә, келәт чаклы гына бер өйдә яшәделәр. Карчыгы бик тә сөйкемле бер әби иде. Соңыннан билгеле булды—ул чыгышы буенча Бакый Урманче нәселенә барып тоташа икән. Затлы нәсел. Мулла бабай турында мәгълүматларым бик аз. Исеменең Гайсә булганын соңрак белдем. Чистай ягында туып, Казан мәдрәсәсендә укыган бугай. Бик олылап искә алалар аны белгәннәр. Безнең әни ягыннан төп нигезебез аларның күршесендә булган. Минем бабайга:

—Хафаланма, Габделгани...—диюе муллабызның акыллы кеше икәнен күрсәтүче факт. Сугыш елларында карчыгы вафат булып, ялгызы гына калгач, кыш көннәре авыл халкы үз өйләренә алып кайтып тәрбияли иде аны. Бездә дә бер ай яшәде. Карт иде инде, җылы мич башыннан төшмәде. Әни шаулашмаска кушып безне тыеп торды. Ризыкның да тәмлерәге аңа эләккәндер, күрәсең, без аны яратып ук бетерми идек. Ләкин әни сүзеннән чыкмый идек. Чыгар идек тә, әнинең күз карашына өстәмә дә—каеш та була иде. Мулла бабайның кабере авылыбыз зиратында, аның рәшәткәсенә беркетелгән пластинкага 1845—1945 дип язылган. Димәк, 100гә хәтле яшәгән.

Мин укытучы белән мулла ялгышмый дип ышанып үстем. Бүген исә, ялгышырга тиеш түгелләр, дим. Чөнки ялгышкан укытучылар, ялгышкан хәзрәтләр шактый. Хәзрәтләр мәсьәләсендә ялгышуның сәбәпләре ачык—алар арасында очраклы кешеләр бар. Аларның күбесе, бигрәк тә авыл җирендә, дин гыйлемен алмаган, үзлегеннән берничә дога ятлаган кешеләр. Әти әйтмешли, наданнар. Ләкин моның өчен аларны гаепләргә ярамый, бушка эшләп йөргәннәре өчен рәхмәт әйтергә кирәк. Ләкин наданлык укытучы белән муллага гафу ителми. Чөнки кешеләр белән эшләүне дөньяви гыйлем дә, дини белем дә таләп итә. Бигрәк тә мәчет тирәсендә үзен белдеклегә санап йөрүче наданнар куркыныч. Юкка гынамыни Тукаебыз надан муллалардан көлгән. Бервакыт шагыйрь Фәннүр Сафинны җирлибез. Мәетен мәчеткә алып бардык, хәзрәтләрнең өйлә намазыннан чыкканнарын көтәбез. Йөри бит шунда бер түбәтәйле адәм баласы.

—Язучылар, кяферләр, мәетне гроб белән күмәләр,—дип туктаусыз сөйләнә, бәйләнә. Шунда мин моны читкәрәк алып киттем дә:

—Абзый кеше, белер-белмәс көе йөрмә сөйләнеп, без гроб белән күммибез, табут белән күмәбез,—дим.

—Нинди табут ул тагын?—ди.

—Белмәсәң, йөрмә буталып, белеп кил,—дигәч, югалды тагын рәхмәт төшкере.

Бүгенге хәзрәтләребезгә ни җитми?

1. Әйткәнемчә, төпле, тирән белем. Берничә дога ятлап алырга әллә ни гыйлем кирәкми. Ә менә кешеләр белән сөйләшү, аларны аңлый белү, юлдан авышканнарны хак юлга кертү, намазга бастыру, диннең асылын аңлату өчен

күп фәннәрдән хәбәрдар булу кирәк. Бигрәк тә вәгазь сөйләгәндә каршында кемнәр утырганын белү зарур. Югыйсә йоласына туры китереп, теге яки бу уңай белән Коръән сүзе ишетергә дип мулла чакырасың, ул ятлап алган вәгазен сөйләргә тотына. Сөйли дә сөйли, тыңлаучының ялыгып беткәнендә бер эше юк. Мин белгәннең чиреген дә белми, бахыр, ә миңа тәмугның нәрсә икәнен һәм башка мин белгәннәрне кабатлый. Бәлки, бу томанарак кешеләр өчен ярыйдыр, әмма кеше бүген томана түгел. Безнең хәзрәтләребез теләсә кайсы философ белән бәхәсләшә алырга һәм бәхәстә җиңүче булырга тиешләр. Бүген ваһһабизм тирәсендә күпме сүз бара, ә шуның төп асылын күпләр белми. Күрәсең, хәзрәтләребезнең күбесе ул мәзһәбнең төп асылын аңлап бетерми. Ярамый яки ярый дип әйтү өчен тирән белем кирәк. Бигрәк тә мәгълүмат чараларыннан хәбәрдар булган белемле яшьләр белән аңлашу өчен алар белгәннән артыграк белү зарур.

2. Игътибарлылык. Хәзрәтләр өчен бөтен кешеләр дә тигез булырга тиеш. Чөнки Ходай кешеләрне тигез итеп яраткан. Кем белән генә сөйләшмәсен, ул каршында торучыны бик зур игътибар белән тыңларга, ихтирам белән җавап бирергә тиештер. Бу һәркемгә билгеле хакыйкатьне шуның өчен әйтәм— мин хәзрәтләрнең игътибарсызлыгы, битарафлыгы белән еш очрашкан кеше. Бер генә мисал—«Сөяркә» пьесасын (элек ул минем кульязмада «Гөнаһсыз гөнаһлылар» дип атала иде) язганда сөяркәлек мәсьәләсендә төрле диннәрнең карашын белү өчен мәчетләргә һәм чиркәүгә бардым. Мәчеттә мине ата бюрократ ничек каршы алса, шулай каршы алдылар. Дини иерархиядә зур урын биләүче иде каршылаучы. Сөйләшүнең ата-анасы булмады. Ярамый дигәннән башканы аңлата алмады. Минем кем икәнемне белмәү бер хәл, ни өчен әлеге сорау белән кызыксынуыма да исе китмәде. Мин юкка килдем, ахры, дип чыгып киттем. Икенче мәчеткә бардым. Анда көлешеп утыручы яшьләр (берсе хәзрәт икән) миңа юләргә караган шикелле карап, шулай ук «ярамый» дигәнне әйтеп, көлешә-көлешә әңгәмәләрен дәвам итеп калдылар. Киттем чиркәүгә. Мине ике рухани (поплар дип әйтик) олылап каршы алдылар. Игътибар белән тыңладылар, нигә кызыксынганымны аңладылар, бөтенесен Христиан дине кануннары буенча аңлаттылар. Керүемә рәхмәт әйтеп калдылар, сорауларым булса, тагын көтеп торачакларын әйттеләр. Мин шунда хәзрәтләребез өчен оялдым. Без, язучылар да, дин әһелләре дә, бер үк эшне эшлибез. Безнең кулда каләм, аларның—тел. Белмим, кайсыбыз гаепледер, язучылар белән дин әһелләренең кара-каршы утырып сөйләшер, хәтта бәхәсләшер өчен ихтыяҗ булса да, бу эшләнми. Безнең төп эшебез—кешенең рухи бөтенлеге өчен көрәшү. Бүген әхлак кысаларында тоту өчен бөтен ресурслардан файдаланган коммунистлар юк. Барысын үзебезгә башкарырга кала.

3. Хәзрәтләребезнең милли мәсьәләдә талымсыз булулары. Дин, идеология буларак, милли проблемалар белән «вакланмый». Коммунистларга да бит милләтләр кирәкми иде. Алар моны диннән алдылар. Коммунистик идеягә табынсаң, синең урыс яки татар, яһүд яки чукча булуың чуртыма да кирәкми иде. Диндә дә шулай. Гарәпме син, фарсымы, татармы син, үзбәкме—мөселман булгач, шул җиткән. «Мөселман кардәшләр!» бөтенесен алыштыра. Юк шул, бөтенесен алыштырып бетерә алмый. Мөселман булсам да, минем гарәп тә, урыс та буласым килми, татар булып каласым килә, гарәп теленнән башка минем үз телем дә бар, ата-бабаларымнан калган үз йолаларым бар. Мәчетләребездә (татарлар салганында) үз телемдә аралашырга телим. Коръән телендә Коръән сүрәләреннән торган дога гына кылынырга тиеш. Коръән теле бөтен мөселманнарны берләштерә, ә милләтне тел берләштерә, йолалар берләштерә. Татар мәчетләрендә урысча сөйләшүче хәзрәтләр булырга тиеш түгел. Урысча сөйләшәсе килсә, өенә кайтсын да хатыны белән сөйләшсен. Татарлар салган мәчет татарча сөйләшүче татарлар өчен дип саныйм. Әгәр кемнәрдер бүтән телдә сөйләшергә тели икән, үзләре мәчет салдырсыннар. Урыста бик тә акыллы сүз бар—«Со своим уставом в чужой монастырь не ходят!» Минем әйткәнем бар һәм тагын кабатлыйм: әгәр татар мәчетләрендә минем телдә сөйләшмиләр икән, мин ул мәчетнең ишеген ачып кермим. Телне

алыштыру динне алыштыру кебек үк монафыйклык ул. Кайсыдыр ки теленнән бизгән татарның хәзрәт булып мөнбәргә басасы килә икән, өйрәнсен ата-бабаларының телен, теләми икән, кем әйтмешли, әтвәливәй. Мин хәбәрдар: дин ярдәмендә кайбер милләттәшләребез сакланып калганнар. Литва татарлары, мәсәлән, телләрен югалтканнар, динне саклаганнар, үзләрен татар дип атыйлар. Аларның татарлыгыннан ләкин татарга ни файда? Алар безнең мәдәниятебезгә берни дә бирә алмыйлар. Мәдәниятсез милләт милләт була алмый. Аларның кайберләре телне өйрәнергә телиләр, тырышалар. Аларга рәхмәтем һәм хөрмәтем зур.

Дин мәсьәләсендә үзгәрүемнең төп асылы—мин мөселман гына түгел, мөселман татар. Мин татар исламы тарафдары. Мине бүтән мөселманнар белән «Лә иләһү иллә Аллаһү» гына берләштереп тора, калганы үземчә—татарча. Минем язганнарымны, кардәш булсак та, бүтән телдә сөйләшүче мөселман укымый, татарча белгән татарым укый. Икенче үзгәрүем: элек мин Алладан курка торган идем, хәзер курыкмыйм. Безне һәрвакыт куркытып тәрбияләделәр. Мин инде без үскән чактагы режимны әйтмим дә. Тарихыбызда да куркыныч вакыйгалар тулып ята. Бәләкәй чакта берәр ярамаган эш эшләсәк, урыс алып китә дип өнне алдылар. (Урыслар үз чиратында «злому татарину отдам» дип балаларын өркеткәннәр). Хәзер андый куркытуның кайдан килеп чыкканын беләм. Үсә төшкәч, райком секретарьларыннан, председательләрдән курыктык. Дөньяны чынлап таный башлагач, мөстәкыйль фикер йөртергә омтылгач, КГБ бармак янап торды. «Алладан курык!» дигәнне дә еш ишетергә туры килде. Бүтәннәре аңлашыла. Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» пьесасында Аксак Тимер әйтмешли, халыкны курку белән өмет арасында яшәтергә кирәклеген Россия хакимнәре бик яхшы белеп эш итәләр. Ә менә нигә Алладан куркырга? Ул бит иң мәрхәмәтле Бөек зат, Ул адәм баласын куркытып тәрбияләргә ярамаганын белә. Бер-берсен куркытыр өчен кешеләр нинди генә законнар чыгармый, ләкин җинаятьчеләр бетми. Шуңа күрә Алладан куркырга кирәкми, оялырга кирәк. Әни әллә шуны аңлады микән, Алладан курык дими иде, Ходайдан оял, дия иде. Хәзер мин ярамаган гамәл кылырга Ходайдан оялам. Ходай алдында минем өчен иң зур җәза шулдыр. Аннан соң Алла колы дигән төшенчәне дә мин өнәп бетермим. Аллага коллар кирәкми дип саныйм. Кол дигән сүздә мескенлек, хокуксызлык, мокытлык ише кешене түбәнсетә торган сыйфатлар ята. Үзе яраткан затны Ходай андый итеп яратмагандыр. Нигә Аллага андый җан көекләре? Аңа Бөек затны олылый белүче, Ходайның бөеклеген акыл белән аңлый белүче, күңеле белән табынучы кешеләр якынрак һәм кадерлерәк. Колга ышанып булмый. Аның бер сынык икмәккә үз-үзен дә сатуы ихтимал. Күрәсең, динне үз файдаларына хезмәт иттерергә теләүчеләргә буйсынырга әзер торучы коллар кирәк. Шуны алар Алла исеменнән беркетеп куйганнар. Ә бәлки, «Алла колы», «Раб божий» дигәндә кол сүзе икенчерәк мәгънәне аңлатадыр, безгә аны ялгыш тәрҗемә иткәннәрдер. «Алла сакласын» дигән сүзне бик еш әйтәбез, мин дә әйтәм, ышанып әйтәм. Чөнки ул мине күп бәла-казалардан, ялгышлардан саклап килә. Мине саклаган бөек зат мәрхәмәтле, мине түбәнсетү уе аңарда юк. Мин аның янында үз урынымны кол булып түгел, горур адәм баласы, ләкин аллалыкка, хәтта пәйгамбәрлеккә дә дәгъва кылмаучы кеше буларак беләм. Һәм бер генә хакимгә дә табынмыйм. Сталин үлгәндә елаганым өчен дә үкенеп туя алмыйм, үземнән үзем һәм Ходайдан оялам. Лә иләһә илаллаһү!

## Идея, идеология, партияләр, коммунизм

Коммунистик идея гаять зур осталык белән бала чактан ук безгә сеңдерелә башлады ки, ун-унике яшьтә үк «Ник? Нигә?Ник алай?» дигән сорауларны бирми башладык. Безнең өчен барысы да уйланылган, сорауларга җаваплар табылган, без шул җавапларны кабатларга гына тиеш идек. Безне беренче класста «октябрятлар» дип атадылар, аннары «пионер» иттеләр, пионер чыныгуын үткәч, комсомолга тапшырдылар. Без, әлбәттә, бу юлны үтүнең ни өчен икәнен аңламадык. Безгә октябрят булу кызык иде. Түшкә йолдыз тагып йөрү үзе генә дә ни тора. Ә пионер галстугы. Сугыш вакытында бөтен нәрсәгә

кытлык иде, әмма пионер галстугы өчен кызыл ситсы һәрвакыт табыла иде. Галстукны күлмәк-ыштаннан да кадерлерәк итеп сакладык. Безне тәртипле булырга, яхшы укырга өйрәттеләр. Тәртип бозсаң, начар укысаң, пионердан чыгарабыз, дисәләр, чын-чынлап кайгыра идек. Ә ул комсомолга керүләр! Атлы чаналарга төялешеп, район үзәгенә киттек. Берәм-берәм комсомолга кабул итү бүлмәсенә кергәндәге дулкынлануымны әле дә хәтерлим. Кулыма комсомол билеты алганда иң бәхетле кеше идем. Мәскәүдә Россия Дәүләт премиясе алганда да ул чаклы куанмадым шикелле. Бүген уйлап куям: ничек камил итеп эшләнгән булган идеологик тәрбия. Җиде-сигез яшьтән алып дөнья белән хушлашканчы безне кулдан ычкындырмаганнар. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәр хәдисенә охшатып, бишектән кабергәчә «укытканнар». Бүген шул системаны җимерделәр, яңасын уйлап табарлык идеологлар юк. Патриотизм дип кычкырган булалар, һәм ул буш кычкыру гына булып кала. «Рус идеясе» уйлап чыгарырга маташалар, ә ул берләштерүгә караганда дошманлаштыруга алып бара.

Октябрят чагымда нинди егетлекләр эшләгәнмендер, онытылып беткән, пионер чагымның кайбер хатирәләре истә. Барабан кагарга бирмәгәч, елаганым хәтердә. Нигәдер пионер быргысыннан кычкырту бәхете дә тәтемәде. Әмма уку белән алдыра идем. Тәртип ягы бераз комачаулый иде комачаулавын, дәрестә тик утыра алмавым өчен «кофе чәйнеге» дигән кушамат та такты укытучы апа. Шунысы кызык, туктаусыз «кайнап» тормасам, укытучы сөйләгәне тыңланылмый иде, мин хыялга чумып әллә кайсы дөньяларда йөри идем.

Комсомолда актив идем. Класста комсомол җитәкчесе, мәктәптә комсомол комитеты әгъзасы булдым. Кушылган эшне ихлас һәм яратып эшләдем. Бигрәк тә стена газеталары чыгару миңа кызык иде. Безнең пионер чакта җырлаган җырларыбызны яшьләргә сөйләп күрсәтәм дә, көләләр. Ә без ышанып, ихластан җырладык.

*Биек тауның башларында*
*Тезелеп үскән әнисләр:*
*Тезелеп үскән әнис кебек*
*Яшәсен коммунисләр.*

*Ленин бабай рәсеменә*
*Үзган саен карыймын;*
*Пионерда булуымны*
*Зур бәхет дип саныймын.*

Бүген кайберәүләр туганда ук зирәк булып, ни буласын, имештер, алдан ук белгәннәр. Имеш, өч-дүрт яшьтә үк коммунизмның уйдырма икәнен аңлаганнар. Мин исә коммунизмның булачагына бик озак еллар ышанып, өметләнеп яшәгән кеше. Чөнки мине ышандыручылар миннән акыллырак, хәйләкәррәк булганнар. Һәм, ни кызганыч, мине ышандыручылар шул системаның корбаннары булдылар. Системага чын күңелдән хезмәт иткән язучыларның язганнары бүген юкка чыкты. Аларның кире әйләнеп кайтачагына да ышаныч юк. Мин кайберәүләрнең андыйларны тәнкыйтьләүләрен кабул итмим, нишлисең, кеше дигән җан иясе һәрвакыт яхшылыкка өметләнеп яши. Өмет яшәтә кешене. Гасырлар буе изелгән халыкка ирек вәгъдә итәләр. Бигрәк тә икеләтә (сыйнфый һәм милли) изелгән халыклар үз дәүләтләре булачагына ышанып, хакимияткә килүче большевиклар ягына бик тиз авыша. Бигрәк тә кайчандыр дәүләт тоткан халык—татарлар революцияне алкышлап каршы ала, аңа бит дәүләт тотарга рөхсәт бирергә җыеналар. Алар әле алданасыларын белмиләр, дәүләт урынына автономия алганга да куаналар. Ничек инде шул ирекне бирүчеләрне мактап язмыйсың? Ник алданды татар? Мин ул турыда «Милләт» дип аталган бүлектә фикерләремне киңрәк язачакмын. Мин дә алдандым. Алданганымны илледән узган елларда гына чынлап аңлый башладым. Ләкин, шулай булуга карамастан, коммунистик

идеянең дошманы түгелмен. Кешеләр уйлап чыгарган әкиятләрнең начарлык, явызлык, әшәкелек белән беткәне юк. Әллә ни чаклы кыенлыклар, авырлыклар, михнәт-газапларны җиңеп, яхшылык өскә чыга. Хәер, чынбарлык, тормыш та шулай бит, әгәр явызлык җиңсә, кешелек дөньясы яшәүдән туктар иде. Коммунизм да шул закончалыкка нигезләнеп уйлап чыгарылган искиткеч матур әкият. Аерма шунда—безгә аны әкият итеп өйрәтмәделәр. Бик күпләр аның булачагына ышанып яшәделәр. Әйткәнемчә, бу коммунизмны уйлап чыгаручыларның һәм шул идеяне безгә сеңдерүчеләрнең оста укытучылар икәнлеген исбатлаучы факт. Алар - кешенең мәңгелек хыялын файдаланып, аны чынбарлыкка бәйләргә тырышучылар. Ярый, коммунизмны матур әкият дидек, аның беркайчан да тормышка ашмаячагын беләбез. Әйе, шулай. Әлбәттә, шулай. Әмма ул без шулай уйлаганга гына шулай. Әйтик, кеше Ходай яратканча һәрьяклап камил булса, урлаша, алдаша, кешенекенә кызыга белмәсә, кирәген генә киеп, кирәк кадәр генә ашаса, нәфесен тыя белсә, аның эшләгәне үзенә һәм баласын яшәтергә җитәчәк бит. (Ә кеше шундый зат ки, ул эшләмичә тора алмый). Димәк, коммунизмның төп тәгълиматы (һәркемнән хезмәтенчә, һәркемгә хаҗәтенчә) үти алмаслык нәрсә түгел икән. Ходайдан да өстен булырга маташкан, Аллалыкка дәгъва кылырга алынган, гөнаһка чумган адәм баласы, әлбәттә, коммунизм кешесе була алмый. Коммунизм идеясен ул башкалар хисабына яшәү өчен файдалана. Бәлки, без әле чын кешеләр дә түгелбездер. Без бүген коммунизм утопия дип, адәми затның камил түгеллеген акларга тырышабыз. Еш кына мин болай дип уйлап куям: бәлки, бүгенге кешеләрне Ходай яратмагандыр, без Иблис токымыннандыр. Ходай яратканнар җир өстеннән киткәндер, Ходай аларны үз янына—күккә алгандыр. Бөтен диннәрдә дә гыйбадәт йортларының манаралары бар, алар барысы да күккә юнәлгәннәр. Адәм баласының күккә ашу символы түгелмени алар? Хыялыбыз—күктә, әмма кылган гөнаһларыбыз безне җибәрми, күк мәңгелек хыял—утопия булып кала бирә.

Заманында мин «Адәм балалары һәм койрыклар» дигән пьеса язган идем. Ни кызганыч, аның кульязмасы сакланмаган. Чөнки кульязманы укыган өлкән агайлар: «Язучы булырга теләсәң, бу әйбереңне кешегә күрсәтмә»,—диделәр. Һәм мин куркып ертып ташлаганмын, ахры. Теркәлеп калсын әле, аның сюжетын язып куйыйм.

Ходай Җирне һәм андагы тереклекне яратканнан соң (кайберәүләр Ходай яраткан дип әйтү дөрес түгел, яралткан дип әйтү дөрес, диләр. Бәхәсләшмим, әмма «яраткан» сүзе миңа ошыйрак тоелә. Яратмаса, яралтмас иде) җир, тереклек белән идарә итү өчен ниндидер затны да яратырга ниятли. Балчыктан әвәләгәне канәгатьләндермәгәч, Җәбраил фәрештә аңа маймылны тотып китерә. «Җирдәге Сезнең урынбасарыгыз кеше дип аталырга тиеш һәм аның шундыйрак булуы мәгъкуль»,—ди. Кеше булачак маймылны башкаларыннан аеру өчен, аның шәрәлеген каплап, кием кидерергә кирәк дип табалар. (Бүгенге кайбер яшьләрнең ярымшәрә йөрүләре аларның маймылдан чыкканнарын исбатлаучы факт). Булачак кешегә кием тегәләр. Ләкин чалбарны кидерергә маймылның койрыгы комачаулый. Койрыкны кисеп ыргыталар.

Ходайның гамәлен Иблис күзәтеп тора. Аның Ходайга үче бар. Чөнки Ходай аны явызлыклар кылганы өчен күктән җиргә сөргән була. Менә шуның үчен алу максатыннан Иблис, маймылның киселгән койрыгыннан кешегә охшаган затлар ясап, җир өстенә җибәрә.

Кешене җиргә хуҗа итеп калдырып, күккә кире менеп киткәндә Ходай кешегә: «Әгәр андый-мондый хәлләр килеп чыгып, яшәү авырга китсә, дога кылып, миңа хәбәр ит»,—дип китә. Койрыктан яралган кешегә охшаш затлар җир өстендә кешеләргә караганда тизрәк үрчиләр. Бөтен нәрсәләргә—агачларга, үләннәргә, болыннарга хуҗа булып алалар. Чын кешегә җирдә яшәү мөмкинлеге калмый. Шуннан кешеләр күккә кулларын сузып, Ходайдан ярдәм сорыйлар. Ходай тәртип урнаштырырга дип җиргә төшә. Төшсә, җир бюрократлар, караклар, мошенниклар һәм башка шуның ише хәшәрәтләр белән тулган. Болар Ходайны танырга да теләмиләр. «Ни кыланасыз, мин бит Җирне яраткан Ходай»,—ди Ходай. «Ә син Ходай икәнлегеңә справка күрсәт»,—диләр

бюрократлар. Койрык-кешеләр кычкырып көләләр. Көрәшеп-көрәшеп тә Иблис токымын җиңә алмагач, Ходай кешеләрне үзе белән күккә алып менеп китә. Аларны пәйгамбәрләр итеп җиргә җибәреп карый. Алар да койрык-кешеләрне игә китерә алмыйлар. Уйлап-уйлап торам да, бүген ул пьеса бигрәк тә актуаль булыр иде дим.

Әйе, минем күңелемә коммунизм идеясе якын иде. Бүген дә якын. Идеяләрнең кайвакытта начарлыкка, хәтта явызлыкка хезмәт итүендә кешеләр үзләре гаепле. Аны явыз нияттә файдаланучы һәм явызлыкны күрә торып та дәшмәүчеләр гаебе белән иң изге төшенчәләр дә пычрана. Хәтта динне дә явызлыкка хезмәт иттереп була.

Коммунистлар партиясенә мин үзем теләп кердем. Коммунистик җәмгыятьнең кайчан да булса төзеләчәгенә ышанып ук бетмәсәм дә, өметләнә идем. Коммунист буларак, минем дә өлешем керсен дидем. Мондый наивлык өчен миннән көләргә була, мин үзем дә бүген елмаям. Әмма дөреслекне әйтмичә булдыра алмыйм. Чөнки әлеге язмам мөмкин кадәр ихлас булырга тиеш. Ясанып маташырга соң инде. Әлбәттә, партиягә керүемнең практик максаты да бар иде. Партия әгъзалары партҗыелышка җыелалар да, татар әдәбияты язмышы турында сөйләшәләр. Андый чакта нигә мин читтә йөрергә тиеш ди әле? Минем әдәбият дөньясына дәртләнеп кереп барган чагым. Үземне бик җаваплы эш эшлим дип ышандырган чак. Фикеремне теләсә кайда кычкырып әйтәм. Кайвакытта арттырып та җибәргәлим. Чын коммунист шундый булырга тиеш түгелмени? Йоклап йөргән кешегә нигә партия?

Партиягә керсәм дә, мин партиянең догматик лозунгларының колы булмадым. Һәрчак үз фикерем булды. Беркайчан да партия лозунгларын үзәккә куеп пьесалар язмадым. Чөнки тормышның үзеннән аерыла алмадым. Ә тормышны мин начар белмим. Эш кешеләре арасында кайнашам. Эш кешеләре - минем төп геройларым. Лозунглар тормыштан аерылган иде шул. Догмаларсыз гына көн иткән авыл кешеләре язганнарыма ни әйтер дип үземне һәрчак контрольдә тоттым. Бу аңлы рәвештә эшләнмәгәндер дә, бәлки. Язучылар Союзында парторг чакта да ортодоксаль коммунист булып булмады, авыл малае булып калдым. Шул коткарды мине «кыска гомерле» язучы булудан. Такташ, әйтмешли, миндә даими рәвештә ике кеше яшәде. Коммунизм тәгълиматларын тулысынча кабул иткән коммунист һәм тормышның коммунизмнан бик ерак икәнлеген аңлаган татар баласы. Татар баласы дип әйтүем очраклы түгел. Татар шундый милләт бит ул— аңа фанатизм ят нәрсә. Дингә дә аның мөнәсәбәте ике төрле—Алланың бирлеген дә таный, барлыгына да ышана, һәм фани дөнья мәшәкатьләрен дә онытмый. Намаз укыганда бар күңеле белән сәҗдәгә китәргә иелә, шул арада бер күзе белән күршесенә карап алырга да өлгерә. Моңардан берәр нәрсә алып булмас микән дип, «на всякий случай» уйлап куя. Мин дә шундый коммунист булганмын, күрәсең. Хәзер мин коммунист булганыма оялмыйм да, үкенмим дә. Коммунист исеме белән берәүгә дә зыян салмадым. Партиядә карьеристлар, жуликлар, мошенниклар булу белән бергә намуслы кешеләр дә күп иде. Алар—үз көчләре белән көн күрүче хезмәт кешеләре. Тик аларның кадерләре генә булмады.

Төгәл генә белмим, кайсы еллардадыр, партиягә без тәнкыйть күзе белән карый башладык. Политбюроның карт-корылардан гына торуыннан үзара көлешә идек. Кремльне «Картлар йорты» дип атый идек. Партия җитәкчеләре турында анекдотларны бер-беребездән куркып тормыйча сөйли идек. Хрущевка да эләкте, Брежневка да. Хрущевның, 20 елдан соң коммунизмда яшәячәкбез, диюенә ышанучы булмады. Аңа хәтта Хрущев үзе дә ышанмагандыр. Совет халкын дуракка санап, аңа ни әйтсәң дә ышана дип уйлагандыр. Шул елларда бик тә актуаль булган лозунг бар иде: «Американы ит, сөт, йон җитештерү буенча куып җитеп, узып китәрбез». Шул лозунг әйтелүгә, анекдот та чыгып өлгерде. Берәү: «Американы куып тотабыз, әмма узып китмибез»,—дип әйтә икән. Аңардан: «Нигә узып китмибез?»—дип сораганнар. «Чөнки ыштаныбызның төбе тишек. Ялангач к... белән алдан йөгерү яхшы түгел»,—дигән теге.

Мәзәге мәзәк инде, ләкин безгә өстән кемнәр күзе карап торганын да белә

идек. Шуңа күрә элек КГБ башлыгы булган Андроповтан көлмәдек. КГБ белән шаярырга ярамаганны система безгә күрсәтте шул. Ул албасты турында күп язылды, кабатлап торуның кирәге юк. Аның безгә китергән зыяны гаепсезгә ату яки утыртып кую гына түгел, ул кешеләрнең күңелендә курку һәм шик тәрбияләде. Мин бу турыда элек КГБда эшләгән берәү белән ачыктан-ачык сөйләштем. Ул кызык сүз әйтте. «Бүтәннәр генә түгел, без үзебез дә куркып яшәдек. Ә куркып яшәгән кеше явызлык кылырга сәләтле»,—диде. Димәк, репрессияләр һәртөрле эзәрлекләүләрне оештыручы КГБ түгел, ә КГБны үз халкына каршы үстерүчеләр. Чөнки һәр дәүләт үзен саклау өчен армия һәм эчке куркынычсызлык оешмалары тота. Хикмәт шунда ки—аларга нинди максат белән нинди бурыч йөклисең бит. Илне тышкы дошманнардан сакларга тиешле армияне дә үз халкыңны кыйнаучы итеп файдаланырга була. Әгәр нәтиҗә ясасаң, КГБ илне җитәкләргә алынган коммунистлар партиясе булган. Димәк, ул җинаятьче. Мондый нәтиҗәгә без соңрак килдек. Һәрхәлдә, мин партиягә ышана идем әле. Политбюрода утыручы агайларга да хөрмәт белән карый идем. Бактың исә, илне җитәкләргә алынган иң югары оешмада хәлләр без көлгәндәгедән аянычрак булган икән. Мин моны СССР халык депутаты итеп сайлангач, үз күзем белән күреп, үз колагым белән ишеттем.

Көннәрдән бер көнне СССР халык депутатларының чираттагы съездында трибуна артына депутат Гдлян чыгып басты. Ул үзе профессиясе буенча аеруча катлаулы эшләрне тикшерүче икән. Шуннан бу депутат тотынды Коммунистлар партиясенең тетмәсен тетәргә. Бигрәк тә политюбюро әгъзаларына эләкте. Шуларның берсен—партиядә икенче урында торган кеше Лигачевны жулик дип атады ул. Әгәр кирәк булса, сүземне дәлилләр өчен документлар күрсәтә алам, ди. Минем гаҗәпләнүдән күзем акайды. Як-ягыма каранам, күпләр аптырашта калган. Уен эшмени. Әле бит ул чакта партиянең көче бетмәгән. Политбюро әгъзалары барысы да съезд президиумында утыра. Гдлян өчен курыктым. Сәхнә артыннан таза-таза егетләр чыгар да, аны ике кулыннан каерып тотып алып китәрләр иде сыман. Ләкин алып китүче юк. Президиумдагы Лигачев: «Мин сине судка бирәм яла якканың өчен»,—ди. Гдлян көлә генә: «Биреп кара, миндә документлар бар»,—ди. Ызгышалар болар. Чишмәгә су алырга килгән хатыннар диярсең. Һични аңламыйм. Шунда мин көләргә тотындым. Тыела алмыйм. Истерика башланды. Партия безне җитәкләүче, намуслылык үрнәге дип йөргәнебез, аны мактап язганыбыз, югыйсә миллионлаган кешеләрнең шуңа ышануы чүп кенә булган икән бит, бездән дә түбәнрәк кешеләр утырган икән бит аның башында. Шуны күрү минем бөтен дөньямны бутап ташлады, яшәвемнең мәгънәсе калмады. Миндә коточкыч депрессия башланды. Кеше күп җыелган җирдә торырга курка идем. Безне Үзәк Комитет поликлиникасына беркеткәннәр иде, шунда мине карыйлар да, нindидер дарулар биреп җибәрәләр. Мин аларны эчәм дә, аңгы-миңге йөрим. Ләкин курку китми. Сизәм, хәлләр мөшкелләнә бара, төннәрен куркып уяна башладым, йокысызлык белән интектем.

Бәхетемә күрә, поликлиникада мин беркетелгән участок врачы алышынды. Яңасының фамилиясе—Зорина. Ул минем авырулар тарихы белән танышты да: «Монда язылган даруларның барысын да эчәсезме?»—дип сорады. «Әйе»,—дидем. Ул миңа карап-карап торды да: «Мондый даруларны психиатрия хастаханәсендә ятучыларга гына бирәләр, туктатыгыз эчүне»,—диде. Аннан кемнедер чакырып алып: «Бу депутат белән шөгыльләнегез»,—диде. Ромашевский дигән әлеге врач (фамилияләрен мәңге онытасым юк) гипноз белән дәвалый икән. Ул минем белән бик озак сөйләште дә, дәваларга кереште. Ике сеанстан соң рәткә керә башладым. Зоринага рәхмәт әйтергә кердем. «Йөрмәгез ул съезд утырышларына. Ул сезнең өчен түгел. Сез - язучы кеше. Сез йөрәк белән уйлаучы. Ә сәясәттә йөрәк артык нәрсә»,—диде. Мин бүгенгә хәтле Зорина белән Ромашевскийга рәхмәтле. Алар мине дәваладылар, коткарып калдылар. Шуннан соң мин бөтен нәрсәне дә йөрәгем аша үткәрмәскә өйрәндем шикелле. Минем өчен Рәсәй дигән илдә, шул исәптән Татарстанда да, табынырлык коммунист потлар (идоллар)

юк иде инде. Үзәк Комитетта, Өлкә Комитетында эшләүчеләр дә «синдәй-миндәй бозаулар» иде.

СССР Конституциясеннән алтынчы статьяны (Коммунистлар партиясенең җитәкче роле турында) алып ташлауны тавышка куйганда ике кулымны берьюлы күтәрдем. Минем партиягә каршы кул күтәрүемне искәргән берәүдән хат та алдым: «Син, җыен әтрәк-әләмнәргә ияреп, үзеңнән кеше ясаган партиягә каршы кул күтәрдең. Син—сатлык җан, әгәр алай кылансаң, башыңа җитәргә дә күп сорамабыз, сиңа 6 грамм кургашын җитә» дигән сүзләр язылган иде анда. Мине андый янаулар куркытмый иде инде. Мин беркемгә дә иярмәдем. Коммунистик идеягә турылыклы булып калсам да, ул идеянең Рәсәйдә тәмам бозылуын аңлап өлгергән идем. Мондый партия, әлбәттә, юлбашчы ролен үтәргә тиеш түгел иде. Һәм шулай булып чыкты да. Бик кызганыч, дистәләгән миллион әгъзасы булган партия бернечә ел эчендә чәлпәрәмә килде. Бу «Народ и партия едины» дигән лозунгның чеп-чи ялган икәнлеген дәлилләүче факт булды. Мин шул чакта халык белән партияне тиңләштерү мошенниклык икәнен аңладым. Партия ул - хакимияткә омтылучыларның оешмасы, халык аңа сайлаучы һәм кул чабып торучы буларак кына кирәк. Халык язмышы белән чын күңелдән борчылучы аерым партия әгъзалары сирәк кенә булса да бардыр, әмма партия үзе андый була алмыйдыр. Үзе теләп партиягә кергән кешенең сүзе бу. Миңа кайберәүләр бүген: «Кичә коммунист идең, бүген «Бердәм Россия» әгъзасы, бу икейөзлелек түгелме?»—диләр. Бәлки, шулайдыр. Әмма мин «Бердәм Россия»гә депутат булып сайланыр өчен кердем. Ул партия халык өчен үлеп кайгырыр дип ышанмадым һәм ышанмыйм да. Ә депутатлык миңа әйтәсе сүземне рәсми трибунадан әйтер өчен кирәк. Бу илдә язучы сүзен ишетүче җитәкчеләр күп түгел. Димәк, сәясәт мәсьәләсендә мин дә шактый шомардым. Әмма депутат булып мин карьера ясап, үз тормышымны көйләр өчен генә сайланмадым. Һәр әйткән сүзем татарга файда булсын дип тырышам.

Партия һәм партияләргә кагылышлы сүзләремнең иң кирәклеләрен әйттем шикелле, йомгак ясасам да буладыр. Алда әле бераз гомер бардыр, яңадан-яңа партияләр оешканын күреп торабыз, киләчәктә күрергә дә насыйп булыр. Аларның гомерләре озын булыр дип уйламыйм. Яз көне умырзаялар калкып чыккан кебек, сайлаулар алдыннан пәйда булырлар да, вәгъдәләрен биреп бетергәч, югалырлар. Алар барыбер Коммунистлар партиясен алыштыра алмаячаклар. Чөнки берсенең дә төпле идеологиясе юк. Ә КПССның, ничек кенә хурласак та, идеологиясе бар иде. Коммунизм идеясе халыкка якын иде. Харап иттеләр партия чиновниклары идеяне. Миннән бөтен кеше дә тигез булырга тиеш дигән идеяне тартып алдылар да, алмашка берни бирмәделәр. Элек тә буш сүз җитәрлек иде, хәзер тагын да күбәйде. Ялган өстенә ялган. Әйе, үзгәрдем мин. Нык үзгәрдем. Тормыш үзгәртте. Мин инде бүген октябрят, пионер булып, укытучыларыбызның «без Ленин бабай оныклары» диюен авыз ачып тыңлап утыручы бала түгел. Партиягә алмашка киләм дип саф күңел белән ышанып яшәүче комсомол да түгел. Яшьлек елларын сагынып, үлгән партиягә ябышып та ята алмыйм, яңаларына да ышанмыйм, ялганны чыннан аерырга өйрәндем бугай. Мин бу сүзләрне шатланып әйтмим. Идеалларның юкка чыгуын күрү шатлык була алмый.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Альбина
Әпсәләмова

# УЛ УТЛАР БЕРКАЙЧАН ДА СҮНМӘС!

*2011 елның 28нче декабрендә бабама—Габдрахман Әпсәләмовка йөз яшь тулган булыр иде.*

*Без аның белән фани дөньяда очраша алмадык—мин аның вафатыннан соң ике ел узгач туганмын. Шуңа да бабамның тезенә менеп утыру, кулыннан тоту һәм аның белән уйнау бәхете миңа тәтемәде... Ләкин һәрвакыт һәм һәркайда мин аның барлыгын тоям. Аның рухы туганнарымның хәтерендә, Маяковский урамындагы фатирыбызның һәр бүлмәсендә, җиһазларда, көндәлекләрдә, дәфтәрләрдә,китапларда, газета-журналларда, орденнарда, күзлекләрдә, каләмнәрдә, конвертларда яши... Әбием бу кадерле хәзинәне яшермәде, миңа аларны тотып, сыйпап карарга рөхсәт бар иде. Мин кечкенә чагымда ук әбиемнән, әтидән, өебезгә килгән кунаклардан гел бабамны сораштыра һәм аларның истәлекләрен тыңлаганнан соң аның турындагы уйларга бирелә идем...*

*Үскән саен бабам турында күбрәк беләсем килде. Без гаиләбез белән аның туган ягына—Мордовия Республикасындагы Иске Аллагол авылына кайттык. Архивны актардык, кинохроника язмаларын карап чыктык, фотоларны барладык. Бабамны якыннан күреп белгән кызыклы кешеләр белән таныштык...*

## Иске Аллагол

Без авыл яныннан үткән елга янындагы чирәмлектә ятабыз. Кызым сикереп тора да йөгереп китә; яр буендагы баканы тотмакчы була, сазлыкка кереп бата, чырык-чырык көлә... Йөз елга якын элек (уйлап карасаң, күпме вакыт!) бу җирдә ул да, бабам—кечкенә малай да шулай ук йөгергәндер, уйнагандыр.

—Аларның өе шушында иде,—Иске Аллагол авылында яшәүчеләр мине нигез янына алып бардылар,—хәзер бу урам Әпсәләмов исемен йөртә. Бу—ул белем алган мәктәп. Анда мемориаль такта да бар, ләкин мәктәбебезне генә үткән ел яптылар шул—бер укучы да калмады...

Мин бу якларда беренче тапкыр, шуна да Иске Аллагол авылын көч-хәл белән эзләп таптым. Авылга илтә торган юл мескен хәлдә, кышын, мөгаен, ул бөтенләй өзеләдер. Бабамның кунакчыл авылдашлары безне өйләренә чакыра, пәрәмәч белән сыйлый, күчтәнәчкә капчык-капчык алма тутыра һәм иң мөһиме—истәлекләре белән уртаклаша... Ишегалдындагы казлар канатларын кагып-кагып ала, кемнеңдер бозавы безгә карап тора—сүзебез аңа да кызык бугай.

Вакыт кирегә әйләнә башлый, 2011 һәм 1911 еллар иң әүвәл кушыла, бутала, кисәкләргә аерыла һәм кинәт барысы да матур, төгәлләнгән картинаны хәтерләтеп күз алдына килеп баса.

## «Крестьян гаиләсендә тудым...»

«Үзем турында. 1911 елда Мордовия АССРның Рыбкино районы Иске Аллагол авылында крестьян гаиләсендә туганмын. Гаиләдә алты бала идек—өч энем сугышта һәлак булды, сенелләрем Мәскәүдә яши.

1923 елда әтием янына Мәскәүгә күчтем. 1929 елга кадәр урта мәктәптә укыдым. 1930 елдан Мәскәүнең төрле заводларында слесарь һәм токарь булып эшләдем. Кечке индустриаль-конструкторлык техникумында укыдым, әмма аны тәмамламадым. 1936 елда Әдәбият институтының кичке бүлегенә укырга кердем. Мин икенче курста вакытта институт көндезгегә әйләнде һәм миңа эшемнән китәргә туры килде. 1940 елда институтны тәмамлагач, мине Казанга җибәрделәр. 1941 елдан—хәрәкәттәге Кызыл Армия сафларында...»

Бу автобиографиядән озак еллар буена түбәндәге юллар төшеп кала килгән: «Әтием, Сафа Әпсәләмов, инкыйлабка кадәр урта хәлле крестьян, инкыйлабтан соң—ялгызак вак һөнәрче була. Авылда хуҗалык тотуын дәвам итә, Мәскәүгә китеп, приказчик вазифасында була һәм кече сәүдәгәрлек белән шөгыльләнә, мал-туар сата, тире иләп эшкәртә. НЭП елларында авылда хуҗалык тотучыларны кулаклар дип атый башлыйлар. 1928 елда әни йорт һәм ишегалды корылмаларыннан кала (алары соңрак колхоз карамагына күчә) авылдагы барлык мал-мөлкәтне сатып, Мәскәүгә, әти янына китә. 1929 елдан әти Мәскәүнең мех фабрикасында сортировщик булып эшли башлый. 1933 елда ул беренче тапкыр кулга алына һәм төньякка ирекле сөргенгә озатыла. Срогын тутыргач, эшенә кире кайта һәм шул ук вазифаны башкара. 1937 елда икенче тапкыр гаепләнә һәм 58нче маддә буенча ун елга хөкем ителә»

Мәскәү прокуратурасы сайтыннан түбәндәге юлларны укыйм: «Әпсәләмов Сафа Гомәр улы. 1885 елда Урта Нократ төбәгенең Иске Аллагол авылында туа; «Мосмехпушнина» фабрикасы, сортировщик. Яшәү урыны: Мәскәү, Ашеулов тыкрыгы, 9-14. 1933 елның 28 октябрендә кулга алына. 1933 елның 7 декабрендә 58-10 һәм 58-11 маддәләр буенча гаепләнә, 3 елга сөргенгә хөкем ителә. 1997 елның ноябрендә аклана.»

Нәрсә эшләгән ул? Совет хөкүмәтен җимерергә яки какшатырга чакырган пропаганда һәм агитация алып бармагандыр бит? Бу хакта сөйләшү катгый тыелган иде. Әтиемнең бабасы турында әбием—Магинә Измаил кызы Чумарина-Әпсәләмова да беркайчан ачылып сөйләмәде. Кемнәндер курыккандай, пышылдап кына үзләренең дә гаиләсен кулаклыкта гаепләп, Татар Юнкие авылыннан куганнарын бәян итте. Әти-әнисен Ерак Көнчыгышка сөрәләр. Шунда әтисе җан-тәслим кыла... Әбием 14 яшеннән берьялгызы Совет иле кинлекләрен гизә. Баштарак нәни куллары белән кара эш башкарып тамак туйдырырлык ипи таба, бераздан укытучы һөнәрен үзләштерә.

Бабамның моңа кадәр басылмаган биографиясеннән бу өзекне мин аның вафатыннан соң чирек гасыр үткәч, язу өстәле тартмасыннан таптым...

## «Балачактан җаныма Тукай рухы сеңде»

Мәскәүгә киткәнчегә кадәрге уникe елын кечкенә Габдрахман туган авылында уздыра.

«Балачактан җаныма Тукай рухы сеңде. Аның «Туган тел» шигырен, мөгаен, йөз мәртәбәләр укыганмындыр. Тукайга мәхәббәт үз төбәгемнең әкиятләрен, җырларын, бәетләрен яратырга ярдәм итте. Тормыш юлымны сайлауда Тукайның тәэсире, һичшиксез, көчле булды...»—дип яза ул.

1918-21 елларда Габдрахман Иске Аллагол мәктәбенең башлангыч сыйныфында белем ала. Мин дә менә шул мәктәптә йөрим. Анда нибары бер класс бар. География картасы каршына туктыйм. Габдрахман фин һәм Карелия фронтларын үтә, Маньчжуриягә кадәр барып житә, аның романнары рус, украин, үзбәк, казакъ, латыш, чуаш, башкорт, поляк, француз, швед, уйгыр, фин, болгар һәм башка күп телләргә тәрҗемә ителә—ләкин Мордовиянең караңгы почмагындагы кечкенә авыл һәрвакыт аңа иң якыны булып кала. Бу—аның нигезе, нәсел шәҗәрәсенең тамыры.

## Әдәбият институты

Өй архивында кадерләп сакланган бабам кәгазьләрен сак кына актарам.

IV курс студенты Әпсәләмовның Әдәбият институты житәкчелегенә юлланган кәгазен укыйм:

«Жәй көне мин Татарстанда булдым һәм Язучылар Берлеге мине Зур Ферганә каналына жибәрде. Анда, кирәкле материалларны жыю сәбәпле, мин тоткарландым һәм тиешле вакытка кайтып житә алмадым (өч көнгә сонардым). Аны нигезле сәбәп санавыгызны үтенәм. Студент Әпсәләмов.»

Нәкъ менә шул сәфәре вакытында студент егет булачак хатыны белән—ул чакта Үзбәкстанда рус теле укытучысы булып эшләгән әбием Магинә белән таныша. Берничә елдан әбиемнен сенлесе Роза да танылган язучыга—киләчәктә Үзбәкстан Язучылар Берлеген житәкләячәк Әсгать Мохтарга кияүгә чыга.

Институтны тәмамлауга бабам Казанга жибәрелә. Ул чакта инде анын берничә әсәре дөнья күргән һәм «Кояш бәхете» исемле хикәяләр жыентыгы басылып чыккан була. Әмма сугыш анын хыялларын жимерә, «Совет әдәбияты» журналынын жаваплы сәркәтибе вазифасында бер елын да тутыра алмыйча, Әпсәләмов 1941 елнын августында фронтка китә.

## Сугыш—әдәбият вакыты түгел

Ул дингез бригадасы составында миномет расчеты командиры, разведчик була. Аннары кыр хәбәрчесе вазифасында Карелия фронтын гизә, Япон сугышында катнаша.

... Баштарак кырыс шартлар әдәбиятны оныттыра. Һәр сугышчынын төп бурычы дошман белән алышу торганда язу-сызу турында сүз булырга мөмкинмени?

Бу уйларын ул Илья Эренбург белән уртаклаша. Теткәләнеп беткән хәрби көндәлектән Эренбургнын 1942 елнын 10 ноябрендә карандаш белән тырышып язган жавабын табам:

«Хөрмәтле иптәш Әпсәләмов!

Иптәшләрчә язылган хатыгыз өчен рәхмәт. Татарларнын каһарманлыгы турында язылган мәкаләм Сезнен—татар кешесенен һәм язучысынын күнеленә хуш килүенә бик шатмын.

Сез дөрес язасыз: әдәбият өчен вакыт киләчәк әле. Жину булса—халык булачак. Халык булса—әдәбият булачак. Хәзер ин мөһиме—фрицларны кыру.

Сезгә истәлек өчен үземнен шигырьләр жыентыгымны жибәрәм. Сугышчан дусларыгызга кайнар сәламемне житкерегез.

Чын күнелемнән көч һәм уныш телим.

Илья Эренбург».

1942 елдан Совет Армиясенен Баш сәяси идарәсе карары нигезендә фронт газеталары милли телләрдә дә чыга башлый. Сугыш барышында бабам «Сугышчы сүзе», «Сталин хәрбие», «Ватан өчен сугышка» газеталарында эшли. Бер үк вакытта тәржемәче дә, мөхәррир дә, жаваплы сәркәтип тә була...

Тора-бара бабам: «Сугыш—әдәбият вакыты түгел»,—дигән фикереннән чигенә. «Карелия урманнарында,—дип яза ул берничә елдан,—ядрәләр яуганда мин үз ижатыма житмәгән нәрсәләрне таптым шикелле. Дөрес, сугыш әле тәмамланмады. Ләкин хәзер инде мин ижади киләчәгемә ышанып карыйм, нәрсә турында язасымны беләм. Язучынын авыр, чәнечкеле юлы мине куркытмый, бернинди кыенлыкларга карамыйча мин шул юлга басачакмын. Чынбарлыкта мин инде күптән шул юлда, канатланыр өчен мина тормышны һәм кешеләрне белү житмәгән. Карелия урманнарында мин тормыш мәктәбен уздым, язучылык һөнәрендә сыналдым».

## Тимер Магинә

1946 елнын апрелендә бабам Казанга кайта. Үзе белән аны үзбәк телында көткән Магинәне дә алып кайта. Тиздән бәхетле парнын балалары—Булат (әтием) белән Ләлә туа. Бабам балаларын бик яраткан, буш вакытын алар белән уздырган: кинога

һәм тимераякта шуарга алып барган, чанада тартып йөрткән, китаплар укыган.

Ләлә апам аның сугышта ниләр кичергәне турында сөйләвен, укудагы өлгереш белән кызыксынып торуын, һәр сәфәреннән күчтәнәчләр алып кайтып куандыруын сагынып искә ала. Аккош күлендә гаилә белән күнелле ял итүләрне онытырга мөмкинме сон? Тиздән яллар Боровое Матюшинода уза башлый, Күктүбә, Сочи, Пицунда һәм Яна Афонга сәяхәткә баралар. Бабамның дуслары—Афзал Шамов, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Газиз Иделле, Гази Кашшаф, Нәкый Исәнбәт, Булат Гыйззәтуллин, аларның хатыннары һәм балалары белән онытылмаслык кич утырулар ешая.

Ләлә Әпсәләмова Казан педагогика институтын тәмамлый. Ул—инглиз теле укытучысы. Бүгенге көндә Мәскәүдә яшәсә дә, Казанда бик еш була. Аның ире— атаклы джаз саксофонисты һәм композитор, «Арсенал» ансамбленең нигезләүчесе һәм алыштыргысыз житәкчесе, Россиянең халык артисты Алексей Козлов.

Булат Әпсәләмов Казан финанс-икътисад институтын тәмамлый, кандидатлык диссертациясен яклый. Ул талантлы галим һәм педагог, аның лекцияләрендә алма төшәрлек тә урын булмый. Ә лекцияләренең конспектлары бүген дә кулдан кулга йөри. Ана республиканың Хезмәт министрлыгын житәкләргә тәкъдим ителгәч тә, ул баш тарта, педагог булып кала. 1995 елның маенда, кырык сигез яшендә ул безнең арабыздан китте. Без, мин һәм эти укыткан институтның икенче курсында укучы энем Тимур, аны бик юксынабыз...

...Сугыштан соң Казанга әйләнеп кайткач, Габдрахман Әпсәләмов кабаттан «Совет әдәбияты» журналының жаваплы сәркәтибе вазифасына алына. Дәртләнеп әдәби эшчәнлек белән шөгыльләнә. Тормышының бердәнбер китек ягы—үз куышы булмау.

Коммуналь фатирларда ижат иткән язучыга ничек кыен булганлыгын күз алдына китерү кыен түгел. Алдымда Первая Малая урамындагы дүрт кеше (икесе—кечкенә бала, берсе—язучы) яши торган 20 квадрат метрлы торакның яшәргә яраклы һәм зурайту кирәклеге юклыгын раслый торган кәгазь. Мин аны гажәпләнеп, әйләндерә-әйләндерә кат-кат укыйм.

Язучы гаиләсенә ун ел эчендә алты коммуналь фатир алыштырырга туры килә. Ниһаять, Бәшировлар, Әмирләр, Шамовлар, Журавлевлар гаиләсе, Хәсән Туфан яши торган Маяковский урамындагы фатирга күченәләр... Өй каршындагы күләгәле Эрмитаж бакчасында бабам сәйран кылырга яраткан.

Әби кояшлы якка караган фатир сайларга, шулай итеп бабама язу өчен шартлар тудырырга тырышкан.

Магинә Әпсәләмова бабамның чын мәгънәсендә калканы, таянычы булып яшәгән. Бабам тыйнак, кыюсыз, үзе өчен берни дә сорый белми торган кеше булган.

«Безнең теләсә кайсыбыздан, өлкән яки яшь әдиптән, Габдрахман Әпсәләмов нинди кеше иде, нинди язучы иде дип сорасалар, без аны һәркайсыбыз күзне йомып әйтеп бирәбез: аңардан да эшчәнрәк берәр кешене табу мөмкин микән, әдәбият мәсьәләләрендә аңардан да гадел икенче бер кешене табу мөмкин микән?»,—дип яза аның турында Гариф Ахунов.

Кырык яшьтән соң Габрахман Әпсәләмов ике инфаркт һәм өч паралич кичерә. Шуларның берсе аеруча авыр була: 1964 елда язучы Башкортстандагы чыгышы вакытында үзен бик начар хис итә башлый. Әбиемә аны вертолет белән килеп алырга туры килә. Инсульт бабамны бик озакка хастаханә койкасына беркетеп куя. Уң як эшләми, сул кул белән генә яза ала... Әбием тау кадәр медицина китаплары укып чыга һәм бабамны аякка бастыра. Машинкада язучылар курсын уза һәм бабамның әсәрләрен үзе баса башлый. Бер үк вакытта бабамның мөхәррире дә була һәм әсәрләргә беренче төзәтмәләрне дә ул кертә.

Боровое Матюшинодагы дача төзелешенең дә бар авырлыгы әбием жилкәсенә төшә. Участокның як-ягына утыртылган 23 каен агачы менә кырык ел инде һаман да югары үрли.

Зәки Нури әбиемне «тимер Магинә» дип йөрткән. Хастаханә табиблары (хәтта баш табиб, бабамның дусты һәм дача күршесе Николай Иванович Чугунов та) аның

белән профессиональ мәсьәләләрдә киңәш-табыш итешкәннәр.

Ул үзе дә холык-фигыленең үзенчәлекле булуын таный. Ятимлек еллары аны шул кадәр чыныктырган ки, бүгенге буын андый авырлыкларны төшендә дә күрә алмый. Ул дөреслекне турыдан бәреп әйтүдән тайчанмады. Шуның өчен аны күпләр яратмый, әмма барыбер хөрмәт итәләр иде.

Бабам еш авырый—әбием тәржемәчеләр белән эш итә һәм кульязмаларны да Мәскәүгә үзе илтә. Аны бөтен Мәскәү әдәби элитасы белә. Переделкино һәм Кукткбәдәге ял вакытында ул иң затлы киенүче язучы хатыны була—Магинә Әпсәләмова Кузнецкий күперендәге ательедан гына киенгән.

Бабам дөнья куйганнан соң, ул аның исемен мәңгеләштерү өчен күп көч куя. Әйтик, язучының тууына 90 ел булганда Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә егерме ел элек шәһәрнең бер урамына язучы исемен бирү турындагы карар кабул ителгәнлеген искә төшерә һәм тиз арада Казан картасында Габдрахман Әпсәләмов урамы пәйда була.

Гомеренең соңгы елларында ул, инде авыру булса да, бабамны искә алу кичәләре, юбилей күргәзмәләре өчен архив материалларын җыюга күп көч сарыф итте.

Әбием бабамнан соң 23 ел яшәде. 2002 елның 18 декабрендә аны бабам кабере янәшәсендә җирләдек.

## «Алтын йолдыз» балкышы

Тыныч тормыш килүгә киеренке хезмәт башлана. Сугыш еллары турында бабамның түбәндәге әсәрләре языла: «Ак төннәр»—Карелия фронтына, «Алтын Йолдыз»—каһарман яшьләргә, «Мәңгелек кеше»—Бухенвальд әсирләренә, «Газинур»—Александр Матросов батырлыгын кабатлаган якташыбызга багышлана.

«Исәнмесез, хөрмәтле иптәш Әпсәләмов!

Сезнең «Алтын йолдыз» романыгызны укып чыктым.

Бик ошады. Каһарманнар язмышы турында күп уйладым... Бу китапны үземдә булдырасы иде: мин аны башка укучыларга да биреп торыр идем.

Безнең кибеттә китабыгыз бар иде, икенче көнне үк аны сатып алып бетерделәр.

Китапны табарга ярдәм итегезче...

Ихлас сәламемне житкереп, Роза Абназова, Омск-20».

1949 елдан башлап Әпсәләмовка укучылардан капчык-капчык хатлар агыла башлый. Хәтта почта тартмасын ике тапкыр зуррак итеп эшләтергә туры килә. Һәр конвертта язучының «фәлән вакытта җавап бирдем» дигән язуы тора.

«Алтын йолдыз» сугыш вакытында ук уйлана һәм 1948 елда язылып бетә. 1949 елда ул «Совет әдәбияты» журналында дөнья күрә, тиздән Татарстан китап нәшрияты аны биш мең тираж белән аерым китап итеп бастыра. Укучылар китапны шул кадәр яратып кабул итә ки, 1952-53 елларда ул татар һәм рус телләрендә алты тапкыр басыла. Рус теленнән тыш, поляк, украин, үзбәк һәм уйгыр телләренә тәржемә ителә.

«Әсәремдә мин совет яшьләренең Алтын Йолдыз, ягъни Ватанга хезмәт итү турындагы хыялларын күрсәтергә теләдем. Төп фикер роман төзелешен билгеләде. Беренче өлешендә мин унынчыларның чиста, берникадәр самими хыялын күрсәттем, алдагы бүлекләрдә—хыялның тормышка ашуын сурәтләдем».

Роман кин янгыраш ала—ил буйлап диспутлар, конференцияләр, авторның укучылар белән очрашулары үткәрелә...

## Җиңүче нур

«Алтын йолдыз»ны язган вакытта ук Әпсәләмов «Газинур» романы өчен материал җыя.

«Газинур» турында мин сугыш елларында ук уйлана башладым. Ул ният Газинур Гафиятуллинга үлгәннән соң Советлар Союзы Герое исемен бирү турындагы Указны укыганнан соң туды. Гази—җиңүче, дигән сүз. Газинур—җиңүче нур дигәнне аңлата. Романга исемне шундук таптым.

«Алтын Йолдыз»ны язганда «Газинур»дан да аерылмадым. Ләкин язарга утыру өчен каһарманымның туган ягына барырга кирәк иде. Ике романны язган арада хикәяләр дә иҗат иттем. Ләкин «Газинур» бер дә күз алдымнан китмәде. Газинурның үзен күреп белмәү язуны кыенлаштыра иде. «Алтын Йолдыз» җинел языллы, чөнки андагы вакыйгаларны үз башымнан кичердем. Газинур турында материал җыйганда аның туганнары яшәгән колхозга бардым. Анда аны барысы да белә, ләкин никтер аның каһарманлыгына шик белән карыйлар. Мәктәпкә кердем. Диварларда Советлар Союзы Геройлары портретлары эленгән. Тик араларында Газинур сурәте генә юк.

Газинурның хатлары сакланмаган. Бары тик бер почмагы көйгән фотография генә таптым. Мина Газинурның туганы ярдәмгә килде. Ул мин яраланганнан сон дәваланган госпитальдә эшләгән булып чыкты. Шул ярдәм итте. Газинурның әтисе—элеккеге крепостной крестьян. Газинур үскәндә гел аның тирәсендә бөтерелгән. Ин авыр сөйләшү Газинурның хатыны—өч баласының әнисе белән булды. Мин аның ахирәтләре белән таныштым һәм һәркайсыннан Миннурины яхшылап күзәтүен үтендем: нәрсә сөйли ул, кайчан көлә, кызара? Романны тәгалләгәч, кулъязмамны тотып Миннури янына килдем. Аны укыганда ул бер кызарды, бер елады. «Дөрес язылганмы?»—дип сорадым. «Дөрес!»—диде ул.

1950 елда күкрәге белән амбразураны каплап Александр Матросов батырлыгын кабатлаган Газинур Гафиятуллин турында роман басылгач, аның исеме белән мәктәпләр, колхозлар, пионер дружиналары атала башлый.

## Ян, ян, сүнмәс ут!

Хәрби темадан вакытлыча читләшеп, бабам гади кешеләр турында роман язуга керешә. Аңа бу җинел бирелә—үсмер чагында язучы Мәскәү заводларында эшләгән.

«Хәзер язган романымда («Сүнмәс утлар») мин атаклы замандашларымның—эшче сыйныфы вәкилләренең күнелен тирәнрәк ачып бирергә теләдем. Романның үзәк темаларының берсен якты киләчәкне күз алдында тоткан халыклар дуслыгы тәшкил итә»,—дип яза Әпсәләмов.

Роман укучылар күңелендә кин яңгыраш ала—«Сүнмәс утлар»ның гомуми тиражы бер миллионга якынлаша. «Роман басылуга, Ленин исемендәге Республика китапханәсе гадәттәгечә ун данә китап ала. Ләкин романга ихтыяҗ шулкадәр көчле була ки, барлык кагыйдәләрне бозып, китапханә тагын 26 китап соратырга мәҗбүр була. Әле шуннан соң да укучылар бу китапны кулга эләктерү өчен озын-озак чиратта торалар»,—«Әдәби портретлар» китабында Рафаэль Мостафин шулай дип яза.

«Сүнмәс утлар» романы өчен Габдрахман Әпсәләмовка Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә (1959).

## Депутат кенәгәсе

Әдәби эшчәнлегеннән аерылмыйча, Габдрахман Әпсәләмов СССРның алтынчы чакырылыш Югары Советы депутаты, КПССның XXII съезды делегаты була.

Бабамның 1962 елның 27 мартында ачылып киткән «Депутат эшчәнлеге кенәгәсе»н кулыма алам. Беренче кенәгәгә язма депутат мандаты алынуын хәбәр итә. Кенәгәдә ул кемнен нинди мәсьәләдә депутат ярдәме сорап мөрәҗәгать иткәнлеген теркәп барган. Мөрәҗәгатьләрнең күбесе сайлауга кадәр үк карауга чыгарылган. «Нәтиҗә» дигән биттән укыйм: «Мөрәҗәгать хәл ителде, бүлмә бирелде; авыл клубын төзекләндерү өчен алты мең сум бүленде; балалар йортына машина бирелде...». Кенәгәдә барлыгы йөздән артык язма бар. Һәр эш җентекләп тикшерелгән. «Корноухово» совхозы сайлаучыларының авылга электр кертү үтенече, пенсионер укытучының эшкә урнаштырырга соравы... Депутат Әпсәләмов күп кенә яшь язучыларга торак шартларын яхшыртуга ярдәм иткән.

Әлбәттә, кайбер мөрәҗәгатьләрне кире кагарга да туры килгән. Әйтик, унике яшьлек кызны көчләгән нииндидер Рәшит Р.-ныкын.

1957 елда, Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрелү уңаеннан, Габрахман Әпсәләмов Хезмәт Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

Мәскәүдән кайткач, Әпсәләмов болай дип яза: «Декадада без әдәбиятыбызның традицияләрен тагын да тирәнрәк тойдык. Һәрвакыт, һәркайчан халкың белән бергә булу, аның язмышы, фикере, һәм максатлары белән яшәү—традициянең төп үзенчәлеге әнә шунда».

Язучы әдәби тәрҗемәчелек белән дә шөгыльләнә. Фадеевның «Яшь гвардия»сен, Казакевичның «Одерда яз»ын, Гайдарның «Тимур һәм аның командасы»н, Новиков-Прибойның «Батыр караб»ын, Гайдар, Лесков повестьларын, Чехов, Пришвин, Короленко, Мамин-Сибиряк, Джек Лондон, Ги де Мопассан хикәяләрен, Белинский, Эренбург, Алексей Толстой публицистикасын татар теленә тәрҗемә итә.

Атаклы полководец, генерал Гани Сафиуллин үтенеченә колак салып, аның сугыш турындагы хатирәләрен укып төзәтә.

1967 елда әдәби эшчәнлеге өчен Ленин ордены белән бүләкләнә.

## Хастаханә койкасы, яңа дәфтәр...

Көчле авыру койкага беркетеп куйса да, бабам эшләүдән туктамаган. Аңа эшләү катгый тыелган булса да! Табиблар Әпсәләмов каләмгә һәм дәфтәргә кулы белән ялгыш кына да кагылмасын өчен ныклы күзәтү алып барсалар да, ул хастаханәдән берничә калын дәфтәрне тутырып чыга. Язучы хастаханәдә «Ак чәчәкләр»дәге Әбузәр Гәрәй улы Таһировның прототибы профессор Терегулов белән таныша.

«Ак чәчәкләр» язучының барлык алдагы әсәрләреннән дә күбрәк дан казана. Бүген дә, әсәрнең кабат басылмавына егерме еллап вакыт узса да, китап кибетләрендә романны сораучылар табыла тора. Һәр татар кешесе диярлек Гөлшаһидә белән Мансурның һәр нәрсәдән өстен мәхәббәтеннән хәбәрдар...

2008 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы язучы әсәре исеменнән чыгып «Ел табибы—Ак чәчәкләр» премиясен гамәлгә куйды. Әлеге премиянең лауреаты итеп республиканың иң яхшы докторлары сайлана.

Автор роман язу барышы турында менә болай ди: «Бер ел элек, «Ак чәчәкләр» романын редакциягә бирер алдыннан, мин бик дулкынландым. Укучылар ничек кабул итәр? Хәзер һәр журналда яхшы әсәрләр басыла. Шул әсәрләр арасында минем романым югалып калмасмы, укучы аны күреп алырмы дигән уй борчыды. Өстәвенә, табиблар тормышы турында яздым... Медицина проблемаларында ялгышмаммы, хурлыкка калмаммы?... Шикләремнең иге-чиге юк иде. Романны берничә табибка кат-кат укыттым. Ләкин күңелем тынычланмады. Эчтән генә бер корт кимерә иде. Минемчә, медицина өлкәсенә кагылышлы хаталар байтак калган булырга тиеш. Шулай булып чыкты да. Журнал укучылар кулына килеп эләгү белән, миңа Әгерҗедән М.Шаммасов исемле табибтан хат килде. Ул медицина терминологиясенә караган берничә хата тапкан. Мин аңа рәхмәт хаты җибәрдем һәм ул хаталарны төзәттем һәм...башка табиблардан тагын да усалрак хатлар көтә башладым. Бәхетемә күрә, андый хатлар башка булмады. Шаммасов күрсәткән хаталарны мин роман аерым китап булып чыгар алдыннан төзәттем. Алар күп түгел иде һәм булганнары да орфографик хаталар иде. Шуңа да карамастан, романны тагын бер кат белгечтән укыттым. Казан табиблары аяусыз һәм шәфкатьле хезмәтләре белән роман өчен материал гына биреп калмады, киңәшләре белән дә ярдәм иттеләр. Мин аларга чиксез рәхмәтлемен.»

Заһидә Сәүбәнова исемле хатын «Казан утлары» журналының ул чактагы мөхәрриренә болай дип яза (ул чакта романның ахыргы бүлеге басылып бетмәгән әле):

«Минем сезгә үтенечем шул: зинһар өчен дип сорыйм, автор Мансур белән Гөлшаһидәне кавыштырсын. Һәм аларның бергә яшәвен бераз булса да сурәтләсен. Мансур Диләфрүзгә тәкъдим ясаганда минем ниләр кичерүемне автор белсә икән. Гөлшаһидә урынында мин булсам, йөрәгем шартлап ярылыр иде».

Заһидә ханым журналны туганнарына һәм хезмәттәшләренә дә кычкырып укыган. Мин аңа изге эше өчен рәхмәт әйттем һәм аны «агитатор» дип атадым. Шуннан соң ул редакциягә бер дәфтәрлек хат җибәрде. Ул бик гыйбрәтле булып чыкты.

«...Сез мине агитатор дип атап ялгыштыгыз. Бер тапкыр да миңа бу эшне тәкъдим итмәделәр,—дип яза Заһидә ханым,—тәкъдим итсәләр дә, мин аны булдыра алмас

идем. Мин ничек кирәк-алай биш класс тәмамладым, анысы да 35 ел элек... Бүген чәчтарашханәдә кассир-гардеробчы булып эшлим. Кеше булмаганда, бигрәк тә кичке сменада мин китап укырга яратам. Чәчтарашханәгә керүчеләр кызыксынып тыңлый. Үзләре чәч алдыра, үзләре әсәр тыңлый. Араларында руслар да була. Аларга рус теленә тәрҗемә ителгән татар язучыларының китапларын укыйм. Тәрҗемә ителмәгән булса, үз сүзләрем белән сөйлим. Бәлкем, шунадырмы, без тату эшлибез. Русча яхшы ук белмәсәм дә, хезмәттәшләрем яратып тыңлыйлар... Чәчтарашханәгә төрле кешеләр керә. Күбесе чыгып киткәндә рәхмәт әйтә. Китап исемен, авторын сорыйлар. Кайвакыт әллә ниндиләре туры килә... Берсендә ир кеше кулымдагы журналны күреп, нәрсә укуым белән кызыксынды. Җавап бирергә өлгермәдем, ул авыз эченнән мыгырданды:

—Ә-ә, татар әдәбияты... Анда укырлык бернәрсә дә юк.

Күз алларым караңгыланып китте, йөрәгемне суырып алып таптадылармыни, көчле авырту сиздем. Аннары ул болай дип тә өстәде: «Татар язучылары арасында классиклар юк һәм булмаячак та.». Әйтергә оят булса да яшереп кала алмыйм—мин елап җибәрдем. Аннары ана:

—Мин үземне надан кеше дип йөри идем. Миннән дә белемсезрәкләр бар икән әле. Надан гына түгел, ахмак сез!—дидем.

Кычкырып әйтмәсәм дә, хезмәттәшләрем безнең сөйләшүне ишетеп торган. Көлделәр һәм бертавыштан болай дип җавап бирделәр: «Ахмакларның чәчен дә алмыйбыз, кырындырмыйбыз да! Поплар кебек озын чәчтән тик йөри бирсеннәр!»

Аннары ул кеше минем яныма килде һәм:

—Исәп сезнең файдага—4:2. Сез, начар капкачы булсагыз да, яхшы җанатар. Гафу итегез, сүземне кире алам. Күрәм, сез яхшы әсәр укыйсыз бугай.

Мин аның ни өчен шулай дип әйтүен аңламадым. Чын күңелдән әйттеме икән, әллә поп кебек йөрергә теләмәүдәнме—белмим. Көне буе мин төшенке кәеф белән йөрдем. Ә сез агитатор дисез.

Бервакыт ниндидер бәйрәм вактында кеше күп иде. Радиодан концерт бирәләр. Бер егет килеп керде дә радионы сүндерде.

—Татарлар җырлый, янгыргадыр, мөгаен,—дип көлде ул. Ярый әле чиратта басып торган 15-20 ир-ат куркакҗаннардан түгел иде, радионы янадан кабыздырдылар. Башкалар тавыш күтәрүгә, егет тынып калды. Ахырдан, акча түләгәндә, ул миңа татарча эндәште.

—Рәхмәт, апа, сез миңа беренче тапкыр татарча концерт тыңларга мөмкинлек бирдегез. Беркайчан да үзебезнең җырларны тыңлаганым юк иде.»

Укучы күреп тора, мин аз гына да ялгышмадым—Заһидә ханым чын мәгънәсендә яхшы агитатор. Кайвакытларда агитаторлык эшен салкын йөрәкле кешеләргә тапшырып без зур хата эшлибез. Агитаторлык эшендә дәртсезлек иң куркыныч нәрсә. Заһидә ханым кебек тыйнак һәм кайнар йөрәкле кешеләр бездә күп, бары аларны күрә белергә, аларга ышанырга гына кирәк».

60-80нче елларда «Ак чәчәкләр» чын-чынлап укучы мәхәббәтен казана. «Заря» кондитер фабрикасы шул исем белән торт чыгара, радиодан әледән-әле Гөлшаһидә җыры яңгырый, телевидениедән баш рольләрне Камал театрының атаклы артистлары Шәүкәт Биктимеров, Әзһәр Шакиров, Нәҗибә Ихсанова, Дания Нуруллина, Равил Шәрәфиев башкарган берничә серияле спектакль уныш казана...

Шуннан озак та үтми, украин телендә чыга торган «Рабочая газета» үзенең укучыларына: «Сезнең иң яраткан язучыларыгыз кемнәр?»—дигән сорау белән мөрәҗәгать итә. Г.Әпсәләмов, Г.Марков, Б.Полевой кебек данлы язучыларны узып, 7нче урынны ала.

Ул чактагысы аңлашыла. Бүген дә төрле кыйтгалардагы интернет челтәреннән файдаланучы яшьләр «Ак чәчәкләр»не унай яктан телгә ала һәм бер-берсенә укырга киңәш итә! Социаль челтәрдә дә ул күпләрнең яраткан китабы буларак күрсәтелә. Аны он-лайн китапханәләрдән укыйлар. «Габдрахман Әпсәләмов. Ак чәчәкләр» дип язуга берничә йөз сылтама пәйда була. Һәркайсында да роман турындагы җылы сүзләргә тап буласың. Димәк, ул бүген дә яшь һәм бүген дә кадерле. Язучының иң зур бәхете шул түгелмени?!..

## «Әкияттәге батыр кебек...»

1979 елның 6 февралендә бабам гадәттәгечә язу өстәле янында утыра һәм яңа китабын төзәтә. Аның соңгы әсәрләре булып Муса Җәлилгә багышланган «Агыла болыт» һәм «Күк күкрәр» исемле тарихи әсәр тора.

7 февральдә ул мәңгелеккә күзен йома. Ә миңа аның белән очрашу өчен нибары ике ел вакыт җитмәде...

70нче еллар ахрында күренекле журналист, ул чакта «Яшь Ленинчы»ның җаваплы сәркәтибе Саимә Ибраһимова «Ак чәчәкләр» һәм «Яшел яр»ны рус теленә тәрҗемә иткән язучы Кузьма Горбуновка яшь укучыларга Габдрахман Әпсәләмовның тормышы һәм иҗаты турында язуын сорап мөрәҗәгать итә. Кызганыч, мәкалә дөнья күрми кала—Кузьма Яковлевич авырый, бабам вафат була. Саимә Ибраһимова Кузьма Яковлевичның хатларын кадерләп саклый һәм күптән түгел генә ул хәзинә белән уртаклашты.

«Хөрмәтле Саимә Ибраһимова!

Хатыгызда миңа карата әйтелгән җылы сүзләрегез, ышаныч белдерүгез һәм зурлавыгыз өчен чын күңелемнән рәхмәтемне җиткерәм. Мин җавабым белән бераз сонардым, тоткарлануымны кичерерсез дип өметләнәм.

«Яшь Ленинчы» газетасы яшь укучыларына татар халкы каһарманнары, фронт һәм хезмәт геройлары турында сөйләп яхшы эш башкара. Һичшиксез, үз халкының талантлы улы Габдрахман Сафа улы Әпсәләмовның тормыш юлы һәм иҗаты турында өлкәннәр генә түгел, балалар да белергә тиеш. Ул аңа лаек. Габдрахманның таланты беркемдә шик тудырмый, шунысы игътибарга лаек, аның таланты кешелекле һәм ул нәфис сүзе белән бүгенге көннең алдынгы, гуманистик идеяләрен пропагандалый. Аның хезмәт фидакаре булуы да шик тудырмый. Билгеле, һәр максатчан эш күп көч һәм кешедәге рухи торгынлыкны җиңүне таләп итә.

Әпсәләмов ничә еллар инде үзенең физик авыруы белән көрәшә. Шул ук вакытта күтәренкелек белән эшләүдән туктамый. Бу батырлыкка рухы белән баһадир булганнар гына бара ала. Бүген без әдәбиятта тагын шундый икенче баһадирны белмибез.

Һәм тагын да мөһиме—гадәти булмаган тыйнаклык язучыны бизи.

Күреп торасыз, мин күп нәрсәләр турында әйттем. Ләкин төп нәрсә турында әйтмәдем, чөнки әле дә булса Габдрахманның эчке сүнмәс утын нәрсә тотып торганын тасвирлау өчен сүз таба алмыйм. Кайвакыт фән һәм сәнгать кешенең бар нечкәлекләрен дә белеп бетермидер кебек. Габдрахман организмында да, җан төзелешендә дә мона кадәр ачылмаган нәрсәдер бар кебек.

Аның белән очрашмавыбызга байтак вакыт узды. Ләкин шунысын хәтерлим—күрешкән саен мин аның җылы нур тараткан һәм әңгәмәдәшен үзенә тартып торган күзләренә карыйсым килә иде.

Тагын да көчлерәк, тирәнрәк фикерле торган, күләмлерәк талантка ия язучылар бар. Габдрахманның таланты бөек газапларны җиңгәндә чагыла. Бу яктан караганда ул сирәк очрый торган, каһарман талант».

Баһадир... Бу чагыштыру бер Кузьма Яковлевич Горбуновның гына башына килми.

«Әпсәләмов, әкияттәге баһадир кебек, татар романы сүнеп күләгәдә калганда, әдәбият мәйданында ялгыз сугышчы булды, китаплары белән татар укучысын тотты, аларны татар әдәбиятыннан читләштерүдән саклап калды»,—дип язды Хәсән Туфан...

Әй, бабай, бабай!.. Син җитмисен җаныма! Минем сиңа бу журналны бүләк итәсем һәм синең белән күп нәрсәләр турында фикер алышасым килә! Еллар узган саен мин син кабызган утларның беркайчан да сүнмәсенә ышана гына барам.

**Рөстәм ГАЛИУЛЛИН**
*тәрҗемәсе*

# АЙДАР ХӘЛИМ: ШӘХЕС ҺӘМ ИҖАТ

*2012 елның 1 гыйнварында танылган шагыйрь, прозаик, публицист, тәнкыйтьче, драматург Айдар Хәлимгә 70 яшь тула. Юбилей уңаеннан журналист Фирдәвес Хуҗин Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче әдип белән очрашты. Түбәндә әлеге әңгәмәне тәкъдим итәбез.*

**—Айдар ага, әңгәмәбезне тәрҗемәи хәлегездән башлап китик әле. Ата-анагыз, нәсел-нәсәбегез, туганнарыгыз, гомумән, туган чыганакларыгыз турында сөйләсәгез иде.**

—Мин әдәбиятта «фаҗигаи кырыгынчы елгылар» дигән исем алган буын вәкилемен. 1942 елның 3 гыйнварында, мин туып өч көн тулганда, әтием, авыл укытучысы, фронтка киткән. Ике ай дигәндә әнием мине, хатларында язуынча, «йөзен күрмәгән улын», Абдуллино станцасында алгы сызыкка китәргә әзерләнеп яткан әтиемә алып барып күрсәткән. Бүтән безгә күрешергә насыйп булмады. Гвардия лейтенанты Нәҗметдин Габделвәли улы Хәлимов сугыш бетәргә дүрт ай кала Словакиянең 503нче биеклеген алганда һәлак була. Башта Модри Камень авылының үзәк мәйданында җирләнә, аннан Зволен каласындагы туганнар каберлегенә күчерелә. 1988 елда Зволен каберлегендә булып, әткәм җәсәден яд иттем... Әниемнең гомере дә чагыштырмача яшьли өзелде. Мин, хәрби хезмәт үтеп яткан солдат, аны күмәргә дә кайтып өлгермәдем. Анама, аның фаҗигале үлеменә багышланган ике шигыремнең «Тальян моны» дип аталганы «Казан утлары»да (1967 ел, сентябрь) басылып чыкты.

Гаиләдә дүрт ир бала ятим калдык. Абыйларымның берсе—Нияз 1976 елны вафат булды. Иң өлкән абыем Гали гомерен Үзбәкстанда үткәрде һәм 2003 елда Ахангаран каласында җирләнде. Үземнән өлкәнрәк абыем Ингель туган авылыбыз Кәркәлетамакта яши. Авылда башлангычны, аннан, көн саен ун чакрым йөреп, Олы Кәркәле җидееллык һәм егерме чакрымдагы Миякә урта мәктәбен тәмамладым. Мине әнием, туган авылым халкы, туган якның гүзәл табигате, беренче чиратта, авылым үрендә басып каршылаган, озатып калган Түгәрәк Имән һәм саф сулы Мендәрле Күл чишмәсе тәрбияләде. Кыскача, менә шулар.

**—Сезне шагыйрь, язучы, публицист, фикер иясе, җәмәгать эшлеклесе дип атыйлар. «Күренекле» дип тә өстәсәң, бик дөрес булыр. Әмма болар бар да иң әүвәл сезгә хас булган бер сыйфатның нәтиҗәләрен генә тәшкил итмиме? Әйтик, сезгә еш кына «ялкынлы публицист» диләр. Холык-фигыль үзенчәлегегез публицистиканың агым-чишмәләреннән яратылган кебек.**

—Мин—каты күнелле публицист түгел, барыннан да элек йомшак күнелле шагыйрь. Шагыйрь итеп танырга теләмәгән тар җанлы көнчеләр генә, шагыйрьлек такыясын салдырып, башкисәр публицистның чәнечкеле шайтан таягын тоттырырга ашыга. Алар үзләрен генә шагыйрь, ә менә «безнең кебекләр» публицист кына булып кала ала, дип саный. Әйе, хак, мин—публицист та. Тик һич тә башкисәр түгел, ә гаделлек яклаучы. Моның белән горурланам. Күрәсең, кемнәрдер әйтмешли, бик көчле, сирәк публицистмындыр. Әмма әле әдәбиятны нәрсәләр туендырып торганын аңламас дәрәҗәдәге каләм иясе түгелмен. Иҗатның гомуми нигезендә, син нинди

генә жанрда иҗат итсәң дә, шигърият ята бит! Менә ни өчен публицистик каләмем шигърият белән чәчкә аткан. Мине публицист буларак таныган адәмзат әүвәлдә шагыйрьлегемне танырга тиеш. Әгәр ул аны танып өлгермәгән яки теләми икән, ашыгырга кирәкми, өлгерер: киләчәктә ул аны барыбер таныячак.

Сез иҗат ялкынының үзенчәлекле чыганаклары турында сорыйсыз. Кызык бу. Шагыйрь—ялкыннан, ә ялкын, диаметраль каршылык буларак, салкыннан яратыла. Минем ялкыным да салкыннан бар булды, чөнки бала чагымда бик нык өшедем. Үземнең гомер буе җылынасым килгәч, кешеләрне дә җылытасым килде. Барлык башка кешелек сыйфатларым шул кайнар белән салкынның каршылыклы бердәмлегеннән килә.

Мин иҗат иткән жанр төрләренең нигезендә нинди дер уртак холык сыйфатлары ятуын сез дөрес чамалыйсыз. Нәфис чәчмә әсәрче-прозаик, балалар шагыйре, журналист, публицист, тәнкыйтьче, драматург, сатирик һәм башка беренче карашка «кушыла алмаган» жанрларда эшләвемнең асылында нәкъ әнә шул шагыйранә холык ята. Шуңа күрә алар берсе икенчесенә бик уңайлы итеп яраклаша. Миңа гомерем буе жанр түгел, вакыт җитмәде. Тагын бер тапкыр кабатлыйм: чын шигырьне язу, бастырып чыгару, сәхнәдән халыкка житкерү өчен бер өлеш матурлык һәм батырлык кирәк булган булса, публицистик әсәр язу өчен ике өлеш матурлык һәм батырлык кирәк. Ул ажгырып торган ялкын, төпсез вулкан...

**—Сабый чакта кем булырга хыялландыгыз? Хыялыгыз тормышка аштымы?**

—Шагыйрь, язучы булырга теләдем дигәнне ишетәсегез киләдер. Юк, шагыйрь булырга да, язучы булырга да, журналист-публицист булырга да хыялланмадым. Туган колхозымда ат караучы булырга теләдем. Гәрчә, урта мәктәп тәмамлаган һәм инде район гәзитендә танылган, хәтта ки район партия комитетының мактау грамотасы белән бүләкләнгән яшь авторны, шунда эшкә чакырып торсалар да. Никита Сергеевич Хрущев безне, урта мәктәп тәмамлаган үсмерләрне, авылны күтәрергә чакыра дип, туган колхозыма кайткан идем. Әмма бер фельетон бастырганнан соң, партбюрога чакырып бик нык кыздырдылар. Авылдан китүдән башка чара калмады. Бу уңайдан караганда, ат караучы булу турындагы хыялым тормышка ашмады.

**—Ярый, кайчандыр шагыйрь-язучы булырга хыялланмаган булсагыз да, шуңа ирештегез, зур танылу алдыгыз. Сез үз иҗатыгыздан канәгатьме соң?**

—Бу минем өчен җавап бирә алмас дәрәҗәдә серле, катлаулы сорау. Канәгать булмас өчен беркайчан да амбицияләр белән газапланмадым һәм дә ки канәгать булырлык дәрәҗәдә пошмас булмадым. Канәгатьлек өчен син үзең яшәячәк заманның язучыга карата таләбен белергә яки бөтенләй дә белмәскә тиешсең. Бигрәк тә безнең кебек илле яшькә кадәр гомерен совет диктатурасы шартларында яшәп картайган әдип өчен. Әйе, иҗатымда күп кенә табыш-яңалыкка, камиллеккә ирештем дип әйтә алам. Әмма үземне тулаем канәгать дип юата алмыйм. Әдәбиятыбыз бик биреште, чүпләнде бит. Ничек канәгать була алыйм? Татарда «Атадан яшь калдым, акылдан буш калдым» дигән әйтем бар. Язучы булу өчен һәрьяклап әзер булганмын, әмма аны сизенмәмәгәнмен генә дияр идем. Менә шушы катлаулы юлда югалтулар да ифрат күп булды. Әйтик, әгәр миндә мәктәп, өй, атам-анам, туганнарым, дусларым тарафыннан шигырь һәм аның холык даирәсе, нәрсәнең чын шигырь, нәрсәнең чын шигырь булмавы турында фәнни-хрестоматик аң тәрбияләнгән булса, мәсәлән, 1959-1966 еллар арасында үземнең җанымда давылланып туган йөзләгән шигырьне «болар чын түгел» дип, кире тыгып куймаган, үз карынымда үзем «бумаган», берничә елга бөтенләй диярлек язудан туктап тормаган булыр идем. Баксаң, соңыннан аңлашылуынча, нәкъ менә шушы «житлекмәгән» дип уйлаган корамалар булган икән кайнардан-кайнар яшьлек шигырьләре!.. Әмма аларны хәзер кайтарып булмый инде...

Мине гомер буе жанр төрлелеге түгел, ә бәлки ике нәрсә—көнелдә туган әсәргә тотынудан курку һәм вакыт житмәү борчыды. Тыныч бүлмәдә түгел, кайда шау-шу күбрәк, шунда тынычлап язам. Шартлары булмаган саен яхшырак, онытылыбрак

язылa. Әле күңелемдә моннан илле ел элек яралып, язылмый йөргән әсәрләрем бихисап. Ышансагыз—ышаныгыз, ышанмасагыз—юк: хәзергәчә утыз яшькә кадәр туган әсәрләремне кәгазьгә төшереп бетерә алмыйм. Мәсәлән, «Самавыр төзәтәбез» дип авыл буйлап йөргән мукшылар турындагы алтмышынчы елларда җанда оешкан шигырем әле дә булса язылмаган. Күпме алар?! Шуларны язып өлгерерменме? Әйтик, «Өч аяклы ат»ны язылганыннан егерме, «Җанчишмә» дигән пьесамны шулай ук егерме ел элек язарга тиеш идем...

**—Сез үзегезне шагыйрь буларак таныла алдым дип уйлыйсызмы?**

—Юк. Аерым шагыйрьләр, әдипләр, халык тарафыннан танылдым, ә менә рәсми әдәбият фәне, формаль булса да тын ала килгән тәнкыйть тарафыннан танылa алмадым. Әмма бу нишләптер һич кенә дә хафага салмый. Үпкәләмим дә. Аптырыйм гына. Мин, гомумән, көнгә чыксам аптырап йөри торган кеше. Ни өчен? Кызык, катлаулы, хикмәтле тойгы бу. Сорау куелгач, җавап бирми булмый. Шундыйрак тойгы бу: башкалар белән бергә бер йөкне тигез, хәтта ки артык тартып та гел читтә калуны анлау өчен һәр кеше шушындый читтә калуны үзе кичерергә тиеш. Әмма адәмзат психологиясе шулай корылган: ул шуны кичермичә генә уртада булырга тели. Нишләтәсең, тормыш шундый. Ашыйсы-эчәсе килә!.. Хәтта моны кичергән хәлдә дә, бу кичерү тигез була алмый. Кемдер барыбер уртада, кемдер читтә кала. Тора-бара, үзеннән шул читтәлегенә күнегәсең.



*Татар дөньясы галимнәре корылтаенда. Сулдан уңга: Айдар Хәлим, академик Миркасыйм Госманов һәм профессор Гриф Хәйруллин (Алма-Ата). 2007 елның октябре.*

Менә күз алдыгызга китерегез: алтмышынчы еллар азагында Мостай Кәрим, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан кебек корифейлар тарафыннан хупланып әдәбиятка килеп кердем. Хәтерләсәгез: «Мин тормышка атылып килеп кердем / Изүләрем чишкән рәвештә...» Шунысы кызык, аларның теләктәшлек юлламаларыннан соң кырык ел үтеп, минем шигърият турында, гәрчә матбугатта, беренче чиратта, үзәк матбагабыз булган «Казан утлары»нда, башкалар белән тигез басылып килсәм дә, әдәби тәнкыйть тарафыннан бер тапкыр да шигъри күзәтүләргә, мәкаләләргә, гомумән, тәнкыйди хезмәтләргә кертелмәдем. Андый мәкаләләрнең авторлары мине кертмичә ничек түзәләрдер дип, аларны кызгана идем. Түзәләр икән. Татар әдәбияты хрестоматияләренә бер генә шигыремнең, хикәямнең дә кертелгәне юк әле. Бары тик өченче меңьеллыкка кергәч, 2005-2008 елларда гына минем иҗатыма—рәхмәт төшкерләре!—каләмдәшләрем Равил Рахмани һәм Равил Фәйзуллин игътибар итеп, мәкаләләр яздылар...

**—Татар прозасы һәм шигърияте бүген нинди хәлдә? Сезнең карашка, алар дөрес юлдамы?**

—Әйе, мин үз карашымны гына әйтә алам. Кемдер аның белән килешмәскә мөмкин. Бүгенге татар прозасы бик йомшак. Анарда, аерым әсәрләрдә, нинди дер таң чаткылары күренеп киткәндәй итә, әмма бу яктылык күкне тәмам яктырта алмый, сызылып кына кала. Кызыксынып укый гына башлыйсың, аһ, юк!.. Кайвакыт без егерме беренче ел ачлыгын сурәтлибез, әмма ачларыбыз, аякларын бөкләп утырып, каклаган каз кимерә. Тарихи романнарыбыздагы «районара әкиятләрне» инде әйтеп тә торасы юк. Бик ихтирам иткән кайбер каләмдәшләрем шактый

четерекле, кызыклы, моңа кадәр күтәрелмәгән темаларга да алыналар. Аерым уңышлар да бар кебек. Мәсәлән, Фоат Садриевның «Бәхетсезләр бәхете», Тәлгат Галиуллинның «Сәет Сакманов» трилогияләрен, Зөлфәт Хәкимнең «Легионер», Гөлчәчәк Галиеваның «Газзәбану», Рәмзия Габделхакованың «Тау артында кояш бар» романнарын һәм кайбер башка әсәрләрне күз уңында тотам. Аларда безгә житмәгән саф һава, яңалыкка омтылу бар. Шул ук вакытта аларда да камил әдәбиятка хас булган элементларның йә чамасызлыгы, йә житешмәве, йә кирәгеннән артып китүе сиздерә. Безгә милләт язмышыннан милләтебез кебек күпне күргән, акыллы, тырыш, тирән хиссияти тукыма-полотнолар кирәк. Казанның алынуы турында да бер хрестоматик хикәябез юк бит безнең. Карамзин, Карбышевларны татар дибез. Кая бу хакта әсәрләребез? Гарьлеге ни тора! Өч йөздән артык язучыбыз «сәтсиәлистик» ярыш ачып алынса, күтәрелмәгән темалар калмас иде. Татар Казаны алыну турында әсәре булмаган татар әдәбиятын әдәбият дип атап буламы? Безнең прозаның төп чирләре—вак темалылык, сурәтсезлек, телсезлек, чамасызлык (тозсызлык) һәм чуар холыклылык. Язучыдан соң укучы һәр нәрсәне тотып, иснәп, татып карый алырга тиеш. Проза мәгълүмати яңалык, дөньяви масштаб алып килергә тиеш. Еш кына бездә боларның берсе дә булмый. Анда еш кына «Радик белән Радия встречаться итә».

Шигъриятта кызыклы гына яңарыш бара. Мин моңа куанам. Бүген безнең уңлап мена диган шагыйрь-шагыйрәләребез үсеп килә. Бу урында аларның исемнәрен атауны кирәк дип санамыйм. Шигырьләрен укып куанганнан соң, аларга кечкенә хатлар язганым, шалтыратып котлаганым бар. Поэзиядәге уңай тенденцияләрнең яклануында һәм саклануында «Казан утлары» журналының һәм аның шигърият бүлегенең уңай ролен билгеләп үтәсем килә. Әлбәттә, болар гына безгә тынычланырга мөмкинлек бирми. Татар мәктәпләренең күпләп ябылуы һәм еш кына манкорт татарның үз кулы белән ябылуы күңелгә куркыныч шом сала. Бу хәл милләтне, аның милли мәгарифен саклау һәм үстерү юллары турында бергәләп уйлашуны таләп итә. Бу көн килеп житте. Ашыгырга иде, җәмәгать.

Гомумиләштереп алганда, безнең шигърият дөнья күләмендә иң көчле шигъриятләрнең берсе була ала иде. Әмма була алмады. Минем карашка, бирегә үткән гасырның алтмышынчы елларында безнең аксакалларыбыз, ул чактагы «партиябез» җибәргән бер стратегик хатаны әйтми китү ярамас. Бу хатаның өземтәләре менә илле ел чамасы инде әйтелмичә үзен сиздереп килә. Мәгълүм ки, үткән гасырның алтмышынчы елларында әдәбиятыбызга бик көчле, шигъри дулкын килде. Бу—сугыш алдыннан һәм сугыш барышында туган буын. Алар үзләренең рухлары белән табигый рәвештә иҗатның ике—гаклый-рационалистик һәм лирик-романтик канатларында иҗат иттеләр. Әлбәттә, бу бик шартлы бүленеш. Шулай да, төсләр үзгәрә торса да, шагыйрьнең танып-белү чарасы үзгәрмәде. Әмма «партиябез» бүлгән бүлем һич кенә дә шартлы түгел, бик конкрет иде шул. Ул шигъриятнең бәкәленә китереп сукты. Әйтик, йөзгә якын яшь шагыйрьдән иҗатлары гаклый-рационалистик хиссият платформасында торган ун-унбишләп талантлыларны сайлап алынды һәм алардан «исемлек-обойма» булдырылды. Икенче, лирик-романтик юнәлештәге яшьләр, әйтик, Рәшит Әхмәтҗан, Кадыйр Сибгатуллин, Зиннур Насыйбуллин, Рифкать Закиров, Разим Вәлиуллин, мин үзем һәм тагын башка берничә шагыйрь бу «обоймадан» читтә торып калдык һәм вакытлы-вакытсыз фаҗигаларга юлыктык. Юк, мин беренче төркемгә ниндидер гаепләр тагарга теләмим. Киресенчә, кабатлап әйтәм, алар бик талантлы шагыйрьләр һәм бүгенге көнгә кадәр шигъриятебезне бик яхшы әсәрләр белән баетып, житәкләп килделәр. Әйтәсе килгәнем шул гына: әгәр бу ике юнәлеш гармоник тигезлектә үстерелгән булса, безнең шигъриятебез ихластан да дөньякүләм танылган шигърият булып житешәчәк иде...

Халыкта «Узган эшкә—салават» дигән мәкаль бар. Иң мөһиме, киләчәгебез якты, ышанычлы булсын. Безнең хаталарны бездән соң килгән яшьләребез кабатламас, дигән өметебез бар. Әйдәгез, Тукаебыз әйтмешли, алга, халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә!..

# ӘДИП ТУРЫНДА КАЛӘМДӘШЛӘРЕ

**Флера НИЗАМОВА:**

—Шагыйрь була, публицист шагыйрь була. Кайбер әдәбиятчылар, шигырьдә ап-ачык, шәрә дип әйтерлек фикер аша теге яки бу конкрет хәл-вакыйгага үз позициянне белдерүне шагыйрьлектән алып китүче шәй дип саныйлар. Заманында Г.Ибраһимовның шушы җәһәттән Тукай белән Дәрдемәндне каршы куюын гына искә алу да җитәдер. Идеалда, теориядә бу чынлап та шулай, ахры. Эстетлар күзлегеннән караганда, үз шигырьләрендә бернинди документаль фактка ишарә итмәгән, тәгаен хәл-вакыйганың, тарихи персонажның исемен атамаган, вакытын күрсәтмәгән, ә чиста образлар, метафоралар белән генә эш итүче әдип кенә шагыйрь була ала кебек. Ләкин мәкаләләрдән йә прозадан гына түгел, ә әдәбиятның иң кайнар, иң өлгер жанрыннан да бүгенге көнебезнең меңләгән сорауларына җавап эзләмибезмени? Бар бит әле бөтен кешелек дөньясы өчен, ә асылда үз халкына төбәп язу. Айдар Хәлим, әлбәттә инде, икенчесе. Ул татар өчен, татарча яза. Кирәк булганда, урыслар һәм бүтәннәр дә ишетсен дип тотынса, урысча да чатнатып үз сүзен әйтә ала. Күп шигырьләренең этәргеч-импульсы йә эпиграфта, йә шигырь исемендә үк чәчрәп тора. Багышламалары да күп. Әйтик, тарихчы Равил Фәхретдингә, шагыйрь Фәрит Габдерәхимгә, бию остасы һәм остазы Фәйзи Гаскәровка, җырчы Илфак Смаковка, татар китабының елъязмачысы Әбрар Кәримуллинга, әллә ничә якташына, авылдашына... Ләкин ул багышлауларның берсе генә дә «альбомный», «юбилейный» шигырь түгел. Һәркайсы тулы тормыш фәлсәфәсе.

Аның «Сабый көче турында баллада»сы бар. Тетрәндергеч тормыш драмасын, хикәя йә булмаса пьеса сюжетын күтәрә алырдай язмышны Айдар Хәлим зур булмаган бер балладага сыйдырган. Юньсез хатын аркасында сабыен югалткан ир хәсрәтен сурәтли ул. «Мөсаббиха әбигә хат»ы—үзе бер шедевр. Йөзьяшәр авылдашы, балачагының әкияти юлдашы Мөсаббиха әбигә эндәшә-эндәшә, автор әби язмышын үз язмышына бәйләп бара, бигүк җинелдән булмаган шагыйрьлек хасиятендә казына, асылда үзенең каян килеп чыгуын, кая таба барышын анализлый. Сагыну, моң тулы озын шигырь. Ә авылдаш карчыкка дәшүе! Башта, холыксыз картыннан җәбер күреп яшәүче әле «яшь» әбигә: «Әбекәй, әбекәй, таланган аккошым!» дисә, инде йөз яшенә җиткән шул ук карчыкка: «Әбекәй, әбекәй, какланган аккошым!»—дип дәшә.

Язучы кеше күп йөрергә, күп күрергә, үзе күргәннәрне йөрәк каны аша сугарырга тиештер. Шунда гына каләм иясенең күнел офыклары, гамь географиясе киңәя алыдыр. Татар язучыларыннан тормышны иң күп күргән, аның төрле катламнарына төшеп караган кеше буларак та беренче чиратта Айдар Хәлимне күрсәтсәк, бер дә ялгыш булмас. Әле тагын иң кыйммәтлесе шунда, йөрү-күрү-кыен ашау-җан талку белән генә чикләнмичә, йөрәккә кан саудырган хәлләрне китапларында халыкка җиткереп килүе үзе бер батырлык. Чаң сугуы, ерткычлыкларны фашлавы калын-калын китапларында гына түгел, яшен ташыдай кайнар һәм тиз жанрда—шигырьдә дә укучыга барып җитә тора бит әле! Түбәндә санала торган шигырь һәм поэмаларның исемнәре үк аларның кайсы вакыйга уңаеннан язылганлыгын әйтеп тора: «Унтугыз чеченкыз турында баллада» «Бакчасарай фонтанына», «Дудай маршы», «Башкорт халкына ачык хат», «Биштау белән хушлашу», «13 гыйнвар, 1991 ел. Вильнюс», «Фәләстинә» һ.б.

«Печән чапканда» исемле китабындагы, шигъри баганалар янәшәсендә документаль фото-сурәтләр дә бар. Берсендә—урман төпләү, агач чыгару күренешләре. Аска болай дип язылган: «Түбән Кама химкомбинаты салынachак мәйданда мең гектардан артык урман киселде. 1962 ел». Шагыйрь яшьлегенә туры килгән әнә шул урман төпләп кала салулар ул заманда күпләрне рухландырса да, бүгенге экологик хәлебездә кичәге урбанизация шаукымы бик тә хаталы эш булып күренә. Гәрчә Чаллы, Түбән Кама гигант төзелешләре бүгенге Татарстанның мал табу чыганагы, горурлыгы булса да. Соңрак 1981 елда язылган «Стәрлебаш урманында» поэмасында һәм «Күләгәсез урман» шигырендә инде бүтән төрлерәк хисләр бөтерелә:

*Кит читкә, калма аста,*
*Яуда үлгән әтиләр сымак,*
*Гәрселдәп ава агачлар!..*

***

*Агачларны колониаль сөю*
*Шундый дәһшәт белән, тәүбәсез*
*Көйдергән ки –*
*Мәңге тере урман*
*Үлгән—күләгәсез, шәүләсез...*

Афоризмнарны халык үзе тудыра дибез. Әйе, халык, әмма халыкның эченнән чыккан аерым даһилары, шагыйрьләре була, шулар тудырадыр әйтемгә тартым фәлсәфи гыйбарәләрне. Айдар Хәлим дә, тормыш күренешләрен кануннарга төйнәп, үз хисенә исем табарга тырышып җаны бәргәләнгәндә,—шигырь ялару мәле шул үзедер инде,—татар йортының диварына элеп куярлык гыйбарәләр иҗат итә. Күрче, ничек төгәл әйткән, дип укыганнардан берничәсен генә китерим:

*Бер кулыма кан сауган исемлек,*
*Бер кулыма шәмдәл-ут алып,*
*Көпә-көндез кеше эзләп килəм.*
*Кеше диңгезендә буталып...*

***

*Чыбык түгел, казык белән каксаң*
*Келәм сыман җанын татарның,*
*Биш гасыр коллыкның шакшысында*
*Йөрәге шартлар хәтта атларның.*

Күп йөрү, күпне күрү дидем. Айдар Хәлимдә андый йөрүләр, күрүләрдән туган фикер һәм хис, спираль сымак бөтерелеп, бөгәрләнеп, һаман бер үк урынга әйләнеп кайта—үз туган халкына, үз милли кырына. Искә төшеп китте: моннан ун-унбиш ел элек, ниндидер эш белән Баулыга баргач, районның шул чактагы җитәкчесе белән бәхәсләшеп кителде. Сүзебез язучы Миргазиян Юныс хакында иде. Миргазиян абыйның туган ягына кайтып яшисе килә, ә җитәкче, Казан тарафыннан төшкән бәяләмәгә тотынып, фатир мәсьәләсен хәл итми тора. «Нинди яхшылык эшләгәне бар соң Юнысның Баулыга?»—дип, сорауны кабыргасы белән куя башлык. Бик сәер таләп. Язучы, китап язудан гайре, тагын нинди яхшылык эшли ала инде, йә?! Һушымны җыеп әйттем: «Ә сез аның теләсә кайсы повестен, мәкаләсен алып укып карасагыз,—дингезче, сәях җанлы язучы Занзибарлар, Сингапурлар турында язамы, Марсель йә Парижны сурәтлиме, шунда ук үзенең Баулысын, Исергәбен, Ык буен искә ала, шуларны зурлый, кадерли. Бу азмыни?» Айдар Хәлимдә дә нәкъ шул сыйфат ярылып ята. Туган җир, туган милләт, туган тел—аның күңел доминантасы шулар. Төрки-татарларның тарихи урынын аңлаудан, бүген шуны җуя баруыбыз ачысыннан оеша булыр аның җан авазы:

*Татар—Рәсәй мең ел түләсә дә,*
*Әҗәте кайтмаслык ятим ул...*

А.Хәлим поэзиясендә татар авылы, аның йола-гадәтләре, дөрли торган офыклары, эремчектәй болытлары, инрәүче таулары, ызаннарга сөрлеккән үләннәре, нурга буялган тәрәзәләре, башлаган кәрәзендә йоклап киткән бал корты, тальян моңына төренеп йоклаган алка таулар, айның утырып туган колынын җилкәсендә өйгә алып керүче ир, балачактагы «урнаш» уены, тал көмеше, космик корабтай комбайннар, күләгәсе юеш солылар, тагын әллә ниләр, әллә ниләр. Тукайның «уйласам авылымны, гаклымнан да мин хәзер язам» дигәне шул буладыр инде. Тоташ йөрәк тибеше, өзлексез ярату. Йөрәк тибеше ритмында сулкылдап торган рифмалар, тигез ритмнар. Ә менә гомерлек әрнүләре, үкенечләре ярсытканда ритмнар үзгәрә, сынып-сынып китә. «Кайсыгызны юатыйм?», «Мәхәббәт турында монолог», «Минем бакчаларымда» шигырьләре, ярсулы-давыллы поэмалары—«Яралы бөртек», «Фәләстинә», «Эксперимент—86», «Беренчеләр»—әнә шундыйлардан. Нигездә үз балачагын искә

төшерү, аның кызыкларын шигъри шәрехләү кебегрәк рухтагы «Биктырыш»ы янә дә җинел һәм тигез келтери. Чөнки анда йөрәк давыллатырдай текә сикерешләр, фикер чоңгыллары юк. Ул—рәхәтлек, кызыклар, балачакның әкияти маҗаралары белән тулган. Ә инде туган авылы төнен ничегрәк хозурланып сурәтли А.Хәлим, нәкъ Тукай вәзененә күчеп бетә, «Шүрәле»ләр, «Пар ат»лар искә төшеп китә:

*Коела күктән шым гына аҗаган балкышлары.*
*Башлана башлый башаклар тс-псы, чыш-пышлары.*
...
*...Утырам капка төбендә, иңдә төннең яртысы.*
*Шылт итми адәм вә яфрак, читән вә каралтысы...*

Айдар Хәлимдәге космик колачлы хис кинлеген-тирәнлеген дә шәрехләүчеләр табылыр әле, бәлки. Үзе бер диссертациягә тарта торган хасият. Аның туган җир төшенчәсе, бер карасаң, Миякә ягындагы Бәләкәй Кәркәлегә сыеп бетсә, икенче яктан, үзе әйтмешли, «Урал белән йөрәгемне урап, Идел белән маңгай сыйтам» дигән кебегрәк кинлекләрдә чайпала. Аларны ул гаҗәеп бай сурәтләрдә чагылдыра: «Гүя мина, кыргый баласына, / Күктән сүнгән йолдыз коелды»; «Ике күзе, йолдызлар сыман, / Чүплеккә, коелып төште»; «Кәркәле күгендә аунап, / Яна ай әвәләнә»; «Тезгененә басып үзәннәрнең, /Мин тауларның атын тугарам» һ.б.

Айдар абыйның шигырьләре ярсыта, йокыны ала. Аларның моңлы көче турында язып утыруым да буш эш, чөнки шигырь организмында казынып, аны укучыга аңлату мөмкин түгел, аның үзен укырга кирәк. Бу бары тик «Сез җибәргән шигъри кошлар минем күңлемә дә кунды, мин аларның сайравын тыңладым»,—дип хәбәр итү генә. Үзенең дөньяга нигә җибәрелгәнен дә яхшы тоя ул. Шагыйрьлекнең ни-нәрсә икәненә дә җавабы бар, үзеннән дә төгәлрәк итеп барыбер әйтеп булмас: «Шигырьгә килсәк, ул—кешелекнең мәңге сабый чагы. Ул картая белми торган яшьлек, саргая белми торган гөлбакча... Шигырь—мәңгелеккә язылган эчкерсез хат. Әдәпнең башы, ашы, тозы...» Айдар абыйга шигъри гөлбакчасында озын-озак йөрүен телисе генә кала.

* * *

**Рифат СВЕРИГИН:**

—Әдәби әсәр һәркайсыбызны балачакка, яшьлеккә алып кайта, туган җиребез, туган телебез, яшәешебез, кеше икәнлегебез, үткәнебез, бүгенгебез, балаларыбыз язмышы, киләчәге турында уйландыра. Тик мондый халәт ике шарт сакланганда гына була ала: беренчесе—китап укучының күңелендә иманлылык, кешелеклелек орлыкларының шытып үскән булуы; икенчесе—әдип каләменең әнә шул имандагы яхшылык-изгелекне тагы да баетып, матурайтып җибәрерлек көчле тәэсире, ягъни эмоциональ сәнгать чаралары белән эш итүе. Тәҗрибәле әдип Айдар Хәлим сәнгатьнең, әдәбиятның шушы хасиятенә, шартларына нык таяна. Аның әсәрләрендә әйбәт, намуслы кешеләргә чиксез ихтирамы, хөрмәте һәм шул ук вакытта күп очракларда гаделлек, кешелеклелек дигән төшенчәләрне аяк астына салып таптау күренешләрен күрсәтүе күңелләрдә төрле аянычлы һәм каршылыклы хисләр дә уята. Туган телебез байлыгыннан бу әдипнең бик оста файдалануы, фикерләрне, күренешләрне үтә дә җете, төсләре тиз генә уңмастай сурәтләр аша бирә белүе хисләребезне тагын да үстереп, кабартып җибәрә.

Инде байтак вакытлардан бирле яшәп килүче карашым буенча, А.Хәлимнең иҗат стилендәге төп үзенчәлегенең берсе итеп, аның әдәби деталь һәм миниатюр бизәкләр белән эш итү сәләтен саныйм. Сүз әдипнең кечкенә мәсьәләдән зур нәтиҗәләргә күчү, нәни генә деталь булып тоелган әйберләргә зур, тирән мәгънәле гомумиләштерү куәтен салу осталыгы турында бара. Ә мона, дөнья әдәбиятларының олы тарихы раслаганча, тик олы сүз осталары гына ирешә ала.

Озакка сузылган хәл-вакыйгаларны бәйнә-бәйнә шәрехләп язу бу әдипнең стиленә ятрак күренеш булып тоела. Бәлки нәкъ менә шуна күрәдер дә, аның масштаблылыкка омтылышы, инде болай да зурны, нииндидер ясалма чаралар кушып, тагын да зуррак, тагын да бөегрәк итеп күрсәтергә теләве шәхсән үземне, ким дигәндә, бераз гаҗәпләндерә. Бу каләмгә һәм аның мөхтәрәм иясенә монументальлек

белән бәйле һәм тормыш океанын киң колачлап, марафоннарча озаклап инләп йөзү ысулларын тагу урынлы булыр микән? Бу «монументальлек чире» йогышлы булып, авторыбыз аны башка «бөекләрдән» йоктырган булуы да мөмкин.

Әдип иҗади байлыкны халык тормышыннан, аның да һәркайсыбызга бик таныш булган ваклыкларыннан, бигрәк тә авылда үсеп, шуннан тормыш дәрьясына ыргытылганнар яхшы белгән биографик детальләрдән ала. Ул аларны, ягъни вак булып тоелсалар да күңелләрдә нык уелып калган истәлекләрне, чын ювелирларча эшкәртә, эчтәлеккә өстәмә тәэсир-мәгънәләр сала һәм шулар ярдәмендә, шулар аша үзенең дөньяга, тормыш-яшәешкә карата төп принципиаль карашларын ачып сала. Әгәр инде бу урында олы чагыштырулар ясарга җөрьәт итсәк, әсәрләренең язылышы ягыннан гына карасак та, бу иҗатның чишмә башы Лев Толстой монументальлегеннән дә бигрәк, Антон Чехов миниатюрлыгына якынрак урнашканын аңларбыз.

Айдар Хәлим—«нәни детальләр» остасы. Ул беренче карашка хәтта артык житди тоелмаган тормыш вакларын да энҗедәй балкып торырдай тирән мәгънәле сәнгать һәм тормыш күренешенә әйләндерә белә. Кешеләр белән тиз аралашучан, яраткан укучысы белән дә уртак телне бик җиңел таба белүче бу әдип, аның иң нечкә күңел кылларына кагылып, хәйләсез-риясыз, гади, гөнаһсыз, хәтта олыгайгач та сабыйлыгыннан чыга алмыйча, беркатлырак, гел шулай ышанучан булып гомер иткән, бүтәннәрне рәнҗетми генә яши белгәннәргә эндәшә, мөрәҗәгать итә кебек. Шуна күрә аның геройлары да шул гадиләр, эчкерсезләр арасыннан. Бу дөньяда сабыйлардан да гөнаһсызрак, саф, эчкерсез затлар юклыгын һәммәбез белә. Чыннан да аларның күз яшьләреннән дә изгерәк, кадерлерәк әйбер бар микән бу дөньяда?! Айдар Хәлим хикәяләре-повестьларының байтагында төп геройлар—әнә шундый сабыйлар яисә сабыйлыктан яшүсмерлеккә чыгып килүчеләр. Тормышка сабыйлар күзе белән карау, күренешләрне яшүсмерләр хөкеме аша үлчәү, күңел бизмәннәренә салып, бәхет-хәсрәт, гаделлек-имансызлык, матурлык-сыйфатсызлык, миһербанлылык-җүнсезлек кебек күренешләрне бәяләү, шуларны күрә-күрә, дөньяны, яшәешне аңларга, бу тигезсез һәм мәрхәмәтсез дөньяда үз урыныңны, үз куанычыңны табарга тырышу—менә Айдар Хәлим әсәрләрендә еш очрый торган мотивларның кайберләре.

Бик күп әсәрләрендә икегә бүленеш—бер якта гүзәллек, сафлык, миһербанлылык, икенче якта явызлык, әшәкелек, башкаларны санга санамыйча, кирәк булганда, тегеләрнең башларына басып, югарыга ыргылучылар күренеп китә. Гомумән, бу иҗатның төп нигезен әнә шул Кеше гүзәллеге һәм аның үзенә хас матурлыгы шартларында яшәргә лаеклы булуы һәм тиешлеге тәшкил итә. Моның шактый ук вак детальләр аша чагылуы һич тә гаҗәп түгел. Әдипнең күп әсәрләрендәге фаҗигалелек, соң чиккә җиткерелгән драматизм еш кына чорның аяусыз тәртипләре, социаль гаделсезлекләргә бәйләп, кешеләрдән кайсының кем булып калуы да авылны кымәкләштерү, сугыш һәм аннан соңгы еллар шартлары яссылыгында күрсәтелә («Кылганнар чәчәк атканда», «Җырлар вакыт», «Казыктагы тальян», «Ыгдыбыгды чокыры», «Кыйбла», «Берлинга хат», «Трофей ашъяулык», «Өч аяклы ат» һ.б.).

Элек тә, бүгенге шартларда да явызлыкның еш кына өстен чыгуы, саф күңеллеләрнең, гадиләрнең бәхетсезлеккә тарулары әдипнең күңелен аеруча яралый. Әнә шундый ике бәхетсез карчык—татар карчыгы Гайния һәм сугыш чорында эвакуацияләнеп, татар авылында төпләнеп калган рус карчыгы Анна Афанасьевна бәхетсезлек кичерәләр. Сугыш вакытында Гайниянең ире, лагерьдагы ачлыктан бер тире һәм сөяккә калып, командирларының мәсхәрәләүләренә түзә атмыйча, качып авылга кайткан булган. Әлбәттә, дезертир монда озак тора алмаган: НКВД кешеләре авылдагы яман аты чыккан үләксә чокырында аны кулга алып, каядыр озатканнар. Гали янадан әйләнеп кайта алмаган, ә Гайниягә «дезертир хатыны» дигән тамга бик озакка ябышып калган. Сугыш чоры бәхетсезлекләрен тылдагыларның да бик күпләре кичергәндер, билгеле. Кешеләрнең мондый рәнҗетелүләрен хәтерләтә торган теге чокырны авылдашлары «Ыгдыбыгды чокыры» дип йөртә башлыйлар. Мәгълүм абревиатураның татарчалаштырып, шулай бозып әйтелеше һич тә күңелне иркәләми. Әмма шушы бозылыш аша геройларның һәм авторның начарлыкка, ямьсезлеккә мөнәсәбәте белдерелә. Инде күп еллар узгач, нәкъ шушы чокырда Анна Афанасьевнаның бердәнбер куанычы һәм туйдыручысы булган кәҗәсенең

бүре тарафыннан ботарлануы—шул мөнәсәбәтне көчәйтү вазифасының икенче уңышлы детале дип бәяләнә ала. Хикәяне чын хикәя итүче башка детальләр дә мулдан сибелгән: Гайниянең урыс телен чиктән тыш имгәтеп, Аннаның ике телне бергә болгатып сөйләшүләренә карамастан, гаҗәеп матур үзара аңлашулары, кәҗәнең Василиса кушаматлы булуы һәм үлем алдыннан кычкырган соңгы авазының карчыкларга «ма-ма!» дип ишетелүе—болар барысы бергә аралаштырып бирелеп, юмор белән җитдинең бергә мәгънәле кушылуы, әдипнең новелла язу осталыгы һәм әнә шулай яңа, оригиналь формада төп фикерне әйтә белүе хакында искәртә.

«Кыйбла» дигән хикәядә бер-берсен яратып, сөеп яшәгән икәү—Гарифулла белән Өммегөлсемнең бөтен тормышы укучы күз алдыннан узып китә. Аларның тормышлары җиңел булмаган, ил тормышы белән бергә яшәгәннәр, тарих сөрешендәге вакыйгаларның авырлыкларын-михнәтләрен дә ил, халык белән бергә татыганнар һәм кичергәннәр. Гадәттәгечә, җанга якын мондый сөйкемле, гади кешеләрне әллә кайлардан эзләп тормый әдип —һәрбер татар авылында андыйларны очратып була торгандыр. Гарифулла белән Өммегөлсемне замана михнәтләре гомерләре буена талкыган—аларга авылны күмәкләштерүгә кагылышлы хәсрәтләрне дә татырга, динне мәсхәрәләү, мәчет манараларын кисеп төшерүләрне, сугыш фаҗигаләрен, соңрак СССР дигән империянең таркалуын да күрергә туры килгән. Хәер, мондый хәлләр бер алар башларыннан гына узганмени?! Әдип миллионнар язмышы турында сөйли түгелме соң? Әмма ул язганнарын чын әдәби табыш, чын хикәя итәрдәй ике нокта—ике деталь таба алган: беренчесе—геройларыбызның икесенә дә гомер буе тынгылык бирми торган хәсрәт барлыгын белдерә—кайчандыр, инде теге заманнарда ук чит-ят җирләрдә боларга сабый балаларын җирләп калдырырга язган икән. Шушыннан безне автор сюжетның икенче ноктасына юнәлтә: бу Тансык атлы сабыйның рухын шат итеп, мөселманча укыйсын укып, җәсаден кыйблага каратып урнаштырылуы лаземлеген төшендерә. Менә ни өчен картларыбызга яңадан сәфәргә чыгарга, җаннарын борчыган гамәлләрне кешечә хәл итәргә тырышырга туры килгән икән. Тора-бара, Кыйбла сүзе үзенең олы мәгънәсенә якынлаштырыла: «Синең кыйбла бармы?», «Син кеше булып яши беләсеңме бу фани дөньяда?» дигән сорауларга җавап эзләүгә әверелә.

Башка әсәрләрендә дә билгеле бер конкрет штрих-билге, беренче карашка зур булмагандай тоелган деталь аша кеше рухының фаҗигале имгәтелеше («Татар вакыты»—сәгать образы), яшь кешеләрнең хыял-омтылышлары, идеаллары, мәхәббәткә карашларының тормыш кырыслыгы, башкаларның явызлыгы һәм тупаслыклары белән очрашып, тәүге җиңелүләре һәм зур авырлык белән булса да, яңадан тураерга, аякка басарга тырышулары сәнгатьчә зур осталык белән бирелгән иде («Өч аяклы ат» һәм «Казыктагы тальян»да без фаразлаган конкрет детальләр әсәрләрнең исемнәренә үк чыгарып куелган).

Айдар Хәлим әсәрләрендә фаҗигалелек күренешләре, явызлык-гаделсезлекнең, тормышның үзендәгечә, күп вакытта өстен чыгуы, тантана итүе шактый еш очрый. Явызлык, имансызлык төрледән-төрле рәвешләргә кереп, чын йөзен яшерергә, алмаштырырга, башкаларга матур һәм иманлы булып күренергә тырыша. Андыйларны автор үзенең гаять бай тормыш һәм журналистлык тәҗрибәсенә таянып, иҗатындагы сатирик байлыкны, шуның чараларын да эшкә җигеп, җиңел фаш итә. Мондый демагогларны «Авылдаш», «Сандугач белән Карлыгач», «Энгер» кебек хикәяләрдә дә күрәбез. Ә кайчагында явызлыкка әлегә мимикриягә тәрәнәсе дә юк. Үзенең турә булырак нинди башбаштаклык ясаса да җәза күрмәячәгенә нык ышанган Тараканов дигән бәндә, яшь эшчеләрнең тулай торакларын карап йөргәндә, һич гаепсез, юаш татар егетен имгәтә һәм үзенең шушы вәхшилеген яшьләрне тәрбияләү юнәлешендә дөрес алым дип саный. «Энгер» дип аталган бу хикәянең сюжетына шушы хәлләрнең ирексездән шаһите булган журналистка «бөек төзелеш»нең символик бүләге итеп бирелгән куртканы искә төшерү детале уңышлы урнаштырылган. Бу урында шулай ук киреккә-кирәкмәскә бүләк биргән булып, формаль кыланып, сугыш газапларын кичергән карт инвалидны чын-чынлап кайгыртудан мәхрүм итеп, уен ясап йөргән чиновниклар да искә төшә («Татар вакыты»).

Тормышны аңлау-аңлату юнәлешендә авторның һәр нәрсәгә җитди һәм ачык мөнәсәбәте, тотрыклы карашлары бар. Ул татар рухын, аның исламга нигезләнгән

яшәү рәвешен яклый. Тик монда төрле милләтләрне, халыкларны бер-берсенә капма-каршы кую дигән әйбернең әсәре дә юк. Төп дошманнары—явызлык, гаделсезлек, имансызлык, демагогия кебек нәрсәләр белән көрәшкәндә милләт, халык дигән төшенчәләрне читкә алып куярга кирәк. Чөнки җинаятьчелек, явызлык, әшәкелек дигән нәрсәләрнең милләте юк. А.Хәлимнең күп әсәрләрендә без татар милләтеннән булмаган яхшы кешеләргә һәм аларның автор тарафыннан сөеп язылган изге эшләренә юлыгабыз. Андыйлар безнең милләтне, аның телен, гореф-гадәтләрен хөрмәт итәләр. Ят-чит җирдә үлеп калган сабыйларының каберен эзләгәндә һәм аны мөселманча, йолаларын җиренә җиткереп, янадан җир куенына тапшырганда Никодим карт һәм аның хатыны—татарча бер аваз белмәүче рус кешеләре—Гарифулла белән Өммегөлсемнең иң кирәкле ярдәмчеләре булып чыга («Кыйбла»).

Ә шулай да шәхсән үземә Айдар Хәлимнең иң зур иҗади ачышлары балалар күнеле, балалар дөньясында сыман. Гәрчә аны тәнкыйтьчеләребезнең берсе дә саф балалар язучысы дип санамый бугай. Бәлки ул үзенең башка, тагын да җитдирәк ачышларына һәм үз кыйбласына әнә шул сабыйлар күнелендәге сафлык, чисталык аша килә торгандыр. Олыгайган көнендә без гөнаһлыларны да шул балалык чорыбызга, идеалларга кайтара, шул вакыттагы мизгел-сурәтләрне, җырларны, сөйләм-әйтемнәрне күнелебездә ничек бар, шул хәлендә яңарта белүен үзе бер иҗат могҗизасы дип санар идем. Әмма беребез дә бу истәлекләр дөньясында озак кала алмый. Нәни геройларының да олы, каршылыклы, мәрхәмәтсез дөнья белән очрашасылары һәм балачакта күнелләренә ингән иман нурларын югалтмыйча саклыйсылары, рәнҗетелгәннәрне яклап, мәйданнарга чыгасылары бар. Әнә шулар мина Айдар Хәлим прозасының әһәмиятле һәм кыйммәтле сыйфатлары булып тоела.

* * *

**Рөстәм ЗАРИПОВ:**

—Әгәр бүген илдәге золымга каршы көрәшкән каләмзатлар исемлеге төзелсә, беренче яки икенче урынга, Анна Политковская янәшәсендә, һичшиксез, Айдар Хәлим лаек дип саныйм. Илнең иң изелгән халыклары аны бары тик беренче дип санавы да мантыйкка сыячак. Ни өченме? Әйтик, А.И.Солженицын кешелек өчен канлы офыкны тудыруда Ленин-Сталин урнаштырган террорчыл режимны гына гаепләсә, ә Анна Политковская мона хәзерге чорны өлешчә өстәсә, Айдар Хәлим карашы күпкә инлерәк. Әдипнең публицистика жанрына караган «Книга печали или записки аборигена» (1991) исемле китабы империячеләрнең ялганын төбе-тамыры белән йолкып чыгарды. Гаделлек хакына искәртик, сугыш ветераны, очучы-сынаучы һәм язучыбыз мөхтәрәм Салих ага Баттал да үзгәртеп кору чорында гына басылып чыга алган памфлетында Явыз Иванны беренче большевик дип атады. Яшерен-батырын түгел, «урыс бөек», «Пушкин бөек», «рус әдәбияты бөек» дигәнне аксиома буларак сендергәнбез. Айдар ага, поляк шагыйре, милли азатлык көрәшчесе Адам Мицкевичның Пушкинга карата «патша эте» дигән бәяләмәсен искәртә һәм «Бакчасарай фонтаны» шигырендә рус даһиенең татар ханына карата гаделсезлеген күрсәтүдән башлап, дәреслекләр, китаплар, фильмнар аша дәвердән-дәвергә уздырыла килгән грандиоз гипноз тәэсиреннән безләрне айнытырга алына.

Шәхсән үзем гамәлдәге публицистикабызны шартлы рәвештә өч төргә аерам: а) нәзакәтле публицистика; б) асыл публицистика; в) әтрәк-әләм публицистика. Нәзакәтле дигәне мон, сагыш, сызланулардан тукылып, әз-мәз юмор белән эретелгән, ә кайчак җинелчә сатира белән дә терәтүле, кактырып-суктыруларга бай, сүзләрне сайлап кына, кемнең дә булса йөзен артык ертмаска тырышып, залимнар өчен унайсызланыбрак дөреслекне бәян итә. Мондыйга Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиевләр хирыс һәм маһир. Асыл дигәнендә беренчелек әлбәттә Айдар аганыкы. Ул ялгыз түгел, Фәүзия Бәйрәмова, Фәндәс Сафиуллин, Зөлфия Кадир, Локман Закиров, Адлер Тимергалин, Фәнзаман Батталларның аткан уклары да унга тиерешле. Әтрәк-әләм публицистика исә теләсә кайсы дәрәҗәдәге эш башында торучыларны данлау, аларга мәдхия уку, һәр «җил чыгаруларына» ярхәмикалла дип тору, һәм шуларга төреп хакимиятне артык ачуландырмый торганрак «гади халыкны яклауга корылышлы», үзен ишетмәячәк, татар телендә күтәрелеп бәрелүне игътибарга

алмаячак затларга чамадан әллә ни чыкмый кизәнешле сафсаталар уздыруны да эченә ала. Бу юнәлештә казганучыларның күпчелеге хакимият каршында алтылы чыбык булып бөтәрләнү, төчеләнү, тәлинкә тоту, караны ак, акны кара дип исбатлау, өреп ялган абруй кабартуда ярышса, мәкерлерәкләр, «олы абзый аны белмәгән, ярдәмчеләре «минауат» дип, үзенә зарар китерә алмастай, иҗтимагый баскычта түбәндәрәк урында торучы кемсәләргә каршы үтә батыр кыяфәт ясап күтәрелеп бәрелә, бер стакан суда тайфун чыгарулары белән халык һәм хаклык өчен көрәшүче дәрәҗәсенә дәгъва итә. Әтрәк-әләм публицистлар, югары даирәләрнең кемгә дә булса кырын карашын тою белән, кушканны көтеп тә тормый, шул затка ябырылырга һәвәс. Мина калса, санап кителгән һәр төрнен яшәешебезгә үз объектив чакырылышы бар.

Әгәр рәсми даирә хадимнәре Айдар Хәлим язганнарның гадел икәнен баштан ук танып кабул иткән булса, һич югы татар фаҗигасенең чишмә башы булган Явыз Иван форпостын торгызуга керешелмәс, Татарстанда миллион баш дуңгыз үрчетү турында программа кабул ителмәс, Кол Шәриф мәчете хозурында, бушлай сыра эчеп күбенешкән туташларны трусиклары төшкән хәлдә тезеп, «Золотая попа» конкурсы уздырылмас, рок-поп концертлар яу кырында шәһит киткән каһарман бабайларыбызның рухларын рәнҗетмәс, татарны эт дип атаучы шагыйрьгә һәйкәл салынмас, ә чүплек башында булса да Сара апабыз Садыйковага торгызыла башлаган һәйкәл азагына җиткерелер, шулай ук зыялылыгы, кешелеклелеге, таланты ачыкланган кадрлардан һәр өлкәне арчу-тазарту бармас иде.

Айдар ага иҗатында шаккатырган нәрсә, аның сүз кадерен белүе, теле камиллеге, образларның үтемлелеге, тирән эрудициясе генә түгел. Мине һәр язганының ифрат дәрәҗәдә камиллеге, оригинальлеге, үлчәмнәрнең төгәллеге, һәр деталь-элементның урынлы сайлануы һәм оясында булуы сокландыра. Бу хакта аерым тукталуның сәбәбе шул, кайбер «язучыларымызның» роман, бәян, поэма, публицистика исеме астында калыплаган эшләнмәләрен техник белемле кеше укыса, «Бәй, биредә өстән яки яннан караш кына, ә кайда фундамент» дигән нәтиҗәгә килә дип беләм. Һәрхәлдә үзем бәгъзе авторларның әсәрләрен бары тик кәлҗемә дип кенә кабул итүдән гаҗизмен. Әдәбият табынына чүп-чар куелуы, әдәби тәнкыйтьнең үзгәртеп кору чорында «үзгәртеп корылуы» нәтиҗәсе.

«Явызлык империясе»нең калканы—ялган бастионы—барча фортификация нечкәлекләрен исәпкә алып төзелгән булуы сәбәпле, аны чәлпәрәмә китерү ифрат катлаулы мәсьәлә. Грек мифологиясендә Горгона атлы гыйфрит-медузаны тораташ итү чарасы—аны үз-үзенә күрсәтү. Россия империясе өчен дә бу үтемле, исәндергеч, билгеле бер арага параличлау күәсенә ия чара. Рус шовинист-милләтчеләре патша Россиясенең җимерелүе өчен үзенең бөек язучыларына да рәнҗи. Хакыйкатьтән карыш та тайпылуны белмәүче чорыбызның бөек рус әдибе Виктор Астафьевны да шуңа өнәп бетерми андыйлар. Айдар аганың әлеге бастионны дер селкеткән икенче китабы «Убить империю» (1997) дип атала. Бу китап дөньяга чыксын өчен утлар-сулар кичәргә, талашырга, сугышырга, йөз суы түгәргә, ишетмәгәннәрне ишетергә дә туры килүен «Веселая книга»сында (1998) китерелгән рәсми документлар, хатлар, мәкаләләр сөйли. Ядрәләр атып торган амбразурага капланып шәһит китәргә дә әзер булуы гына йөрәк каны белән язган китапның дөнья күрүенә һәм укучысы белән очрашу бәхетенә ирештерә. «Этот непобедимый чеченец» (1996) китабында Айдар ага чечен халкы тарган бәланең җинаятьчел асылын, исем-фамилияләрне атап, энәсеннән җебенәчә ачыклый. «Современный смешанный брак или кольцо безответственности» (2005) дигән хезмәтендә милләтне астан кимерүче катнаш никахның шовинистлар тарафыннан «мәхәббәт» ышыгында кулланылган үтемле корал икәнен һәм, бер як өстенлеге шартларында гамәлгә керүеннән чыгып, аның әхлаксызлыгын дәлилли.

Мин Айдар Хәлимнән цитата китерергә базмыйм, чөнки мөкаммәл дәрәҗәдә органик бөтенлектәге төп контексттан тартып алынган теләсә кайсы өлеш язучы фикерен бозарга, хилафлык китерергә мөмкин. Бөтен килеш уку фарыз ул язганнарны. Бер сулышта... Карашымча, аның китаплары Татарстанда гына түгел, Россия, СНГ илләрендәге мәктәпләрдә һәм вузларда җентекләп өйрәнелүгә лаек. Ни аяныч, Татарстанның китапханәләрендә томнары тезелеп тормый. Зарурсызларның томнары бихисап, аларны ачып караучы да юк, ә менә А.Хәлим китаплары күренми,

чыкмаганнар. Маңкортлашу чиренә прививка буларак һәр милләттәш өчен алар әҗәл даруы сыман, ләбаса. «Өлкән туган» милләтеннән булганнарга шовинизм кәсафәтен кисәтү өчен дә агабызның иҗаты кулай булуына шик юк.

Айдар Хәлимне публицист буларак олылавым, аның башка жанрлардагы осталыгын танымау булып аңлашылмасын. Чын язучы гомер буе бер китап яза диләр. Аның публицистикасы, шигърияте, прозасы бер үк идеалга, милләтне үлемнән аралауга укталышлы. «Без—исән!»—штурвалын ул тоткан иҗат карабы әләмендәге девиз-шигарь бу!

«Татар балалар шигърияте һәм орчык-малай Биктырыш» (2010) китабына килсәк, биредә әдибебез әлеге өлкәдә бәгъзе «бөек» шагыйрьләребезнен милләткә Иван Сусанин хезмәтендә булуларын ачып салу белән беррәттән, әдәбият дәреслекләре әзерләүче галим-галимәләрнең талымсызлыкларын гына түгел, ә акыл һәм мантыйк белән бик үк дус булмауларын да ачыклаган. Бу теманы ул «Казан утлары»нда «Сез беләмсез кая барганны?» дигән мәкаләсендә дә күтәргән һәм аның белән бу җәһәттән бәхәскә керүче ул чакта табылмаган иде. Монда, дөрес сүзгә җавап юк, дигән халык җәүһәрен искә төшереп, сагышлы елмаеп куюдан гайре чара калмый.

Әдип компромиссыз, максималист кеше, берәүнең дә нәни генә хатасын да уздырып җибәрми, уйлаганын йөзенә бәреп, кистереп әйтә. Тик танымый булмый, иң әүвәл үз-үзенә таләпчән. Ул хәтта, башкалар булмаганда үз-үзе белән якага-яка килми микән? Кичәге «мин»е хаталанса, бүгенге «мин»е кичәгесен аямыйдыр дип чамалыйм.

Аның иҗатында бер генә дә буш сүз, кемгәдер ошарга тырышу, төчеләнү тапмассыз. Айдар аганың әсәрләрендә берсеннән-берсе тәҗел фикерләр таслаптыгызлап урнаштырыла, әйтерсең, бүген әйтмәсәм иртәгә соң булыр дип шөлли һәм форсаттан тулаем файдаланып калырга ашыга. Әсәр калыплаучылар өчен ул һәрчак уяу иҗатчы, еш кына «авыртмаган башка тимер тарак» булып тора. Лилипутларның уяу Гулливерга көче һичкайчан җитмәячәк, ә күрмәскә, танымаска азапланулары көлке генә.

Милли бәйрәмебез—Сабан туен шөкәтсезләү ысуллары байтак: бөтен кеше белгән телдә алып бару; чучка итеннән шашлык куырып бәйрәм һавасын сасыту; милли җырлар урынына «татар җыры» дип исемләнгән чүп-чар эшләнмәләрне җир акыртып әйләндерү һ.б. Әмма иң ямьсезләгәне—батырның алдан ук билгеләнүе. Тагын да шөкәтсез итә торган нәрсә, баш батыр итеп адәм күтәрә алмаслык авырлык җыеп, чучканы хәтерләтүче, «сумо» ярышы өчен генә тәс һәм анда хурга калуы бәхәссез кешене батыр калдыру. Мондый белән сөлге тотып көрәшү җинелрәк көрәшчене алдан ук икеләтә тигезсез хәлгә куя. Язучылар арасындагы бәйге дә гадел булсын өчен нидер хәл итәргә кирәк. Газета-журнал редакцияләрендә эшләүчеләрнең, Язучылар берлеге идарәсе әгъзаларының теге яисә бу бүләккә лаек дип тапкан әсәрләрен башка язучыларныкы белән янәшә Интернетка элүне кулай дип саныйм. Галимҗан Гыйльманов һәр язучы үз блогын булдырсын дигән тәкъдим белән матбугатта да чыккан иде. Кыскасы, гаделлеккә ирешү юллары юк түгел кебек үзе. Әмма бу тараф белән китсәк, бөек саналучы бәгъзеләребез иҗатының гомумән зарурсызлыгы фаш булып куймагае.

Язманы, Рәсүл Гамзатовның «Минем Дагыстаным» китабындагы бер хикәятен чак кына үзгәртеп, болай тәмамларга рөхсәт итегез: байлык турында хыялланган каләмзатлар байлыкка тиенә, дан дип талпынганнары анысына ирешә, ә хакыйкать эзләгәннәренең гомерләре юлда уза! Ак юллар сина, мөхтәрәм Әдип...

# «БӨЕК МӘГЪНӘ ЭЗЛИ ЮКСА ШАГЫЙРЬ»

Әдәбият тарихы турында сүз алып барганда, илленче, алтмышынчы елгылар, дип сөйләү гадәткә кергән. Каләм осталары мәйданына унмы, егермеме ел саен төркем-төркем аяк басканнарның, бәхәссез ки, шигърияткә яисә прозагамы алып килгән үзенчәлеге булмый калмый, әмма ул барлык иҗатларда да ярылып ятмый. Кайвакыт теге яки бу шагыйрь турында, нәрсәсе белән сезгә якын, сөйләгез әле, дисәләр, гомерен буе югары уку йортында әдәбият белән бәйле фәннәр укыта торып та, сүзсез каласың. Андый чакта, язганнарында яраттырырлык нинди сыйфат бар әле соң, дип уйланасың, һәм күпчелек очракта, кызганыч ки, тапмыйсың. Мин моны хәтта кайбер халык язучылары, Тукай бүләге ияләренә карата да әйтә алам. Язучылар исемлегендә, үзем тарафыннан дистәләгән әсәрләре укылып та, унай бәя бирүе кыен булган прозаик яисә шагыйрьләр шактый. Ни хакында язган, ничек язган—истә дә калмаган була. Ә бит, исемнәре бары тик норматив тәнкыйтьнең әйләнешенә, әдәбият тирәсендәге түрәләрнең дуслары исемлегенә кергәннән чыгып кына, чыннан да, яхшы



язадыр, дип, аерым берләренең иҗатына мәдхияләр яудыручы тәнкыйтьчеләр һәм галимнәр бар. Әдәбияты нинди—тәнкыйтьче дә шундый, һәм киресенчә.

Сиксәненче елгыларның әйдәман шагыйрьләреннән булып, затлы сүз мәйданына атылган Ркаил Зәйдулла иҗаты исә алган бүләкләренә карата беркем күңелендә дә шик тойгысы уятмавына иманым камил. Ркаил—замандашым, еш кына фикердәшем. Ихлас һәм нечкә халәтендә җанга бик якынаеп та киткән шикелле. Тупасрак тотышы, дорфарак сүзе белән үпкәләткән чаклары юк түгел, хәтта ул вакытта да аңа карата якынлык хисләрен күңелдән сызып ата алмыйм. Еллар узса да, авылча калган, үзенчә калган, үзенчә язган һәм язганын да үзенчә укыган кеше Ркаил.

Кайбер кирәгеннән дә артыграк күкләргә чөелгән бер төркем яшьләребезнең уртак рухта, уртак темаларга шактый охшаш стильдә иҗат ителгән сумбур әсәрләрен игезәк интонация белән укыганнарын ишеткәндә яшьтәшләремне уйлыйм. Газинур, Ләбиб, Ркаил... Бер арбага җиксәң дә, бер тарафка омтылсалар да, өчесе өч төрле чапкан атлар кебек алар.

Иҗат кичәләре еш кына төрле буын шагыйрьләрен сәхнәдә очраштыра. Макташып, мактангалашып та алгалыйлар. Сүз шигырьгә житкәч, барысы да урынына утыра—чүбе кибәктән аерыла. Сәхнәне кайчандыр Мөдәррис Әгъләмнең, Рәдиф Гаташның, Зөлфәтнең көр тавышы тота иде, ә хәзер—безнекеләрнеке.

Бәйрәм тантанасы. Өлкәннәр, урта буыннар, әле генә әдәбият мәйданына атлаганнар—халык алдына имтихан бирергә чыгып баскан бер сурәттә. Сүз яшьләргә бирелә. Кызы да, егете дә, аңлаешсыз җирлектә туган образлар белән чуарланган әсәрләрен, үчле кысылган тешләреннән, күтәртеп куелган тамак төбеннән сытып, имгәтеп чыгарып, кайдадыр еракка, томанлы офыкларга карап, уртак бер янгырашка китерелгән тавыш белән укый. Алардан соң сүзне безнең буын ала. Тартылган җәя кебек көтәм. Ул да түгел, Ркаилнең ирләрчә нык, диварларны тетрәткән тавышы, киемнәрне ертырдай булып, туп-туры күкрәккә ыргыла. Сәхнәдән укыганнары артык катлаулы да түгел кебек юкса... Янгырашы, фикере беркемне битараф калдырмый. Зал көчле алкышларга күмелә.

Замандашлары белән шагыйрь үзе дә горурлана. Буындашларына, дусларына багышлаулар аның иҗатында зур урын алып тора. Алар—гадәти юбилей котлаулары да, мактау чабуына тотынып, авторы да югары күтәрелү өчен махсус сайланган адресатлы әсәрләр дә түгел. Боларда—безнең яшьлек сәхифәләре янгырашы...

Аларда—милли гамь, ир гаме..., шагыйрьгә кадерле предметлар, жан ияләре, хыяллар..., үкенеч, өзгәләнү, гасабилык...

*Без сабыйлар шленнән бит, дустым!*
*Иртә киткән ишләр өчен дә*
*Йончу атлар тәсле ауныйк әле*
*Җиләк үскән карлар өстендә.*
(«Ләбибкә»)

Ркаил үз зәвыгы таләп иткән югарылыкта яза, публика зәвыгына, милләт ихтыяжына туры китереп укый. Анда залны тою гадәттән тыш көчле. Күренеп тора, ул шигырьне шигырь итүче төп сыйфатның һич тә гасырлар буе килгән символлар түгел икәнлеген белә. Әлбәттә, гомумән алганда, аларсыз шигърият юк. Ә бит кайвакыт гап-гади генә сүз дә, җөмлә дә бихисап поэтик янгырашлы булырга мөмкин. Мин Ркаилне шул тоемы өчен аеруча яратам.

Берәү, бәлки, һичкем аңламастай, реаль жирлеге булмаган әллә нинди образлар тудырадыр, икенчесе, форма сазлыгына батып, фикер йөгәнен кулдан тәмам ычкындырырга мөмкин... Ркаил андый әсәрләрнең халыкка эстетик ләззәт тә, акыл тәҗрибәсе дә бирмәвен яхшы аңлый. Аның иң гади әсәрләре дә шигъри камил, жанны тартып, тыңлаган саен тыңлыйсыны китереп тора. Ул—чын мәгънәсендә халык шагыйре, халыкчан шагыйрь.

Ркаил Зәйдулла иҗатын гомуми күзәткәндә, гадилеккә, аңлаешлылыкка, янгыраш камиллегенә омтылып, һич тә примитив язучы түгел икәнлеге күренә. Аның һәр катламга якын булырлык әсәрләре җитәрлек. Кайбер шигырьләреннән чыгып карасаң, Ркаил—үтә элитар иҗатчы да. Тарихи мәгълүматка нигезләнеп, укучы акылын эшкә җигеп язган әсәрләрен укыганда, интеллектуаль поэзия остасы икәнлеге дә ачыла. Мәшһүр шәхесләрнең образын тудырган әсәрләрен дә традицион мәдех жанрында язмый ул. Татар шагыйрьләренең эшафоттагы соңгы минутларын тасвирлаган әсәрдән бер өзек:

*Кояш кына менә ярсыта бик...*
*Дивар ышыгына сыенып,*
*Ул аны да өзеп алыр иде!*
*Тик*
*кояшның*
*юк шул*
*муены...*
(Җәлил кояшы)

Ркаил Зәйдулла китапларын кулга алгач, укудан туеп, бер кырыйга атмыйсың; башка бер эшең чыкса да, тагын укырмын әле, дип, битен билгеләп, якынгарак алып куясың. Туйдырмый, чөнки образлар, фикерләр дингезе тирән. Туйдырмый, чөнки формалар, алымнар дөньясы бай. Тукайлар, Туфаннар иҗатына хас төрлелек күзәтелә аның китапларында. Әйе, Ркаил үз-үзен артык күп кабатламавы, шигырьдән шигырьгә янача ачылуы белән кызык. Шул ук вакытта аның әсәрләрен бай әдәбиятыбыз мисаллары белән дә бутамыйсың.

Ркаил Зәйдулла иҗаты—йодрыклы иҗат. Борынгылар хак әйткән: хакимияткә оппозициядә тормаган, тарихыннан, милләт язмышыннан канәгать шагыйрь—шагыйрь түгел. Көрәшнең мәгънәви кырын билгеләүче троплар аның әсәрләрендә зур бер катлам тәшкил итә. Шул ук вакытта яшен ташы, бөркет, ук-сөңге образларын ул, билгеле ки, милли көрәш әсәрләренә генә уздырмый. Әдәби образ-детальләрнең кулланыш мәйданын котелмәгәнчә күчерү, кинәйтү, сүзләргә яңа мәгънә мөмкинлекләре бирү аның язганнарын бик күпләрнекеннән аерып куя да. Марсель Галигә аталган бер шигырендә шагыйрь болай дип яза:

*Күкрәү килә. Эчеңдәге кинә*
*Яшен ташы булып бер чыксын,*

*Кузгатсын ул гомер көзләрендә*
*Сүнгән өметләрнең җырчысын.*

Ркаил Зәйдулла иҗатында фәлсәфи лирика үрнәкләре дә тулы бер цикл тәшкил итә. Уйланып һәм хөкем итеп язу, өздереп әйтерлек нәтиҗәләргә килү хас аңа. Шул уйлануларны гади фикер сөреше рәвешендә генә тудырмыйча, тезелеп килгән, үзгәрешләрне һәм уйлау логикасын аңлатырлык әдәби детальләр чылбыры сыйфатында укучыга ирештерү—Ркаил Зәйдулланың яраткан алымы:

*Көзнең бозлы җиле исте:*
*һавадагы пәрәвезләр*
*әкрен генә йөзгә күчте.*

*«Үзгәрде әшъялар төсе...»–*
*салкын йолдызлардай күчте*
*төнге учакларның исе.*

*Селтәп атты аргамагым:*
*акбүз әләм сулышыдай*
*дерелдәде бармакларым.*

*Кирәк микән кулны изәү?–*
*тибеп ята кар астында*
*ялгыз кизләү...*

(«Кизләү»)

«Бөек мәгънә эзли юкса шагыйрь»,– дип яза Ркаил, һәр иҗатчының гамь белән яшәвенә ишарәләп. Зәйдулланы борчымаган проблема бар микән?! Шулай да араларында әле аталмаганнарыннан рухи бөеклек турында уйлануларын телгә аласы килә. Бөеклек һәм биеклек турындагы әсәрләрнең күпчелеге –билгеле ки, һавалы гадиләрдән дә битәр, хакимияткә ирешкәннәр колагына. Бик тә оригинальләре, төрле ассоциацияләргә корылганнары да җитәрлек:

*Кузгала тау...*
*Һәм таш оча алдан –*
*Ул ләззәт таба үзенә ыртүдән.*
*Дустым, кеше!*
*Син үзеннән карап*
*Акыл сатма, тукта...*
*Кайчагында түбән тәгәрәү дә*
*Бөеклеккә илтә дөньялыкта.*

(«Таш турында риваять»)

Ркаил Зәйдулла—кем әйтмешли, коеп куйган шагыйрь генә түгел, бай һәм киң тасвир дөньясы тудырган прозаик һәм инде берничә әсәре белән халык күңеленә узган драматург та. Шулай да аның иҗатында шигърият һәрвакыт беренче урында торды, ул аның башка төрдәге әсәрләренә җан сулышы өрде. Тормышта шагыйрьләрнең проза әсәре, ә прозаикларның шигъри әсәр язу очраклары да байтак, әмма эш шунда: монда шагыйрьләр ота, прозаиклар оттыра.

Р.Зәйдулла шигырьләре гомумәдәбият җирлегендә ничек мәрҗән кебек ялтырап ятса, прозасы да гомуми агым өстеннәнрәк ага. Шул ук вакытта аның иҗатында тезмә һәм чәчмә текст каршылыгы ап-ачык чагылыш тапты. Ркаил, бер яктан, шигъри иҗек биеклегенә, яңгырашның сафлыгына иреште, икенче яктан, прозасы аша шигырьдә бөтен мәгънә тирәнлеге белән әйтеп бетерә алмаганын, урын тапмаганын күздә тоткан укучысына җиткерде.

**Рифә РАХМАН**

**Редакциядән:**

*2010 елның 23 гыйнварында Татарстанның Г.Тукай һәм М.Җәлил исемендәге премияләр лауреаты Ркаил Зәйдуллага 50 яшь тула. Каләмдәшебезне юбилее белән котлыйбыз, сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез.*

# КАЙДАН АЛА АЛАР БУ КӨЧНЕ?!

*«Казан утлары»н үзем алдырып укый башлавыма быел 45 ел тула. Беренче тапкыр журналда шигырьләрем дөнья күргән ел иде ул. Рәхмәт төшкере!—шуннан бирле даими басылып киләм. Тик үземнен уй-фикерләремне белдереп редакция почтасына махсус хат язарга туры килгәне булмады. Унынчы сан кулга килеп кергәч, «ниһаять форсаты чыкты!» дип уйлап куйдым да, шушы хатны язарга утырдым.*

*Журналның һәр яңа санындагы шигырьләрне укудан башлап җибәрү гадәтемә сеңгән иде. Фәнис Яруллинның көндәлекләре бу традицияне бозды: тәүләп аңа тотынам (әгәр хатын миннән дә өлгеррәк булып чыкмаса) һәм киләсен көтеп алам.*

Мин татар әдәбиятында үзенең лаеклы урынын тапкан, зур исем-дәрәҗәләргә ирешкән каһарман әдипнең тулаем иҗатына нинди дә бер бәһа бирергә җыенмыйм, ул минем бәягә мохтаҗ да түгелдер, ул еллар сынавын (нинди бәхет!—үзе исән чагында) үткән һәм аңа бик күпләр бик күптәннән бәһане биргәннәр инде.

Кулга каләм алырга сез үзегез мәҗбүр иттегез: «Бу көндәлек язмалары сезгә ошыймы? Аны укыганда нинди хисләр кичерәсез?» дип сорыйсыз соңгы санда. «Ә нигә әле редакциядә шундый сораулар туган?»—дигән сорау куям мин дә сезгә үз чиратымда. Җил исми яфрак селкенми дигәндәй, шик-шөбһә дә уянды күңелдә: әллә, мәйтәм, «нигә бу әйберне бирәсез?», «нигә аны озынга сузасыз?», «нигә ул әледән-әле исемле кешеләрнең «бакчасына» (башына) таш ыргыта да тора?» кебек сүзләр килеп ирешә башлаганмы редакциягә? Хактыр, юктан гына тумады бу шик-шөбһәм. Чөнки дә алдагыларында көндәлектә тулы исемнәре белән аталып килгән кешеләрнең (күпчелектә авторның каләмдәшләре) инициаллар белән генә күрсәтелүе күңелдә ризасызлык тудыра башлады. Әйтик, «баш редактор Р.Х., гомумән, көлә белә микән?», «Өченче көн М. килеп китте... Романын «Казан утлары»нда чиратсыз кертмәгәннәр»е өчен Туфанга бик ачуы килгән». Арытабан да шулай дәвам ителсә, көндәлекләрнең укымлылыгы тәэсир көче кимемәсме, дигән уй да уяна күңелдә. Көндәлекләрен матбугатка әзерләгәндә пәһлеван йөрәкле Фәнис Яруллин бүгенге көндә Олимп тавы үрендә аяк бөкләп утырган «әдәбият Аллалары»на кечтеки генә сүз тидерергә дә курка башлаган дигән фикерне башыма да кертәсем килми.

Әйе, турысын ярып әйткәндә, Казан—«бөекләр» каласы ул. Анда бик азга гына барсаң да, боларның кайсысы кайсысыннан «бөегрәк», кайсысы кайсысыннан «биегрәк» икәнлеген аера алмыйча аптыраште калып та торасың. Мин яшәгән төбәкләрдән Казаннар күренмәсә дә, «шигъри шәмем» шунда кабынганга, рухым белән гомер бакый Казанга табынып, андагы сулышны белеп-тоеп яшәгәнгә, үземнең дә күпмедер кимәлдә катнашым булган татар әдәби хәрәкәтенә битараф кала алмаганым өчен язам бу күңелсезрәк юлларымны. Кичерерсез, читкәрәк тайпылып киттем, минем дә хәтер төпләремдә күмерләр көйреп яткангадыр, күрәсең...

Ә көндәлекләр татар әдәбиятында зур вакыйга булып саналырга хаклы. Көндәлек бит ул истәлек түгел. Матур сүз «кәгазьләренә» төрелмәгән, әдәби бизәкләргә буялмаган чеп-чи чынбарлык чагыла анда. Кешене кичә-бүген ниләр борчыганы, ниләр йөрәген кайнатканы, бергә кайнашкан дус-ишләрнең, каләмдәшләреннең сиңа мөнәсәбәте турында күңелеңдә туган уй-хисләр суынмаган килештән теркәлә бара. Шәхси хис-фикер чагылышы дип тамгаласаң да, шәрә хакыйкать өстенлек ала. Ә хакыйкать, Фәнис Яруллин язмышында аеруча, беркайчан да татлы булмый, ул әрем кебек—кабу белән йөзең сытылырдай ачы була. Әгәр автор хәл-вакыйгаларга, кешеләрнең аның үзенә, башкаларга мөнәсәбәтендә аларның холык-фигыльләренә, тышкы һәм эчке сыйфатларына шул көндә, шул кич-иртәсендә туган кичерешләрен күңел бизмәненә салып, хак бәяне язып куя икән (бу тәңгәлдә безнең уртаклыклар да байтак), безгә дә аны ничек бар шулай кабул итәргә кала. Бернинди үпкәләшсез, бернинди аңлатмасыз. Бу көндәлекләр—тормыш үзе язган, кирәдән төзәтмә кертергә мөмкин булмаган документлар. Алар шуның белән кыйммәтле, алар шуның белән

көчле һәм тәэсирле. «Ошыймы?» дигәнегезгә минем җавабым шул.

Ә икенчесе: «нинди хисләр кичерәм»ме?—горурлык хисе кичерәм. Татар хатын-кызларының асылдан-асыл вәкиле, көндәлекләрнең төп героинясы Нурсөя белән горурланам. Исеме җисеменә туры килсә килер икән: бөтен җаны-тәне, фәрештәләр затыннан яралган шикелле, нурдан-яктылыктан гына тукылган, күрәсең. Теркәлгән көннәрнең һәрберсендә диярлек без шушы якты исемгә тап булабыз: «Кичә Нурсөя елап кайтып керде», «Нурсөя бүген... гел авыртынып йөри», «Нурсөя... мина килгән вак-төяк уңышсызлык өчен үземнән дә ныграк борчыла». «Нурсөя больницага киткәннән бирле өйләр суык. Бөтен җылыны алып китте», «Аның чирләве минем үземнең чирләвемнән дә яманрак» һ.б. Сез ничектер, ә мин менә шушындый җан авазларына юлыккан саен тетрәнеш кичерәм, йөрәгем чымырдап-чымырдап китә. Әйтерсең, ул бүген генә язылган, әйтерсең, ул бездән нинди дер ярдәмне бүген көтә. Әлбәттә, Фәнис белән Нурсөя кичергәннәрнең меңнән берен дә кичермәгән бәндә балаларына бу җан авазлары гади-гадәти хәл сыман күренер, юк-бар өчен борчылып яту дип тә кабул ителер. Аңлап та була: кешенеке—кештәктә; кеше хәлен кеше белмәс, үз башына төшмәсә—юктан гына тумагандыр мондый мәкальләр. Шушы урында бөек Некрасов юллары хәтергә кунаклый: «Есть женщины в русских селениях... Коня на скаку остановит, В горящую избу войдет». 150 ел тулып килә боларның беренче тапкыр яңгыравына. Көндәлекләрне укыганда Нурсөяне күз алдыма бастырам да, «русских» дигәнен «татар»га һичнинди ташлама ясамыйча алыштырырга була дип уйлап куям. Ләкин беркем белән дә чагыштыра алмыйм. Таба алмыйм андый прототипны—әдәбиятта да, тормышта да. Бигрәк тә бүгенге заманда табам димә. Менә бер мисал. Минем «фазенда»га күршерәк урта яшьләрдәге бер ханымнан авыр операция кичергән иренең хәлен сорашып торам бер көнне:

Җавап: «Аягына басып, бакчага йөри башласа, тернәкләнеп китәр әле. Ятакка гына калмасын инде берүк,—димен аның төшенке сүзләренә өмет чаткылары сибәргә тырышып.

—Ятакка калса мин шул... (бу урында мин аның сүзен атауны килештермим) карап ятаммы! Аллам сакласын. Квартирны бүләм дә чыгам да китәм. Җир җимертеп, любой ирне каратып йөрер чагым әле минем...»

Һәм мин Нурсөянең бернигә дә биргесез иң күркәм, энҗе-мәрҗәннәрдән дә зиннәтле сыйфатын билгеләргә җөрьәт итәм: ул—фидакарьлек! Аның бу сыйфаты безнең барча-барча татар хатын-кызларыбызга, яшенә дә, картына да, илаһи үрнәк. Ул үзенең бөтен гомерен язучы Фәнис Яруллинга багышлаган сынмас-сыгылмас хатын гына түгел, ә татар әдәбиятын кабатланмас яңа исем белән баетуга бәһаләп бетергесез өлешен керткән көрәшчене гәүдәләндергән героик образ булып та күзаллана. «Нурсөя ныклап чирләп китсә мин нишләргә тиеш инде? Алла белсен»—бу юлларның тирән мәгънәсенә тагын бер кат урап кайтыгыз. Әйтүчеләр дә табылуы ихтимал: ирне карау геройлыкка керәмени соң?! Әйе, бөтендөнья юксылларын яклап көрәшү җинелрәктер дә әле янында торганны, күршеңдә яшәгәнне яклап аяусыз көрәшкә ташлануга караганда....

Көндәлекләрнең икенче кыйммәте, бәлки дә беренчел кыйммәтедер, әнә шул безнең күз алдыбызда яшәгән горур сынлы, чирләргә дә вакыты калмаган мең мәшәкатьле Нурсөя образы. Тере образ. Аның белән горурлану хисе йогышлы булсын иде. Язучыларның хезмәтен хөрмәтләгәндә аларның тән һәм җан сагында торган Нурсөя кебек фидакарь затларны да, их, олыларга, кадерләргә онытмасак иде!

Хат азагында, Фәнискә сәламәтлек телим дисәм, ничектер килешсез яңгырар кебек, ә менә Нурсөягә түземлек-сабырлыкны, сызланусыз яшәвен Ходайдан ялварып сорыйм!

**P.S.** Журналда озак еллар баш мөхәррир вазифасын башкарганда сүз ирегең гамәлгә куйган, әдипләрнең һәм журнал укучыларның шәхси фикер төрлелегенә юл ачкан Равил Фәйзуллинны дәвам ителәчәк көндәлекләрдә, исеме кайсы яктан гына телгә алынса да, автор да, редакциядәгеләр дә Р.Ф.га әйләндермәсләр, һәм дә, мөмкинлек табып, «...утлы күмер»не һәр сан саен чеметем-чеметем генә түгел, тулырак-күләмлерәк итеп бирсәгез, укучыларыбызга тагын да бер куаныч китерер идегез дигән ышанычта калам.

**Рим ИДИЯТУЛЛИН.**
*Уфа.*

# БЕРГӘЛӘП ГӘЗИТ ЧЫГАРДЫК

Мин—Баулы районының Кызылъяр авылыннан, ягъни Фәнис Яруллинның авылдашы, замандашы, гомер буе аралашып яшибез. Кызылъярда яки Казанга барсам әле дә күрешкәләп торабыз.

Бу көндәлекләр аны якыннан белгән кешеләргә дә бик кирәк. Чөнки без әллә нигә бер 2-3 сәгать күрешеп-сөйләшеп, Нурсөянең тәмле чәйләрен эчеп таралышабыз да, аларның калган тормышларын бик томанлы гына күз алдына китерәбез. Ә бу көндәлекләр аларга карата олы ихтирам, соклану хисләрен бермә-бер арттыра, без яратып укый торган шигырьләрнең һәм башка әсәрләрнең нинди бәягә тууын белү—безгә үзебезнең тормышның вак-төяк мәшәкатьләреннән зарлану оят икәнен кисәтә. Болар бигрәк тә хәзерге яшь буын өчен мөһим: яшәүнең мәгънәсе, башына авырлык килгәндә дә «тормыштан суынмаска» (Фәниснең шигыреннән) өндәү—болар бит бәяләп бетергесез кыйммәтләр. Менә бит Фәнис Яруллинның һәрбер әсәре нинди тән-җан-күңел газаплары-авыртулары аша туа икән! Нинди ихтыяр көче һәм рух ныклыгы салынган икән 53 ел урынга кадакланган гәүдәгә!

Минем шундый тәкъдимем бар: «Казан утлары»нда басылган көндәлекләр буенча әңгәмәләр, җыелышып кычкырып укулар үткәрергә, әдәби түгәрәкләрнең Фәнискә багышланган утырышларында шулардан өзекләр укырга кирәк.

Өстәп шуны да язып китим әле. Фәнистә иҗат очкыннары Кызылъяр мәктәбендә укыганда ук сизелә иде. Фәнис миннән бер ел алда укыды. Ул VII класста, мин VIда чакта без мәктәп стена газетасының редколлегиясендә идек: ул—редактор, мин—секретарь (кулдан язучы), Сәхибгәрәев Фаиз—художник. Газетага кайбер сатирик мәкаләләрне Фәнис шигырь формасында бирә иде. Кайберәүләрнең «ул урын өстенә калгач кына яза башлаган» дигән сүзе һич дөрес түгел. Мин, Кызылъяр мәктәбендә 38 ел укыткан кеше буларак, быел сентябрь аенда Яруллиннарның авылга кайтып, клубта авылдашлар белән үткәргән очрашу кичәсендә дә бу турыда сөйләдем. Без бик хуплыйбыз: былтыр авылда ана мәһабәт өй салып бирделәр, кайткан чакта анда яшәргә бөтен шартлар да тудырылган.

Хәзер ул йорт музей статусын алды. Музей мөдире, ветеран татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мәдинә Гыйлаҗева Яруллин иҗатын һәм тормыш батырлыгын пропагандалау буенча тынгы белмичә эшли. Тирә-як авыллардан, районнардан музейга экскурсиягә киләләр. Төрле район семинарлары делегатлары да килә монда.

Бу болгавыр заманда кыйбласын җуйган бәндәләргә туры юл күрсәтүче маяк алар авылыбыз горурлыгы булган Фәнис Яруллин һәм аның тугры тормыш юлдашы Нурсөя ханым!

**Галимә ГАЛИМУЛЛИНА.**

*2011 елның 12 октябре.*

Фәнис
Яруллин

# ХӘТЕР ТӨПЛӘРЕНДӘ УТЛЫ КҮМЕР

КӨНДӘЛЕКЛӘР

## 1987

**2 сентябрь.** 25 августта Минзәләгә барып, «Кызлар күнеле—тирән сер»не карап кайттык. Укытучыларның август конференциясенә дип бу спектакльне Алабуга районыннан махсус чакыртып куйдырдылар. Үземне дә шул вакытка чакырдылар. Конференцияләренә дә дәшкәннәр иде, арыдым дип кермәдем. Конференциядән соң көндезге өчтә спектакль башланды. Спектакльдән соң тамашачылар белән фикер алышу оештырганнар иде. Тамашачылар бар да укытучылар иде. Спектакль турында әйбәт-әйбәт сүзләр әйттеләр, күп кенә сораулар бирделәр. Фикер алышу сәгать ярым барды. Райкомның беренче секретаре Рәшит Сәитович Хәммәдиев тә чыгыш ясады.

Минзәлә якларына бер дә барган юк иде. Әйбәт каршыладылар. Кунакханәдә люкс номер әзерләп куйганнар иде. Анда йокы бүлмәсеннән тыш зур залы бар, шул залда спектакльдән соң артистлар, режиссерлар җыелышып сөйләшеп утырдык. Рәшит Сәитович әйбәт кеше икән. Гадәттә райком секретарьлары үзләрен бик эре тота, ә бу бик гади.

«Сухой закон» кертелгән вакыт. Ә артистларның тамаклары кычыта. Кайтып китәселәр килми. Шул вакыт икенче секретарь сумкалар күтәреп, ахылдап килеп керде. Эчемлеге дә, ашамлыклары да бар иде! Үзе чыгып китте. Киткәндә: «Берүк шаулашып утырмагыз. Монда стеналар юка, төрле кеше бар»,—диде. Авызга бераз шайтан суы кергәч, шаулашмыйча гына утырып буламыни? Житмәсә, артистлар белән. Безнең шаулашып утыру янәшә бүлмәдәгеләргә бер дә ошамаган һәм алар иртүк жалоба белән Хәммәдиевкә барганнар. Хәммәдиев аларны бик житди кыяфәт белән тыңлаган да: «Мин аларны бүген үк гостиницадан куам»,—дигән. Аракыларны безгә үзе жибәрткән бит инде, һәм безнең дә икенче көнне кайтып китәсен белә. Иртән килгәч, шуларны сөйләп көлдерде.

**5 ноябрь.** Кичә Ф.Әхмәтов шалтыраткан иде. «Мин полковник булдым»,—ди. Уртачарак салганда «полковник», күбрәк жибәрсә «генерал» була ул. Ләкин үзе әйбәт кеше. «Кем елый соң?» жырын һаман беркемнән дә жырлатып булмый әле, ди...

## 1988


**1 гыйнвар.** 31е көнне Сәйрин Яна ел каршыларга чакырды. Минем белән бергә хезмәт иткән егет, штурман булып эшләде, хәзер пенсиядә. Аларга кичке 6ларда киттек. Без барып бераз утыруга әллә кемнәр җыела башлады. Шау-шу, эчү. Бересе көнне Сәйрин күрмәгәндә генә такси чакыртып, көчкә качтык. Өчесенә хәтле жибәрмим дип чат ябышты. Мондый тавышлы жирләргә йөри алмыйбыз икән инде без.

*Дәвамы. Башы 2011 елның 1нче санында.*

**19 гыйнвар.** Кичә Марс Шабаев килде. Ул минем юбилей комиссиясенең председателе. Юбилей Г.Камал театрының иске бинасында 10 февральдә булыр дип торабыз. Янадан берәр үзгәреш килеп чыкмаса.

Мине 50 яшь уңаеннан Хезмәт Кызыл Байрагы орденына тәкъдим иткән булдылар әле. Тик Почет Билгесе ордены тәтемәгәннәргә анысын ук бирмәскә мөмкиннәр икән. Бирмәсәләр алмаска туры килер инде, шул гына.

**8 февраль.** Беркөнне Сарманнан Дамир Гарифуллин шалтыратты. Сочида булдым, Островский музеена кердем, ди. Синең китапларынны сорадылар, ди. Мин үземдә булган «Упругие паруса»ны калдырдым, ди. Аннан тагын шуны әйтте: Сарманда Фәнис Яруллин урамы бар икән. Ике ел инде бер урамыбыз синең исемне йөртә, давай, кил, урамыңны күрсәтербез, бик әйбәтләп очрашу үткәрербез, ди. Безнекен белмәссен, барып та чыгарбыз әле...



*Фәнис белән Нурсөя. 1974 ел.*

**9 февраль.** Бүгенге көн мина олы шатлык алып килде. Халыклар Дуслыгы ордены белән бүләкләү турында СССР Верховный Советы Указы чыкты. Иң беренче газеталарга күзәтү биргәндә радиодан үзебез ишеттек. Аннары Туфан белән Нәҗибә шалтыратты. Аннары китте... китте. Ә минем какраз туалетка керәсе көн. Анда инде мин кимендә сәгать ярым, юынулары белән ике сәгатьләп ятам.

Көне буе шалтыраттылар... Бер иллеләп кеше шалтыратты бугай. Г.Бәширов та шалтыратты.

Бүгенге «Социалистик Татарстан»да Г.Бәширов белән М.Шабаевнын мина карата язган мәкаләләре бар. Гомумән, орден алу күнелле нәрсә икән.

**15 февраль.** 10 февральдә юбилей кичәсе булды. Бик зурлап уздырдылар. 800 кеше бар иде диделәр. Әле керә алмый калучылар да күп булды. Балтачтан, Арчадан, Минзәләдән килгәннәр иде. Обком секретаре Кадырметов орден тапшырды. Котлаулар бик күп булды. Кайберләренә сүз бирмәскә теләгәннәр иде, сәхнәгә сикерешеп менеп котлый башладылар...

Анда берсе: «Нишләп Ф.Яруллин иҗатын тәнкыйтьчеләр әз яктырта?»—дип сорау җибәргән иде, Ф.Мусин шуна җавап биреп китте. Менә, диде, бездә татар әдәбияты тарихынын алты томлыгы чыгып килә, шул әдәбият тарихында Ф.Яруллин иҗаты да лаеклы чагылыш табар, диде.

Аннары: «Нишләп Ф.Яруллиннын китаплары сатуда юк?»—дип сорадылар. Туфан: «Аның нәкъ менә китапларының сатуда булмавы, кибетләрдә ятмавы әйбәт тә инде», —диде. Бу әлбәттә, бик дөрес җавап түгел. Беренчедән, китаплар бик аз тираж белән чыга. Кайсы 5 мең, кайсы 10 мең данә. Икенчедән, китапларны чыгарырга ашыкмыйлар. Язучылар союзында председательнекен, аның урынбасарларыныкын, нәшрият тирәсендә кайнашучыларныкын, кайдадыр түрә булып утыручыларныкын яки аларның туган-тумачаларыныкын каты тышлы итеп, әсәрләре язылып бетүгә үк бастырып чыгаралар. Китап чыгару проблемасы бездә берәр вакыт бетәр микән? Йә кәгазь җитми, йә акча. Бездә һәрвакыт нидер җитми. Бигрәк тә иҗат кешеләрен кысалар.

**12 апрель.** Ябалак-ябалак кар яуды. Бераздан эретеп бетерде, янадан янгыр явып алды. Көннәрне җылытыр дип торганда, киресенчә, тагын суытып маташа менә.

Яз шулай инде: назлы кызлар кебек. Кызларны да менә чыга, менә чыга дип капка төбендә сәгатьләр буе көтеп, чыкмаса ярсып кайтып китәсен. Ә ул син кайтып

китқәч кенә урамга чыга һәм сине килмәгән дип үпкәләп кереп китә...

Нурсөя грипп белән чирләп йөри. Дүрт көн инде. Бүген мина да эләгергә маташа, ахры. Борыннарга юеше килеп житте инде. Грипп—әрсез кызлар кебек, качсан да эзләп таба.

**15 апрель.** Көн ямьсез. Яз елак. Тыенкы гына яңгыр ява. Быел, гомумән, шундый вак яңгырлы яз. Яшеннәр юк әле. Көннәр жылы түгел. Берничә тапкыр кар да яугалап китте узган көннәрдә. Бакчага барган юк.

Бер шигырь яздым.

*Быел да яз килеп җитте,*
*Сау чыктык кышларны да.*
*Яңгыр, әйдә, ява бирсен –*
*Бәлки куккә дә кирәктер*
*Яшь коеп бушанырга.*

Нурсөя көн дә больницага йөри. Грипптан осложнение дип борынына УВЧ бирәләр. Аллергиясе артыннан айдан артык чапкан иде инде. Тагын бусын жидене назначить иткәннәр.

**18 апрель.** Нурсөя бакчага барып кайтты. Өйгә быел да кергәннәр. Тәрәзәнен пыяласын алып. Бөтен нәрсәне туздырып атканнар. Өйне жыештырып, бер күршедән тәрәзәне куйдырып, кишер һәм редиска чәчеп кайтты.

**25 апрель.** Кичә Рәшит Әхмәтжанов яна чыккан китабын—«Йөрәк бәйрәме»н кертте. Китабы матур гына чыккан. 8 табак. Квартирга күченәләр. Өч бүлмәле квартир бирделәр. Безнен квартирлар булырга ошамый. Былтыр өметләндереп куйганнар иде, хәзер бу эш сүнде. Гаеп кемдәдер.

**3 май.** Квартир мәсьәләсендә Идиятуллинга приемга барырмынмы әллә дигән идем, ана да йөрәк житми. Күтәрешергә, йөртешергә кеше кирәк. Баруын да файдасыз булуы бар.

**4 май.** Мин ике көн инде горисполкомга шалтырату белән мәшгуль. Кешесен тотып булмый. Кичә, менә-менә килер дигәч, ярты сәгать саен шалтыраттым. Булмады. Бүген шалтыраттым—бүген Идиятуллин булмый диделәр. Шуларга шалтыратасы булгач, бүтән эшкә кул бармый. Ә бит ул начальствоны эзләп ничәмә-ничә көннәрен югалткан кешеләр бер мин генә түгел. Безнен менә шулай вакытны урлаулары өчен аларны берәр жәзага тартасы иде. Шулвакыт эшкә вакытында килерләр иде, бәлки... Бездә түрәләргә сүз әйтергә ярамый: алар кагылгысыз. Алар—дәүләт эшендә! Ә башкалар нинди эштә? Совет власте кешеләрне тигезлибез дип төрле касталарга аерды.

**5 май.** Нурсөя бүгеннән рефлексотерапияга йөри башлады. Теге уколы да бар әле...

**12 май.** Кичә бер квартир тәкъдим иттеләр. Бардык Туфаннар белән. Ләкин безгә дигәненә кереп булмады. Ул йортка кешеләр күченә башлаган инде. Башка бер квартирны гына карап чыктык. Кечкенә инде. 26 кв.м., балконы, ягъни лоджиесы зур, ике бүлмәне инләп тора. Ләкин Нурсөягә ин ошамаганы—лифтына коляска белән генә кереп булмый. Тышкы яктан 5 сырлы баскыч, эчке яктан 4 сыр менгәч кенә лифтка керә аласын. Ә ул басмаларга коляска белән менеп булмый. Тагын күтәреп менәргә кала. Әле исполкомга шалтыраткан идем, ошамаса, бармагыз, башка берәр жирдән тәкъдим итеп карарбыз, ләкин әле якын арада гына бетә торган йортлар юк, диләр.

**18 май.** 16 май көнне Идиятуллинга хат язып, Нурсөядән секретарена илттердем. Квартир мәсьәләсе ничек хәл ителер инде. Кичә безнен квартирны карарга берәү килде. Университетта укучы студент. Үз йортлары белән Северный поселокта торалар икән. Әнисе белән. Бернинди ижат кешесе түгел, инвалид түгел, икесенә безнен ике бүлмәле квартирны тәкъдим иткәннәр. Әле ошатмыйча чыгып китте. Бу панель йортта, кечкенә кухнялы йортта ничек яшәмәк кирәк, ди. Сәламәт кеше шулай ди. Ә мин авыру кеше шушында уналты ел яшәдем инде. Һәм бу квартира әле безнен өч кешегә бирелгән иде. Әни авылга киткәч кенә икәү калдык. Ижат

кешесенең бер артык бүлмәгә хакы барлыгын да искә алсаң, бу безнең дүрт кешегә бирелгән квартир булып чыга.

**13 июнь.** Кичә бакчада бер кызык хәл булды. Зәет Мәҗитовларның басмасы турында бер кыр үрдәге бала чыгарган. Кичә шул үрдәкнең өч баласы әллә берәр нәрсәдән куркып, безнең бакчага килеп кергән. Нәрсәләр чиелдаша икән дип карасак, өч үрдәк баласы безнең сукмактан чабышып бара. Мин раскладушкадан башны калкытуым булды, болар куркышып төрлесе төрле якка чабып таралыштылар. Аларның чиелдашкан тавышына аналары очып килде, төшмәде, куркып күлгә очты. Бу үрдәкнең балаларын аналары янына тотып суга җибәрергә дип Нурсөя бөтен бакчаны бетереп үрдәк балаларын эзләде. Берсен тоттык. Мин дә башыннан сыйпап куйдым үрдәк баласының. Аннары күлгә җибәргән идек, шунда ук анасы килеп тә житте. Теге икесе аналарын таба алганнардырмы, күренмәделәр.

Каравылчының эте Белка да кичә балаларын алып килде. Аның алты баласы бар. Икесен ияртеп килгән. Ашарына бирергә бер әйбер дә юк иде, ипи ашамыйлар хәзерге этләр, шикәр-конфет ашатып җибәрдек. Ансын ашадылар. Берсе шикәрне бик өнәп бетермәде.

Бүген Г.Камал театрының иске бинасында «Кызлар күнеле—тирән сер»не куялар. Һәм тагын 19 ында була. Минзәлә театры Казанга гастрольгә килде.

**14 июнь.** Кичә Минзәлә театры минем «Кызлар күнеле—тирән сер»не күрсәтте. Мин дә бардым. Халык тулы иде, хәтта балконнарда да буш урын юк иде. «Быелгы гастрольләребез бик начар башланды, халык әз йөри. Менә бүген икенче тапкыр гына аншлаг әле. Берсе Илдар Юзеевның «Сөйгәнемнең туган көне» спектакле иде»,—диделәр. Артистлар да бик рухланып уйнады. Мине дә сәхнәгә менгерделәр. Чәчәкләр бирделәр.

Нурсөя дә кеше әз килсә нишләрбез дип куркып барган иде. Мин башта бармам дип торган идем, соңыннан такси чакырттык та киттек тә бардык. Туфан да, Илдар да бар иде. Соңыннан бераз спектакль турында сөйләшеп тордык. Туфан: «Анонимканы Рәжибә язу белән килешмим, яраткан кеше яраткан кешесенә начарлык эшләмәс,—ди.—Ә башка яклары бик әйбәт барды. Югыйсә тимер-томыр турында күп яздың инде,—ди.—Монда чын, саф мәхәббәт бар, яшьлек ялкыны бар»,—диде. Илдар Юзеев анонимка турындагы Туфан замечаниесе белән килешмәде. Әйбәт спектакль, диде, котлады. Хәзер син юлың тапкансың инде, язарга да язарга кирәк, диде. Барганда теләми генә барылган иде, күнел үсеп кайтты. Яңа әсәрләргә рух өстәргә булсын.

Спектакльдән алган тәэсирләр күңелдән бер шигырь этеп чыгарды.

*Үз-үзеңне олылау да кирәк,*
*Шунсыз яшәп булмый дөньяда.*
*Кирәк икән, чум син диңгезләргә,*
*Йә күтәрел биек кыяга.*

*Тыйнаклык та кирәк яшәгәндә,*
*Тик булма син җансыз күләгә.*
*Тормыш бәйгесендә зур бүләкләр*
*Көрәшә белсәң генә эләгә.*

*Мин көрәшәм әле көчем барда,*
*Хурлык түгел хәтта җиңелү.*
*Кешеләргә бер үҗәтлек бирә*
*Биеклеккә таба үрелү.*

Бүген төштән соң 60 укытучы килде. Өйгә бервакытта да алтмыш кеше кергәне булмагандыр әле. Болар бөтен Татарстаннан җыелган татар теле һәм әдәбияты укытучылары. Бер айга белемнәрен күтәрергә килгәннәр. Өйдә басып торырга да урын калмады. Күбесе коридорда басып торды. Бер уннан артыгына китапларны бүләк иттем. «Җилкәннәр» повестен нигә программага кертмиләр?»—дип сорыйлар.

Бер китабын да кибеттә юк дип зарланалар. «Шигырь китапханәсе»ндә чыккан китап та бер-ике атнада таралып бетте. Халык күрми дә калды. Бер район кибетендә дә юк, диләр. Болар инде бөтен Татарстаннан килгән кешеләр. Чынлап та юктыр, күрәсең.

**24 июнь.** Төенчекләр арта бара, ордер юк әле. Берәр вакыт бөтен төенчекләрне чишеп кире шушында яши башларга туры килмәгәе әле.

Көннәр кызу тора. Бакчага атнасына 1-2 барып йөрибез. Җиләкләр өлгерде. Җыясы, эшкәртәсе генә. Ләкин Нурсөянең тазалыгы беткәннән бетеп бара. Тәннәре ятуга лачма тиргә бата, аннары салкын тия. Умыртка сөяге сызлый. Ничек мине икенче этаждан сөйрәп йөридер, мескенкәй. Юынган көнне ваннага гына ике тапкыр күтәреп кертергә, ике тапкыр күтәреп чыгарырга кирәк. Һәр атнада ике тапкыр юынгач, атнасына сигез мәртәбә күтәрергә туры килә өйдә генә. Ә бакчага барганда төшерергә-менгерергә. Баргач, тагын шулай ук. Яңгыр ява башласа, өйгә кертергә, көн аязса, тагын чыгарырга.

**28 июнь.** Бүген тагын бик күп укытучылар килде. 40лап диделәр. Бөтен илдән килгән татар теле укытучылары. Монда—Казанга белемнәрен күтәрергә курска җыелганнар. Шунда берръттән мине дә күрәсе иткәннәр. Һәрберсенең кулында «Фәнис Яруллин—Корчагиннар токымыннан» дигән методик кулланма. Авторы З.Н.Хәбибуллина. Бу методик киңәшләр укытучыларга Ф.Яруллин иҗаты буенча дәрес-лекция үткәрү өчен әзерләнгән. Татарстан укытучыларның белемен күтәрү институтының татар теле һәм әдәбияты кабинеты тарафыннан эшләнгән.

«Каз кычкыра» повесте чыккан «Казан утлары» күп кенә иде, шуларны бирдем. Җитмәгәннәренә әнә шул методик кулланмаларына кул куйдым.

**29 июнь.** Бакчада мин һәрвакыт тышта ятам.Күккә карап ятканда дөнья мәшәкатьләре истән чыга. Күк үзенең биеклеге, серлелеге, чиксезлеге белән тормыштагы вак-төяк уйларны оныттыра. Өскә озаграк карап ятсаң, ул урталай ярылып киткәндәй була. Югары катлам күренә. Анда төсләр куерак, болытларның агышы да башка якка. Күрәсең, күкнең төрле катламында һава агышы төрле якка буладыр. Күккә менеп китеп, биеклекнең зәңгәр сыеклыгында эреп югаласы килә. Ләкин җир кешесе булып тугач, җиргә төшми хәлең юк. Нурсөя нидер әйтә дә, җиргә төшәм.

**12 июль.** Ордер һаман юк. Төенчекләр өстендә утырабыз...

**25 июль.** Ниһаять, без дә юньлерәк квартирлы булабыз бугай. Ордерның яртысын, ягъни корешогын бирделәр. Шуның белән ачкычларны алдык. Бераз әйберләрне үзебезнең машина белән ташыдык. Ташырга Рәшит белән Әхтәм булышты. 27сендә бөтенләй күчеп китәрбез дип торабыз. Мебельләрне күчерергә машинаны безнең урынга килүче кеше үзем табармын диде.

**22 август.** Яңа фатирга күченгәнгә дә айга якын вакыт үтте. Кулга ручка тотарга туры килмәде әле.

27 июльдә күчендек. Әйберләрне төяшергә редакциядән егетләр килде. Ркаил Зәйдуллин, Ирек Нигъмәтҗанов, Ләбиб Лерон һәм Айрат Садыйков. Ике бүлмәле квартир. Бу—фатир алу түгел, алмаштыру гына. Ләкин тегесеннән шәбрәк. Иң ошаганы—залда ике тәрәзә булуы. Тегендә безнең кояшсыз як иде. Залы зур—22 кв.м., спальный бүлмәсе—12 кв.м. Ике якта да лоджие. Прихожий зур, иркен. Тик менә ваннасы утырып юына торган гына, миңа бик уңайсыз. Алыштырырга кирәк булыр. Магазиннарда да шушындый кечкенә ванналар гына икән әле. Өч тапкыр юындырды инде монда мине Нурсөя. Су җылырак кына, кайнар су юк әле. Лифт тә эшләми. Халык күченеп бетмичә эшләтмәсләр, мөгаен. Күченгәндә әйбер ташып ватарлар дип куркалар бугай. Ярый әле Рәшит Әхмәтҗанов белән күрше йортка эләктек. Бакчага бергә йөрибез. Ул күтәреп менгерә, төшерә.

Шунсы кызык: горсправкага яңа адресны биреп өлгергәннәр. Бер Мөхәммәт исемле абзый горсправкадан адресны алып килеп җиткән күченеп ике атна үтүгә. Шигырьләр яза икән. Шигырьләрен укып эт итеп арытып китте. Шигырьләрендә бер яңа фикер дә юк. Шуларның бер-икесен эшләп редакциягә бирә алмассыңмы, ди. Монда бит эшләрлек әйбер юк, дип карыйм, барыбер дәфтәрен калдырып

китте. Бүген дәфтәрен алырга килергә тиеш. Бу шигырь белән женләнгән картлар да туйдырды. Качып та булмый үзләреннән. Кешегә кырт кисеп кенә әйтә алмыйм, үзем йомшак инде. Шуна киләләрдер.

**1 сентябрь.** Күчеп килгәннең икенче көнендә квартирны баса яздылар. Берәү ишеккә бик озак звонок бирде башта. Мин: «Кем бар?»—дип кычкырган идем, ишетмәде. Аннары әле бер, әле икенче ачкыч тыгып ача башлады. Һәм ачып керде. Мин: «Кем бар?»—дип кычкыргач, чыгып китте, ишекне япмады да. Йөзен күрә алмадым, мин залда ята идем. Ярый бераздан Рәшит Әхмәтжанов керде. Нишләп ишегегезне ачык тотасыз, ди. Сөйләп бирдем хәлне. Берничә көннән 14нче этажның бер квартирын басканнар. Ачкыч яратып. Хәзер өйне ташлап китәргә дә куркабыз.

**7 сентябрь.** Кичә бер аферист карчык алдап чыгып китте әле үзебезне. Мин 6нчы этажда торам, 5 сум акча биреп торыгыз әле, ди. Нурсөянең 5леге юк икән, ике өчлекне биреп чыгарды. Картаеп килүче бер маржа. Жилләр искән «мескен» карчыгыбыздан. Монда тора торган кеше түгел икән. Без ачык авызларны ничә тапкыр алдадылар инде, һаман ышанабыз. «Больниска бара идем»,—дип сүз башладылармы, аферист була икән. Шулай жәлләтеп башлыйлар алар сүзне. Инде хәзер «үләбез» дисәләр дә ышанмаска кирәк дибез. Ләкин бераз вакыттан икенчесе икенче төрле итеп алдый бит аның, тагын ышандыра.

**14 сентябрь.** Бүген беренче мәртәбә лифттан файдаланып карарга насыйп булды. Бакчага барган идек, кайтуыбызга лифт эшли башлаган. Әй, сөендек! Нурсөя күп итеп алма жыйган иде. Башта алмаларны менгерде. Аннары колясканы алып төшеп мине алып менде. Аннары үзе машинаны читкәрәк алып куярга дип чыккан иде, кергәндә лифт эшләми дә башлаган. Их, кайчан коммунизм житәр икән? Анда бөтен нәрсә гөрләп эшләп торыр иде!

**26 сентябрь.** Туфан рәислектән китәргә гариза биргән. Дөрес эшләгән. Талантлы кешегә администраторлык комачаулый гына. Вак-төяк эш күмеп китсә, әллә нинди талантларың да чүп астында кала.

**30 сентябрь.** Биш көн инде тәмуг газапларында яшибез. Аста, беренче катта, бойлер дигән нәрсә икән безнең. Көне-төне мотор эшләп тора. Реактив самолетта барган кебек. Колаклар тонды, йоклап булмый. Фатирны алгач шундый сөенгән идек. Сөенечебез озакка бармады.

**5 октябрь.** Бу тавыш йә акылдан яздыра, йә үтерә инде безне. Ике көн Рәшит Әхмәтжановта кунып чыктык. Әмма гомер буе кешедә яшәп булмый ич.

**6 октябрь.** Үземнең бер генә дустым да юклыкка көннән-көн ныграк ышана барам. Хәлең ничек дип Союздан ник берсе килеп карасын! Ә бит Нурсөя барып әйтте, хәле авыр, зур температура белән ята, дип. Ярый Рәшит кереп йөри, ләкин ул үзе дә бала хәлендә—ярдәм итә алмый. Әгәр берәрсе авыр хәлдәмен дип чакыру жибәрсә, мин шушы хәлемдә дә янына барыр идем. Кешеләр нишләп бу кадәр битарафланды соң?

**11 октябрь.** Бүген көндезге икеләрдә бер сәер карт килде. Украинадан. Исәбе—мине терелтү икән. Минем турыда радиодан ишеткән. Мин бит пенсионер кеше, вакытым күп, нигә ярдәм итмәскә, ди. Самавыр куйган идек, чәй дә эчмәде. Менә, ди, эчкә тын алып озак кына чыгармый торырга кирәк, шунда бөтен чирдән котылып була, ди. Ярдәм итә алмаячагын аңлагач, гафу үтенеп чыгып китте! Менә нинди кешеләр дә бар дөньяда. Бер аферисты алдап йөри, икенчесе кешегә бераз ярдәм итеп булмасмы дип, үз пенсиясенә билет алып озын юлга чыга.

**19 октябрь**. Бойлер рәхәтләнеп үкерә. Хәзер мин ижат итәсе урынга кешеләргә рәнжеп, әкрен килгән әжәлне көтеп ятармын микәнни?

**12 декабрь.** Н.Хрущев безне «коммунизм»да яшәтмәкче иде, үзен очырдылар. Брежнев заманында «нык үскән социализм»га килеп кердек. Ә Горбачев, 2000нче елга хәтле һәр гаиләне фатирлы итәм, диде. Менә без дә, шушы вәгъдәгә таянып, 2нче каттагы тавышлы фатирдан котылыр өчен шушы ук йортның әлегә хәтле буш торган 9нчы катына менеп кунакладык. Монда менү өчен бик күп кешеләргә үтенеч хатлары язарга туры килде. Житмәсә, фатиры да безнекеннән кечерәк.

Әҗәлен житмичә үлеп булмый, диләр. Тегендәге тавыштан үлмәс өчен бер чара булды бу.

**26 декабрь.** Берничә көн элек Зәкия апалар килеп икене кунып китте. Ит алып килгәннәр. Безнең итләр күбәйгәч, көнне жылытты. Тамчы тамып утыра. Ике көн инде. Суыткыч җүнләп эшләми иде. «Мир» дигән ул суыткычны без сәүдә министрына хат язып кына сатып алган идек. Суыткычыбыз туганда ук чирле булып чыкты. Мастерскойдан да, заводтан да мастер чакыртып карадык. Бичара «Мир»ның авыруын тапмадылар. Чакырта торгач, бер «салмыш» мастер килеп чыкты да суыткычыбызны төзәтеп куйды. Реле дигән нәрсәдә булган икән хикмәт. Сөенә-сөенә бу мастерга бер ярты тоттырдык. Киткәндә ул: «Бу суыткычлар бер сезнеке генә түгел, башкаларныкы да ватылып тора»,—диде.

## 1989

**4 гыйнвар.** Бүген Апас район китапханәсеннән һәм Апас урта мәктәбеннән килделәр. Минем китапларны алып килгән бер унлабы, аларга автограф язып бирдем. Соңыннан бергәләп фотога төштек. «Тере язучылар безгә сирәк килә, сезне үз күзебез белән күрәсебез килгәнгә килдек»,—диделәр. Мин: «Апастан ук килеп, бер соравыгыз да юкмыни?»—дигәч. Апаста урта мәктәп бер генә, анда татар һәм рус класслары бар, диделәр. Китапханә эшчесе Әлфия: «Хәзер татар китапларына карата кызыксыну арта башлады. «Казан утлары»н кулдан кулга йөртеп укыйлар, былтыр китапханә бер генә данә ала иде, быел икегә язылдык»,—дип торды. Адәм көлкесе. Татар районында татар мәктәбе юк! Район китапханәсе «Казан утлары»н икене ала. Ә бит татар язучыларының иң яхшы әсәрләре беренче булып «Казан утлары»нда басыла.

**7 гыйнвар.** Кичә бик каты эч белән ашказаны авырта башлады. Төне буе укшытты, ике тапкыр косып та алдым. Бүген дә хәл мөшкел. Эч мускуллары калтырый, ашказанына таш тутырган кебек авыр. Хәтта яшисе килми. Яшәгәнче тиз генә үлеп китсәң иде дә бит.

*Туйдым инде, туйдым дөньясыннан,*
*Һәрбер көне аның—мең газап.*
*Бу авыру мине ничә еллар*
*Үтереп килә шулай аз-азлап.*

*Күңелемдә бетте үҗәтлек тә,*
*Эш диеп тә янмый-көймимен.*
*Миннән инде күптән туйганнардыр,*
*Хәтта үзем кешене сөймимен.*

*Бүген китәр идем дөньясыннан,*
*Карамыйчы алдым-артыма:*
*Нурсөянең мәхәббәте тота,*
*Яшим бары шуның хакына.*

Нурсөянең дә аягы сызлый, шешенә дә. Көненә бер мәртәбә кочкә генә аскы катка почта карарга төшеп менә. Күп йөрелмәсен өчен хәзер почтага да махсус төшермәскә тырышам инде: йә газеталарны ипигә-сөткә, йә башка кирәк-яракка чыкканда гына алып керергә кушам. Лифт һаман эшләми. Кайчан эшләсе дә билгесез...

*Дәвамы киләсе саннарда*

# ӘЛЕ АЛДЫН, ӘЛЕ АРТЫН КҮРСӘТӘ ИКӘН...

БЕР ТАНЫШ РӘССАМ СӨЙЛӘГӘННӘРДӘН

Эштән кайтып барганда Габделбари очрады.

—Карале, малай, бер генә сәгатьлек эш бар иде, —диде. Үземнен дә йомышым төшәр дип, килештем мин. Һәм без алар яши торган урамга борылдык. Кайту унаена ул тулай торакка кереп сылу гына кыз да ияртеп чыкты. Подъезд төбендә хатыны очрады.

—Кайтуыгызны көтеп җиткерә алмадым инде. Чәй кайнаган, — диде ул иренә. Аннары йөгерә-атлый каядыр китеп барды.

Нинди эш микән дип уйландым мин. Хуш. Кердек Габделбариларның кыр шикелле өйләренә. Кунак кыз, үз кеше сыман, шунда ук йокы бүлмәсенә кереп китте. Мин залга чыгып утырдым. Хужа исә үзенен карангы бүлмәсендә югалып торды. Аннан ул өч-дүрт фотоаппарат алып чыкты. Мина яктырткыч лампалар тоттырды. Шунда гына ниндидер рәсемнәр төшерәсебезне төшендем. Ул арада йокы бүлмәсеннән «Мин әзер» дигән тавыш та ишетелде һәм зал уртасына... Микеланджело мадоннасы кук шәп-шәрә теге кыз чыгып басты. Лампаларның яктылыгы кая төшүенә игътибар итмичә, мин башымны читкә бордым. Көтелмәгән күренештән күз алларым карангыланып китте, тез буыннары йомшарды. Габделбариның эндәшкән тавышыннан гына айнып киткәндәй булдым. Хужа үзе фотоаппарат «тәрәзәсе»нә чекерәеп текәлгән, үзе мине әрли.

—Кая монда кендек уемтыгы, кая күкрәк алмалары чагылышы?! Чиксезлеккә төбәлгән карашларны күрмим... Бер яктылык яссылыгында бирергә кирәк бит аларны. Лампаның берсен яннанрак тотып, икенчесен астан өскә таба бирep карале...

Секунд саен «черт» иттерергә житешкән Габделбариның кулларына күз иярми иде. Куллары гына түгел, гәүдәсенең минутына йөз төрле кыяфәткә керүе дә ут өстендә биюче тылсым иясен хәтерләтә.

Үзе әйтмешли, «сюжет, сюжет» дип ярты сәгатьләр чамасы «кылангач», фотограф тынычлангандай булды. Хәтта йөзендә канәгатьлек билгеләре дә чагылып китте. Аннары, шаулый торсын дип, мина чәй янартып килергә кушты.

Күрмәгән нәрсә булмаса да, тәнгә төшкән дерелдек һаман узмый иде әле. Шунадыр, күрәсен, кухняда шырпы кабыза алмый газапландым. Чәйнек астына ут алгач, тәрәзә каршына барып баскан гына идем, Габделбари тавышы ишетелде.

—Син нәрсә, яшьти, бик озак кыймылдыйсың анда, әллә ашарга ук утырдынмы?

—Юк ла...

—Алайса, чык монда.

Бу юлы «мадонна» диванда «сибелеп» ята иде. Янына бер чүмәлә китап өелгән. «Бурда моден» һәм башка шундый затлы журналлар идәнгә сибелгән. Кызның гүя аларда гаме юк. Ул күз карашын тимер рәшәткәле тәрәзәгә төбәп тирән уйга талган...

Ә без... Без тагын күпмедер вакыт матур сюжет эзләп азапландык. Аннары ...аннары килешенгән вакыт буенча сәгать шалтырады. Дәшми-нитми генә кушканны үтәп барган кызның да теле ачылды. «Мин киенәм», дип йокы бүлмәсенә кереп китте ул.

Бер минуттан без өчебез дә ишек төбендә басып тора идек инде. Габделбари кызга рәхмәт әйтте, кулына берничә кызыл унлык тоттырды.

...Урамда ишегаллары жыештырып йөргән Габделбариның күргәч, егерме еллар элек булган әлеге вакыйга исемә төште. Ә бит аның картиналарыннан төзелгән күргәзмәләр шәһәрдән-шәһәргә күчеп йөрде. Ә бүген йөзләгән сәнгать әһелләре анын кебек эшсез, йә бик түбән хакка жан асрарга мәжбүр.

—Хәлләр ничек, яшьти, күптән, бик күптән күрешкән юк.

—Үзен күреп торасың, менә шулай маташабыз инде. Кызык бу дөнья: башта шәп-шәрә алдын күрсәтә, аннары арты белән борыла икән... Нишлисен инде, шундый замана килде безгә..., —диде дә, сүз озайтып торырга урын калдырмыйча китеп барды Габделбариебыз.

**Мидхәт САДЫЙКОВ**

# «СУДЛАРНЫҢ ГОМЕРЕ МӘҢГЕЛЕК...»

*Фарук Фатыйх улы СӨНГАТУЛЛИН–Татарстан һәм Россиянең атказанган юристы, «Халыклар дуслыгы» ордены, күпсанлы медальләр иясе. 1987-88 елларда—Казан шәһәр прокуроры, 1988-94—Татарстанның баш дәүләт арбитры, 1995–2008 елларда—Идел буе округының Федераль арбитраж суды рәисе.*



**—Фарук Фатыйхович, нәрсә ул Дәүләт арбитражы? Гомумән, арбитраж суд ни өчен кирәк?**

—Үзегез беләсез, узган гасырның 90 елларында Россиядә икътисади үзгәрешләр башланды, илдә базар мөнәсәбәтләре формалашты. Шушы шартларда бәйсез суд системасы булдыру зарур иде. 1991 елда «Арбитраж суд турында»гы РСФСР Законы кабул ителде.

Арбитраж суд учреждениеләр, предприятиеләр һәм оешмалар арасындагы бәхәсләрне тикшерә, ягъни, икътисад өлкәсендә килеп чыккан низагларны хәл итүнең хокукый механизмы булып тора. Шул ук вакытта конституцион орган булып исәпләнә.

**—Сез бу вазыйфага шактый урау юллар аша килгәнсез икән...**

—1942 елның 2 гыйнварында Буа районының Әхмәт авылында туып, 75 йортлык шул авылда үсеп, әти-әни йортыннан жиденче классны тәмамлагач чыгып киткән кеше мин. Башта Буадагы икмәк хәзерләү предприятиесенә балта остасы, столяр булып урнаштым. Күңел биреп эшләдем—бүтәннәр 600 сум алганда минем айлык хезмәт хакым 1000 сум чыга иде. Аннары шунда ук автослесарьлар хәзерли торган училищега кердем. Аны укып бетергәч, Казанга китеп, автопаркта эшли башладым. Шундук дүртенче разрядлы слесарь итеп куйдылар. Өлкән яшьтәге слесарьлар яшьләрне ярты чакрым ераклыктагы кибеткә аракы алырга жибәрәләр иде. Бервакыт моны миңа кушмакчы булдылар. Әһә, дим, бер барсаң, кабат йөгертәчәкләр—көнгә өч тапкырдан исәпләгәндә, алты чакрым юл килеп чыга бит. «Вася дәдәй, синең ничәнче разряд?»—дип сорыйм моннан. «Өченче»,—ди. «Ә минем—дүртенче...—Синең үзеңә йөгерергә туры килә инде, ачуланма...» Бүтән миңә мондый нәрсә белән борчымадылар... Шунда эшләгәндә рационализаторлык тәкъдиме белән дә чыктым—иске самосвалдан автокран ясадым.

**—Үсмер чактан ук тормышка чытырдап ябышкансыз. Мондый үҗәтлек каян килә?**

—Нәселдәндер. Минем бабай да, әти дә аякларында нык басып тора торган кешеләр булган—бөтенесенә дә үз тырышлыклары белән ирешкәннәр. Әти сугыш вакытында үзен генә түгел, иптәшләрен дә ачлыктан саклап калган кеше. Сугышта яраланган атларны, газапланып ятмасыннар дип, атып үтерә торган булганнар. Әти, бу гадәтне үтәмичә, шундый бер атны суеп, итен солдатларга ашаткан.

Шушы вакыйгадан соң яралы атларны атуны тыйганнар, әти ысулын файдалана башлаганнар... Ә бабай үз заманының хәйран хәлле кешесе булган, бөтен дөньяны гизгән, Мисырга хәтле барып җиткән.

**—Юрист булу теләге яшь чакта ук бар идеме?**

—Юк, мин башта философ булырга хыялландым. Үзлегемнән философия, психология, социология фәннәрен өйрәндем, марксизм-ленинизм теориясен, немец идеологиясен үзләштердем, «Капитал»ны укыдым. Хәтеремне шомарттым—алтышар куплетлы шигырьне бер уку белән яттан сөйләргә өйрәндем. Соңыннан, студент булгач, бер китапны бер кичтә укып, хәтердә калдыра идем. Әмма философия факультеты өч кенә шәһәрдә—Мәскәүдә, Минскида, Тбилисида гына бар икән. Мәскәүдә, мәсәлән, нибары илле кеше алалар—анда күбрәк «Үзәк Комитет балалары» булачагы билгеле иде инде.

Шулай итеп, юридик факультетны сайладым. Студент чакта ук үзем эшли торган предприятиедә юрисконсульт булдым, ә университетны бетергәч, адвокат булып эшли башладым. Әмма ике айдан ук моның минем эш түгеллеген аңладым. Улы хулиганлык эшләгән ата кеше, мәсәлән, адвокат яллау өчен башта кассага түли. Аннары аңа билгеләнгән адвокат аннан шәхсән үзенә акча бирүне таләп итә. Гаиләдә болай да фаҗига—ә безнең яклаучы органнарыбыз аңа өстәмә зыян сала. Бервакыт шундый хәл булды: Зеленодольск шәһәрендә бер кызны көчләгән өчен егерме егеткә җинаять эше ачтылар. Егерме җинаятьчегә ул шәһәрдә нибары алты адвокат бар иде, безгә дә барырга туры килде. Егерме кеше судка берьюлы килми, судны туктаусыз кичектереп торырга мәҗбүрләр. Казан белән ике арада үз хисабыма йөрим, ә теге адвокатлар җинаятьче егетләрдән акча алып торалар. Миннән ул эш булмады. Мөмкинлек чыкты—Казанның Бауман районы прокуроры ярдәмчесе урынын тәкъдим иттеләр. Ике ай эчендә мин анда судьяларның тугыз ай дәвамында кабул иткән сигез карарына протест яздым. Шуннан соң кайвакытта карар чыгарганчы, судны туктатып, минем белән киңәшләшә торган булдылар. Бер ел эшләгәннән соң инде республика прокуратурасына—бүлек прокуроры итеп күчерделәр. Аннан Татарстан Өлкә комитетына. Анда финанс хокукларын, салым системасын ныклап өйрәндем. Чөнки Милли банк, Төзелеш банкы, финанс министрлыгы эшләренә күзәтчелек итү эшен йөкләделәр. Ә 1986 елда инде Казан шәһәре прокуроры итеп куйдылар.

**—Бик авыр чорга эләккәнсез—ул вакытлар күпләр хәтеренә үсмерләрнең урам сугышлары белән кереп калган...**

—Әйе, иллешәр-алтмышар малайдан торган группировкалар, шәһәр халкының котын алып, урам тутырып сугыш оештырып йөри иде. Милиционерлар өч-дүрт машинага төялешеп килеп төшә, әмма аларның гына көче җитми. Кулга алынганда үсмер коралын ташлап өлгерә, димәк, аңа каршы җинаять эше дә кузгатып булмый. Ниндидер яна чаралар уйлап табарга кирәк иде. Мин шәһәр милиция башлыкларын чакыртып сөйләштем: ике генә түгел, берьюлы ун патруль машинасы белән килеп, группировканы чолгап алырга! Малайларны баштанаяк сыйпарга—тентергә ярамый, анысы закон бозу була—шул арада аның кесәсендә пычак-фәлән барлыгы сизелә, шаһитлар алдында ул тартып алына, димәк, салкын корал йөрткән өчен җинаять эше дә кузгатып булачак! Шулай итеп, көн саен унлап үсмерне утыртып куя башладык. Мин эшкә керешкәндә Казанда 90 группировка бар иде, ике ел эчендә 7гә калды.

**—Җаваплы урында эшләгәндә һәммә нәрсә шома гына бармагандыр...**

—Төрле хәлләр булды. Бервакыт зур урын биләгән бер кешенең кызын көчләгәннәр, дигән шикаять килде. Тикшерә башлагач, шул ачыкланды: кыз үзе тәртипсез тормыш алып барган, җинаять эше кузгатырлык нигез юк. Әти кеше минем өстән шәһәр комитетына мөрәҗәгать итте, һәм икенче секретарь миңа шалтыратып, «гаепле» егетне кулга алырга боерды. Мин үз дәлилләремне китереп,

мона каршы чыктым. Секретарь: «Без сине эштән куачакбыз!»—дип кычкырды. Шушы хәлдән соң, шәһәр комитеты мина шелтә бирү турында карар проекты әзерләде. Әмма партия өлкә комитетының ул чактагы беренче секретаре Гомәр Усманов әлеге шелтәне бирдермәде. Алай гына да түгел, мине Татарстанның баш арбитры итеп билгеләү турында тәкъдим кертте. Вакытны сузмыйча, шул ук көнне Мәскәүгә киттем, иртәгесен минем яна урынга билгеләнүем турында указ чыкты. Шулай итеп, 1988 елда Дәүләт арбитражы рәисе булып эшли башладым. Ул чакта әле компьютерның ни икәнен дә белмиләр иде. Аны беренчеләрдән булып Америкадан кайтарттым. Бүген бик унышлы файдаланыла торган «Консультант», «Гарант» программалары ул вакытта юк иде әле. Мин «Госарбитраж» исемле, кануннарны компьютер ярдәмендә эзләп табу системасын оештырдым. Аның файдасы ифрат дәрәҗәдә зур. Мәсәлән, адвокатка шикаять язарга кирәк, ул, билгеле, төрле елларга карый торган законнарга таяна. Егерменче еллардагы законны эзләп табу өчен, мәсәлән, тузанлы шкафларда ул бик озак казынырга мәҗбүр. Советлар Союзы вакытында гамәлдәге законнар һәм башка карарлар гына да 30 миллионлап иде бит. Әлеге яна программалар юрист хезмәтен бик күпкә җиңеләйтте.

**—1995 елда Сезне Идел буе округының Федераль арбитраж суды рәисе итеп билгеләгәннәр. Илдә ничә округ бар? Сезнекенә кайсы республика-өлкәләр керә?**

—Россия буенча 10 округ исәпләнә. Идел буе округының Федераль арбитраж суды исә Әстерхан, Волгоград, Пенза, Самара, Саратов, Ульяновск өлкәләре һәм Татарстан республикалары арбитраж судлары кабул иткән суд актларын тикшерү белән шөгыльләнә. Идел буе округының озынлыгы якынча 1200 чакрымны, мәйданы 460 мең кв. км. ны тәшкил итә, әлеге төбәктә 17 миллионга якын халык яши.

**—Җитәкче булгач, эшне нәрсәдән башладыгыз?**

—Иң гади тормыш проблемаларыннан. Чөнки судның бернәрсәсе дә юк иде. Мина Инженер урамындагы илленче елларда төзелгән, ишелеп баручы мәктәп бинасын тәкъдим иттеләр. Түшәмнәре череп, җылыту системасы күгәреп беткән кызганыч кыяфәтле йорт. Аны ремонтлаганда бакчасыннан гына да егерме «КамАЗ» чүп чыкты. Хәзер суд бинасы әнә ничек балкып тора. Ишек алдында бакча, таш түшәлгән сукмаклар, фонтан, борынгы Рим стилендәге ротонда... Керү юлларына асфальт җәйдек, автомобильләр өчен кереп туктау урыннары булдырдык. Урамның исемен дә «Правосудие» дип үзгәрттек. Судьялар сайлап алу, суд аппаратында эшләү өчен хезмәткәрләр туплау, аларны укыту һәм квалификацияләрен күтәрү буенча да җитди эш алып барылды. Бердәм компьютер челтәре булдырдык. Идел буе округына керүче өлкәләр белән контакт урнаштырдык.

**—Фарук Фатыйхович, безнең халык арбитраж судына гына түгел, башка судларга да бик үк ышаныч белән карамый шикелле...**

—Бу ышанмау коммунистлар заманыннан, гаепсез кешеләрне «халык дошманы» дип хөкем иткән чордан ук килә. Аннары, урамга чыгып сораштыру үткәрү гадәте бар. Мәсәлән, ире белән аерылышканнан соң, милекне дөрес бүлмәде дип, судтан риза булмаган хатынга, яисә яна гына төрмәдән чыккан кешегә мөрәҗәгать итсәләр, билгеле, җавап объектив булмый, ә сораштыручылар шуларга карап нәтиҗә чыгара.

**—Судьялар бары тик законга гына буйсына дигән сүз бар. Бу—тормышта да шулаймы?**

—Әйе, Россия Конституциясендә һәм судьялар статусы турындагы законда судьяларның мөстәкыйль булуы һәм законга гына буйсынырга тиешлеге турындагы маддә бар. Судьялар беркемгә дә буйсынырга тиеш түгел, әмма алар арасында хакимият башлыклары «командасы»н тынлаучылар да очрый. Менә бер мисал. Берәү бер предприятиене яптырып, аның базасында үзенең туганы өчен икенче предприятие ачмакчы була. Хакимият башлыгы тарафыннан хуплау таба. Куркыныч астында калган предприятие хуҗалары, үз төбәгендәге судтан яклау күрмәгәч,

безгә мөрәҗәгать итте. «Урындагы кешеләр» арбитраж судына да басым ясамакчы булганнар иде, әмма без җирле судның гаделсез хөкемен кире кактык. Шулай итеп, беркемгә дә буйсынмавыбыз аркасында, әлеге предприятиене һәм бик күп кешенең эш урынын саклап калдык.

**—Ничек уйлыйсыз, безнең илдә коррупция кайчан да булса бетәрме?**

—Миңа еш кына: «Кайчан да булса җинаятьчелек бетәрме?»—дигән сорауны бирәләр иде. Моңа гадәттә болайрак җавап бирәм: Җир йөзендәге беренче җинаятьче Адәм белән Һаваның улы Каин булган—ул үзенең туганын үтергән. Җинаятьчелек шуннан бирле килә. Аның белән көрәштә уныш белән унышсызлык чиратлашып тора: йә без аны җиңәбез, йә—ул безне. Коррупция белән дә нәкъ шул хәл. Минемчә, безнең заманга Чыңгыз Хан җитми. Аның чорында җинаятьчелек булмаган—кечкенә генә җинаять өчен дә, әйтик, елгага кече йомышын башкарган өчен дә (ул чакта коелар юк, суны елгадан эчкәннәр), кемлегенә карамастан, каты җәзага тартканнар. Җәза котылгысыз булган.

**—Бүгенге заман шартларында нәрсә эшләргә мөмкин?**

—Беренчедән, арадашчы структуралардан котылырга кирәк. Элек бездә бер финанс министрлыгы бөтен мәсьәләне хәл итә иде. Хәзер исә эреле-ваклы дәүләт оешмалары күп—төрле инспекцияләр, казначейство, алкогольгә каршы көрәш инспекциясе, транспорт инспекциясе... Бу учреждениеләрнең берсенең дә кирәге юк, алар халыктан көчләп акча алып ятучылар гына.

Икенчедән, законнарны төгәл, ачык, аңлаешлы итеп язарга кирәк—бер генә министрлык та үзеннән өстәмә инструкция кертерлек булмасын.

Өченчедән, законнарны көчәйтергә кирәк. Мәсәлән, кеше үтерүчеләрне гомерлек төрмәгә ябалар—ни өчен ул җинаятьчеләрне гомер буе ашатып яткырырга? Юл-транспорт фаҗигаләре китереп чыгаручыларга карата да законнар йомшак. Юл кагыйдәләрен даими бозучыларның машина йөртү таныклыкларын гомерлеккә алырга кирәк! Ә инде исерек килеш руль артына утыручылар—алары булачак кеше үтерүчеләр бит! Исерек килеш кеше таптатканнарын исә үтерүче буларак хөкем итәргә.

Законны хәзер кем яза? Депутатлар. Ә алар кемнәр? Җырчылар, спортчылар—алар чын законның ни икәнен беләме? Бу эшне юристлар, икътисадчылар башкарырга тиеш.

**—Эш процессында нинди дә булса карар чыгарганнан соң үкенгән чакларыгыз булмадымы?**

— Юк. Бер генә суд карарын да законсыз чыгармадым дип уйлыйм. Миңа әле дә элек эшләгән судьялар белән очрашып торырга туры килә, рәхмәт әйтәләр, намуслы булдыгыз, беркайчан да мәҗбүр итмәдегез, диләр. Бу—минем өчен бик куанычлы. Бервакыт Мәскәүдән суд бинасының ишек төбенә милиционер куярга дигән күрсәтмә килде. Ә мин: «Кешеләр судка иркенләп кереп йөрергә тиеш»,—дидем. Алар бит безгә кызык эзләп килми. Судьяларны да игътибарлы булырга өйрәттем. Шул ук ерак Әстерхан өлкәсеннән, мәсәлән, кеше ике тәүлек буе килә. Аның гозерен өстән-өстән генә тыңлау гафу ителә торган нәрсә түгел.

**—Судларның кирәге калмаган көннәр булыр микән?**

—Булмас. Бала нәрсәнең җинаять икәнен, аның өчен нинди җәза биреләчәген белеп үсәргә тиеш—ә бездә әлегә ул юк. Менә бер вакыйга. Хатыны ире өстеннән җинаять эше кузгатуларын сорый—ире ана кул күтәргән, «үтерәм!» дип кычкырган. Мин бу иргә әйттем: «Аңлат хатыныңа: сине утыртсалар, чыккач, сине эшеннән куачаклар һәм ана балагыз өчен эш урыныннан алимент килмәячәк. Кайчан да булса синнән «судимость» алыначак, әмма ул «дело»нда калачак. Ә бер 8-10 елдан малаеңның ФСБга, яисә полициягә, оборона заводына һәм тагын шундый оешмаларның берсенә эшкә керәсе килер—аны алмаячаклар, чөнки әтисенең

«судимосте» бар. Димәк, хатының баласының язмышын да боза диган сүз»,—дидем. Бу хатынга шулай хокук дәресе бирдек.

**—Фарук Фатыйхович, Арбитраж суд рәисләре билгеле бер срокка гына билгеләнәме?**

—Мине «гомерлеккә» дип билгеләделәр—ул чорда шундый закон иде. Власть үзгәргәч, бу срокны алты елга калдырдылар. Дөрес, посттан киткәч тә эшләргә мөмкин—фән белән шөгыльләнергә, мөгаллимлек итәргә, дәүләт хезмәтенә барырга. Мина болар кирәкми дип уйлыйм. Балачактан килгән һөнәрем бар—әле дә кулымнан балта төшми. Шәһәр читендәге йортымда бөтен нәрсә үз кулларым белән эшләнгән. Шуннан тәм, ямь табам, бакча үстерәм. Чит илләрдә күп йөрим. Китап язарга да ниятем бар—анысын Казанның мең еллыгына килгәч, Россиянең беренче президенты Михаил Горбачев тәкъдим иткән иде.

**—Матур әдәбиятка ихтирамыгыз зур икәнен беләбез. Кемнәрнең әсәрләрен яратып укыйсыз? Нинди тапшырулар карарга яратасыз? Татар җырчыларыннан кемнәрне тыңлыйсыз?**

—Күреп торасыз, китапханәм зур, классик әдәбиятны да, дөнья әдәбиятын да, заман язучыларының әсәрләрен дә калдырмый укып барырга тырышам. Дөнья халыклары тарихын, бигрәк тә үзебезнең татар халкының тамырларын өйрәнәм, телләр үзләштерәм—болар беркайчан да туйдырмый. Татар концертларын тыңларга яратам. Хәзер яшь җырчылар күп, җырласыннар, әмма Илһам Шакиров белән Әлфия Афзаловага берсе дә җитә алмас кебек.

**—«Казан утлары» белән сез ни дәрәҗәдә таныш?**

—«Казан утлары»н озак еллардан бирле алдырам. Ул—үзе тоташ бер тарих. «Казан утлары»—татарның беренче журналы, әдәбиятыбызның энциклопедиясе, аның рухи көзгесе. Заманнан артка калмас өчен матур әдәбиятны гына түгел, публицистик әсәрләрне дә укып барырга тырышам.

**—Кызыклы әңгәмәгез өчен рәхмәт! Дөньяда күпне күргән тәҗрибәле кеше буларак, бәлки бүгенге яшь буынга әйтер сүзләрегез бардыр?**

—Үсмер чагымда яна туган сарык бәрәненә игътибар иткәнем бар иде—бөдрә йонлы, матур, әмма үзенең бер дә акылы юк. Адәм балалары да шулай: матур булып туа, ә акылны бөртекләп үзенә җыярга кирәк—шул чагында гына тулы канлы тормышта чын кеше булып яши аласын...

*Әңгәмәдәш*—**Алмаз ГЫЙМАДИЕВ**

Габдулла
Галиев

## ДОГА КЫЛЫП КИТ!

Быел әллә ничегрәк булды. Тормыш мәшәкатьләре артыннан куып йөри торгач, һәр елны җәй башында зыярат кылырга бара торган вакытым сузылды.

Ниһаять, иртәгә бу изге гамәлемне үтәргә булып, йокларга яттым. Иртәнге намаздан соң кояш бераз күтәрелә төшкәч, тәһарәтемне яңартып зиратка юнәлдем. Зиратыбыз ерак түгел безнең, авыл башында гына. Капкасыннан кергәч, тукталып, «Әссәламү галәйкүм, кабер әһелләре!»—дип сәлам биреп, белгәннәремне укып дога кылдым. Шөкер, зыярат кылу тәртипләрен бераз беләм, шулай да дулкынландыра, күңелем сагында ялгыш җибәрмәдемме икән дигән уй тора. Хәер, бирегә бер дә дулкынланмыйча кем генә керә ала икән? Зират капкасын ачуга син мондагы тормыш белән яши башлаган кебек буласың: капка артында калган дөнья онытыла, сине тел белән генә аңлатып булмый торган халәт биләп ала. Үзеңнең дә кайчандыр бирегә бөтенләйгә киләсеңне күз алдына китереп, тән күзәнәкләре чемердәп куя.

Ә шулай да җәйге зират күңелле. Кайда гына күз төшермә—яшеллек, чәчәкләр. Шул илаһи күренешкә тагын да ямь биреп кошлар сайрый, зиратның нәкъ урта бер җирендә күккүк моңлана. Кошларның сайравы да урмандагы кебек түгел, бирэдәгесе бәгыреңнән үзегенә үтеп керә, әйтерсең лә, бу моң агач башларыннан түгел, каберләрнең үзләреннән агыла. Бу моңлы аһәңнән күңелең йомшый, күзеңнән сыгылып чыккан яшь керфекләреңне каплап ала. Ямансу, бигрәк ямансу шул бирэдә! Һәм сагышлы да—күңел кыллары сагыштан өзелергә җитеп тартыла.

Зиратта күз яше күрсәтергә ярамаганын исемә төшереп, кульяулык белән чыкканын сөртеп алгач, газиз әниемнең, бәгырьләрне өзеп уналты яшендә үлеп киткән улымның каберләре янында һәм туган илен яклап сугыш кырында башын салган әтиемнең рухы өчен кыйблага карап кылган догаларым тәмам булгач, урынымнан тордым да, таныш гүр ияләренең каберләре алдында туктала-туктала зираттан чыгу ягына юнәлдем. Әнә шулай чыгып барганда һич тә көтелмәгән хәл булды: алдыма лап итеп ботак кисәге килеп төште. Сискәнеп тукталып калдым. Чү?! Нәрсә соң бу? Җил эшеме? Алай дисәң, яфрак селкенерлек тә җил юк, тирә-як тып-тын. Башымны югары күтәреп, агач башларына текәлдем. Кайсысын гаепләргә белмичә аптырап торганнан соң, каршымдагы кәүсәсе муртая, тузлары куба башлаган юан каенга: «Һәй, картлач! Алдыма төшкән ботак синең бүләгенме?»—дип аваз салдым. Каенның карасу төскә кергән ботакларындагы сирәгәйгән яфраклары минем тавышымны ишеткән кебек лепелдәшеп куйдылар да, кинәт әллә нәрсә булды, каен кәүсәсе әйләнәсе

бер мизгелдә ялт-йолт яшен ялтыраган төсле күзне камаштырып бер яктырып, бер сүнеп алды. Мин башымның авыраеп киткәнен тойдым. Күз кабакларым да авыр нәрсә бастырган төсле йомыла башладылар... Шул ук мизгелдә каен ягыннан: «Гафу ит, адәм баласы! Синең алдыңа ботагымны сындырып мин ташладым»,—дигән аваз ишеттем.

—Син?

—Әйе... мин...

—Аны эшләү нигә кирәк булды соң?

—Сине туктатасым килде.

—Мине нигә туктатырга кирәк соң?

—Хәзер әйтәм. Мин инде ничә еллар күзәтәм сине. Син һәр елны бирегә зыярат кылырга киләсең. Син килгән саен мин бу елны, бәлки, минем яныма да тукталып китәр дигән өмет белән көтеп алам сине. Ләкин син янымнан гамьсез генә узасың да китәсең. Менә быел алдыңа ботагымны ташлап булса да туктаттым сине.

—Нигә туктаттың?

—Дога кылып кит!

—Кемгә?

—Минем тамырларым астында ятучы гүр иясенә.

—Әйтче, андый аерым догага лаек кем ул?

—Ул—сиңа таныш адәм.

—Мин андый адәмне белмим.

—Беләсең. Малай вакытыңны хәтерлә!

—Тырышам да, хәтерли алмыйм бит әле менә...

—Әйдә, алайса, икәүләп хәтерләп карыйк. Исеңә төшер: син иптәш малайларың белән өлкәннәргә ияреп аны озатырга килдең.

—Шуннан?

—Озата килүчеләр кабер өстенә каен утыртып калдырыйк дигәннәрдер, мөгаен. Сез берничә малай зират куелыгына кереп каен үсентесе эзләргә керештегез. Син мине табып казып алдың. Хәтерлисеңдер, мин бармак юанлыгы гына каен малае идем.

—Менә хәзер хәтерли башладым кебек. Без сине Борһан абыйның кабере өстенә утырттык, шулаймы?

—Шулай. Иң аянычы шул: озата килүче коммунист дусларының «без сине онытмабыз» дигән вәгъдәләре ялган булып чыкты бит. Инде әнә күпме еллар үтте, аның янына килеп искә алучы да, дога кылучы да юк. Тирә-ягымдагыларга дога кылынганда миңа бик авыр. Күреп торасыңдыр, мин бик нык картайдым, тамырларым череп бетә бара, кәүсәм мертайды, тиздән авып төшәрмен дә, зираттан чыгарып ташларлар. Аның кабере дә минем артымнан ук җир белән тигезләнеп юкка чыгар. Син дә бирешкәнсең, карт кеше бүген бар, иртәгә юк. Үтенечем шул, дога кылып кит! Исәннәрдән аның каберен белүче кеше син генә бит хәзер. Китеп барма. Дога кыл!

—Гафу ит, мин аңа дога кыла алмыйм. Ул бит фанидан иман китермичә, Аллаһының барлыгына ышанмыйча китеп барды. Юк, юк, мин аңа дога кылып өстемә гөнаһ ала алмыйм.

—Чү! Алай кырт кисмә! Исеңә төшер, бик болгавыр еллар иде бит ул. Бәлки, ул үзенең наданлыгы аркасында шаукымга бирелеп адашкандыр. Аның кебек алданганнар аз булганмыни ул елларда. Мәрхәмәтле, шәфкатьле булыйк!

—Ничек итеп аңлатыйм соң сиңа... Минем догам барыбер аңа барып ирешмәячәк бит. Ирешкән хәлдә дә, кабул булмас...

—Анысы Аллаһы Тәгалә эше. Ул үзенең колын ташламас. Дога кыл!

Мин кинәт сискәнеп, айнып киттем.

Тир баскан маңгаемны кулъяулыгым белән сөртә-сөртә үз хәлемә кайтырга тырыштым. Бераз хәл алгач, хәтер йомгагымны сүтә-сүтә каен әйләнәсендәге агачларны күзәтеп чыктым. Бередә каеннан көньяктарак юан гына имән булырга тиеш иде. Әнә, урынында утыра икән әле, әмма еллар үзенекен иткән—кабыклары коелып ул да бирешкән, шәрә кәүсәсе генә калган бичараның... Әйе, таныш урыннар иде бу миңа!

Ни соң бу? Чыннан да, каен миңа дәшеп, безнең арада шундый гәп булдымы? Әллә хикмәтле бер төш күрдемме? Әллә инде күңел күзем бу урынны танып алып, түрдәге хәтерем уянып, баш мием бөтенесен дә тикшереп һәм эшкәртеп, сөзмәсен аңыма шулай үтемле, тәэсирле төскә салып бирдеме?..

Шактый вакыт икеләнеп торсам да, дога кылмыйча китә алмадым мин моннан.

Зиратны чыккач, заманында бөтен авылны тетрәндергән вакыйганы күз алдымнан кичерә-кичерә өйгә таба атладым.

...Авылны сөт күбеге кебек ап-ак шомырт чәчәкләренә төргән утыз сигезенче елның мае. Урамда пыр тузып уйнап йөргәндә, югары оч малайлары шомлы хәбәр алып килделәр. «Ишеттегезме әле, Борһан абый үлгән,—диде Котдус. Кемнеңдер вафат булуы авылда һәрвакыт зур вакыйга итеп кабул ителә, аны тизрәк бер-берсенә житкерергә ашыгалар. Мин уенны ташлап өйгә йөгердем. Өйдәгеләр ишеткәннәр икән инде. «Үткән шимбәне капкалары төбендә күкрәгән тотып йөткереп утыра иде. Ярый әле янына туктап хәлен белешкәнмен. «Бер дә алга киткән жирем юк, көннән-көн рәтем бетә бара»,—дип зарланып калган иде мәрхүм»,—диде әти. «Чехут белән авырый иде түгелме соң үзе?"—дип сорап куйды әни. «Чехут дип сөйләшмиләр инде хәзер. Туберкулез диләр»,—дип әнине төзәтте әти. «Ничек дип атасаң да бер инде, әтисе. Ул чирдән котылу юк диләр. Шомырт чәчәк атканда алып китә диюләре дә хак икән»,—диде әни.

Ул арада күршебез Минезакир абзый кереп житте. Ишек катындагы урындыкка утырып исәнлек-иминлек сорап дога кылгач, йорттагыларга күз йөртеп: «Ишеттегезме әле, Борһанетдин вафат бит»,—диде.

—Ишеттек. Урыны ожмахта булсын,—диде әти.

—Ай-һай, булыр микән?—Минезакир абзыйның йөзе борчулы төс алды.

—Алай шөбһәләнергә ярамый,—диде әни. — Иншаллаһ, Аллаһының рәхмәте киң, ташламас.

—Сүзең алтын, бик шулай булсын иде дә, килен,—диде Минезакир абзый... Әмма бит Раббебез үзен танырга куша. Ә ул... Борһанны әйтәм... нишләгән?

Әти белән әни сораулы караш белән Минезакир абзыйга текәлделәр.

—Борһанетдиннең партиянни икәнен беләсез бит?

—Беләбез. Шуннан?

—Шуннан—шул, үзенең хәлен сизенеп, өзеләсе көнне иртән барысын да янына жыеп әйткән бу. «Миңа мулла чакыртмагыз. Женаза намазы да укытмагыз, берсе дә кирәкми. Мине озын ящиккә салып, коммунистларча күмегез»,—дигән.

Әти белән әни өчен гажәп, хәтта бик гажәп хәл иде бу. Әти бер ноктага текәлеп башын селкеп-селкеп торды да: «Малаеның сүзенә әтисе Сабир карт нишләде икән?» — дип, авыр сулап куйды.

—Нишләсен,—диде Минезакир абзый.—Баштарак бик нык каршы килгән. Күрше-тирә картлар да бергәләп үгетләп караганнар, юк, Борһанетдинне берничек тә көндерә алмаганнар. «Мин коммунис булып яшәдем, коммунис булып үләм. Жәсәдемне дә туфракка коммунисларча коммунислар индерсен»,—дип кистереп әйткән ди Борһанетдин.

Уфылдашып утырган өйдәгеләрне калдырып, мин урамга, иптәшләрем янына элдердем. Урамда да сүз Борһан абый турында гына иде.

Бу көтелмәгән хәл белән бигрәк тә өлкән яшьтәге әби-карчыклар килешергә теләмәде. «И-и, мулла чакыртмыйча, женаза-намазсыз авылда мәет озату ничек була инде ул, ә? Шәригатебезгә каршы килеп ... Ата-бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтләребезне бозып... Кит, гомер булмаганны. Әстәгъфирулла үә әтүби иләйһи! Авылың белән әллә ни күрерсең,—диештеләр як-якка каранып. Ул көнне авыл урамнары әллә ничек шомлы, куркыныч иде. Без малайларның коммунист кешене ничек күмүләрен үз күзебез белән күрәсебез килеп, күңелләребез ашкынып әсәрләнде.

Иртәгә иртән Борһан абыйларның йортына урам аркылы кыйгач кына торган Нәбиулла абзыйларның капкалары турына җыелырга сүз куешып өйләребезгә таралдык.

Иртән, кояш күтәрелеп килгәндә, шул сүз куешкан урында идек инде без. Биредән Борһан абыйларның йортлары, капка төпләре уч төбендәге кебек күренеп тора, рәхәтләнеп күзәтүеңне бел.

Хәер, минем ул йортка кергәнем бар иде. Үткән елны сыерыбыз көтүдән чирләп кайткач, әти: «Улым, бар әле, ветсанитар Борһан абыеңны чакырып кайт»,—диеп аларга йөгерткән иде. Борһан абый колагына эрзин трубка куеп сыерыбызның күкрәген, эчен тыңлап тикшерде дә, башын түбән иеп уйланып торгач, кулына тотып килгән букчасыннан дарулы шешә алды. Аннан йөткерә-йөткерә шул даруны чиләктәге суга тамызып, сыерыбызга эчерде. Шунысы исемдә калган: Борһан абыйның йөзе шул вакытта ук кипкән лимон кебек сары, күз төпләре убылган чокыр кебек күгелҗемләнеп эчкә батып тора иде. Күрәсең, әни әйткән «чехут» белән инде авырый башлаган булгандыр, мәрхүм.

Көтәбез. Барыбызның да күз карашлары шул йортның капка төбенә төбәлгән. Әлегә капкадан чыгып-кереп йөргән берничә хатын-кыздан башка берни дә күренми. Бераз торгач, кереп йөрүләр ешайды. Шул арада берничә ир-ат ияртеп, авыл кешеләре партург дип дәшә торган Хөбби абзый, алар артыннан ук камсамуллары белән комсұрк Рабигый абый кереп китте. Алар эчкә үтү белән зур капканы киереп ачып куйдылар. Күз карашларыбыз шул якта, тын да алмыйча көтәбез. Озак көттермәделәр, ул арада кызыл ситсыга төрелгән табутка салып Борһан абыйны күтәреп чыктылар да, тукталып калдылар. Ул арада култык астына гармун кыстырган колхозның бердәнбер «полуторка»сы шоферы Алекси абый һәм җилкәләренә мылтыклар аскан камсамуллар да чыгып үз урыннарына бастылар.

Хөбби абзый табут күтәргән сафны күздән кичерде дә, кулы белән ишарәләп кузгалырга команда бирде. Табут алдына басып шуны гына көтеп торган Алекси абый гармунын бөтен мехы белән сузып ниндидер кызганыч урыс көе тартып җибәрде дә, атлап китте. Аның артыннан табутны күтәргәннәр кузгалдылар. Капка төбендә Борһан абыйның әнисе Фәрхенурттәй белән хатыны Зәйтүнә апа яулык очлары белән яшьле күзләрен сөртә-сөртә елап калдылар. Соңрак ишетелде: Борһан абыйның әтисе Сабирҗан карт карчыгын кисәткән: «Бу хәлләрдән соң ул безнең малаебыз түгел. Кара аны, озатырга керәсе булма»,—дигән. Кергән Фәрхенурттәй, ана йөрәге түзәме соң инде!

Без малайлар да иярдек. Коммунистларча күмүнең ничек тәмамлануын азагына кадәр күрәсебез килде.

Урам буйлатып авылыбыз башындагы зиратыбызга юл алдык. Көпә-көндез, иртәнге сәгатьтә гармун шыгырдаганны ишетеп яшь-җилбәзәк капкадан йөгереп чыга. Табутны күргәч, тизрәк кереп китү ягын карый. Берәүләр безнең үткәнне койма ярыгыннан, икенчеләре кече капкаларын кысып кына ачып күзәтеп калалар. Алекси абый кызганыч көйләрне алыштырып кына тора. Шуларның берсен бер мең тугыз йөз бишенче

елны японнар белән сугышта океан төбенә киткән «Варяг» матросларына багышлап чыгарылган җыр икәнен үсә төшкәч, кабат ишетеп белдем.

Әкрен генә атлап барабыз, авыл халкы авылдан чыгып качкан диярсең: очраучы да, озатып калучылар да берән-сәрән генә, аларның да берәүләре: Аллаһыдан гафурын-рәхим сорап кыйблага борылып дога кылып калалар. Икенчеләре нидер пышылдап йөзләрен читкә боралар. Капкаларыннан башына салган ак шәлен җилфердәтеп чыгып килүче Мәгълифә әби түзмәде, бот чабып: «Әстәгъфирулла! Әстәгъфирулла!—дип кычкырып җибәрде дә, күзен усалландырып тезеп китте.—Нишләвегез бу? Нишләвегез, җәмәгать? Гомердә булмаганны... Авыл картлары ни карый? Нишләп динебезне мәсхәрә итәргә ирек куялар! Иманын югалткан адәмгә нигә изге зиратыбыз туфрагыннан урын бирәләр? Йә Раббем, кичер...» Әллә кайдан гына Нурҗиһан апа атылып килеп чыкты да, карчыкның кулыннан эләктереп алды: «Күп сөйләшмә! Теленне тый, юләр карчык. Партияннилэргә каршы сөйләргә ярыймени!? Узган атнаны гына Кәримулла абзый белән Миннегалине төн уртасында килеп энкеведе дигәннәре алып китте. Сине дә йөзьяшәр карчык дип тормаслар, жылы түшәгеңне дә кайтып күрә алмассың. Әйдә! Әйдә! Кояш күрде, жил алды»,—дип, тегене җилтерәтеп өенә алып кереп китте.

Ниһаять, зират капкасы алдына килеп туктадык. Сүз әйтүче булмагач, ияреп без дә эчкә үттек. Табутны җиргә төшереп, казылган кабер алдына куйгач, Хөбби абзый, йомшаган күнелен басарга тырышып борынын тарткалап торгач: «Без бүген Ленин партиясенә биргән антына соңгы сулышына кадәр турылыклы калган коммунис иптәшебез белән хушлашабыз», диде. Тагын нәрсәләрдер сөйләде, барсы да исемдә калмаган. Сүзен: «Хуш, коммунис иптәшебез. Без сине бервакытта да онытмабыз. Кабереңә сукмагыбыз өзелмәс»,—дип тәмамлады.

Мәетне әкрен генә кабергә төшерделәр. Күмү башланды, тимер көрәкләр бер-берсенә бәрелеп чыңлады, өлкәннәр кабергә туфракны учлары белән салдылар. Җир өстенә кабер калкып чыккач, казыгына кызыл йолдыз беркетелгән, тактасына Борһан абыйның исем-фамилиясе, туган-үлгән елы, ае язылган шул һәйкәл кебек нәрсәне кабер башына кадап куйдылар. Кайсысыдыр шулчак, агач утыртырга кирәк, диде. Хөбби абзый безгә: «Ягез әле, малайлар, берәр төрле агач үсентесе алып чыгыгыз», диюгә зират куелыгына кереп үсенте эзләргә керештек. Каен үсентесен беренче булып мин табып алдым. Аны мәетнең аяк очына утыртып та куйдылар. Ул арада: «Хушлашырга!»—дигән команда булды. Затворларны шалтыратып мылтыкларга патроннар салдылар. Кабердән берничә адым арткарак чигенеп бастылар да, мылтыкларын һавага төбәп бердәм дөпелдәтеп өч тапкыр рәттән залп бирделәр. Агач ботакларына кунып сайрап утырган кошлар куркудан котлары алынып, чыр-чу килеп һавага күтәрелде. Зиратта шомлы тынлык урнашты. Озата килүчеләр шактый вакыт бер-берсенә күтәрелеп карарга курыккан шикелле башларын түбән иеп, үз уйларына бирелеп басып тордылар.

Белмим, нәрсә уйладылар икән алар ул минутларда? Табут күтәреп, гармун шыңгырдатып урамнан узганда авыл кешеләренең ярым нәфрәт белән күзәтеп калган чытык йөзләре, ә бәлки, барысын да тагын бер кат сискәнергә мәҗбүр иткән сүзләре белән Мәгълифә карчык күз алларына килгәндер. Берсе көрсенеп, авыр сулап куйды. Барсы да уйларыннан айнып башларын күтәрделәр, сүзсез генә кайтыр юлга кузгалдылар. Без дә иярдек. Безнең дә күңелләребездә тел белән генә аңлатып булмый торган авыр тойгылар иде.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Зур Болгаер һәм Кече Болгаер

Зур Болгаер һәм Кече Болгаер авыллары Апас районына керә. Зур Болгаердан район үзәге Апаска 26 чакрым, ул үзе жирле үзидарә Советы үзәге. Кече Болгаер исә Апастан 23 чакрымда, жирле үзидарә Советы исәпләнгән Зур Болгаердан 3 чакрым ераклыкта утырган. Болгаер атамасы Казан ханлыгы чоры чыганакларында Болгар Кривой-Болгаер дип күрсәтелә. 1565-67 елларга караган мәгълүматны туплаган Зөя өязенең теркәү кенәгәсендә дә авыл исеме нәкъ шулай бирелгән. XVIII йөзгә караган мәгълүматларны без Д.А.Корсаков чыганагыннан табабыз. Зур Болгаерда XVIII йөздә ясаклы татарлар саны 174, керәшен татарлары 15 булган. Кече Болгаер авылында ясак түли торган татарлар 58, керәшен татарлары 15 саналган. XIX йөз чыганагы буенча (А.Артемьев), Шаһиян суы буена урнашкан Зур Болгаер авылындагы 154 хужалыкта 475 ир-ат һәм 301 хатын-кыз көн иткән, авылда бер мәчет булган. К.П.Берстель китабында күрсәтелгәнчә, Олы Болгаер авылында барлыгы 1335, Кече Болгаерда 789 татар кешесе яшәгән.

Нажия апа Борһанова мәгълүматларына караганда, Болгаер, Бәки һәм башка авыллар халкы бергәләшеп Чабыр жыены үткәргән. Чабыр бик олы һәм билгеле бәйрәм булган. Анда Сембер, Самара, Нижгар якларыннан да кунакка килгәннәр. Ике Болгаер халкы да бик гади һәм кунакчыл булган. Кайберәүләр килгән кунакларын әйбәтләп сыйлап жибәрү өчен ужымнарына кадәр сатканнар.

Заманында Зур Болгаер һәм Кече Болгаер авыллары халкы да чукындыру сәясәтеннән зур зыян күргән, халыкнын бер өлеше көчләп христиан диненә күчерелгән. Авылларда ташланган керәшен зираты урыннары бар, ләкин керәшеннәр калмаган, алар күптән янадан үз диннәренә кайтканнар.

Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, Зур һәм Кече Болгаер авылларына Болгар ханлыгыннан ике агай-эне килеп урнашкан. Олысы Инеш яисә Шаһиян суы ярына, икенчесе Иске йорт дип атала торган урынга утырган. Ләкин, су житмәү сәбәпле, халык авылнын хәзерге урынына күчкән.

Зур Болгаер белән Кече Болгаер авыллары арасында Даулы тигезлеге бар. Бу урындагы жир өчен ике авыл—Зур Болгаер һәм Кече Болгаер халкы сугышканнар, хәтта Зур Болгаернын өч кешесе үтерелгән дип сөйлиләр. Ике авыл яныннан да Инеш яисә Шаһиян суы ага.

* * *

Кече Болгаер авылы урамнарыннан һәм басу-кырлардан күңелле тавышлар чыгарып шифалы сулы Карлыганлык чишмәсе, ташларга бәрелә-бәрелә Шалтыравык чишмәсе, Нәжип, Хәбир, Һади, Зәбир һәм Челтер кизләүләре һ.б. агып ята. Челтер чишмәсе ермак буйлап ага. Башлангычын ул Алан чишмәләреннән ала. Бу чишмә

*Дәвамы. Башы 2006 елның бнчы санында.*

турында бер риваять тә йөри. Имештер, кыш көне чишмә янындагы ташны ваткач, аның астыннан бер көтү елан чыга. Алар качып беткәннәр, ә урыннары кап-кара булып калган, ди.

Авыл янында урманнар да күп. Әтрәч борылышындагы Биектау урманында элек боланнар очраган. Янәшәдә генә Куак урман, Куаклык урман, Карамалык урманнары бар.

Кече Болгаерның кайбер гаиләләре чукындырылган. Ләкин алар барысы да кире исламга кайтканнар.

Бөек Ватан сугышына авылдан 186 кеше китә. Сугыш кырында 79 кеше ятып кала. Исән калган ветераннар һәм сугыш елларында эшләгән өлкәннәрне авылда бик хөрмәтлиләр. Гомумән, Кече Болгаерда өлкәннәргә хөрмәт зур.

Болгаер атамасының кайдан килеп чыгуы турында ике фикер әйтергә була. Беренчедән, аны болгар этнонимы белән бәйләргә мөмкин. Икенчедән, әлеге авылга нигез салган кешенең Әбелхәер исемле булуы да бик ихтимал. Авыл тарихына кагылышлы документлар күбрәк туплангач, атаманың килеп чыгышы, һичшиксез, ачыкланыр.

## Идрәс–Тинки

Идрәс-Тинки авылы Апас районында, район үзәге Апастан 8 чакрымда, Каратун тимер юл станциясеннән—20, Тәтеш пристаненнан 28 чакрым ераклыкта урнашкан,

А.Артемьев җыентыгында күрсәтелгәнчә, авылның 61 хуҗалыгында 176 ир-ат һәм 154 хатын-кыз булып, авылда бер мәчет эшләгән. К.П.Берстель мәгълүматларына караганда, авылда барлыгы 593 татар кешесе гомер кичергән.

Нажия апа Борһанова мәгълүматларына караганда, Идрәс-Тинки авылы халкы июнь башларында, күршедәге Әнәле, Иске Йомралы, Каратай һәм Дүртөйле авыллары халкы белән бергәләшеп, Шыкма исемле җыен үткәргән.

Аксакаллар сөйләве буенча, авылга XVI йөзнең 50нче елларында Идрәс (икенчеләре Тинкә баба, ди) исемле кеше нигез салган.

Авыл нигезләнгән вакытларда бу тирәдә кара урман булган. Ышна-басулар урман төпләгән кешеләрнең исемнәре белән аталган.

Авылның көнчыгыш ягыннан Баба-Тау сыртлары күтәрелеп китә. Ә көнбатыш ягыннан үзәнең йөзьяшәр имәннәре, мәһабәт наратлары, зифа буйлы каеннары, бөрлегәне, җиләкле аланнары белән урман үзәнә чакырып тора. Баба-Тау сыртлары яныннан кояш нурларында җылынып, салмак кына Үләмә елгасы агып ята.

Авылда күлләр дә бар. Ишбулат бабай, Габдулла (кызганыч, ул хәзер кипкән), Гилмуч, Бетле, Шәм күлләре авыл табигатен ямьләп торалар,

Авыл уртасында бер урын Мулла бакчасы дип атала. Элек ул мулланың яшелчә бакчасы булган. Җәй көне бу урынга яшьләр кичке уенга җыела. Авылның түбән очында халыкка күп игелек күрсәткән Керәнлек басулары сузыла. Керән күп үскәнгә халык аны шулай атаган. Ул ямь-яшел болынлык, җәен аннан авыл халкы мул итеп печән җыеп ала. Авылда халык телендә Ком базы дип аталган чокыр бар. Элек-электән авыл халкы моннан үз кирәгенә ком, балчык алып файдаланган.

Авылның өч урамында күптәнге өч кое бар. Ләкин халык алар суыннан файдаланмый инде. Авылның югары очында бер кизләү чыга. Хәзер авыл көннән-көн үсә, матурая, яңа йортлар калкып чыга, яшь гаиләләр арта. Авыл уртасында мәчет салынган, мәдрәсә ачылган. Алтын куллы, тырыш, тирә-юньдәгеләргә карата игелекле кешеләр яши Идрәс-Тинки авылында.

## Иске Әнәле

Иске Әнәле Апас районында, район үзәге Апас авылыннан 2 чакрымда, Каратун тимер юл станциясеннән—12, Тәтеш пристаненнән 33 чакрым ераклыкта урнашкан Әнәле—борынгы авыл. Ул Казан ханлыгы чорында ук булган. Археологлар Иске Әнәле авылы янында борынгы болгар чорларына мөнәсәбәтле шәһәрлек билгеләгәннәр. К.П.Берстель җыентыгында күрсәтелгәнчә, Иске Әнәле авылында

1359 татар кешесе яшәгән.

Нажия апа Борһанова мәгълүматларына караганда, Әнәле авылы халкы күршедәге Иске Йомралы, Идрәс Тинки, Дүртөйле, Карабай авыллары халкы белән бергәләшеп июнь башында Шыкма исемле җыенны бәйрәм иткән.

Олылар сөйләвенә караганда, элек бу авыл ике чакрым түбәндәрәк, хәзер Ур әйләнәсе дип йөртелгән җирдә утырган булган. Бу ур казылып ясалган 1-1,5 метр биеклектәге өемнән гыйбарәт. Ур әйләнәсе янында Әнәле 200 еллар чамасы яшәгән. Авыл атамасы шул торак пунктны беренче башлап оештыручы һәм нигезләүче Йәнейле исеме белән йөртелгән. Авыл кечерәк Инеш янында урнашкан булган. Бу урын елга-суларга бай булмаганга күрә һәм тагынниндидер сәбәпләр аркасында, соңыннан халык хәзерге урынына күченгән. Бу яңа җир мул су чыганакларына һәм урманнарга бай һәм бәрәкәтле урын була. Элекке урыннан яңа урынга күчеп беткәннән соң авыл Иске Йенәйле исемен ала. Тора-бара авыл исеме Иске Әнәле дип йөртелә башлый. Гасырлар узу белән авыл зурая, үсә һәм ныгый. 1800 елларга авылда 300дән артык хуҗалык була. Авыл үскән саен чәчүлек җирләргә мохтаҗлык арта бара. 1895 елларда Иске Әнәле халкы күршедәге Дүртөйле кешеләре белән берләшеп авылдан 5 чакрым ераклыкта Шәм күле ышнасы җирен ачалар. Иске Әнәле авылында байларның күп булуы һәм җирне бүлеп бирүче землемерны сатып алулары, ягъни ришвәт бирүләре нәтиҗәсендә, бергә ачылган 103 гектар чамасы Ышна җиренең 25 гектары гына Дүртөйле авылы кешеләренә бирелә, 78 гектары Иске Энәле авылы милке итеп беркетелә. Бу гаделсезлек ике авыл кешеләре арасында зур низаг китереп чыгара һәм ул 1930 елларга кадәр дәвам итә. Үсеп житкән икмәккә ут төртү, Тәтеш пристаненә икмәк ташый торган йөкчеләргә һөҗүм итүләр еш булып торган. 1930 елларда күмәк хуҗалыклар оештырыла башлагач, бу 103 гектар җир Калинин исемендәге колхозга (Татар Черкене) бирелә.

Шәм күленә хәзер камыш үскән, ул бетү алдында.

Әнәле авылы халкы нигездә икмәк үстерү һәм терлек асраучылык белән шөгыльләнә. Авылда 15 тегермән эшләгән. Шулардан 3 жил тегермәне, май сыгу, ярма яру, йон теттерү һәм калганнары он тарту өчен су тегермәннәре була. Тегермәннәрдән күрше авыл кешеләре дә файдаланган. Авылда тегермәннәрдән тыш 2 мир келәте (уңыш начар булган елларда ярлыларга икмәк белән ярдәм итү фонды сакланган), 1 җәмәгатьчелек кибете, 4 байлар кибете, мәчет һәм 9 тегермән буасы була. 1913-14 елларда бетон стеналы кизләү, бетон стеналы кер юу буасы ясала һәм авылдан читтәрәк күл казыла.

Авылда 10га якын бай яши. 1930-32 елларда 7 бай хуҗалыкның байлыгы тартып алына һәм гаиләләре Себергә җибәрелә.

Иске Әнәле авылында 1930 елда «Яңа ил» исемле күмәк хуҗалык (колхоз) оеша.

Заманында авыл халкының бер өлеше чукындырылган. Андагы керәки нәселен керәшеннәр дип йөртәләр. Зиратлары да аерым булган.

Элек Әнәле шактый зур авыл булган. Әнәле авылыннан 4 гаилә аерылып китеп, Дүртөйлене нигезләгәннәр.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# ТЫН ДӨНЬЯЛАР МОҢЫН ТЫҢЛАГАНДА...

## Нәкыйп Каштановка 70 яшь



Бу дөньяда үз гомерендә бер тапкыр да табибка күренмәгән яки кулына китап алып карамаган кеше юктыр. Гомер кадерле. Саулыгың китә башласа аның кадере тагын да арта төшә, шифаханәгә барырга туры килсә, аны бер белмәгән табиб кулына да тапшырасы килми, танышларыңны эшкә жигеп, белемле, тәҗрибәлесен эзли башлыйсың. Нәкыйп Каштановка да «Язучылар табибы» дигән исем тикмәгә генә ябышмагандыр. Хәер, утыз еллап гомерен республика клиник хастаханәсендә меңнәрләгән авырулар кабул итүгә багышлаган, медицина өлкәсендә фәнни тикшеренүләр алып барып югары нәтиҗәләргә ирешкән, «Точечный массаж» (Казан, ТКН, 1993), «Гангрена легких. Эмболия легких. Тромбоз. Инфаркт легких» (монография) (Казан, «Матбугат йорты» нәшрияты, 2006), «Трактат о врачевателе» (Казан, »Медицина» нәшрияты, 2006), «Клиническая пульмонология» (Мәскәү, «Триада-Х» нәшрияты, 2008) һ.б. хезмәтләр авторы, табиб-галим язучыларныкы гына була алырмы?

Нәкыйп Каштанов әдәбият дөньясына да медицина аша килеп керә дисәк ялгыш булмастыр. Әле медицина институтында укыган чагында ук республикада чыга торган газета-журналларда сәламәтлек, экология, дөрес яшәеш, дөрес тукланыш турында язмалары белән катнашып, укучыларыбызга табиб буларак кирәкле киңәшләрен бирә. Әдәби сүзгә тартылу, тәнне дәвалаганда җанга да игътибарлы булырга кирәклеге, кешене сүз белән үтереп тә, терелтеп тә булырга мөмкин икәнлеген аңлау кулына каләм алдыргандыр... Тән һәм җан берлеге шагыйрь өчен бербөтен.

*Гомер үтә,*
*Сизелми дә: йә сүз эзләп, йә сихәтләп -*
*Гүя бер йөрәк тибеше...*

Көндезләрен аның күз алдында күпме кеше язмышы, тормышы, саулыгы... Табиб күзе үткер. Каршысында гомеренең санаулы көннәрен яшәүчеләр дә очрамый калмый. Әле тормыш юлына аяк басып кына килүче яшь җан өмет күзе белән төбәлгән мәлләрдә югалып калмаска, аңа шагыйрьлеге ярдәмгә киләдер. Кешелек, Яшәеш, Гомер кадере турындагы юллар, бәлки, шул мизгелләрдә туадыр...

*Үзәгемә үткән гаҗизлектән*
*Дару эзләп табар идем -*
*Әбугалисина булсам әгәр...*

Нәкыйп Каштановның тормыш юлы шәхес буларак та кызыклы гына. Мәктәп, югары уку йорты эскәмиясеннән төшеп иненә ак халат салганчы аңа әле шактый гына авыр хезмәтләр башкарырга туры килә.

1942 елның 8 гыйнварында Чувашстан Республикасының Батыр районындагы Кыр-Бикшик авылында туган егет, урта мәктәпне тәмамлагач, берничә ел Әстерхан якларында балык промыселында, соңрак Уфа шәһәрендә кирпеч заводында эшләп ала. Сүз дә юк, ныклы ихтыяр көче, саулык, үҗәтлек сорый торган эшләр. Армия сафларына алынгач, дүрт ел буе Ак дингездә, Төньяк Хәрби дингез флотында хезмәт итүе дә чын ир-егетләрчә. Медицина институтын тәмамлаганнан соң юллама белән җибәрелеп Чистай районы хастаханәсендә эшли.

Н.Каштанов әдәбиятнең төрле жанрларында иркен иҗат итә. Ул тел, милләт язмышына да битараф түгел—эчтән янып, уйланып, борчылып йөргән уй-фикерләрен җәмәгатьчелек белән дә уртаклаша. Халкыбызның күренекле улларын зурлап язылган язмаларын туплаган «Бушлыкта ут янмый...» (Казан, «Сүз» нәшрияты, 2010) китабы басылып чыга. Әлеге китаптагы язмалар белән танышканнан соң, Н.Каштановның нәсел җебе Ф.Бурнашка барып тоташканын белгәч: «Чынлап та, ут бушлыкта яна алмый шул, тормышында нәрсәгәдер ирешү өчен нәсел-нәсәбеннең, тамырларыныңның да ныклы булуы да кирәк», дип уйланып куясың. Нәселләрендә булган каләм тибрәтүчеләрнең шигырьләрен туплаган «Нәселебез мәрҗәннәре» («Сүз», нәшрияты, 2011) китабын укыгач, менә тагын бер кат инанасың.

Борчу-хәсрәтләрне беркем дә чакырып китерми, ләкин тормыш аларсыз да була алмыйдыр, кайчакта яшәеш күген тоташ кара пәрдә каплап алган сымак була, ачыклык күренми, үзеңне дөньяның иң бәхетсез кешесе итеп хис итә башлыйсың, күңелгә җырларның моңлысы килә, шигырьләрнең сагышлысы туа. Үзенең тыныч холык-фигыленә хас булганча, Н.Каштанов салмак ритмга көйләнгән шигырьләре аша хәсрәт-борчуларына да сөеп-яратып эндәшә.

*Хәсрәтләрем,*
*Сезгә шундый күнектем мин,*
*Үз иттем мин сезнең утны яна-яна.*
*Китсәгез дә бер көн,*
*Кычкырырмын кебек:*
*«Сездән башка яшәү юк,—дип,—бу дөньяда!»*

Халкыбызның йөзек кашы булган «Кыйссаи Йосыф» китабының асыл кыйммәтен гади-аңлаешлы тел белән, шул ук вакытта әдәбият галимнәре фикерләве дәрәҗәсендә шәрехләп укучыларга җиткерергә теләве аерым бер соклану уята. Гасырлар буе сакланып килгән Йосыф китабының тирән һәм тәрбияви дәрәҗәсенең никадәр зур булуын, ләкин аңа игътибар җитмәүгә борчылуын белдереп, «Кыйссаи Йосыфка сәяхәт» китабын (Казан, «Матбугат йорты»нәшрияты, 2005) нәшер итә. Китап чыгару зур чыгымнар сорый торган бу заманда авторның милләтпәрвәрлеге, үткәнебез һәм киләчәгебезгә ихтирам белән карый торган инсан булуы күренә. Ул һәр татар кешесенең өендә Коръән белән бергә Йосыф китабының да булырга тиешлеген ассызыклый, һич югы укып булса да чыгарга кирәклеген төшендерә. «Сине бераз кызыктыра алган булсам, олуг китапны укып чыгарга күңелендә теләк уята алган булсам, максатыма ирештем дигән сүз. Хәзер инде «Йосыф китабын» эзләп табасың гына калды. Өеңдә юк икән— кибеткә бар, кибеттә юк икән— китапханәгә кер, китапханәдә юк икән— таныш-белешләреннән сора». Бу—Н.Каштановның укучыга гозер-үтенече.

Шагыйрь нинди генә җитди булмасын, үзенең иҗатында лирикага, хис-мәхәббәт шигырьләренә урын бирми кала алмый. Мәхәббәт шигырьләре— шагыйрь иҗатының бер бизәге, тажы ул. Яшәештә шагыйрь мәхәббәтенә аерым игътибар. Гашыйклар, күңелләренә хуш килгән шигырь юлларын күчереп, алып бер-берсенә сәлам итеп юллыйлар:

*Мин Кояшың булсам,*
*Миннән сиңа*
*Төшмәс иде сыңар күләгә.*

Алар инде көйгә дә салынып җыр-монга әверелсәләр, шагыйрьгә икеләтә куаныч. Н.Каштановның утызлап шигыренә көй язылып 2011 елда «Сүз» нәшриятында «Сөю елгасы» исемле ноталы җыр китабы булып дөнья күргән.

Балалар өчен язган шигырьләре булсынмы, житди-уйландыра торган яки лирикамы—Нәкыйп Каштанов иҗатына табигыйлек хас. Иҗатының балалар шигырьләре белән ачылып китүе дә, бәлки, әнә шул асыл сыйфатны - табигыйлекне саклап каласы килүдән тугандыр. Әдәбият институтларында белем алмаса да, шигырьләрендә төгәллек, ритм-рифма урынлы, тумыштан килгән сәләт тормыш тәҗрибәсе белән бергә үрелеп шигърият дигән олы дөньяны аңларга,ачарга ярдәм иткән. Үзен шагыйрь итеп хис итү сөенечен дә аңа балалар өчен язган шигырьләрен туплаган тәүге китабы - «Шәһәргә килгән Аю» бүләк иткән бит. Егерме биш китапның дистәгә якыны нәкъ менә балалар өчен язылган шигырь-табышмаклар, хикәя-әкиятләр, бәяннәр. «Төлке операциясе» (1995), «Айгөлнең туган көне» (1997), «Кикрикле гөмбә» (2000) һ.б. китаплар—нәниләрнең яраткан китаплары булгандыр дип уйлыйсы килә.

Кулыма Н.Каштановның фәлсәфи уйланулар аша туган шигырьләрен туплаган, 2002 елда «Рухият» нәшрияты чыгарган «Язмыш орчыгы» дип исемләнгән китабын алам. Әлеге китабы аша шагыйрь шигъриятнең төрле формасында эш итә белүче шагыйрь буларак та ачыла. Биредә хикәяләп язылган шигырьләр дә, поэма да, шаян-юмористик стиль белән иҗат ителгән әйтешләрне дә күрәсең.

...Язмыш орчыгы. Хак Тәгалә тугач та аны адәм баласының кулына тапшыра. Ничек әрләр ул гомер җебен... Сүтелеп китәрлек салмак-сүлпән итепме яки сокланырлык, аллы-гөлле, җете төсләргә урапмы... Монысы инде үзебездән тора. Һәркем холык-фигыленә хас булган үз дөньясын үзе тудыра. Нәкыйп Каштановның тын дөньялар моңын тыңлаганда шуңа янә бер кат инандым. Ә язмыш орчыгы зыр-зыр килеп әйләнә дә әйләнә...

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**

---

# Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:
1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

# ТАРИХЧЫ ШАГЫЙРӘ



1941 елның 15 декабрендә Татарстанның Әгерже районы Исәнбәй авылында туган Гөлзада Әхтәмова урта мәктәпне тәмамлагач берникадәр вакыт Сарапул шәһәрендә яши. Ул анда төрле һөнәрләр башкара– төзелештә дә, сәүдә хезмәтендә дә, балалар бакчасында тәрбияче булып та эшли. 1963–69 елларда Алабуга педагогия институтының филология факультетының рус-татар бүлегендә белем алганнан соң, шул ук институтта бернечә ел библиограф вазифасын башкара. Язмыш жилләре аны янәдән туган ягыннан читкә–Себер якларына алып китә, дистә елга якын анда яшәп, Эвенкиядә геофизик эзләнүләр экспедициясендә техник-геофизик, шул ук вакытта мәктәптә рус теле һәм әдәбияты укытучысы да.

1984 елда Г. Әхтәмова Татарстанга кайта, Алабуга шәһәрендә сәяхәтләр һәм экскурсияләр бюросында методист, татар теле укытучысы һәм китапханә мөдире вазифаларында хезмәт куя.

Тормыштан алган белеме һәм тәжрибәсе нигезендә Г. Әхтәмова Алабуга шәһәре тарихын өйрәнеп, анын 1000 еллык кала икәнлеген рәсми-тарихи документлар нигезендә исбатлауга лаеклы өлеш кертә, «Борынгы Алабуга» (1995) һәм «Алабугам минем« (1995) исемле тарихи очерклар жыентыгы дөнья күрә.

Шагыйрә буларак, Г. Әхтәмова балаларга атап ижат итә. Чаллының «КамАЗ» нәшриятендә анын нәниләр өчен язылган дүрт китабы, 2004 елны Казанда «Матбугат йорты» нәшриятендә сайланма лирик һәм балалар өчен язган шигырьләрен туплаган «Йөрәгемдә яшен» исемле күләмле жыентыгы басылып чыга.

Гөлзада Әхтәмова дистәдән артык китап авторы. Тарих, татар халкынын үткәне белән тирәнтен кызыксыну, киләчәге өчен борчылу анын шигырьләрендә дә кин чагыла:

*Тыңгылык белмәс күңелгә*
*Бабамнар рухы дәшә.*
*Миндә бүген үткән белән*
*Киләчәкләр көрәшә*

–дип яза ул үзенең бер шигырендә.

Г. Әхтәмова–2004 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

# ЯЗУЧЫ, ЖУРНАЛИСТ, РӘССАМ

Журналист һәм язучы Дания Гайнетдинова – нигездә балалар өчен иҗат итә. Урта мәктәпне тәмамлагач, икътисадчы һөнәре буенча (Чабаксар шәһәрендәге план-икътисад техникумы һәм Казан финанс-икътисад институты) белем алса да



күңелендә булган иҗади эшкә тартылу Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укырга да мөмкинлек бирә. 1975 елда Татарстан китап нәшриятына редактор булып эшкә керә, үзенең дә республикада чыгып килә торган төрле газета-журналларда шигырьләре, нәсер-хикәяләре басыла башлый. Әдәби мохиттә кайнау, күренекле язучылар белән даими аралашып киңәш-фикерләр алышу аңа үзен язучы буларак үстерергә ярдәм итә, әдәп-әхлак, балалар тәрбиясе, табигать дөньясын саклау темаларын үз эченә алып язылган хикәяләрен туплаган «Күнел жылысы» (1990), «Өермә» (1992), «Каен җиләге» (2007) исемле китаплары дөнья күрә.

1991 елдан – «Татарстан» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясендә балалар редакциясенең өлкән мөхәррире вазифасында. Биредә ул татар, рус, чит ил язучыларының әсәрләре буенча радиопостановкалар эшләп үзен балалар дөньясын тирәнтен аңлый белүче кызыклы журналист итеп таныта. 1995 елда Россия күләмендә уздырылган конкурста Беренче дәрәҗә дипломга ия була. Д.Гайнетдинова – бүгенге көнгә кадәр яшь тыңлаучыларын яңадан-яңа мавыктыргыч тапшырулары белән сөендереп килә, аларның үзләренең дә язмаларын эфир аша яңгыратып әдәбиятка мәхәббәт тәрбияли.

Ул күп кенә җырлар авторы да. Аның «Гомер чишмәсе», «Яшә, Казан!», «Адаштым томаннарда», туган ягын зурлап язган «Туган ягым Теләче» (ул 1952 елның 2 гыйнварында Теләче районының Олы Тиләҗе авылында туа) исемле җырлары бар.

Д.Гайнетдинова – һәвәскәр рәссам да, рәсем сәнгате өлкәсендәге төп темасы майлы буяу белән киндергә табигать күренешләрен төшерү, натюрмортлар, балчыктан сыннар ясау – әлеге өлкәдә дә осталыгын елдан-ел арттыра барып, зур уңышларга ирешеп шәхси күргәзмәләрен оештыра, танылу ала.

Аның әдәбият һәм рәсем сәнгатендәге хезмәтләренә бәһа биреп, иҗаттәш дуслары Х.Әюпов, Г. Садә, Л.Ихсанова, Р.Шаһиеваның язмалары дөнья күрде.

Д.Гайнетдинова – 1997 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## Зыя Ярмәкинең тууына 125 ел

Шагыйрь Зыя Ярмәки (Әхмәтзыя Шәйхетдин улы Насыйров) 1887 елның 9 (яна стиль белән 21) гыйнварында Самара губернасы Богырыслан өязе (хәзер Самара өлкәсенең Келәүле районы) Иске Ярмәк авылында мулла гаиләсендә туа. Авыл мәктәбендә башлангыч белем алганнан соң, ун елга якын Чистай шәһәрендәге Закир ишан мәдрәсәсендә, 1909-12 елларда Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә укый. Шунда укыганда иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. 1912 елда Эстәрлетамак шәһәрендә «Яшьлек дәртләре» һәм «Күрсәтәм» исемле ике шигъри җыентыгы, тагын бер елдан Уфада «Тойгыларым» һәм Оренбургта »Әдәбият гөлләре» исемле шигырь китаплары дөнья күрә.

1912 елда Зыя Ярмәки туган авылы Иске Ярмәккә кайта һәм балалар укытырга керешә. Берара, 1915-17 елларда, авылда мулла булып та тора. Инкыйлабтан соң яңадан мөгаллимлек хезмәтенә күчә, туган ягында төрле вазифаларда эшли. 1931 елның көзендә Үзбәкстанга күчеп китә. 1935- 63 елларда Фирганә өлкәсенең Ташлак район башкарма комитетында җаваплы секретарь һәм бүлек мөдире була.

Зыя Ярмәки шигырьләре, нигездә, Тукай поэтик мәктәбе үрнәгендә, классик поэзиягә һәм халык җырларына хас үлчәүдә язылган. Алар төгәл, ритмик эчке рифмаларга бай һәм хәтергә тиз сеңүчән музыкаль яңгырашлы булулары белән аерылып торалар. Ул табигать күренешләрен оста тасвирлый.

Зыя Ярмәки 1965 елның 26 ноябрендә үзе күп еллар яшәгән Ташлак авылында вафат була һәм Фирганә өлкәсенең Маргилан шәһәрендәге Хуҗагәз дигән зиратында җирләнә.

## Галимҗан Латыйпның тууына 100 ел

Шагыйрь Галимҗан Латыйп (Галимҗан Шакирҗан улы Латыйпов) 1912 елның 20 гыйнварында Башкортстан Республикасының Чакмагыш районы Яна Дөмәй авылында крестьян гаиләсендә туа. Башлангыч мәктәпне тәмамлаганнан соң туган авылында кызыл почмак мөдире, китапханәче, соңрак салым җыючы, заем таратучы булып эшли. Бәләбәй шәһәрендәге укытучылар әзерләү курсында, Казандагы Урман техникасы институты рабфагында, Казан финанс-икътисад институтында укый. 1939-40 елларда Советлар Союзы – Финляндия сугышында катнашып, гаскәри хезмәт мөддәтен тутырып кайтканнан соң, берникадәр вакыт Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире, 1941-50 елларда Татарстан Республикасының финанс контроле оешмаларында дәүләт инспекторы-ревизоры, 1951-60 елларда «Пионер» («Ялкын») татар балалар журналы редакциясендә әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире булып эшли.

Г. Латыйп авылда укыганда ук каләм тибрәтә башлый: клуб сәхнәсе өчен такмаклар, инсценировкалар, скетчлар яза. Матбугатта беренче шигырьләре 1932 елда Башкортстан Республикасының татарча үзәк матбугат басмасы «Коммуна» (хәзерге «Кызыл таң») газетасында басыла, «Юл буйлап» исемле тәүге шигъри китабы 1939 елда Казанда дөнья күрә.

Г. Латыйп зурлар өчен дә, балалар өчен дә яза. Поэзиядә аның шагыйрь буларак хис һәм фикер игътибарын даими биләп торган үз темалары бар. Болар — туган ил, хезмәт романтикасы, халыклар дуслыгы, тынычлык.

Шагыйрьнең тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Ул Егор Исаевның «Суд памяти» («Хәтер хөкем итә») поэмасын, Д. Бедный, С. Михалков, С. Маршак, А. Прокофьев, А. Твардовский, Пабло Неруда, Никола Вапцаров һәм башка рус һәм чит ил шагыйрьләренең әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

1986 елның 4 ноябрендә Казанда вафат була.



Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнен сәхифә!

*Ак җилкән*

*Бәләкәйләр*

# БӘЛӘКӘЙ МАРАТ

## Кулак көчеге

Беренче сыйныфта укыганда булды бу хәл. Тәнәфес вакытында кәгазь йомарламнары атышып уйнаганда, минеке Сталин портретына барып тимәсенме. Нәкъ күз төбенә. Кылыйланды да калды юлбашчыбыз. Кашы да киселде.

Коелып төштем. Шулай булмыйча, Алладан да өстен даһи зат лабаса! Мәктәптәге көнебез аның исеме белән башлана, аның исеме белән тәгәлләнә. Сталин!!!

Барысы да шомда. Илгиз дустым гына битараф. Сәер малай ул, кинаяле. Авызында җыен тузга язмаган сүз. Әле кичә генә:

—Беләсенме, безнекеләр немецларны ни өчен туктата алмый?—дип, бәбәкләрен киереп баккан.

—Безнекеләрме... безнекеләр...

—Белмәсәң, бел,—дип бүлде дустым минем ык-мыгымны,—сугыш алдыннан безнең поездлар Германиягә: «Пшеница-пуф-пуф»—дип, бик авырлык белән генә барганнар, ә кайтканда: «Пудыр-мудыр-пиф-пиф»,—дип элдертәләр генә икән.

—Шуннан?

—Шуннан шул, ангыра баш, германнар безнең бодай ипиен ашап симергән, үзебезгә—алабута. Пудыр-мудыр бизәнергә генә ул.

Риббентроп—Молотов пактына мөнәсәбәтле баш бетәрлек сүзләр булган ич болар. Мин моның асылына күп еллар үткәч кенә төшендем. Авылда да үзгә фикерле кешеләр яшәгән икән бит!

Әле дә яныма килде дә:

—Исең китмәсен иске чикмәнгә, кәгазь ертыла инде ул,—дип пышылдады.

Ул арада укытучы керде. Артыннан ишек ябылырга да өлгермәде, иң алгы партада утыручы кычыткан чыпчыгыдай тик тормас Мияссәмә яналыкны очыртып та җибәрде.

—Апа, Марат Ысталинның күзен чыгарды!

Ошбу хәбәрдән мөгаллимәбезнең аяклары атламас булды, шып туктап калды.

—Пәртриткә кара, апа,—дип ярдәмгә ашыкты әләкче бетчә,—иптәш Ысталин югары оч Әбелмәлих исәргә ошап калды бит.

Минем җаным уч төбенә йомарланган, чыгам-чыгам дип кенә тора.

—Әйдә, директорга!—диде Фәһимә апа үтә бер кискенлек белән, җаваплылыкны үз өстенә алырга теләмәде.

Юлбашчы безгә исән күзе белән сөзеп карап калды.

Директорыбыз Җәмилә апа кечерәк кенә буйлы, мул гәүдәле. Башында һәрвакыт кубанка. Кавалерист булган дип сөйлиләр иде аның турында. Булса булгандыр, теле кылычтан да үткен. Мәктәпне генә түгел, бөтен авылны дер селкетеп тота.

Ул укытучының аңлатып бетерүен дә көтмәде, кыска кулын һавада уйнатып алды

да, өстәлгә китереп сукты. Бу шулай кәтелмәгәндә булды ки, хәтта кара савытлары да сикерешеп идәнгә тәгәрәде.

—Аһ, син, кулак көчеге!

Директор кабат йодрыгын йомарлады. Тик бу юлы өстәлне тынычлыкта калдырды, кулын авырттырган иде, ахры.

—Син бит, көчек, бу җинаятьне Әкрам кулак котыртуы буенча башкардың, шулаймы?

Ул, яшькелт күзләреннән ут чәчеп, мина текәлде.

Бу зәһәрле карашны күтәрү мөмкин түгел иде, башым үзеннән-үзе күкрәгемә салынып төште.

—Әкрам кулак әле хак җәзасын алачак! Бу минем сүз, парторг сүзе. Төшендеңме, көчек?

Әкрам кулак—минем карт әтәем. Аның башка колхозчылардан бер аермасы да юк анысы. Хәер, дөрес әйтмим, аермасы зур. Ник дисәң, безнең Кәзкәй авылында карт әтәйләрдән ары берәү дә мунчада яшәми. Элек бай булу белән мени. Картый әйтә, капма-каршы салынган алты почмаклы ике зур өебезне, ләфкәбезне, ун атыбызны, утар тулы мал-туарыбызны, кием-салым, савыт-сабаларыбызны сәүит тартып алды, ди. Бу ике өй хәзер дә бар. Берсендә авыл советы урнашкан, икенчесендә ниндидер агроүзәк. Ләфкә дә исән-сау, тик ул инде советныкы. Халык карт әтәйнең кызыл билле прәннеген әле дә сагынып сөйли. Ә минем аны әлегә авыз итеп тә караганым юк.

Директор дошманга чыгарса да, халык Әкрам картны нигәдер үз итә иде. Юмарт, хөсетсез, ярдәмчел булганга, ди картый. Ул сөйләгән бер вакыйга хәтердә уелып калган.

—Җомга көн иде,—дип тәфсилләп китте әбием,—күрше-күләнне чәйгә дәшкән идем. Шулай күгәрченнәрдәй гөрләшеп тәгамләп утырганда карт әтәннең тавышы ишетелде. Ни булды икән дип чыгып бактым, күренми.

—Атасы, син кайда?

—Мин утарда, кортка, ыштан чыгар,—ди бу.

—Әстәгъфирулла, ниткән ыштан?

—Әйткәнне эшлә!

Өстендәгене бер сөальчегә салып биргән икән, буш кул.

Шул бушкуллыгы сөргеннән саклап калган да инде карт әтәйне. Авыл нык торган: җибәрмибез, бетте-китте, вәссәлам! Ә үзе исә уллары на җил-янгыр тигертмәгән, куркыныч янауга читкә чыгарып җибәргән. Тегеләр төшеп калганнардан түгел, әлбәттә, үз юлларын тапкан. Әткәем, мәсәлән, мөгаллимлек юлын сайлаган, җир читендәге башкорт балаларына аң-белем биргән.

Буш кул дигәннән, карт әтәй ул «чирен» мина да йоктырган, күрәсең. Менә бер мисал.

Сөн бозга төренеп, салкыннар башлануга, мәктәп бушап калгандай булды. Һәрхәлдә, йөрмәүчеләр бермә-бер артты. Андыйлар безнең класста да бар иде. Төп сәбәп—кием кытлыгы.

—Октябрятлар нәкъ фронтташлар кебек бер-берсенә ярдәм итәргә бурычлы,—диде укытучыбыз Фәһимә апа,—артык-портык киемнәрегезне алып килегез, без йөрешне йөз процентка җиткерергә тиеш.

Артык егылып төшүче күренмәде күренүен, әмма мин әткәем, тагын аның фронтовик өч энесе үрнәгендә, октябрят дигән мактаулы исемнең данын ишәйтергә карар иттем. Өйдәгеләргә белгертмичә генә сандык төбеннән бер чигүле күлмәк табып алдым.

Фәһимә апа әнкәйне очратып, күп рәхмәтләрен җиткергән. Шушы рәхмәт мине харап итте дә инде.

Икенче көнне мәктәптән кайткач ни күрим, чигүле күлмәк чөйдә эленеп тора. Йөрәгем жу итеп китте.

—Мин дүрт бала карыйм, Бәдрижамал бер баласын да укырга йөртә алмый,—диде әнкәй.

—Алар ярлы.

—Без баймы?
—Мин октябрят.
—Октябрят булсаң, әнә, иске киез итек, олтанлыгы да, шуны илтеп бир. Иптәшең, беләсең килсә, аягына булмаганга укырга йөри алмый. Ә чигүле күлмәкне үскәч үзең киярсең.
...Болар алда булган хәлләр. Хәзерендә директор алдында җавап тотам. Дөресрәге, мыш-мыш борын тартам.
—Октябрятлар оешмасы—большевистик сәяси оешма, анда кулак көчекләренә, мәчет кортларына урын юк,—диде директор, укытучыга мөрәҗәгать итеп,—бу мәсьәләне тиз арада хәл итегез.
Гаҗәпләнмәгез, мәчет корты дигәне дә мин булам инде. Барысы да бер башка—түз генә. Чөнки карт әтәйләр нәселенең бер канаты муллалык иткән, директор сүзләре белән әйтсәк: «Халыкны дин сөреме белән агулаган!»
Кулаклык өчен дә, муллалык өчен дә гаепне мин күтәрергә тиеш. Үзем теләп алмаган ла.



—Аңлатма яз, Акрамов,—дип, директор киеменә үрелде, каядыр ашыга иде булса кирәк. (Жәя эчендә генә аңлатма бирәм: мин мәктәптә кулак бабамның фамилиясе белән йөрдем, унынчыны бетергәндә генә Әмирханов икәнлегем ачыкланды).
Гыйлемем аңлатмалар язар дәрәҗәдә түгел иде, хәрефләрне генә өйрәнеп бетердек бит әле. Язу ягы да бик чамалы. Шулай да: «Тәртип бозмам», дигән җөмләне сырладым үзе.
—Имзаңны куй, числоны теркә, бүген 1941 елның 17 ноябре.
Әлеге хәлләрнең шаукымы өебезгә дә килеп житте. Юк, ачуланмадылар. Сукмадылар да. Алай жиңелрәк тә булган булыр иде әле.
—Үзенне түгел, данлыклы әткәнне, Әмирхан мөгаллимне хур итәсең бит, шунлык та акылың юкмени соң синең?—диде әнкәй үпкәле тавыш белән, ә күзләре мөлдерәмә. Ул әткәйне һаман исән итеп күрә, хәлбуки, үлеме турындагы кара язуны алган идек инде.
Кара язулар бабамның калган улларына да: Галимжан агаем белән Әбелгас агаема да килде, фәкать Әбелхан агаем гына урап кайтты.
Әкрам бабай үзе төрмәдә вафат булды. Заготзерного ашлык ташыганда ничәдер кило бодае өстенә чыккан, имеш.
Зур ыру әнә шулай күзгә күренеп саекты.
Тормыш елгасы бернигә карамый ага бирә. Ышанасызмы-юкмы, тора-бара мин мәктәбебезнең сәяси лидерына әвереелдем бит. Жәмилә апа үч саклаучылардан түгел иде. Октябрятлыктан чыгару куркыту өчен генә уйлап табылган нәрсә иде, күрәсең, аны белми дә калдылар. Лидерлыкның исә акка кара белән язылган исбатламасы бар.
Туган-үскән Актаныш якларына бер кайтуымда журналистлар «Колхоз ударнигы» газетасының 1948 ел, 9 апрель санын бүләк иткәннәр иде. Тикмәгә түгел. Ник дисәң, бу санда «Аеш жидееллык мәктәбе пионерларына Кәзкәй мәктәбе пионерларыннан хат» урнаштырылган икән. Менә шуннан бер өзек: «Колхозыбызның югары уныш звеносын шефлыкка алган идек. Шул звено участогына укучылар 140 центнер тирес чыгардылар, 95 центнер көл, 10 центнер кош тизәге жыйдылар. 4 апрельдә оештырылган өмәдә генә дә 420 центнер тирес чыгарылды...
Пионерлар тапшыруы буенча, Зоя Космодемьянская исемендәге дружина советы председателе: М.Акрамов»
Менәтерәк, вәйт!
Сугыштан кайткач, директорыбызның ире Кашапов абый да укытучы булып эшләде. Аннан соң ничектер кисәк кенә күченеп тә киттеләр.
Жәмилә апа күп еллар үткәч мине үзе эзләп тапты. «Социалистик Татарстан»

(хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасында эшләгән чагында редакциягә хаты килеп төште. «Марат, мин сезнең язмаларыгызны көтеп алам, яратып укыйм. Горурланам. Бу минем өчен зур шатлык», дигән.

Оныта язганмын, теге хәвефле гамәлнең файдасы да тиде бит, шуннан соң мәктәптә барлык портретларны да пыяла рамлыларга алыштырдылар.

## Мәхәббәт мәктүбе

Элек көтүдән соң янә бер көтү була торган иде: кичке көтү. Ул фәкать сөтбикәләр өчен генә. Ә көтүчеләре—бала-чага.

Һәр урамның үз урыны. Без исә 10—15 йортлы Сөн тыкрыгында яшибез, ындыр артындагы яланга чыгабыз. Сыерлар чүпләнә, ә без шашынып уйныйбыз. Башлап йөрүчебез инде бишенче сыйныфка күчкән Халидә исемле кыз. Озынчарак йөзле, кылыч борынлы, кара кашлы. Житезнең житезе, бөтерчектәй бөтерелә. Үзе тел бистәсе, авызы сүздән бушамый.

Халидә башлыча аулак өй уеннарына һәвәс иде. Жырлары да үзгә. Без Илгиз белән, мәсәлән, үзе үк үткәргән жыр ярышында «Комсомолка Гөлсара» жырын башкардык. Бөтенесенә дә ошады, дәррәү кул чаптылар. Чыны да шул, бик шәп жыр ул.



*Туплар шартлый, җирләр тетри,*
*Йолдыз якты, төн кара.*
*Мылтык алып, кылыч тагып*
*Дошманнарга каршы бара*
*Комсомолка Гөлсара.*

Халидә сулакай кулын гына селтәде.

—Яланда да мәктәп жырын жырламагыз сана,—диде.

—Алайса, ялан жырын үзең жырлап күрсәт,—диде Илгиз.

Халидә ялындырмады, куш учы белән шома чәчен сыпыргалагандай итенде дә, чәрелдәп тә жибәрде:

*Ял вакыты җиту белән*
*Солы сал атларына;*
*Ярым дисәң, яр дип сөйсәң,*
*Тилмертмә хатларына.*

Анын такмакларын үтеп барышлый Гыйндулла корткасы да тыңлап торган икән.

—Шәмсетдиннең бу бытбылдыгына да ис керә башлаган бит,—дип сөйләнде,—аякларында эржинкә, жыенга чыкканмени.

Нинди ис, һич аңламадым. Эржинкәсе әйбәт анысы. Минем үземнең дә әткәйдән калган чүәк бар. Жон оекбаш киеп, жеп белән кысып бәйләп куйгач, зурлыгы да сизелми. Тик ул мәктәпкә йөрергә генә.

—Хәзер йөзек салышлы уйныйбыз, бер рәткә тезелешеп басыгыз,—диде Халидә, анын үз утызы утыз.

Отылган кешегә жәзаны да ул үзе бирә. Илгизне, әнә, әтәч булып кычкыртты, Мияссәмәгә биергә кушты. Инде минем чират та житте.

—Ә син, Марат, әйт, кемне сөясен?—диде.

Аптырап калдым. Билгеле, сөйгән кешеләрем бар минем. Әнкәйне, әткәйне, инәкәйне, Әфка абыйны, сеңелләрем Клара белән Венераны... Сизеп торам, Халидәнең тел төбе бүтән.

—Жә, сузма, башкаларның да уйныйсы килә. Давай, әйт, кемне сөясен?

Каршыма үк килеп басты бу, буып ташларга әзер, валлаһи.

—Сине,—дидем мин давайлаудан котылу мәсләгеннән,—сине...

—Бүгенгә житте, сыерларыгызны барлагыз, кайтабыз,—диде Халидә.

—Авызын капладың син бу чикерткәнең, күр, ничек куырылып төште, маладис,—дип хуплады мине Илгиз.

Икенче көнне Халидә яшертен генә кулыма ниндидер конверт тоттырды. Үзе шунда ук юк та булды. Карасам, хат. Өчпочмаклы. Фронттагы берәр туган-тумачадандыр, мөгаен. Чөнки мин беренче сыйныф белеме кысаларында гына булса да барча карендәшләргә дә хат яза идем. Кулымның сызма сурәтен дә сырлыйм. Алар үзләренекен. Шуна күрә хатны өй алдында ук ачасы иттем. Ачтым да катып калдым, гүя башыма тукмак белән тондырдылар.

Хатның беренче битендә ике күгәрчен рәсеме. Томшыкларын терәшкәннәр. Уң яктагысының астына «Марат» дип язылган, сул яктагысына—«Халидә». Чит-читләрендә буяу карандашы белән ясалган чәчәкләр.

«Марат, жаным! Мине сөюеңне белеп йөри идем инде. Мин дә сине өзелеп сөям...»

Хатны тулысынча укып чыгарга тәвәккәллегем житмәде. Йөзем яна, кулым калтырый. Нишләргә? Мәсхәрә лә баса бу! Белеп алсалар, үртәп интектерәчәкләр бит. Жаным, имеш. Башына тай типкәндер ул кылыч танаунын. Сабакы...

Болдырда аяк тавышлары ишетелде. Бу Әфка абый. Әнкәйнең энесе, яшь арабыз 5-6 ел гына. Ул сизенсә, вапши харап.

—Сыер тигәнәккә баткан, кара аны, селәгәенне агызып йөрмә, ныклап кара,—дип, абый колакны борып китте.

Тигәнәк кайгысымы соң әле монда. Хатны кая яшерергә? Әүвәл өйдәгеләр күрмәгәндә генә кәбәрткәдәге чыра тартмасы астына шудырдым. Инәкәйнең күәс чиләге тирәсендә кайнашуын күргәч, аны этә-төртә янә кәбәрткәгә атылдым...

—Бабасырларың кузгалдымы әллә, балам, бер урында утырып тора алмыйсың,—дип, хәлгә кермәкче итте инәкәй,—кәрәчин тамызып карыйм соң.

—Ярар, башта тышка чыгып керим әле.

Хатны бу юлы лапастагы улак эченә төрттем.

Инде ятарга да була. Ләкин йокым йокы булмады, төне буе саташып чыктым. Имеш, Әфка абый хатны тапкан да, авыл буе кешеләргә укып йөри. И, көләләр. Очраганы берсе «кияү» дип мыскыл итә...

Уянып киттем дә, атылып ишек алдына чыктым. Таң беленеп кенә килә иде әле. Лапаста сыер мөгри. Жә, аллам, улакның астын өскә китергән лә баса, мөртәт. Хат та шунда аунап ята.

Хат, ниһаять, тәрәзә кашагасында урын тапты. Әмма бу вакытлыча гына. Аннан ничек тә котылырга кирәк. Бердәнбер юл—иясенә кире кайтару. Тик ул чагында Халидә белән сөйләшергә туры киләчәк. Ә минем сөйләшү түгел, шәүләсен дә күрәсе килми. Вәйт бәла.

Инәкәй учак тергезеп жибәрде. Һәм шуның белән мәсьәлә дә хәл ителде. Йөгереп бардым да хатны утка тондырдым. Өстемнән таш төшкәндәй жинеләеп киттем.

—Кәрәчиннен файдасы тидеме, балам?—дип сорады инәкәй.

—Тиде, тимәгән кая.

Халидәдән дә үчне кайтардым анысы. Туйганчы каз боты ашаттым. Кызлар белән су кергәнен сагалап тордым да, алар йөзешкән-шаярышкан арада күлмәгенә чиләп төен салдым. Аннан куак арасына посып, күзәтеп тордым. Әй, жәфаланды да соң. Алай тешләп карый, болай әйләндергәли, юк, төен бирешми. Бирешергә тегә, төкрек белән дә юешләнгән ич. Хатына күрә таман, кылыч танау.

Нишләмәк кирәк, гыйшык-мыйшык учагын дөрләтүче геннарның йокыдан уянмаган чагы булган шул әле ул.

## Гармун кулларыбызда

Халидәнең хатындагы бер жөмләне, темасына туры китереп, махсус әлеге бүлеккә калдырдым. Менә ул жөмлә: «Мин сөйгәнемнең гармунчы булуын теләгән идем...» Кызыкайның гыйшкый язмышында бу хәлиткеч сәбәп булгандыр, мөгаен, югыйсә

борын асты да кибеп житмәгән малайга мәхәббәт хисләрен белдермәс иде.

Кайчан, ничек гармун уйнарга өйрәнгәнмендер—хәтерләмим. Беренче гармунымны исә институтка укырга кергән елны комиссионкадан йөк бушатып эшләгән акчага алдым. Аяклы фотоаппарат, гармун—болар кечкенәдән килгән буй житмәс хыялым иде.

Без бәләкәй чакта авылыбызда бер генә гармун бар иде. Ул да булса, клубта. Хәтта мәктәп тә озак еллар гармунсыз яшәде. Күрәсең, клуб гармуны эләккәләгәндер кулыма. Ул гармун әле булса төшләремә керә. Шырпы кабы зурлыгында гына иде. Ә тавышы—бөтен Сөн буен колачлый. Көмеш телле—кызуда да, салкында да бер дәрәҗәдә чынлый, янгырашын үзгәртми. Саратский тибындагы уникe телле гармун. Бездә аны «Русский» дип йөртәләр иде: күреген тартканда бер тавыш, йомганда икенче тавыш. Шул исәпкә октавалары арта.

Гармун шыгырдатуымны минем үземнән элек авыл таныды булса кирәк. Шулай бер көнне яланга бозау куып кайтканда капка төбебезгә колхоз персидәтеленен жигүле аты килеп туктады. Кузлада—амбар каравылчысы чатан Вәли абзый.

—Өстенә җүннерәк киеменне ки, персидәтел чакыра,—диде ул,—тиз бул!

Персидәтелнен кара лаклы трантасына утырып, ындыр табагына менеп киттек. «Кызыл олау» көне икән, халык шыгрым. Директорыбыз Җәмилә апа да шунда.

—Сина бик мөһим бурыч йөкләнә, Акрамов,—диде ул житди кыяфәттә, «Кызыл олау»нын музыкаль оформлениесе өчен җавап бирәчәксен—менә гармун, бар, алгы бричкага утыр.

Бричканын ун янагына кызыл флаг эленгән, ә сул янагына: «Фронтка—«Яңа тормыш» икмәге!»—дип язылган кызыл комач беркетелгән иде.

Бричка хуҗасы Сәгадәт тутакай мине калын иреннәрен җәеп каршы алды.

—Бәй, апай, синмени әле бу, әйдүк-әйдүк, башка авыллар гармун белән килгәндә көнләшеп үлә идем, хәдер, әнәтрәк, үд гармунчыбыд да бар,—дип, мине олауга күтәреп үк утыртты.

Ифрат көчле ул, беләкләре бастырык юанлыгы, капчыкларны бүксә урынына гына сикертә.

—Продукциян менә монда, апай, бүген бал да тамыдган Гали абдан,—дип тә өстәде. Аеруча җаваплы эш башкаручыларга колхоз ашамлык бирә иде. Аны кыска гына «продукция» дип йөртәләр иде.

Җәмилә апа нотык тотты. Гадәттәгечә, озак сөйләде, әле тагын да дәвам иткән булыр иде, персидәтел генә бүлде.

—Кузгалдык, тарт, энем, гармунынны!

Олауны кул болгап озатып калдылар. Барасы юл шактый: Актаныш безгә - ун чакрым, Актаныштан Әҗәкүл - биш чакрым. Баруы-кайтуы утыз чакрымнан арта.

«Музыкаль оформление»нен бурычы—Җәмилә апа кат-кат колагыма киртәләгәнчә, гармун уены аша «Яңа тормыш» колхозынын күркәм омтылышын район житәкчелегенә житкерү, данын бөтен тирә-якка тарату.

Әйтергә кирәк, булдырдым. Олауны каршы алган район түрәсе бигрәк тә «Комсомолка Гөлсара» көен ошатты, унлап дәфтәр, бер кап буяу карандашы, бер кап чукмар башлы каләм дә бүләк итте. Әби-апалар юл унаенда алма, чия, карагатише җимешләр белән сыйладылар.

—Бәй, апай, кулын жинел икән, әнәтрәк, бүген ашлыкны жилгәртмәй генә кабул иттеләр бит, рәхмәт төшкере,—дип, Сәгадәт тутакай да үсендереп җибәрде.

Янгыр гына бераз кәефне бозды. Авылга кайтып житәрәк Агыйдел аръягыннан кара болыт ишелеп килде дә, чиләклә п-чиләкләп койды. Туктаусыз күк күкри, яшен яшьни: дөбер дә дөбер, чалт та чалт. Яшен яктысы ябык күзләр аша да үтеп керә. Куркыныч. Ахыры заман диярсен.

—Апай, мина алмаш табылыр, ә син авылда берләнбер, суык тия күрмәсен,—дип, тутакай өстемә кәҗәнен япты.

Ул жәйне кызыл олау өстендә үткәрдем дисәм дә арттыру булмас. Мине инде таныйлар. «Бигрәкләр дә оста уйный инде бу Кәзкәй малае»,—дип мактау сүзләре ирештерәләр.

Үзем исә Сәгадәт тутакайның жырына мөкиббән идем.

Еш жырламый, әмма жырласа, тавышы иртәнге пароход авазыдай Кәзкәйдән Актанышка ишетелә иде.

*Агыйдел буйлары матур*
*Аккошлар уйнаганда.*
*Минем йөрәккәем ярсу*
*Гел сине уйлаганда.*

Әлеге көй гармунга кушылып жырланмый, ялгыз башкарыла. Мин аның үзенчәлекле техникасына әле дә төшенә алганым юк. Тавыш бизәкле түгел, ул ничектер күкрәктән бернинди каршылыксыз, турыдан-туры чыга. Ихтимал, көчлелеге шуның белән анлатыладыр. Шулай да бер югары нотада тавыш калтыранып китә. Бу аңа кабатланмас шарм өсти.

Безнең авылда болай итеп Сәгадәт тутакай да Рабига апа гына жырлый иде. Бүгенге көндә андый жырчыларны очратканым юк. Грузиннарда, хохолларда бар бу ысул, тик аларда, акапелла стилендәге берничә тавышлы күмәк жыр ул.

Гармунчы буларак, абруем артканнан-арта гына бара. Шимбә көннәрендә клубны ачып, бичерлар (урысча «вечер» сүзеннән) үткәрергә рөхсәт ителгәч, янә бер баскычка күтәрелде. Чөнки бичер—бию тамашасы. Бию өчен исә гармунчы зарур.

Шимбә киче килеп життеме, мөдир Сажидә апа безгә төшә дә, юмалый-юмалый клубка алып менеп китә. Кызларны ду китереп биетәм. Рәхмәт йөзеннән, кесәмә көнбагыш, кабак төше тутыралар.

Бичернең үз репертуары. Ул нигездә өч көйдән гыйбарәт: Камаринская, Барыня, Мари такмагы. Каф тавы артындагы урысның исе дә килмәгән ерак татар авылында Глинка операларында урын алган Камаринская ничек төпләнеп калгандыр, анысы миңа караңгы, ә ул татарча милли аранжировкада бик жилле янгырый иде.

Сез: «Әпипә»ләр кайда иде соң?—дип сорарсыз. «Әпипә»ләр дә бар иде, билгеле. Тик аларның урыны—сәхнә!

Урам—үзенә, сәхнә—үзенә.

Мин инде бердәнберлегемә тәмам күнегеп житкән идем. Борын—чөйдә. Кәкитләнергә өйрәндем. Кәжәләнәм дә. Үзем исә бичерларны сагынып көтеп алам.

Чираттагы бер шимбәдә Сажидә апа килмәде. Сагаеп калдым. Соңаргандыр гына, килер, беркая китмәс дип юатам үземне. Күңелне барыбер нидер тырный, каһәр. Ярар, дим, башка күзегезгә кырып салырга да булмам, дим. Ялынырсыз. Үкенерсез...

Түзмәдем, клубка үзем менеп киттем. Ә анда ачык ишектән гармун тавышы бөркелә. Шыпан-шыпан гына тәрәзәгә килеп капландым. Ни күрим, гармун бер солдат кулында. Теттерәләр кызлар биеп. Уйнавы минекеннән калыш анысы, бәлки, шулай тоелгандыр гына, ләкин бу инде - чын егет.

Шул рәвешле сугыштан яраланып кайткан Әхтәм абый минем жәй буена сузылган «бердәнбер гармунчы» монополиясенә киртә салды. Тора-бара авылда гармуннар күренә башлады, тагын да сәләтлерәкләр калкып чыкты.

## Рәшәткәле тәрәзә

«Тимер ишеккә уелган рәшәткәле тәрәзәнең келәсе чылтырады. Күп тә үтми, анда Мөкәррәмәгә богау салган милиционерның мыегы, аннан соң йөзе күренде...»

Әлеге өзек «Мөкәррәмә» исемле повестемнан алынды. Бу тулысы белән дөреслеккә туры килә. Актаныш төрмәсенең ул рәшәткәле тәрәзәсе күңелемдә гомерлеккә уелып калды минем.

...1943 ел. Язгы чәчү чоры. Тиздән соңгы кыңгырау. Хуш икенче сыйныф! Алда—жәй. Су керү, чүмәлә тарттыру, балык каптыру.

Балык дигәннән, Идел мул типте, балык күп быел. Илгиз белән көн дә олы

балыкка йөрибез. Зур кармакка тирес корты саплап, кармакны төнгә салабыз да, көтү белән барып алабыз. Эләгә. Кичә бәләк буе опты капкан иде. Шуңа күрә инәкәйнең таң белән уятуына гажәпләнмәдем. Гадәттәгечә, иркәләнебрәк:

—Тагын әз генә,—дип, әйләнеп яттым.

—Тор, балам, йоклап ята торган чак түгел, йортыбызга кайгы керде,—диде инәкәй яшь аралаш.

Йокым мизгел эчендә качты.

—Ни булды, инәкәй?

—Әнкәңне милициягә алып киткәннәр, балам, ашарына илтеп, хәлен белеп кайт,—диде инәкәй,—безне эштән жибәрмиләр.

Шушы урында, лирик чигенеш ясап, инәкәй турында мәгълумат бирү урынлы булыр дип саныйм. Ул - әнкәйнең инәсе, безнең әбекәебез. Әнкәйгә инәкәй булгач, безгә дә инәкәй иде. Ифрат дәрәҗәдә гадел, ярдәмчел вә сабыр зат. Эшчән, аруталуны белми. Кием-кыяфәте дә күнеле кебек үк саф-чиста һәм пакь иде. Олыгайгач, авылның ак әбиенә әйләнде. Кечерәкләр «алма әби» дип йөртәләр иде. Чөнки кесәсендә һәрвакыт алма булыр иде.

Тәкъвәнең тәкъвәсе. Уку-язуы юк, әмма бик күп догаларны яттан белә. Безнең өйдә мосафирлар еш була. Алар кышкы озын кичләрдә дин тарихын сөйлиләр иде. Мин, мәсәлән, Кол Шәриф мәчетенең мөхтәрәм имам хатибы Рамил хәзрәтнең пәйгамбәрләр турында радиодан бәян иткән хикәятләреннән бәләкәй чакта ук азмы-күпме хәбәрдар идем.

Әле дә исемдә, бервакыт инәкәй төн уртасында аякка бастырды.

—Дөнья бетә, иман китерегез, ай тотылган!

Барыбыз да догага иңдек. Ә бераздан этләр өрүдән туктады, ай яктырды, шом басылды. Без айны Иблис мәлгуньнән коткара алуыбызга куанышып, юрган астына чумдык. Яшенле янгыр килә башласа да, ишек-тәрәзәләрне, моржа авызын догаларыбыз белән сугарабыз. Мин житкән егет булганчы кече йомышымны рәсүлебез Мөхәммәд пәйгамбәр үрнәгендә тезләнеп башкардым. Тик, кызганыч, алга таба мәгълүм сәбәпләр аркасында минем тәрбия марксистик юнәлеш алды, саф дин читтәрәк калды.

...Актанышка барып житкәндә иртә иде әле. Түбәсенә чәнечкеле тимер чыбык эленгән тоташ биек койма ышыгында озак кына эш сәгате башланганын көтеп утырдым.

Халык тыз-быз. Ләкин миңа алар бармы да юкмы. Бөтен күзәнәкләремне, бөтен барлыгымны уй баскан. Әнкәем бик тә әйбәт. Бригадасы һәрвакыт алда бара. Аны, әлбәттә, чыгарачаклар. Бүген үк житәкләшеп кайтып китәрбез әле, Алла боерса.

Инәкәйнең борчулы йөзе дә күз алдыма килеп ала.

—Әйттем мин аңа, алдына-артына карап йөр, дидем...

Инәкәй әнкәйне һаман кисәтеп тора. Чөнки әнкәй төшке ашка кайтканда крандас төбенә ни дә булса салып кайта. Инәкәй моны бурлыкка саный. Өченче көн дә әнкәй тавыкларга бер улак кибәк юнәткән иде.

—Теге хатын (ачуы чыкканда ул кызын шулай дип атый иде), тагын урлашкан, барыгыз, күз-колак булыгыз,—дип, инәкәй, һәрвакыттагыча, мине һәм сеңелләремне сакка чыгарып жибәрде.

Хәзер дә инәкәй бурлыкка ишарә итә иде. Шул кибәк өчен төрмәгә ябалар микәнни?..

Ниһаять, ишекне ачтылар. Мин гозеремне житкердем. Мыеклы милиционер, әйберләремне тикшергәч, тимер ишеккә уелган рәшәткәле тәрәзәне ачып оран салды:

—Акрамова, сиңа төенчек!

Төрмә ягында идән түбәндәрәк иде, ахрысы, әнкәйнең сузылган кулы гына шәйләнеп китте. Кычкырып жибәргәнемне сизми дә калдым.

—Әнкәй, әйдә кайтабыз, әнкәй!

—Марат, улым...

Милиционер шап итеп тәрәзәне ябып куйды.

Безне кара кайгы басты. Узган ел гына бер кесә яшь арыш урлап уган өчен

Мәфтукәттәйне ун елга утыртканнар иде. Әфка абый кешеләрнең сөйләшүен тыңлап торган, әнкәй чәчү агрегатында эшләүче Тәзкирәттәйне урлашырга котырткан икән. Имеш, чәчү нормасын киметәләр дә, калган симәнәне икесенә бүләләр.

Тәзкирәттәй җинаятькә бармаган, бу хәлне чәчми-түкми тиешле җиренә житкергән. Әнкәйне басуда ук кулга алганнар.

Хәзер инде мин бур малае да. Авылда кылт итү дә эзсез генә үтеп китми шул. Беркөнне дәрес уртасында җирән баш Хәләф урыныннан торды да:

—Апа, Маратларга тентү керде,—диде.

Бөртенеп чыктым. Барча күзләр укытучыга төбәлгән: ул ни әйтер?

—Борһанов, дәрестән читләшмә, мәсьәләнне чиш,—диде Фәһимә апа тыныч кына. Мин аны барып кочаклый яздым.

Директорыбыз Җәмилә апа да нишләптер бу вакыйганы куертмады, иртән коридордан үтеп киткәндә хәтта аркамнан да сыйпап узды.

Тентү керде, әйе. Бөтен җирне актарып бетерделәр. Өй түбәсенә дә менделәр, идән астына да төштеләр. Мунча, абзар-кура—берсе дә калмады. Алма бакчасын, кое тирәсен очлы тимер ярдәмендә тишкәләп тикшерделәр. Шөкер, бернәрсәсез киттеләр.

—Ул җирән башны акылга утыртырга кирәк,—диде Илгиз. Мин үзем дә шул фикердә идем. Кайтырга чыккач, якалап алдым моны. Куркынып калды Хәләф. Күзләре челт тә челт. Шулай озак кына бер-беребезгә карашып тордык. Иң элек ул телгә килде.

—Җә, Марат, суксаң сук та, мина кайтырга кирәк, инәй чирләп ята...

Кулларым үзеннән-үзе ычкынды. Ничек инде инәсе чирләп яткан малайны тукмаклыйсың ди?

Әнкәйнең төрмәдә утыруына да иртәгә нәкъ бер атна тула. Кичтән олы балыкка кармак салып кайткан идем, зур гына кызылканат эләккән. И, сөенгәннәрем.

Өйгә атлап түгел, очып кайттым. Инәкәй капка төбен себерә иде. Чүп-чардан арындыргач, тирә-як хозурланып калган, әйтерсең лә яшел хәтфә җәйгәннәр. Көн искиткеч матур. Якты, җылы. Һәр тарафта яз елмаюы...

—Балыгыңны үзең чистарт, балам, мин учак тергезермен,—диде инәкәй,—иртәрәк кузгалырсың, әнкәң дә юксынадыр.

Күзен угалый-угалый Клара белән Венера да безнең янга чыкты.

—И, йокы чүлмәкләре, ничек торасы иттегез?—дип шаяртты инәкәй.

—Без әллә кайчан уянган идек инде, күзне генә ачып булмады,—диде Клара.

—Балалар, карагыз әле, әллә күземә күренә инде...

Карасак, тау башыннан, турыга юл ярып, әнкәй төшеп килә...

—Әнкәй кайта!

—Әнкәй!

Без бер сулыш белән урыныбыздан кузгалдык та, абына-сөртенә әнкәйгә каршы йөгердек...

—Әнкәй!!!

Язгы матур көн безгә бетмәс-төкәнмәс бәхет алып килде.

Тәзкирәттәй әүвәлге сүзләреннән баш тарткан икән. «Кеше котыртуы белән генә намуслы кешегә яла яктым»,—дип, милициягә барган.

Әлеге мәкерле хәлнең эчке агымнары турында мин бернәрсә дә белмим, чөнки бервакытта да төпченмәдем, әнкәйнең ярасына тоз саласым килмәде.

Тормышыбыз, дәһшәтле сугыш катгыйлыгы белән аралашып, үз эзенә төште. Әнкәй—командир, инәкәй—комиссар. Ә без дүрт бала: Әфка, Марат, Клара, Венера—бәләкәй солдатлар.

Алда исә янадан-яна көтелмәгән сынаулар...

**Марат ӘМИРХАНОВ**



*Саумысыз, «җилкән»челәр! Мин* ***Гөлзилә ГАФУРОВА*** *1996 елның 6 декабрендә ямьле Алан авылында дөньяга килгәнмен. 2003 елда авылыбыз мәктәбенең беренче сыйныфына укырга кердем. 2009 елдан Салавыч урта мәктәбендә укый башладым.*

*Кечкенәдән шигырьләр, хикәя-әкиятләр язарга яратам. Табигатьне бик яратам, шуна да шигырьләремнең күбесе табигать белән бәйләнгән...*

## Киләчәк күрсәтер!

**Җәйге таңда торып чыктым бакчаларга,**
**Ишетергә сандугачның тавышларын.**
**Ниләр диеп сайрый икән бу сандугач,**
**Әллә инде баса шулай сагышларын?**

**Җәйге таңда торып төштем чишмәләргә,**
**Чиләк-чиләк тутырып алдым суларын.**
**Чишмәләр дә ага никтер ярсып-ярсып,**
**Җиткерергә теләп әллә уйларын?**

**Әкрен генә кояш әнә өскә үрли,**
**Торган саен безгә ныграк елмая.**
**Чишмәкәем, зинһар инде, өзгәләнмә,**
**Сандугачым, зинһар инде, елама!**

**Кара төннән соң да әнә кояш чыга,**
**Тормышта да шулайдыр ул, күрәмсең.**
**Хисләреңнән көлеп әгәр елатсалар,**
**Килер бер көн, сөенепләр көләрсең!**

## Якыная бәхет...

*(Җыр...)*

**Җәйге матур кичтә**
**Чылтырыйдыр чишмә -**
**Җанга якын аның тавышы.**
**Дөрләп яна учак,**
**Синең җылы кочак**
**Ишеттерә йөрәк кагышың.**

**Инеш җырын суза,**
**Кошлар сайрап уза,**
**Таллар шаулый җилләр искәндә.**
**Якыная бәхет**
**Шушы ямьле кичтә**
**Шатлык йотымнарын эчкәндә.**

Күктә йолдыз балкый,
Салмак ай тибрәлә,
Каурый кебек ага болытлар.
Шушы матур кичне,
Пакь мәхәббәт хисен
Беркайчан да, ахры, онытмам.

### Хыял...

Гашыйк булдым синең соры күзләреңә,
Күзем төбим синең уйчан йөзләреңә,
Битем куям синең кара чәчләреңә,
Ярсып типкән куе кайнар йөрәгеңә.

Йөгереп килеп керәм синең кочагыңа,
Учларымны куям синең учларыңа,
Мине салдың сөюләрең учагына... –
Ә бит болар барысы да хыял гына...

### Карлар кебек вакытлыча гына...

Кышкы ачы салкын кич урамда
Мин барамын йөгереп синең янга.
Шыгыр–шыгыр карның тавышы,
Әйтерсең лә ташу агышы.

Кышкы ачы салкын кич урамда.
Кар аклыгы–күңелең сафлыгы.
Сине өзелеп–өзелеп сагынганга
Кысып кочар өчен ашкындым.
Тик...

Язмаган шул сине кочаклаулар,
Күзләреңә карап көлүләр.
Язын карлар эреп беткән кебек
Эреп акты синең сөюләр...

## КАРАШ

Атна дәвамында явымсыз һава торачак дисәләр дә, төштән соң табигать кискен үзгәрде: күк йөзен тоташ болытлар каплап алды һәм пыскып кына көзге салкын янгыр яварга тотынды. Кояш әле бер, әле икенче болыт артыннан үрелеп, жиргә нурларын сибәргә тырышты, жылы карашы белән кешеләрне иркәләргә теләде, әмма усал болытлар алагаем олы куллары белән кояшның самими йөзен каплап, ана тирә-юньне нурландырырга ирек бирмәделәр. Янгыр отыры көчәйде һәм ишсп-ишеп яварга тотынды.

Синоптикларны кисәтеп тә тормыйча килгән әлеге әрсез кунак бик күпләрне авыр хәлдә калдырды. Юка гына киенгән һәм кул чатырларын алырга кирәксенмәгән кешеләр качарга урын эзләп чабыштылар. Мин дә, үтәли жилдән һәм әрсез янгырдан сакланыр өчен, үземне-үзем кочаклап, тукталышка кереп ышыкландым. Гадәттә гел вакытында йөрүче автобусым бүген, мина үч иткәндәй, сонара. Пәлтәмнең сонгы жебе дә юешләнде дигәндә, ниһаять, офыкта өзелеп көткән «якын дустым»

—47нче маршрут автобусы күренде. Уку йортыннан чыкканда ук әзерләп куйган унсигез сум акчамны учыма кыстым да, автобусны каршыларга дип юл кырыена чыгып бастым.

Ишекләр ачылды. Мин берничә секундтан җылы автобус эчендә идем инде. Озак сайланып тормыйча, шофер янындагы буш урындыкка барып утырдым. Юл озын һәм күнелсез иде. Үземне бераз мавыктырырга дип сумкамнан чыгарып китап караштыра башладым. Бер бит, ике, өч... Кинәт кемнеңдер көйдергеч карашын сиздем. Тагын бераздан мине үтәли тишеп чыгачак бит бу! Күтәрелеп караргамы, әллә карашы белән үземне «ашатып» барыргамы? Сизмәгәнгә салышып, китап битләрен актарырга керештем. Ләкин кайда инде ул сизмәү?! Моңа кадәр салкыннан күшеккән тәнем кисәк кенә эсселәп китте, сулышым ешайды, яңакларым ут капкандай янарга тотынды, карашымны китап битенә юнәлдерергә никадәр генә тырышсам да, керфекләрем мине тыңламады һәм күзләрем үзләреннән-үзләре сихри караш иясенә төбәлделәр.

...Менә ул!!! Менә ул —минем хыялымда йөргән сөйгән яр! Имәндәй нык гәүдә, озын буй, төпсез кара күзләр, сызылып киткән кара кашлар, дулкын-дулкын кара чәч.. Мин, сихерләнгәндәй, егеттән күземне ала алмыйм. Кешегә шулай карап торырга ярамаганлыкны акылым белән аңласам да, йөрәгем тыңламый. Шулай да, бар ихтыяр көчемне туплап, карашымны автобус эчендәге реклама кәгазьләренә юнәлттем. Ниндидер таныш хәрефләр, таныш сүзләр. Мин аларны укыган булам, ләкин укыганым аңыма барып житми.

...Өстемдә һаман шул ук караш. Түзмәдем, кабат күтәрелеп карарга булдым. Безнең карашларыбыз тагын очрашты. Юл буе читтә басып барган чибәр егет минем каршыма килеп басты. Хәлиткеч мизгелнең —танышуның котылгысызлыгын уйлаудан йөрәгем күкрәк читлегеннән чыгып төшәрдәй булып тибәргә тотынды. Санаулы вакыт аралыгында хыял канатларыма утырып күккә ашкандай булдым, егетнең күзләреннән сирпелгән нурларда коендым, икебезнең арага сузылган аллы-гөлле салават күпере аша хыялыма таба атлап китәргә җыендым. Егет исә, күземә туп-туры карап салкын бер елмаю белән елмайды да:

—Гафу итегез, сез билет алмадыгыз һәм инде кайчаннан бирле минем урынымда утырып барасыз! —диде.

Көтелмәгән сүзләрдән мин өнсез калдым. Күкнең җиденче катында адашып йөргән хыялым, төшәргә баскыч таба алмаганлыктан, дөбердәп җиргә егылып төште һәм мин, мингерәгән кешедәй шаккатып, егеткә төбәлдем. Кондуктор исә ачулана ук башлады.

—Урынымны бушатыгыз әле! – диде ул.


Әлеге сүзләр аңыма барып җиткәндә, «Академик Парин тукталышы» дигән игълан яңгырады. Учымда килгәнлектән юешләнгән унсигез сумны кондукторга тоттырдым да, ишеккә атылдым. Автобустан ничек төшкәнмен дә ни рәвешле юл аркылы чыкканмындыр – һич хәтерләмим.

Җәяү кайтып барганда гына оялудан кызарганлыгымны сизеп алдым. Кайта-кайта, юләрлегем үземә үк көлке булып тоела башлады.

**Айгөл ГАБДРАХМАНОВА.**
*Казан Федераль университеты, II курс.*

# РЕБУС

Ребусны чишсәгез,
Константин Станиславскийның
канатлы сүзләрен укырсыз.
*(Жавабы киләсе санда.)*




*Төзүчесе* **Зөфәр ХИСАМОВ.**

## Тукран ла бионикага ярдәм итә

Кытай галимнәре тукранның анатомиясен, төгәлрәк әйткәндә, аның баш сөяге һәм томшыгының үзенчәлекләрен җентекләп өйрәнгәннәр, имеш. Чыннан да, бик кызыклы мәсьәлә бит! Чуар кошчык, азык эзләп «башын эшләткәндә», ягъни томшыгы белән агач кәүсәсен чукыганда, башының хәрәкәт тизлеге секундка 7 метр чамасында була икән. Ә хәрәкәт ешлыгын шатырдавыннан чамалап була - автоматтан аталар диярсең, билләһи! Шундый тизлек һәм ешлыкта кайры астындагы каты агачны чукыганда аның томшыгы ничек тузып бетми икән дә, башы ничек чәлпәрәмә килми икән? Кара аркалы һәм кызыл җилкәле, «ак погоннар» таккан көяз тукран егетен шаклар катып бинокльдән күзәткәнем дә булды.

Кытай галимнәре исә соклanudан бигрәк файдалы мәгълүмат алырга омтылганнардыр, мөгаен. Кошны аның баш сөягенең кайбер урыннары күзәнәксыман төзелешле булуы да, томшыгының тетрәнүгә чыдамлы булып формалашуы да травмалардан саклый, имеш. Шуңа күрә гүзәл кошкай, агачларга зыян китерүче корткычларны юк итеп «урман Айболиты» ролен башкару белән генә чикләнмичә, хәзер техника белгечләренә иминлек чараларын шәбәйтергә дә өйрәтмәкче, күрәсең.

Тукран турында укыгач, узган гасырның икенче яртысында туып тернәкләнгән «бионика» атамалы чагыштырмача яна фән исемә төшкән иде. «Бионика» грек телендәге «яшәүче»не аңлата торган «бион» сүзеннән алынган. Бу фән белгечләре, тере организмнарның һәм үсемлекләрнең төзелешен, яшәү үзенчәлекләрен тикшереп, нәтиҗәләрен техникада, инженерлык мәсьәләләрен хәл иткәндә кулланалар. Шуңа күрә бионика карамагына кергән проблемаларны санап чыгу да мөмкин түгелдер, мөгаен. Ул биология, химия, физика, кибернетика һәм электроника, навигация, элемтә һ.б.ш. инженерлык фәннәре белән бәйләнештә тора.

1960 елда АКШның Дайтон каласында бионика буенча уздырылган беренче симпозиум бу яңа фәннең туган көне дип санала.

Күрәсез ки, мөхтәрәм укучыларым, язмам башында искә алган кытай галимнәре тукран томшыгын бер дә юкка гына өйрәнмәгәннәр. Томшыкның һәм баш сөягенең төзелеше турында үзләре шәрехләп сөйләмиләр дә. Тел яшерәләр. Юкка гына түгел инде. Чөнки андый ачышларның техника өлкәсендә шактый күп яңа җайланмалар уйлап табуга этәргеч булуы мөмкин.

Табигать кочагында «күзенне ачыбрак» йөрсәң, бик кызыклы күренешләргә юлыгуың ихтимал. Шундый бер вакыйганың шактый күп вакыт узгач абруйлы халыкара фәнни конференция делегатлары алдында бик кызыклы яңа караш белән доклад сөйләргә этәргеч булуы хакында шәрехләбрәк сөйләрмен әле.

**Ким ШАКИРОВ**

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*E-mail: kazanutlari@yandex.ru*

# ҖЫЕЛЫЙК БЕР ТҮГӘРӘККӘ...

*Татар традицион мәдәниятен яктыртуны максат иткән «Түгәрәк уен» альманахының дөнья күрә башлавы мәдәни тормышыбызда вакыйга булды, дисәк тә хак, чөнки әлегә кадәр татар фольклорына багышланган аерым бер басмабыз юк иде. Ниһаять, без шундый басмага ирештек. Ул ничек туды, кемнәрне күздә тотып нәшер ителә, алга таба нинди планнар белән яши һәм ни өчен—альманах? Шундый сораулар белән без «Түгәрәк уен»ның баш мөхәррире шагыйрә **Илсөяр ИКСАНОВА**га мөрәҗәгать иттек.*




—Берни дә буш урында тумый, табигый ки, һәр нәрсәнең җирлеге була. Шуның өстенә һәр нәрсәнең үз вакыты житү, ниндидер алшартларның үтәлүе дә зарур.

Әле 1991 елда, Мәдәният министрлыгы каршында Татар фольклор үзәге оешкан вакытта ук, Үзәктә эшләүче галимнәр үз алларына махсус журналларын булдыру максатын да куялар. Ләкин бу максат тормышка ашканчы, күрәсез, 20 ел вакыт кирәк булган. Ә безнең—әлеге басманы дөньяга тудыручы мөхәррирләрнең—шушы эшкә керешеп китүе өчен Татар фольклор үзәге оештырган «Түгәрәк уен» фестивальләрендә катнашуыбыз кирәк булгандыр, күрәсең. Әлеге фестивальнең проект авторы һәм аны төп оештыручыларның берсе, Татар фольклор үзәге директоры Фәнзилә Жәүһәрова безне—«Сөембикә» журналы мөхәррирләре Гөлсинә Хәмидуллина һәм Илсөяр Иксанованы, Сембер өлкәсенең Иске Кулатка районында узган беренче «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклоры фестиваленә жюри әгъзалары буларак чакырган иде.

Рәсәйнең 17 төбәгеннән жыелган фольклор коллективларының чыгышын караганнан соң, халык күңелендә әле моңа кадәр дөньяга чыкмаган күпме хәзинә саклануын күреп таң калдык. Шул бәһасез байлыкны бөтен халкыбыз белән бүлешү теләге иң элек шунда бөреләнә башлагандыр. Әлбәттә, без, гомер буе матбугатта эшләгән кешеләр, бу хәзинәне халыкка таратуның иң кулай юлын вакытлы матбугат дип таптык. Инде Төмәндә үткән икенче фестиваль вакытында Тубыл өлкәсе Вагай районының Олы Карагай авылыннан килгән Гөлнараның: «Сез үзегезнең бирегә килеп, себерәкләр белән бер телдә якын туганнардай аралашып, бер үк жырларны жырлап утыруыгызга ышанасызмы соң?»—дип гаять хисләнеп әйткән сүзләре күңелдәге ниятебезне тагын бер кат ныгытып жибәрде. Әйе, без, татарлар, шулай бер түгәрәктә булырга, һәрдаим аралашып торырга, бер-беребезне рухи баетып яшәргә тиеш тә. Аралашуның юллары күп төрле һәм аның берсе, һичшиксез, басма сүз.

Екатеринбург кабул иткән өченче фестиваль вакытында шахталарда алтын чыгарган, күмер кискән милләттәшләр белән очрашулар вакытында кулыбызга килеп кергән күңел дәфтәрләре, һичшиксез, татар укучысына барып ирешергә тиеш иде. Чит якларга бәхет эзләп китеп, жиде кат жир асларында тир түккән ир-атларның кулларына каләм алып үз тормышларын шигъри калыпка салган язмалары үзе бер тарих бит. Ә андый язмалар, андый тарихлар «Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге» (элек «Татар фольклор үзәге») фондында гына да никадәр! Кыскасы,

материалларга кытлык булмаячагы көн кебек ачык иде. «Түгәрәк уен» альманахы әнә шулай туды.

Аңлашылганча, басмабызның төп максаты халкыбызның гасырлар дәвамында тупланып килгән асыл мирас сандыгын ачып, андагы хәзинәне барлау, дөньяга күрсәтү белән бергә, аерым кешеләрнең үз күңелендә генә сакланган җәүһәрләрне уртак сандыгыбызга сала бару. Ерактагы, «караңгы» авылларда аерым фидакарь затлар тарафыннан җыелган кечкенә музейлардагы, теләсә кайсы дәрәҗәле музей фондларын баетырлык энҗе бөртекләренә тиң табылдыкларны күргәндә, бу хәзинәләр дә дөньяга чыгарга тиеш ләбаса, дигән теләк туа иде. Беренче санныбызны әзерләгәндә Яшел Үзән районының Ислам авылындагы изге урынга—Әбелкасыйм баба чишмәсенә кайткан җирдә генә дә ике гаҗәеп музейга тап булдык. Аның беренчесе—Ислам авылындагы искиткеч фидакарь зат Шамил әфәнде (ул шулкадәр тыйнак, хәтта үзенең фамилиясен дә атамады) туплаган ачык музей, икенчесе—Шырдан авылы балалар бакчасында гап-гади тәрбияче Зөлфия ханым Закирова оештырган гаҗәеп бай музей. Мондый күркәм күренешләр һичшиксез басмабызда урын алырга тиеш.

Онытылып барган уеннарыбызны, йола-бәйрәмнәребезне чыганаклардан күтәреп, хәтердә торгызып, тормышыбызга кайтаруда да безнең альманахыбыз ярдәмче булыр дип ышанабыз. «Түгәрәк уен»ның беренче санында профессор Марсель Бакиров тәкъдим иткән Сөмбелә бәйрәме турында тарихи мәгълүмат һәм бәйрәмне үткәрү өчен сценарий үрнәген Мәдәният йортлары хезмәткәрләре хуплап кабул иттеләр. Мондый эшләрен алар киләчәктә дә дәвам итәчәк.

«Изге урыннарыбыз», «Кушам ат», «Алдым каләм, яздым сәлам...», «Йөрәк язмалары», «Шәҗәрә», «Вакыт көзгесе» – болар укучыларыбыз белән турыдан-туры бергәләп эшли торган сәхифәләребез. Ә фольклорчы галимнәребезнең хезмәтләре, экспедиция материаллары, татар мәдәниятен өйрәнгән чит ил галимнәренең язмалары, халкыбызның традицион яшәешен чагылдырган матур әдәбият үрнәкләре исә, укучыларыбызга мәгълүмат бирү белән бергә, рухи азык та булыр дип ышанабыз. Альманахның эчтәлеге турында сөйләгәндә, кыскача менә шулар. Әлбәттә, ул эчтәлекне без галимнәребез, язучыларыбыз, укучыларыбыз белән бергәләп баетырбыз дип өметләнәбез.

Инде, ни өчен альманах дигәндә... Аңлатмалы сүзлекләрдә «Альманах—бер чорда яшәгән төрле авторларның әдәби, тарихи һәм публицистик характердагы әсәрләр җыентыгы» диелә. Шулай ук альманах сүзенең иң элек календарь мәгънәсендә кулланылуы да мәгълүм. «Миллият сүзлеге»н төзегән галим, язучы Адлер Тимергалин исә: «Альманах—гарәп телендәге «тукталыш» дигән сүздән алынган. Чүлләрдә кәрван йөртүчеләр туктап төн кунган вакытларда учак тирәсенә җыйналып төрле хикәятләр сөйләгәннәр, кызыклы хәлләрне бәян иткәннәр. Соңыннан шундый эчтәлектәге язмаларны туплаган басманы да «әл-манах» дип атаганнар»,—дип аңлата. Бу турыда Д.Н. Ушаковның аңлатмалы сүзлегендә дә әйтелә.

Халкыбызның традицион мәдәниятенә кагылышлы төрле төстәге язмаларны туплаган басманы нәкъ менә Адлер Тимергалин аңлатмасындагы альманах итеп тәгаенләү дөрес булыр. Чынлап та, бу—рухи хәзинәләребезне бүлешә торган уртак мәйданыбыз. Без шулай итеп сибелгән-чәчелгән, төрле шивәләрдә сөйләшкән, ләкин һәрвакыт үзенең тамырларын тоеп, тарихи үткәнен хәтерләп, үзенең милләте белән горурланып яшәгән татарларны бер түгәрәккә җыярга телибез һәм «Түгәрәк уен»ыбыз татар халкының рухи аралашу мәйданына әверелер дип ышанабыз. Моны дәлилләр өчен әле күптән түгел генә Саба районының Түбән Шытсу урта гомумбелем бирү мәктәбендә күреп-танышып кайткан «Дубая» халык уен кораллары фольклор ансамбле җитәкчесе Илшат Шәрифуллинның сүзләрен китерәсем килә. «Саба район Мәдәният йортының методик кабинет җитәкчесе Рәйсә апа Имамиева безне, фольклор коллективлары җитәкчеләрен җыйгач, «Түгәрәк уен» сезнең өстәл альманахыгыз булырга тиеш»,—дигән иде. Ә мин, сезнең белән күрешкәч, ниһаять, үземне аңлардай кешеләр таптым дип куанам».

Бергә булыйк!

# М

**«МОАБИТ ДӘФТӘРЕ»**, М.Җәлил тарафыннан 1942-44 елларда күбесенчә Моабит (Берлин) фашист төрмәсендә үлем көтеп ятканда язылган шигырьләр циклы. 93 шигырь теркәлгән 2 блокнот сакланган. Гарәп графикасында язылган беренче блокнотны төрмәдән әсир сугышчы Г.Шәрипов алып чыга. Ул аны Франциядә Каршылык хәрәкәтендә (Сопротивление) катнашкан Н.Терегуловка бирә. Терегулов исә 1946 нын мартында СССРга алып кайта. Латин графикасында язылган икенче блокнотны шагыйрьнең камерадашы, Бельгиядә Каршылык хәрәкәтендә катнашкан А.Тиммерманс алып чыга. 1947 нең язында совет консульствосы аны Брюссельдан Казанга җибәрә. Ул елларда М.Җәлил исеме тыелган була. СССР КГБсы, шагыйрьне җинаятьчелектә гаепләп, эш ача, аңа сатлык җан исеме тагыла. Тик И.В.Сталин үлгәннән соң гына И.Френкель тәрҗемәсендә шагыйрьнең берничә шигыре «Литературная газета»да (25 апрель, 1953) басылып чыга. Тулысынча шигырьләр татар телендә 1953 нең ахырында «Моабит дәфтәре» исеме б-н (Г.Кашшаф редакциясендә) дөнья күрә. «М.Д.» циклы—Бөек Ватан сугышы еллары татар поэзиясенең иң зур казанышларыннан берсе. М.Җәлил шигъри сүзне гражданлык яңгырашы б-н баетты, татар поэзиясенә героик төсмерләр алып килде («Җырларым», «Алман илендә», «Ышанма» һ.б.). «М.д.» үз эченә ш.у. үтә лирик, юморга корылган шигырьләр һәм балладалар алган. Шагыйрь ил сакчысының эчке дөньясын, аның ватанына булган кайнар мәхәббәтен һәм тугрылыгын, дошманга карата нәфрәтен тирән ача алган. Патриотизм темасы «М.д.»ндә яңа эстетик дәрәҗәгә күтәрелгән һәм нык тәэсиргә ия булган сәнгати көч б-н ачылган. Шигырьләр үз эченә татар язма әдәбиятының күпгасырлык традицияләрен, татар фольклорының мотивларын алган, ш.у. шәрык поэтикасы, рус һәм дөнья әдәбияты тәэсирендә язылган. «М.д.» күп мәртәбә татар һәм рус телләрендә басыла, 60 тан артык чит телгә тәрҗемә ителә. «М.д.» мотивларына нигезләнеп рәссам В.П.Аршинов югары сәнгати цикл иҗат итте. Татар композиторлары (С.Сәйдәшев, Р.Яхин, З.Хәбибуллин) цикл шигырьләренә җырлар яздылар. «М.д.» поэтикасының йогынтысын Р.Фәйзуллин, Р.Харис, И.Юзеев иҗатларында сиземләп була. «М.д.»нең төп нөсхәсе ТРның Милли музеенда саклана, һәр елны шагыйрьнең туган көнендә экспозиция оештырыла. Циклга 1957 дә Ленин премиясе бирелә.

Әд.: Мустафин Р. По следам оборванной песни. К., 2004; Кашшаф Г. Муса Җәлил. К., 1961.

*Р.Ә.Мостафин.*

**МОЗАФФАРИЯ** Маһруй Габделвәли кызы (1873, Казан губ., Тәтеш өязе Олы Тормы а. – 5.12.1945, Казан), язучы, педагог. Мулла гаиләсеннән. Башлангыч белемне атасыннан ала, соңыннан үзлегеннән укый. 1891 дән туган авылында балалар укыта. 1894 Казанга күчә. 1901 дә үз өендә кыз балалар өчен җәдит мәктәбе («М.Мозаффариянең абыстайлар мәктәбе») ача, соңыннан Хәдичә Әхмәрованың хосусый хатын-кызлар мәктәбендә укыта. 1917 дән соң хатын-кызлар арасында агитатор була, №5 мәктәптә укыта (1925 кә кадәр); 1935 тән мәктәпкә кадәрге балалар оешмалары инспекторы. 1905 тән матбугат битләрендә хатын-кыз эмансипациясенә багышланган мәкаләләр һәм шигырьләр бастыра («Мәшһүр хатыннар», 1907; «Габдулла Тукаевның хатын-кыз галәменә тәэсире», 1913 һ.б.). «Яднамә» (1901) укыту әсбабы авторы.

Әд.: Өмет йолдызлары: XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар хатын-кыз язучылары әсәрләре. К., 1988; Рәсүлева З., Хуҗиәхмәтов Ә. Мәгърифәт йолдызлыгында. К., 1998; Татар шигърияте: XX гасыр башы. К., 2004.

*А.М.Ахунов.*

**МОЗАФФАРИЯ** Мәхмүдә Хуҗиәхмәт кызы (1893, Казан–1969, ш.у.), шагыйрә, педагог. М.Г.Мозаффария кызы. Ф.Аитованың хосусый мәктәбендә укыта, 1922 дән Казанның Яңа бистә татар мәктәбендә. Беренче шигырьләрен 1907 дә «Әл-Ислах» г-тасында бастыра. Хатын-

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

кызларның ирләр б-н бер хокукка ия булу тиешлегенә багышланган мәсьәләләр б-н чыгышлар ясый, аларны мөстәкыйль булуга өнди, белем алуга чакыра («Уйганыйк, ханымнар!», «Ханымнар», 1907 һ.б.).

Әд.: Өмет йолдызлары: XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар хатын-кыз язучылары әсәрләре. К., 1988; Рәсүлева З., Хужиәхмәтов Ә. Мәгърифәт йолдызлыгында. К., 1998; Татар шигърияте: XX гасыр башы. К., 2004.

*З.З.Рәмиев.*

**МОНАСЫЙПОВ** Вахит Сабит улы (20.12.1928, Казакъстан ССР Актюбинск ш.), язучы. Татар һәм рус телләрендә яза. М.Горький исем. Әдәби институтны тәмамлый (Мәскәү, 1971). 1959 га кадәр Актюбинск ш. яши, паровоз депосында слесарь, Көнбатыш-Казакъстан геолог. экспедициясендә коллектор, өлкә радиосында корресподенция челтәре житәкчесе, «Ленин алмашы» («Ленинская смена») яшьләр г-тасында махсус корреспондент булып эшли. 1959 да Казанга килә, 1969 га кадәр «Чаян» ж-лының фельетоннар бүлеген житәкли. 1980 дә Әстерхан ш. китә. Ижатында аеруча юмор һәм сатира өлкәсендә уңышлы эшли. Казанның «Чаян», «Казан утлары», »Сөембикә», «Ялкын» ж-ларында, Мәскәүнең «Крокодил», «Смена», »Наш современник», Польшаның «Карусель», Чехиянең «Рогач», Венгриянең «Лудаш мати» ж-ларында басыла. М.ның жанлы, тапкыр сатирик хикәяләр, фельетоннар һәм юморескаларында кеше кимчелекләре, жәмгыять тормышындагы тискәре күренешләр көлкегә калдырыла. «Сак булыгыз» (1965), «Көлке — гөнаһ түгел» («Смеяться не грешно», 1967), «Кешеләр арасындагы кеше» («Человек меж людей», 1972), «Күктән ингән бәхет» («Счастье с неба», Волгоград, 1981), «Усал юморист» («Злой юморист», 1988), «Соңгы ачы көлчә» («Последняя горькая лепёшка», Волгоград, 1990) хикәяләр жыентыклары авторы. Балалар өчен язылган жыентыкларга («Сәләхетдин бүреге», 1967; рус телендә 1976; «Тайга печән кем сала?», 1970) кергән әсәрләрендә автор кечкенә геройларының ялкаулык, дорфалык, саранлыгыннан көлүдән тыш, аларга яшел «аптека» байлыклары турында сөйли. М.ның хикәяләре башкорт, мари, кыргыз, украин, казакъ, алман һ.б. телләргә тәржемә ителгән.

*Р.М.Габделхакова.*

**МОРАН** Рувим Давидович (8.9.1908, Херсон губернасы Берёзовка а. — 1986, Мәскәү), шагыйрь, тәржемәче. «Сайлау» («Выбор», 1968), «Соңгы сәгатьтә» («В последний час», М., 1990). Рус теленә Мәүлә Колый, Г.Кандалый, Я.Емельянов, Г.Тукай, Н.Думави, М.Жәлил, Ф.Кәрим, Х.Туфан, С.Хәким, Ә.Ерикәй шигырьләрен (татар телен өйрәнеп) тәржемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Орден, медальләр б-н бүләкләнә. 1948-55 елларда нахакка репрессияләнә, соңыннан реабилитацияләнә.


**МОРАТ** (Моратов) Газинур Васикъ улы (18.8.1959, Кукмара р-ны Зур Сәрдек ав. туа), шагыйрь, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2001). Казан ун-тын тәмамлагач (1981) «Татарстан яшьләре» газетасында бүлек мөхәррире булып эшли. 1984-88 дә «Ялкын» ж-лында бүлек мөдире, 1989-91 дә ВЛКСМ ҮК каршындагы республика әдәби ижат берләшмәсе житәкчесе, 1991-93 тә «Идел» ж-лы редакциясендә бүлек мөдире, 1993-95 тә «Татар иле» газетасының баш мөхәррир урынбасары. 1995 тән «Мәдәни жомга» газетасында баш мөхәррир урынбасары вазифасында. «Жир хәтере» исемле беренче шигырь жыентыгы 1985 елда дөнья күрә. Аның «Мин дөньяны тыңлыйм» (1988), «Оча жырлар» (1991), «Түбә» (1998), «Төнге әверелеш» (2005) жыентыклары өчен тирән фәлсәфи уйланулар, тормыш вакыйгаларын киң колачлау, аларны сурәтләгәндә әхлакый аспектларга басым ясау хас. Шигырьләре романтик рухлы, бер үк вакытта заманча публицистик яңгырашлы. 1990 еллар татар поэзиясендә М.ның да «Ачлык» (1992) поэмасы аерым урын тота. Монда 1990 еллар башында татар халкы милли үзаңы үсеше белән бәйле вакыйгалар, суверенитет өчен көрәш турында сүз бара. М. шулай ук «Жәяүле кошлар» (2002) дигән әдәби-публицистик, «Тылсымлы тел» (1989), «Ачык дәрес» (1995) исемле балалар өчен язылган жыентыклар авторы да. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. (2000), Республика яшьләр оешмасының М.Жәлил исем. (2007) премияләр лауреаты.

Әд.: Галиуллин Т. Поэтическая публицистика // Татарстан. 2003. №11; Шәрәфиев Р. Хакны әйтүчеләр иллә бар // Казан утлары. 2003. №8; Мансуров З. Чичәннәр кайтавазын кемнәр кечәйтә // Казан утлары. 2005. №9.


*Г.М.Габделхакова.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

## *«Казан утлары» архивыннан*



*«Казан утлары» журналының 70 еллыгы тантанасыннан күренеш. Г.Камал театры. Август. 1992 ел.*



*Татарстанның халык язучысы Мөсәгыйт Хәбибуллин шагыйрь Әхмәт Исхакны искә алу кичәсендә чыгыш ясый. Аның янында Әхмәт Исхакның җәмәгате Гөлсем ханым. 2005 ел.*



*Тарихчы, академик-галим Миркасыйм Госманов (1934-2010). Ул безнең журналның актив авторы һәм редколлегия әгъзасы иде. 2004 елгы фото.*



*Мәшһүр җырчы, Россиянең һәм Татарстанның халык артисткасы Зилә Сөнгатуллина. 1983 ел.*



*Авылдашлар. Мәгъсүм Насыйбуллин һәм Тәлгат Нәҗмиев Кукмара районының Байлангар авылында. 2000 ел.*

## МӘСКӘҮДӘ ТАТАРСТАН КӨННӘРЕ

Мәгълүм булганча, үткән елның март аенда Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре арасында сәүдә-икътисади, фәнни-техник, социаль-мәдәни хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелган иде. Ул уңышлы гына тормышка ашырылып килә. Мәсәлән, августта республикабызда Мәскәү көннәре булып узды. Ә 24-27 ноябрьдә Мәскәүдә Татарстан көннәре үткәрелде. Анда Президентыбыз Рөстәм Миннеханов катнашты.

Бәйрәм Тәүбә тавында урнашкан 1941-45 елгы Ватан сугышы үзәк музеенең Дан залындагы Солдат һәйкәленә чәчәкләр салудан башланып китте. Чарада республикабыз һәм Мәскәү шәһәре җитәкчелеге вәкилләре белән бергә Татарстаннан килгән сугыш ветераннары да катнашты.

Аннары татарстанлылар мәскәүлеләр белән бергә бөек шагыйребез Г.Тукай һәйкәленә чәчәкләр куйды. Белгәнебезчә, Мәскәүдә Г.Тукайга һәйкәл быел яз көне куелган иде. Скульптураның авторы—рәссам С. Щербаков. Монумент Казанда коелды һәм Татарстан хөкүмәте тарафыннан Мәскәүгә бүләк итеп тапшырылды. Һәйкәл Замоскворечье районының Новокузнецкая урамында, Мәскәүдәге Татар мәдәнияте үзәге буларак билгеле Әсәдуллаевлар йортыннан ерак түгел урнашкан. Бу көнне бөек шагыйребез рухын яд итәргә килгән халык арасында Мәскәү шәһәре мәдәният департаменты башлыгы С.Капков та бар иде.

Татарстан делегациясе каһарман-шагыйрь М.Җәлил исемендәге 1186нчы мәктәптә дә булды. Бүгенге көндә ул—Мәскәүдә татар милли-мәдәни компонентлы бердәнбер мәктәп. Укытучылар белән Президент Р. Миннеханов, Татарстан мәгариф һәм фән министры А.Гыйльметдинов, Мәскәүнең мәгариф департаменты башлыгы И.Калина, шәһәрнең көньяк-көнчыгыш административ округы префекты В.Зотов һ.б. очрашты. Мәктәп 1997 елда балалар бакчасы бинасында ачыла. 2006 елда ана М.Җәлил исеме бирелә. Тагын бер елдан ул махсус төзелгән 4 катлы матур бинага күчә. 2008 елда мәктәпнең ишегалдында М.Җәлилгә һәйкәл куела. Бүгенге көндә ул—Мәскәүдә каһарман-шагыйрьгә куелган бердәнбер һәйкәл. Әмма 2012 елда Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре арасында хезмәттәшлек турындагы килешүне тормышка ашыруның бер чарасы буларак, Мәскәүнең Муса Җәлил урамында шагыйрьгә һәйкәл торгызу күздә тотыла.

Мәскәү шәһәре мэриясендә Президент Р.Миннеханов, Мәскәү мэры урынбасары А.Горбенко, Татарстан мәгариф һәм фән министры А.Гыйльметдинов, сәнәгать һәм сәүдә министры Р.Зарипов һ.б. катнашында узган «түгәрәк өстәл» ике арада сәүдә-икътисади һәм фәнни-техник хезмәттәшлекне үстерү мәсьәләләренә багышланды. Анда республикабызның һәм Мәскәү шәһәренең эре предприятиеләре җитәкчеләре чыгыш ясады. Очрашу ахырында Мәскәү дәүләт университеты ректоры В.Садовничий һәм Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры И.Гафуров бу ике югары уку йорты арасындагы хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куйды.

Мәскәүдә Татарстан Республикасы көннәре уңаеннан берьюлы берничә күргәзмә дә эшләп торды. Шуларның берсе—Музейлар берләшмәсе бинасында оештырылган Татарстан Милли музее күргәзмәсе. Бирелә XIX-XX гасырларда Казан татарларының тормыш-көнкүрешендә киң кулланылган кием-салым, бизәкләп эшләнгән өстәл, урын-җир япмалары, сөлге, чаршаулар, намазлыклар, калфак, түбәтәйләр, Казан читекләре һ.б. белән бергә хәзерге заман һөнәр осталары—«Туран» фонды унганнары, күн мозаикасы осталары С.Кузьминых, И.Гайнетдинов, Н.Кумысникова, зәркән сәнгате остасы Л.Рыговская, керәч сәнгате остасы Б.Шубин һ.б.ның әсәрләрен күрергә мөмкин иде.

Мәскәүнең халыкара музыка йорты бинасында Г.Тукайның 125 еллыгы уңаеннан нәшер ителгән китаплар күргәзмәсе, «Сынлы сәнгатьтә Тукай» экспозициясе, Татарстан турында фотокүргәзмә, китаплар һәм халык һөнәрчелеге әйберләрен сату оештырылган иде. Халыкара музыка йорты 2002 елда төзелгән. Гомуми мәйданы—42 мең квадрат метр. Анда 556 һәм 524 тамашачыга исәпләнгән камера һәм театр заллары бар. 1700 урынлы Светланов залы—арада иң зурысы. 24 ноябрьдә биредә Татарстан

сәнгать осталарының зур концерты булып узды. Тамашачыларны Мәскәү шәһәре мэры С.Собянин һәм республикабыз Президенты Р.Миннеханов сәламләде.

—Мәскәү Татарстанда житештерелгән товарларның барысын да диярлек куллана,—диде үз чыгышында С.Собянин.— Быел гына да без 1000 берәмлек машина төзү техникасы, зур күләмдә нефтехимия продукциясе сатып алдык. Моннан тыш, бүгенге көндә Мәскәү хакимиятендә Татарстанның идарә итү тәжрибәсе киң кулланыла. Төрле исәпләүләр күрсәткәнчә, хәзер Мәскәүдә 500 меннән артык татар гомер кичерә. Алар төрле өлкәләрдә унышлы хезмәт итә.

—Чыннан да, Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре арасында хезмәттәшлек көннән-көн ныгый бара,—диде Р.Миңнеханов үз чыгышында.—Былтыр ике төбәк арасында товар алмашу 40 миллиард сум тәшкил иткән иде, агымдагы елның 10 ае эчендә бу күрсәткеч 45 миллиардка житте.

Зур концертны татар халкының Гимнына әйләнгән «Туган тел» жыры белән Татарстанның халык артистлары Ренат Ибраһимов һәм Алсу Сафина башлап жибәрде. Кичәдә шулай ук Татарстан дәүләт симфоник оркестры, Татар дәүләт жыр һәм бию ансамбле, Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбле, дәүләт камера хоры, Казан хореография училищесы коллективы, «Созвездие-Йолдызлык» фестивалендә жиңү яулаган «Восторг» триосы, «Дорога из города» бию театры, күренекле опера жырчылары Ә.Агади, А.Шаһиморатова, М.Казаков, татар халык жырларын моңлы итеп башкаручы жырчыбыз Ф.Каһиров һ.б. чыгыш ясады. Концерттан соң бөтен тамашачыларны Президент Р.Миннеханов исеменнән Мәскәүдә Татарстан Республикасы көннәре үткәрелү уңаеннан оештырылган чәй мәжлесенә чакырдылар.

Мәскәүдә Татарстан көннәрен уздыруда Язучылар да актив катнашты. Алар арасында Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, шагыйрь Р.Вәлиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь И.Ибраһимов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Р.Фәйзуллин, шагыйрь, тарихчы, публицист Р.Бохараев, язучы, тәржемәче Г.Хәсәнова да катнашты. Алар Мәскәүнең төрле китапханәләрендә әдәбият сөючеләр белән очрашты, китапханәләргә Татарстан китап нәшриятында чыккан китапларны бүләк итте. Ә Л.Рюмина житәкчелегендәге Мәскәү фольклор-мәдәният үзәгендә Татар дәүләт жыр һәм бию ансамбле концерты булды. Театр сөючеләр Россия дәүләт академия Кече театры сәхнәсендә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының «Зәңгәр шәл» һәм В.Качалов исемендәге Казан рус Зур драма академия театрының «Дядюшкин сон» спектакльләрен карады.

**ЭШ СӘФӘРЛӘРЕ**

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов Польша Республикасына сәфәр кылды.

Ул анда Австрия башкаласы Венадан килде. Башта Рөстәм Миннеханов Гданьск шәһәрендә Польша татарларына куелган һәйкәлгә чәчәкләр салды. Биредә ул татарларның Леон Крычиньский исемендәге милли-мәдәни үзәгендә дә булды. Польшага визиты кысаларында Татарстан Президенты Гданьскиның фәнни-техник паркын карады, Маршал Мечислав Струк белән очрашты.

***

Рөстәм Миннеханов ике көнлек эш визиты белән Иран Ислам Республикасында булды.

ТР башлыгы визит кысаларында Иран житәкчеләре белән очрашты һәм берничә объектта булды. Рөстәм Миннеханов Ассалуйе шәһәрендә «Парс» энергетика технопаркы эше белән танышты. Тәһранда Инновацияләр һәм технологик хезмәттәшлек үзәге эшчәнлеге белән танышты. Көнчыгыш Әзәрбайжан провинциясе губернаторы һәм Ислам Республикасы тышкы эшләр министры белән очрашты. Рөстәм Миннеханов визит ахырында Иран Ислам Республикасы Президенты Мәхмүт Әхмәдинежад белән очрашты.

**КОТЛЫЙБЫЗ!**

«Гасырлар авазы—Эхо веков» журналы редколлегиясе әгъзалары Д.Р.Шәрәфетдинов (баш мөхәррир), Р.К.Вәлиев, Д.И.Ибраһимов, В.И.Пискарев, Г.Э.Рафыйкова, Б.Ф.Солтанбәков, И.И.Гәрәева да лаеклы рәвештә Дәүләт бүләгенә ия булдылар. Журнал 16 ел дәвамында чыгып килә, әлеге чорда аның 63 саны дөнья күргән, гомуми күләме 621,5 басма битне тәшкил итә. Моның белән беррәттән, журналга кушымта рәвешендә редакция тарафыннан 36 китап (668,5 басма бит) әзерләп бастырылган. Журнал республикада гына түгел, Россиядә дә дәрәжәле фәнни басмаларның берсе булып тора. «Гасырлар авазы—Эхо веков» журналы һәм аның кушымталары республикада тарих фәне үсеше, документларны өйрәнү һәм архив эше үсеше өчен дә зур әһәмияткә ия. Басыла торган материалларның төп өлешен архив документлары нигезендә тарихи тикшеренүләр, шулай ук фәнни комментарийлар әзерләнгән документлар алып тора. Журналда РФ регионнарыннан фәнни оешма хезмәткәрләренең, чит ил галимнәренең дә хезмәтләре дә-

нья күрә. Эшләү дәверендә журнал үзен профессиональ басма итеп танытты, аның публикацияләре академизм һәм күпкырлылыгы белән аерылып тора. Чыганакларны квалификацияле шәрехләү, милли тарихи хәтергә карата сакчыл караш, милләт тарихын дөньякүләм тарихи контекстта, Россия һәм Татарстан халыклары бердәмлегендә карау—болар журналны чыгаручыларның төп эш принциплары. Фәнни әйләнешкә яңа, элегрәк билгесез булган документлар кертеп жибәреп, журнал яңа историографик мәйдан әзерли, киләчәк фәнни тикшеренүләргә этәргеч бирә.

### ГИМН СҮЗЛЕ БУЛМАГАЕ

Дәүләт Советының Президиум утырышында ТР Дәүләт гимнына иң яхшы сүзләр проекты буенча иҗат бәйгесен үткәрү турында нигезләмә кабул ителде һәм конкурс комиссиясе составы расланды. Бәйге 2012 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр ике этапта үткәреләчәк. Тәкъдимтекстлар киләсе елның июленә кадәр кабул ителә (420060, Казан ш., Ирек м., 1 й., Татарстан Республикасы Дәүләт Советы. «Татарстан Республикасы дәүләт гимны»).

### ИСХАКЫЙ АРХИВЫ КАЙТТЫ

Татарстан мәдәният министры Айрат Сибагатуллин житәкчелегендәге республика делегациясе Төркиядә булып кайтты. Алар анда Габдулла Тукайга багышлап үткәрелгән фәнни-гамәли конференциядә катнашты. Әлеге халыкара форум вакытында Төркиядәге Гаяз Исхакый фонды Татарстан делегациясенә язучының компактлы дискларга күчерелгән архивын бүләк итте. 15 дисктан торган бу архив 6036 биттән тора. Күптән түгел Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма һәм музыкаль мирас үзәге бинасында Шәрекъ кулъязмалары: өйрәнелүнең хәзерге торышы һәм алдагы бурычлар» дигән темага «түгәрәк өстәл» уздырылды. Шушы җыен вакытында Мәдәният министрлыгының бүлек мөдире Дамир Натфуллин Г.Исхакыйның дискларга күчерелгән архивын ТӘҺСИ директоры Ким Миңнуллинга тапшырды. «Безнең институт Төркиядәге Гаяз Исхакый фонды белән күптән хезмәттәшлек итә. Әлеге олы бүләк төрки халыклар тарихын, шул исәптән Көнчыгышны өйрәнүгә әһәмиятле өлеш кертер, һәм бу архивка ия булу безгә өстәмә бурычлар да йөкли. Институтның Зөфәр Рәмиев житәкчелегендәге текстология бүлеге Г.Исхакыйның 15 томлыгын әзерләүне тәмамлап килә. Билгеле, язучының кинкырлы иҗаты 15 томлык белән генә чикләнә алмый. Бу материалларны җәмәгатьчелеккә кайтару—безнең бурычыбыз»,—диде К.Миннуллин.

### ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышында соңгы айда башкарылган эшкә хисап ясалды, республика язучыларының XVII корылтаена әзерләнү хакында сөйләшү булды.

Утырышта Башкортстанда яшәп иҗат итүче шагыйрь Салават Рәхмәтулла, әдәби тәнкыйтьче, прозаик Маргарита Небольсина, әдәбият галимәсе Әлфия Галимуллина, шагыйрә Рушания Арсланова Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде.

Утырышны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов алып барды.

### АПАНАЙ МӘЧЕТЕ ЯҢАРДЫ

Ниһаять, уналты ел төзекләндергәннән соң, Казандагы тарихи йортларның берсе булган Апанай мәчете, ишекләрен ачып, жомга намазына җыелган халыкны каршы алды.

Дин-кардәшләребезнең шушы олы шатлыгын уртаклашырга Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та килгән иде. Илбашы үзенең чыгышын Аллаһ исемен искә алудан башлады һем шушы зур вакыйганы якынайтуга үзләреннән өлеш керткән кешеләргә, дин әһелләренә, хезмәт коллективларына рәхмәтен белдерде. Апанай мәчетенең гомере дәвамлы булуын, биредә гыйбадәт кылучыларның беркайчан да өзелмәвен, рухани тормышның кайнап торуын теләде. Мәчетнең имам-хатибы Вәлиулла хәзрәт Якуповка мәхәллә эшендә уңышлар теләде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Кышкы урман.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы, тәржемәче **Гәүһәрия Хәсәнова (Мәһдиева)**.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Республикабыз җәмәгатьчелеге зур югалтуга дучар булды. Күренекле прозаик һәм драматург, Татарстан Республикасының халык шагыйре, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе һәм М.Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты **Фәнис Гатаулла улы Яруллин** 9 декабрьдә 74нче яшендә вафат булды.

Ф.Яруллин 1938 елның 9 февралендә Баулы районының Кызылъяр авылында дөньяга килә. 1954 елда сигезьеллык мәктәпне тәмамлаганнан соң «Татнефть» берләшмәсенең Баулы бүлегендә монтер булып эшли. 1957 елда Совет Армиясе сафларына чакырыла.

Фәнис Яруллин, нык имгәнгәннән соң каты авыруга бирешмичә, тормышта үз урынын табуга ирешә. 1970 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлады. 1964 елда аның тәүге иҗат җимеше—«Мин тормышка гашыйк» шигырьләр җыентыгы, 1971 елда «Җилкәннәр җилдә сынала» повесте дөнья күрде, шуннан соң «Аерылмас дустым» шигырьләр җыентыгы, «Сулыш», «Әсәрләр җыентыгы» басылып чыкты. Аның шигърияте—заманыбыз сулышы һәм тормышны сөю пафосы белән сугарылган, авторның лирик хакыйкате.

Соңгы елларда аның «Тозлы тамчы», «Җан авазы» һ.б. шигырьләр җыентыклары, «Язмышлар язылганда» повесте, «Зәңгәр күлдә ай коена» кебек әкиятләр җыентыклары дөнья күрде.

Ф.Яруллин милли мәдәниятебезгә бәяләп бетергесез өлеш кертте. Аның биографиясе һәм иҗаты татар әдәбияты өчен батырлык, фидакарьлек, рухи көч һәм туган якны чиксез сөю гәүдәләнешенә әйләнде.

Милли мәдәниятне үстерүгә керткән өлеше өчен ул «Халыклар дуслыгы» ордены белән бүләкләнде.

Максатка омтылышлы, намуслы, зыялы кеше арабыздан китте. Аның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

**Р.Н.Миңнеханов, М.Ш.Шәймиев, Ф.Х.Мөхәммәтшин, И.Ш.Халиков, Ю.З.Камалтынов, А.М.Сибагатуллин, И.Р.Метшин, И.М.Ибраһимов.**



Гәүһәрия Хәсәнова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)